# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Лилия ФӘТТАХОВА. Шагыйрь – бары юлчы... *Шигырьләр.* ....3

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА. Гөлханым турында хикәят. *Повесть.* ....8

Нәҗибә САФИНА. Гомер буе көткән ул якты таң... *Шигырьләр.* ....83

Фирдүс ГЫЙМАЛТДИНОВ. Шом. *Повесть.* ....88

Нәфисә САБИРҖАНОВА. Җылы сүзең җанны кочакласын... *Шигырьләр.* ....130

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Вахит ИМАМОВ. Мәңгелек мөһаҗир. *Тарихи драма.* ....134

ЯҢА ИСЕМНӘР

Гөлинә ШӘЙХИ. Һава кебек шундый кирәк чагың... *Шигырьләр.* ....157

Миләүшә ХӘСӘНОВА. *Хикәяләр.* ....160

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ – ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Михаил ХОНИНОВ. Җәй җитте исә... *Шигырьләр. (Әлфия СИТДЫЙКОВА тәрҗемәсе).* 163

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Кая барасың, татар әдәбияты?
*(Әдәби әсәрләр бәйгесеннән соң уйланулар – 2).* ....165

*Фотоархив:* «Ялкын» журналына – 100 ел. ....172

*Кайтаваз:* Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛОВ. Авылыма кайтып килдем әле. ....174

Гөлзәлифә ӘХМӘТГАЛИЕВА. Көтеп алган журналыбыз. ....176

Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА. Бердәй горурланып һәм сөенеп... ....176

*Китап күзәтү:* Ихтыяр КЫЯМОВ. Хакимлек – Ходайның бүләге дә, аның ләгънәте дә.
*(Фирдүс Гыймалтдиновның «Урда ханы Үзбәк» (2023) китабына күзәтү).* ....178

*2024 ел – Шәхесләр елы:* Милләтне авыл саклап калачак.
*(Фәнир ГАЛИМОВ белән Алинә ХӘБИБУЛЛИНА әңгәмәсе).* ....181

*Хатлар яздым утырып:* Мәхмүт Хәсәнов, укытучы Рафика апа, Нурихан Фәттах, Әсрар Галиев, Илшат Шакирҗанов, Нур Сафиуллин, Минтимер Шәймиевнең Марсель Галиевка язган хатлары. ....183

Әдәби сканворд. *Рәис ГАБДУЛЛА төзеде.* ....187

*Газиз тавышлар:* Затлы каләмнән затлы эз кала *(Әмирхан Еникинең тууына – 115 ел).* ....188

Кыска гомер, озын юллар үткән әдип *(Әнвәр Давыдовның тууына – 105 ел).*
*Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 3 (1217) 2024*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

✉✉: Редакция адресы: *420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.02.2024, график буенча 29.02.2024, басылып чыгу вакыты 04.03.2024
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-0365. Тираж 3300.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.
12+
© «Казан утлары», 2024 ел



Лилия
Фәттахова

# ШАГЫЙРЬ – БАРЫ ЮЛЧЫ...

***

Бер оеткы салдым күңелемә,
Әй, ачысын әле бер чымырдап.
Шигъри икмәк булып күпереп пешсен
Һәм таралсын кулдан кулга соңра...

Авыз итсәң, син дә сөенерсең –
Күңелең кабат таныш тәмнәр җыяр...
Алып кайтыр сабый чакларыңа,
Иң тансык тәм бит ул – хәтер сые.

Алып кайтыр туган якларыңа.
Чикмән кигән булыр бәрәңгеләр...
Чикләмичә хыял аргамагын,
Уйнар гармун, җырлар өянкеләр...

Сөйгән ярың капка төбең саклар,
Тәрәздәге утка әфсен укып.
«Әй, яшь чаклар, – диеп көрсенерсең, –
Бигрәк татлы иде таңгы йокы...»

Озак торса, ачып китәр камыр...
Шигъри икмәк булыр ачы тәмдә.
Ямь өстенә ямьнәр өстәлсә дә,
Качып булмас дөньялыкта гамьнән.

Елмаюың юып алыр йөздән
Хафаланган илнең күз яшьләре.
Вөҗдан бизмәненә яшең тамар...
Кирәк чакта – кыен – сүз дәшмәве...

---

Лилия ФӘТТАХОВА (1972) – *шагыйрә, прозаик; С.Сөләйманова (кызыксындыру), Ш.Галиев исемендәге әдәби премияләр лауреаты; «Танырсыңмы?..», «Карурман миләүшәсе», «Ишет мине!» исемле китаплар авторы. Яңа Чишмәдә яши.*

...Бер оеткы салдым күңелемә.
Әй, кабартсын әле бар уйларны.
Йөрәк кенә түзсен. Сынатмасын.
Якынайтмый торсын соң туйларны...

***

Ә шигырьләр – шагыйрь күңеленең
Харитасы алар.
Кайсы юлдан чыккан? Кая бара?
Кайда сазлык, таулар?
Гомеренең кайсы акланында
Нинди утта янган?
Кай тарафта сөю багы тапкан?
Кай сөюдән танган?
Кемне аклап, кемне каһәрләгән? –
Кем хатадан хали?!
Бер карасаң, гап-гади зат кебек,
Бер карасаң – гали!
Юк, шигырьләр – вакыт харитасы,
Шагыйрь – бары юлчы...
Ул заманда син дә яшисеңдер,
Мәрхәмәтле булчы...

***

Хәзер инде еллар кадерлерәк –
Үткәне дә, алда көткәне дә.
Унсигезең булып озаткан да,
Онык булып тәпи киткәне дә.

Хәзер инде еллар үзгә тәмле –
Рәхмәтлесең насыйп һәрбер сыйга.
Аңа синең киләчәгең белән
Кичәгеңнең мизгелләре сыйган.

Хәзер инде еллар салмаграк –
Ашыгалар ашыкмаган сыман.
Хәзер инде кыйбла якка таба
Йөзебезне бора бакый иман.

Еллар хәзер сәгать белән түгел,
Савап гамәл белән үлчәнгән күк.
Акъәбиләр, Акбабайлар артсын –
Аклык кына артып торсын берүк.

***

Һәр адымда хәят җәйрәп ята,
Һәрбер тында аның сулышы.
Без күп вакыт күрмибез дә аның
Торган чагын җанга елышып...

Ә ул сине һәр иртәдә көтә –
Мәтрүшкәле чәй йә каһвә булып,
Тәрәз төбендәге гөлләр булып –
Йә елмаеп сиңа, яки сулып.

Ә ул көтә балаң телендәге
Йомры җомак сыман серләр аша,
Тып-тын сөю булып урала ул,
Йә йөрәктән ургып-ургып таша.

Ә ул көтә шәһәр урамына
Кереп тулган шашкын агым булып.
Эшеңдәге мең мәшәкать булып,
Сине гамьсез уйларыңнан йолып.

Ә ул сине тын кичеңдә көтә
Айлы күге, йолдызлары белән.
Шыбыр-шыбыр яуган яңгырлары,
Аяк астындагы кары белән.

Син күрсәң дә, күрми йөр(е)сәң дә,
Көтә Хәят синең яшәвеңне.
Ул мизгелләр булып шакый сиңа,
Ул башкача сиңа дәшә белми.

Ул җаныңа синең тулыр иде –
Җаның балкыр иде мең төс белән.
Хәят хакын хаклаганда гына
Үкенечле булмас кебек үлем.

...Һәр адымда хәят җәйрәп ята,
Саф сулышы – һәрбер тының саен.
Тере чакта яшә генә бары,
Яшәмичә үлгәннәргә кыен.

## «Ерагайды таулар...»

«Ерагайды таулар...»,
Авыр гына сулап,
Шулай диде бүген
Туксан яшьлек әби.
«Яшьрәк чагым булса,
Көнгә ничә урап
Төшәр идем икән?..
Җиләк пешә мәмрәп...
Мәтрүшкәләр үсә...
Түзәр идеммени?! –
Таулар ерак хәзер...»

Мин дә карыйм тауга.
Төшәрмен күк әле
Әллә ничә урап –
Таулар якын гына.
Мәтрүшкәләр, җиләк...
Гөмбә җыяр вакыт...
Ничек түзмәк кирәк –
Кул сузымы ара!
...Сискәнепләр киттем:
Якын араларны
ерагайта барып,
миңа насыйп еллар
Тауга менеп бара...

***

Йөрәк типкән чакта йөреп була
Бу дөньяның төрле юлларыннан.
Исән чакта сөенергә кирәк
Синең өчен Җирдә юл барына...
Исән чакта сөелергә кирәк
Сөйгәнеңнән. Илдән. Җирдән. Күктән.
Күзләремдә бүген кояш җәйли.
Кояш бүген җан-бәгырьгә үтә...
Үзәгемә үтеп өзгәләми,
Үзәгемнән ул үземә илтә...
Ул да миңа илткән ул юлларны
Эзләгәндер күптән...

***

Уйлап барам: безнең илнең
Кешеләре чыдамракмы, юлларымы?
Юллар – юлсыз, адәмнәре уйсыз һаман.
Юллар – безгә, без юлларга шундый таман.
Уйларыбыз дөрес юлны эзләп тапса,
Юллары да рәтләнер күк берәр заман.

***

Җирнең дә җырлаган чагы бар,
Җирнең дә елаган чагы бар.
Җир дә бит кешеләр шикелле –
Күз салсаң, нәкъ шул ук чалымнар...

Җирнең дә язлары тәпили
Нарасый бөредәй куанып.
Тып-тыныч таңнары уяна,
Сандугач җырына юанып.

Күк ярып кошлары ашкына
Очарга өйрәнгән ягына –
Кыйгаклый-кыйгаклый моң кайта,
Камышлы күлләре сагына.

Җирнең дә җәйләре өлгерә
Җиләктәй сылу кыз шикелле.
Болыннар чәчкәгә күмелә –
Сөйкемле була Җир! Сипкелле!

Ургыла терек сут югары –
Тамырдан – яфраклар очына.
Җир-рәссам бизәкләр төшерә
Галәмнең кытыршы учына.

Күзе дә, кышы да мул Җирнең.
Яңгырга... Карына... Табын мул!
Юмарт Җир «мә» диеп кул суза,
«Бир!» диеп торучы адәм ул.

Аш белән атканга таш ату
Гадәтен үз иткән нилектән?!
Тарлыктан? Барлыктан? Зурлыктан?
Эрелек – Кирелек – Кимлектән?

Елаган чагы күп Җиркәйнең...
Ут яна хәсрәтле йөрәге.
Ут ягып йөр(е)гән кешеләр –
Терекнең кот-сөмсез өрәге...

Җир дә бит кешеләр шикелле...
Бик авыр тын ала, сизәмсең? –
Әлвидаг көйләре колакта,
Көйләми ничекләр түзәсе?

***

Юл язган илләрдә юл язган уйларның
Җан сорап ярсыган мәлләре.
Җанкыйгыч уйларда бар тәмуг кызуы...
Һай, авыр дөньяның хәлләре...

Көннән-көн шомлырак хәбәрләр ирешә.
Уңнан да, сулдан да. Бар яктан!
Кайлардан көч алып, уйларың сипләргә
Һәм басып калырга аякта?

Күптәннән килештем: хаклык ул бер түгел,
Мең икән – мең кеше күзендә.
Казыйлар күбәйгәч, буталды уй, юллар...
Онытылды Аллаһның сүзе дә.

Хак уйга, хак сүзгә юл сабар көннәрне
Күрәсе иде ул... соңламый.
Мизанда һәр мизгел – тере җан санынча.
Хаклыкны башка сан зурламый!

Зурламый...

***

Кайбер чаңны авыл гына ишетә,
Кайбер чаңны яугир генә ишетә.
Кайбер чаңны зур давыллар иш итә.
Давыл тынмый кемнәр кемне ишетә?..

***

Яшәрмен мин әле һаман гүя,
Уяу килеш йоклап һәм уянып.
Нидер булганына көрсенгәләп,
Нидер булмаганга мең куанып...

***

«Татарлар елмаеп үлделәр...» –
Никадәр көч бар бу сүзләрдә!
Күзләрдә – җәлладның балтасы,
Мыскыллы елмаю – йөзләрдә!

Татарның лаеклы уллары!
Алармы яшәүне сөймәгән –
Тоткынлык томанын аралап,
Алар үз көйләрен көйләгән!

Алар үз илләрен саклаган,
Алар үз өйләрен яклаган...
Барыбер табылган ул Хаклык –
Ак йөзгә кара тап ятмаган.

Хакыйкать бүген дә чаң суга:
Рух зәгыйфь, ләкин бит ул исән!
Тик һаман да әле җәлладлар
Тел кисә, тел өчен баш кисә.

Августның иң соңгы көннәре...
Көзгә бер адымлык ара бар.
Тез чүкмәс Хакыйкать йөзендә
Кан саркып торган бер яра бар...

***

Язны көтә иде күңел. Язны...
Ни дисәң дә, кыш ул – салкын аклык.
Җанны өшетерлек хәлләр Җирдә –
Яз каршында бу языкны ничек аклыйк?
Сыерчыклар әнә кайтып җиткән.
Сары томшык – кошчыклары туар тиздән...
...Ә кайдадыр туган бала үлеп ята,
Кәфен төсе иңә бара алсу йөзгә.
...Ә кайдадыр йортлар җимерелә –
Аш пешереп көтмәс хатын – ирен.
Хатыньмы бу?! Әллә Катыньмы бу?
Ничек аңлатырсың моны, илем?
Элеккечә түгел бу яз. Түгел...
Элеккечә түгел һавалары.
Күкрәк тутырып сулыш алыйм дисәң,
Кереп тула сугыш хафалары.
Тынны буа ялган хакыйкатьләр...
Күкрәк кага ярыммәхбүс ыру...
Умырзая түзми – сыгылып төшкән:
Мылтык көпшәсендә – үлем җыры...

Язны көтә иде күңел. Язны...
Хәятнең ул иң-иң садә чагы.
Хәят үзе хәйран калган көннәр –
Кешеләрдән ни көтәргә тагы?

***

Тоз дип шикәр каптыралар, шикәр дип – тоз.
Икесе дә ак, дибез дә ялгышабыз.
Тозны баллы дидертәләр, әйтми кара!
Йөзне чытып, ялган йотып тормыш бара.
Кемдер авыр, кемдер җиңел яраклаша.
Җаны белән сату итә, караклаша.
Җә дип тора, мә дип тора – сарыклаша.
Бу хәлләрне күреп торып гарык ласа...
Күңел күзен буалар да, ак – хак була.
...Тик шикәрне тоз диюче ахмак була!
...Шикәр капкач, шикәр диик, тоз – тоз булсын.
Тормыш һәрчак үз түменчә узып торсын.

*«Оясында ни күрсә...» әдәби конкурсы*



Нәбирә Гыйматдинова

# ГӨЛХАНЫМ ТУРЫНДА ХИКӘЯТ

ПОВЕСТЬ

*– ...Исеңдәме?*

*Кай тарафлардан ишетелә соң бу тавыш?*

*Борыла да карый, борыла да карый...*

*Челтер-челтер аккан чишмәгә карап сихерләнгән нәни кызчык телгә киләме?*

*Әллә немец әсире койма ярыгыннан сузган салам курчак җанланамы?*

*Студентлар тулай торагы бүлмәсенең ишегеннән бөдрә чәчле башын тыгып: «Тор әле, шигырь укыйм», – дип, ярты төн уртасында уяткан Зөлфәт кыбырсыймы?*

*Бәлки җаны моңнан гына тукылган Мөдәррис юксынып эндәшәдер?*

*Тотык итеп Мәскәүләргә озатылган Ханбикәнең җаны җиде кат күкләр аша иңриме? («Азат хатын» журналын «Сөембикә»гә үзгәртергә йөргәндә, баш мөхәррирнең нинди утларда тетелеп янганы рухларга да мәгълүмдер, шәт.)*

*Бу ниятеңнән ваз кич дип үгетләүләр, куркыту-өркетүләргә карамастан, Бөтендөнья «Ак калфак» татар хатын-кызлары берләшмәсе оештырып, шуның беренче утырышына Җир шарының төрле кыйтгаларыннан чакырган татар ханым-туташлары гөрләшәме?*

*Татарстан Дәүләт Советы депутаты чагында: «Ятим балалар өлешенә кермәгез!» – дип, мөнбәрдән ачынып сөйләгәннәренең кайтавазымы?*

*Унике ел ярлыкау комиссиясендәге җәмәгать эшенә күмелгәндә, аны нинди генә язмышлар белән очраштырмады Ходай! Төрмәләрдән*

---

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА (1956) – *Татарстанның халык язучысы; «Мәхәббәттә гөнаһ бар», «Икебезгә дә авыр», «Үзем генә беләм» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

*коткарасын – коткарды, булышасына булышты ул. Шуларның берсе, өчесе, бишесе, унысы... дәшәме аңа?*

*Рәсәй Иҗтимагый палатасына ике еллык срокка сайлангач, татарның гасырлар буе төзәлмәгән ярасына тоз сипкән адәмнәр белән сүз көрәштерүләр, ул бәндәләрнең хаксыз икәнен исбатлаулар, безнең милләтнең бөеклеген-зурлыгын күрсәтеп ясалган чыгышлар кабат хәтердә яңарамы?*

*Исеңдә, һәммәсе дә исеңдә...*

*Берни дә онытылмаган-җуелмаган, чөнки алар каурый каләм белән йөрәккә үк язылган. Кызык һәм кызганыч хәлләр, эреле-ваклы вакыйгалар, төрле даирә кешеләре белән аралашулар, хезмәтен бәяләгән Бакый Урманче, Гомәр Бәширов, Туфан Миңнуллин, Индус Таһиров, Миркасыйм Госманов, Фәндәс Сафиуллин, фикердәшләре Флора Әхмәтова-Урманче, Камәрия Хәмидуллина, Филисә Хәкимова, Тәэминә Биктимерова кебек гали затлар, иҗатташлар, дуслар һәм шулар янәшәсендә үк уңышларын күпсенгән хөсетләр (көнләшү – татарның иң яман чире!), яхшысы да, яманы да аның түкми-чәчми саклыйсы байлыгы.*

*«Ул дан-шөһрәткә җиңел генә ирешә», дип уйлаучылар ялгыша, нык ялгыша. Үзенең хәлен аңлатыр өчен аңа «эчем – ялкын, тышым – салкын» дигән җыр сүзләре дә җитәр кебек.*

*Кыскасы, бу әсәр без белмәгән Роза турында.*

## 1. «Сәерлегең бар инде синең...»

Гаҗәеп төбәк инде ул Аксубай иле! Аның һәр авылында бүгенге көнгә кадәр колаклар үрә торырлык риваятьләр яши. Берничә ел элек Кыязлының иген басуында нефтьчеләр торба үткәрер өчен бульдозер белән тирән чокыр казыганда, борынгы зур каберлеккә тап була. Шакката халык: мәетләрнең (сөякләрнең диик!) буе ике метр чамасы. Хәтта үлчәп карыйлар, чын, биредә пәһлеваннар күмелгән. Кемнәр болар? Һәрхәлдә космостан иңдерелгән затлар түгел, шушы якныкы. Бәлки Аксак Тимер Биләр каласына һөҗүм иткәч (Биләр якын гына), гаярь ирләр дәррәү аны якларга кузгалгандыр, һәм тигезсез көрәштә һәлак булгандыр? Минуты-сәгате белән яптырдылар бу каберлекләрне, мәгълүм ки, кайбер риваятьләрнең авызы тиз томалана. Ә менә Яңа Үзи авылында Мәрҗән амазонкалары турындагы риваять буыннан-буынга күчә. Болгар белән Биләрне җимергән дошман гаскәре Мәрҗән ханлыгын (Бүгенге Яңа Үзи тирәсе) туздырганда кырылган ирләр урынына Тырышмал хуҗаның унике кызы, кулына ук-җәяләр тотып, кирмәнне якларга ташлана, әмма Аксак Тимер аларны камап, әсирлеккә ала һәм көн-төн туфрак ташыттырып, биек тау өйдерткәч, этиләре белән тереләй күмәргә җыенганда, кызлар аккошларга әверелеп, күккә атыла. Халык хәтеренең иң төпкелендә сакланган (хәтта ки әкиятләргә тартса да!) әйберләргә тияргә ярамый! Ә Яңа Үзидә әлеге риваятьләрдән дә көчлерәк вакыйгалар шактый. Инкыйлабтан соң совет власте дин тамырына балта чабып, мәчетләрнең манарасын кисеп, йә складларга, йә мәктәп-клубларга әйләндергәндә, Үзилеләр 1901 елда төзелгән иман йортын сәнәк-көрәк белән коралланып иштермәгән. Бунт күтәргән өчен төрмәдә черетерләр дип

курыкмаган ирләр, заманында мондый нәрсәләр өчен баштан сыйпамаган власть.

Бәлки сулаган һавасы, җир-сулары белән Тырышмал хуҗадан күчеп калгандыр аларга көрәш дәрте? Вәлиулла карт Үзидә хөрмәтле аксакалларның берсе саналган икән, гаҗәпмени! Саналырлыгы бар: ул авылдашларының бушка, бертиенсезгә артык ашлыгын ат арбасына төяп, Чистай өязе базарына илтеп саткан. 1921 елның карлы-бозлы язында хуҗа сигез кызы белән ике малаен түрдәге сәкегә тезеп:

– Нишлибез, оланнар? – ди. – Ачлык афәте якынлаша.

Карчыгы Мәликә:

– Авызыңнан җил алсын, атасы! Бигрәк шомлы сүзләр сөйлисең, – дигәч, карт:

– Син миңа тыгылма, үз эшеңне бел, – дип ачулана.

Им-томчы Мәликә абыстайның «үз эше» – дәвалау. Ул оста гына сынган-каймыккан кул-аяк сөяген ялгый, буыннарны утырта, дога белән өшкерә, болардан да хикмәтлерәге – берәр әйберен кыстырып, төшлек куйдыртырга аңа тирә-яклардан кешеләр килә. Яулыкмы ул, күлмәкме, карчык шуны мендәр астына салып йоклый. Ни гаҗәп, аның күргән төшләре һәрвакыт рас килә. Кемнәр, кайдан «хәбәр» ирештерәләр – серен бирәүгә дә ачмый.

Гаиләдә бердәнбер туендыручы кеше – ата, балалар алдында аның абруен төшереп, шик белдерү гөнаһ икәнен аңлаган карчык хатасын тиз төзәтә:

– Шулай дисеңмени, Вәлиулла?

– Шулай дим. Җәй корылыгы белән интектерер. Кояшта игеннәр көеп каралыр, җир ярылыр, коелар кибәр. Быел күп итеп бәрәңге чәчәрбез, оланнар. Сез – кызкайларым, көн дә күл-елгалардан су ташып, бәрәңгеләрне сугарырсыз. Кодрәтле сулыкларыбыз саекмас, иншаллаһ.

Әти сүзе – закон, кызлар иртә-кич бәрәңге төбенә кырыгышар чиләк су сибә. Чынлап та, ил-көнгә ачлык дигән аждаһаябырыла... Баксаң, Вәлиулла үзенең ишле гаиләсен (унике тамак!) генә кайгыртмаган икән. Көзге айларда ул ишегалдына такта кисәкләрен ялгап, озын-озын өстәл әтмәлли. Мәликә абыстай мич тутырып, арыш онынннан ипи сала, казанда бәрәңге пешереп кыздырган терлек мае бутап, боламык төя. Зәйнуллиннар көн дә ярдәмгә мохтаҗ ялгыз карт-корыны, ятим балаларны җыеп ашатуны гадәткә кертә. Күпләрне үлемнән коткара бу йортның игелекле хуҗалары.

Күмәк хуҗалык төзегән авылдашларына да кушыла Вәлиулла. Кара эштән чирканмаган алдынгы колхозчыны Бөтенсоюз старостасы Михаил Калинин белән очрашуга җибәрәләр хәтта. Карт үлгәнче аңа рәхмәт укый. Укырлык та: хөкүмәт җитәкчесе аңа төргәге белән тукыма бирдертә. Ул чорларда ситса – хатын-кыз хыялланган иң дефицит товар, җилкәсенә салып кайта аны Вәлиулла.

– Кемгә бу, кемгә? – Капкадан ук кызлары әтиләрен сырып ала.

– Каян ишеткән Калинин бабагыз миндә кызлар әртиле икәнен! – дип гөрелдәп, «йөге»н сәкегә куя гаилә хуҗасы. – Сезгә, сандугачларым, сезгә! Сигезегезгә дә күлмәк тектерерсез, Алла кушып. Күлмәкләрегезне купшы итмәссез, аргы очта ике ятимә кыз баланың өсте сәләмә, аларга да өлеш чыгарырбыз.

Сталин белән бер елда, бер көндә үлә аксакал. Авыл халкы аны елый-

елый озата. Терсәктән кулы канга баткан юлбашчы миллионнар каһәре белән Ленин әргәсенә – Мавзолейга урнаштырылса, иманлы Үзи картының җәсәде дога белән җир куенына иңдерелә.

Ә аңарчы...

...Ул сугыш тәмамланганнан соң, октябрь аенда туа. Элек: «Октябрьдә туганнарның Ленин була бабасы», – дип җырлаганнар, ә аңа андый революционер «туган» кирәкми, чөнки бишек тирбәтүче, үчтеки сикертүче бабасы исән әле. Бала олыларның кылган гамәлләрен лакмус кәгазе кебек үзенә сеңдереп үсә. Күрә кызчык: карт ялгыз карчыкларның коймакапкасын төзәтә, кышкы бураннарда карын көри, мич төнлекләрендәге корымны чистарта... Ходай ризалыгы өчен, ди. Савап өчен, ди. Бүләк калдыра ул оныгына: үзендәге күркәм сыйфатларны аңа күчерә. Кемнеңдер хәсрәтен бүлешкән, егылганны торгызган, мохтаҗларга булышкан, усал җилләрдән ышыклаган Роза: «Изгелек эшлә дә суга сал, халык белмәсә – балык белер», – дип яшәмәдемени! Яшәде, яши...

Зәйнуллиннарның нәсел сызыгында Вәлиулла улы Рәхмәтулла да аерым урын билидер. Булачак әти унсигез яшендә фронтка китә.

Кайтырбызмы, кайтмабызмы?
Сау булыгыз туганнар!

Ат арбаларына төялгән ир-атларны моңсу җыр озата: «Сау булыгыз...»

– Улым, сугышка кергәндә, Аллага тапшырыл. – Вәлиулла борын астына мыек та төртмәгән улының аркасыннан сыйпый. Атаның күзендә мөлдерәмә яшь. – Әзрәк ныгырга иде дә сиңа. Ашыктың, улым.

Ә бер кырыйда Рәхмәтулланың вәгъдәләшкән кызы Солтанәт сыктый. Авылда егет гомере – кыска, унҗиде-унсигездә өйләнә ул. Алар да көзгә кавышмакчы. Рәхмәтулла соңгы тапкыр сөйгәненә күз ташлый: «Көт!»

1943 елда Сталинград янында яраланып, контузия алган солдат җиде ай хәрби госпитальдә ятып, Үзигә кайтса, авылда күпме яңалык! Мәктәп директоры Хафизә апа Әмирова Чистай педагогия училищесында укыган туганының кызы Фигальне алар авылына китерткән. Яшь укытучы фронтовикны һуштан яздыра. Чибәр кыз да аңа битараф түгел, ахрысы, сөрмәле күзендә мәхәббәт яралгысы шәйләнә. Бәлки хистән дә көчлерәк акыл: «Рәхмәтулла – төпле нәсел баласы, гаилә томкасы булырлык ир», – дигәндер. Егет өйләнешү турында сүз кузгаткач ул шунда ук ризалаша. Өйдәгеләр генә пошаманда:

– Ныгытып уйла. Сине сугышка бүтән озаткан ие, улым.

Мәликә абыстай, күрәсең, өй бусагасыннан шул «бүтән» атлап керер дип өметләнгәндер, ә монда хәлләр тамырдан үзгәрә.

– Уйладым мин, әни! – Сугыш кырыслатып, ике сөйләттермәгән егетнең инде капка төбендә аты җигелгән, арбага салам түшәлгән, дугасына кыңгырау тагылган. – Күчтәнәчләрне төенчеккә төйнәп, чыгып утырыгыз, Иске Кармәткә кыз сорарга барабыз, – дигәч, нишләсен, күнә әти-әни.

Фигальнең бала тудырмас борын итәге сабыйлар белән тула: Рәхмәтулланың яшьли үлгән бер апасының өч сабыен үстерә ир белән хатын. Үзләренең беренче балалары тугач, ул вакытта авыл советы

секретаре вазифасындагы Рәхмәтулла кызын Ландыш дип терки дә, җиде айдан аны Розага үзгәртә. Каләм белән кәгазь секретарьнең үз кулында. Сыз да яз, сыз да яз! Сугыш хатирәләре күңелен нечкәрткән чакта Рәхмәтулла үзе ычкындырганмы, әллә «яхшылык теләгән» адәм сер итеп кенә Фигальнең колагына пышылдаганмы, очлы «без» беркөнне капчыкны «тишә». Госпитальдә дәваланганда, Ландыш исемле шәфкать туташы йөрәген җилкендергән икән. Сугыш кырында җаныңны суырган Газраил белән тартышканда, йомшак кулы белән сызлануларыңны бастырган фәрештәгә тап бул да хисләреңне йөгәнләп кал әле син! Акыллы хатын, көнләшеп, иренең җанын ашамый, Рәхмәтуллага болай да авыр, юклыктан-хәерчелектән өшәнгән сугыш арты авылын тергезәсе. Ә дәүләт, акыртып, халыкның җиде кат тиресен туный. Өй борынча налогка йомырка, май, йон җыеп йөрү гарьләндерә Вәлиулла улын. Ир район партия комитетына бара да:

– Йорт саен ятим, ач-ялангач бала, йорт саен ире сугышта үлгән тол хатын! Теләсәгез нишләтегез, асыгыз-кисегез, мин аларның соңгы телем ипиен тартып ала алмыйм, – ди. Аңа шунда ук «хөкем карары» укыла. «Партбилетыңны өстәлгә куй!» Ә кызыл тышлы кенәгә – теге елларда иң кодрәтле документ. Сугышта да аны ир-атлар күкрәк янында йөрткән. (Узар еллар, Розага (инде Роза ханымга) исән килеш бер тапкыр да күрмәгән икенче бер газиз кешесенең пуля тишкән партбилетын күрсәтерләр.)

– Мәгез! – Рәхмәтулла ике дә уйламыйча билетын өстәлгә ыргыта.

Соңрак гафу ителәә ир, аңа колхоз йөклиләр. Кемгә дилбегә тоттырасын чамалый райком секретаре, ат урынына үзе җигеләчәк Рәхмәтулла. Тик «һава торышы» тагын бозыла: Роза артыннан туган малаен сөннәткә биргән әти кешене берәү органнарга «чага».

– Безобразие! Коммунист башың белән дини йолалар үтисеңме? – Секретарь һавада йодрык болгый. – Искелек калдыгы! Хорафатчы! Партбюрода тезләнеп, гафу сора! Хаталандым диген.

– Ата-бабам гореф-гадәте хата түгел.

– Вон кабинеттан! Вон колхоздан!

Бу юлысы аны партиядән үк сөрәләр. Күмәк хуҗалыкның ферма-абзарларындагы тишек-тошыкларны озак ямамый анысы, аңа каныккан секретарьне кәнәфиеннән аткарып, рус кешесен билгелиләр. Ә яңа түрәгә йолаң ни дә, сөннәтең ни, колхоз артта сөйрәлә, колхозга җен кебек эшләгән Рәхмәтулла кирәк.

Рәиснең өендә дә коммуна тормышы. Аларның бусагасына кемнәр генә килеп егылмый. Мәликә әбисе – «халык духтыры»: хаста-авыру аңардан шифа-дәва өметләнә, көн дә ишле гаиләне тагын да ишәйтеп өйгә халык җыела, кеше сулышыннан тәрәзә пыяласы парлана хәтта. Роза әлегә чүп-чарны иләктән или белми, сырхау апа-әбиләрнең аһ-зарын тыңлап, күз яшьләрен күреп, йөрәгенә сыйдырып бара. Өйдәге мохит, колхоз дип чапкан тынгысыз ата, бер-бер артлы туган сеңелкәш-энекәшләр, әнисенең һәрдаим:

– Син баш бала, бәләкәчләрне карарга тиеш, – дип тукуы бәлки әкияттәге кебек «ел үсәсен ай үстергәндер?» Иртә олыгайдымы икән Розагөл?

Ләкин шушы ыгы-зыгылы тормышта берсенә дә аяк атларга җөрьәт иттермәслек хыялый дөньясын ача кызчык.

Алты яшьләр чамасындагы Розаны өйдәгеләр югалта. Оныкның көнозын күзгә-башка чалынмагач, Вәлиулла карт тавыш куптара.

Сарай-келәтләрне, чормаларны тикшерәләр, урамдагы бала-чагадан сорашалар – кызчык юк! Инде көн кичкә таба авыша. Авыл халкы да сәнәк күтәреп эзләргә чыга. Һәркемнең күңелендә шом: бүре-фәлән генә апкитмәсен... Сугыштан соң урмандагы ерткычлар отыры явызланды: еш кына абзар-кураларга һөҗүм итәләр. Шулай даң-доң чиләк төбе кагып, этләрен һау-һау өрдертеп, авылны дер селкеткәндә, Үзинең тирә-якта «белекче» даны таралган усал Шәрипҗамалы тәрәзәдән генә:

– Ерактагы сулы җирләрдән карагыз, сулы җирләрдән! – дип кычкыра. Тәрәзә шапылдап ябыла.

Монысы бүредән дә куркынычрак: «Нарасый елгада баткан булса?!»

Ә бу вакытта чакрым ераклыктагы Бикчабар күле тирәләрен әйләнеп алҗыган кызчык үләннәр арасына посып аккан чишмә кырыена чүмәшеп, җыр тыңлый. Чишмәнең тавышы әнисенеке кебек моңлы икән. Тамаша, аллы-гөлле күлмәк кигән күбәләкләр суда канат очын чылата, бал кортлары безелди, чекерт-чекерт чикерткә сайрый, ул да түгел, озын торыкларын вәкарь белән генә атлатып, ике торна якынлаша. Курыкмыйлар (гөнаһсыз сабый табигатьнең бер кисәге, сукмас-кыйнамас!), кояш җылыткан ерганактан су эчәләр.

Әнә теге югары яктагы урманнан суга сусап, кети-кети уйнарга яраткан шүрәле абзый да килмәгәе. Су анасы Бикчабар басмасында чәчен тарыйдыр. Нигә аның алтын тарагын урлаган ул малай? Роза Иске Кармәттә әнисенең әнисе – Фәсыйгөлбәяннарда еш куна. Мөгаллимә әбисе: «Кеше әйберенә тияргә ярамый», – ди әнә. Аларның өендә киштә тулы китап. Сугыштан әйләнеп кайтмаган Вәли бабасыннан калган күбесе. Тукай җыентыкларын тышыннан таный кызчык.

– Зур әни, укы, – дип, алмаш-тилмәш китереп биргәндә әбисе:

– Моны ничә кат укыдым бит инде, бәбкәм, – дисә дә, оныкныкы: «Тагын укы!»

...Көндез барып җитәсе җиренә ашыккандай кызу-кызу аккан чишмә кичкә табан салмаклана. Ул гүя бишек көе көйләп Розаны йоклата.

...Иртән өч ятимәнең төпчеге Мөкаддисә (кызчык аларны әнисенең балалары дип уйлый) битенә сулышын өреп уята.

– Сине төнә Бикчабар күле янындагы чишмәдән таптылар. Нишләгәнсеңдер анда. Сәерлегең бар инде синең.

Ачуы килгәндә тугани апасы аны гел шулай үчекләр: «Сәерлегең бар инде синең».

## 2. «Тукай безнең авылныкы»

Таулар... Ник алар аны үзенә тарта икән? Балачакта бу хакта ул ни уйласын, сабый фәлсәфә кора белми. Соклану, ярату, таң калу – әлегә шул гына. Ә яши-яши Роза аларның хикмәтен аңлар: Таулар кешенең күңел офыгын киңәйтә, биеклеккә алып менә, болытларга орынган түбәсе җаныңны күкләр белән тоташтыра икән.

Дөнья буйлап сәяхәт иткәндә, ул Һималай, Тянь-Шянь, Кунь-Лунь,

Эверест кебек шанлы тауларны күрер, әмма туган авылы таулары белән Урал таулары дөньяда иң матурлары булып хәтергә уелыр.

Беркөнне болында уйнаганда, Газизҗан исемле малай: «Тукайның

«Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным, тәнем белән», –

дигән шигыре безнең Үзи турында бит», – ди.

Бала-чагага ни, Газизҗан нәрсә генә сөйләсә дә – барыбер, ә менә бу «ачыш» Розаны шаккатыра. Чын мәгәр, дөрестер, Үзи авылы тау итәгенә җәелгән, чишмәсе дә «аяк очында» гына! Кармәт әбисеннән әллә ничә тапкыр кабатлаттырды әлеге шигырьне, ник ул: «Сезнең авыл турында», – дип әйтсен. Газизҗан инде Розага абый кеше, кыз беренче сыйныфка, ә малай өченчегә бара, аның китапханәдә укымаган китабы юк, телендә гел шагыйрьләр сүзе, үзе дә шигырь яза, ди. (Әтисе сугышта үлеп, әбисендә тәрбияләнгән ятим киләчәктә Газиз Кашапов-Үзиле тәхәллүсе белән әдәбият дөньясында танылачак дип берәрсе юрадымы икән ул чакта авылда?)

Кыз кочагыннан ташыган сөенечен кочаклап, өйләренә йөгерә:

– Әни, әни! Габдулла Тукай безнең авылда туган, ди, Маһруй әби Газизҗаны!

Һәр укучысының күңеленә ачкыч яраткан укытучы ничек «юк!» дип кырт киссен!

– Кызым, Габдулла Тукай – барыбызның да яраткан шагыйре. Әнә күрше Сөнчәле авылында да таулар биек, алар да аны безнеке дияргә мөмкин. Әтиең олы апасы Гадилә янына Свердлау якларына китмәкче. Кунакка. Анда Урал таулары хәттин биек икән. Уралдагы татарлар да, шәт, Тукайны безнеке дип саныйдыр. Газизҗанны ялганчы дип үртәмә берүк, Апушны үзенеке итәсе киләдер инде аның, икесе дә шыр ятим. Кырлай тудырган Тукай бабагызны, кызым. Хактан да, Арчада шундый авыл бар. Хәсән атлы абыең да – зур шагыйрь. И Аллам, еракта әле ул, еракта. – Әнисенең күзендә яшь бөртекләре җемелди. – Безнең туган ул Хәсән Туфан. Нахакка хөкем иткәннәр, бичаракаемны. Монысын үскәч аңларсың инде, кызым.

Аңлыйсын әллә кайчан аңлаган Роза: Кармәт әбисе аны сөргендә, сөрген – бер гаепсезгә сөрелгәннәр җире, бәбкәм, ди. Артыгын сөйләми, анысын да «үскәч»кә калдыра.

Күрәселәр алда икән! Үзи халкы гомер-гомергә кое суы эчми, җәен-кышын чәйлеккә чишмәдән ташый. Авыр күтәреп имгәнер димәгәннәр, бот буе кызларны да көянтә-чиләк астырып, «көмеш су»га йөрткәннәр. Чиләге җиргә тия-тия, ярты суы түгелә-түгелә кайта кыз бала. Бер генә мәртәбә барсаң икән әле! Әти-әни генә гаеплеме икән соң? Сугыш ярасы төзәлмәгән авыр заманалар, һәр йортта җидешәр-сигезәр (унар!) оланшак. Әләксә – иң зурысына эләгә. Алтымы сиңа, тугызмы, син – «зур кеше!» Розага да су юллары таныш. Өйалдындагы бак бушады исә, аны җәлт кенә тутырасы.

Түбән яктагылар өчен чишмәгә тар гына басмадан йөрешле. Әйтерсең

сират күпере! Шуннан таймыйча, егылмыйча туп-туры басып чык. Иңнәрендә чиләкләрен уйнатып, ике дус – Замирә белән Шәмсенур суга килә. Алар – Газизҗан яшьтәшләре. Замирә – ятимә, әнисе бүтән ир белән никахлашкач, кызын әбисе белән бабасына ташлап китә. Йөзенә ай нурының кершәне ягылган диярсең, чибәр Замирә! Ә өстендәге күлмәге! Апасы Мәрвия – оста тегүче, сеңлесен курчак кебек киендерә.

Ә басмада... басмада әтәчләр сыман ике малай кукрайган. Учларында балчык! Кашапов Газизҗан белән Волков Газизҗан – адашлар. Рус түгел лә Волков! Аның патша армиясенә хезмәткә алынган бабасы русча ярты сүз белмәгән. Стройда моңардан:

– Фамилияң ничек? – дип сорыйлар икән.

Нәрсә ул «фамилия» дигәнең? Егет аптырап баш кашый. Кушаматлары бүре инде аларның. Ул татарча:

– Бүре мин, – ди, – бүре!

Авызын күккә терәп, бүре булып улап та күрсәтә рекрут.

– Понятно, ты Волков, – ди командир. – Так и напишем в документах.

(Үтәр еллар. Газизҗан Волков Мәскәү астындагы Космик тикшеренүләр үзәгенең иң җаваплы җитәкчесе булып китәр.)

Менә адашлар сүзсез генә кызларны күпердән уздыра. Ә кире менгәндә, аларга сукмак «бикләнә».

– Тукайның берәр шигырен сөйләгез! Шунсыз уздыру юк, – ди Кашапов Газизҗан. – Ә-ә, ятламадыгызмыни? Мәгез, алайса!

Малайлар учындагы туфракны чиләкләргә томыра. Бу хәл әллә ничә мәртәбә кабатлана, кызлар елап бетә.

Тукайны яратуын әнә шулай белдерә Газизҗан.

Әлеге тамашаның шаһиты Роза сулышы кабып, өенә чаба.

– Әни, әни! Тыңлале, «Туган тел» шигырен дөрес сөйлимме мин?

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле...

Кармәт әбисе күңеленә сеңдергән шигырьнең өтеренә хәтле ятлаган ла ул. Әгәренки «басма сакчылары» каныкса – тотлыкмыйча ярып салыр... Йа, Маһруй Газизҗаны ник аңа каныксын да, ник чиләген пычратып, балчык атсын, Роза сөйкемле укытучысының кызы лабаса!

Дәрестә Тукай әсәрләрен яттан сөйләгән Фигаль апаларын йотлыгып тыңлый класс. Илленче еллар уртасында мөгаллимнең илаһи затка тиңләнгән чагы. «Акай күзле шайтан» – телевизор юк, интернет юк, нибарысы китап һәм Сүз кодрәте. Болардан да көчлерәк «тәрбия коралы» дөньясында да юк!

Газизҗанның да кызларга «бәйләнүе» усаллыктан түгел. «Бел инде син Тукайның берәр шигырен, бел!» Белә кызлар, белә. Алар горур, алар малай-шалайның әмеренә буйсынырга гына теләми.

– Зур әни миңа «Туган тел»нең соңгы куплетын да укый. Нишләп анысын сөйләмиләр соң, әни?

– Кайчандыр бер сөйләрләр, кызым.

Анасының җавабына киләчәк соңлап кына үз төзәтмәсен кертер.

Һәм Розалар, Газизҗаннар буыныннан яшерелгән дүртенче куплет йокымсыраган татарның бәгырен теләр.

И туган тел! Синдә булган
Иң элек кыйлган догам;
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
Әткәм-әнкәмне, Ходам!

### 3. Әсир немец курчагы

Тук-тук, тук-тук... Күңелле генә поезд тәгәрмәчләре тәгәри. Розаның әтисе белән Гадилә апаларына кунакка барышлары. Ул гаиләсе белән Свердлау өлкәсенең Асбест бистәсендә яши. Әтисенең кече апасы хатларында язган Урал таулары, чынлап та, Үзи тауларыннан биегрәкме икән?

Авылдан кырык чакрымдагы Норлат станцасында Сабан туендагы хәтле халык, менә барысы да этешә-төртешә, вагоннарга кереп тула. Поезд кузгалуга калын тавышлы бер хатын:

– Пассажиры, приготовьте билеты, – дип кычкыра.

Билетлар тикшерелеп, кешеләр урынына урнашкач, шарт-шорт катыргы чемоданнарның биге ачыла, төенчекләр чишелә, тамак ялгарга сәфәргә өеннән кем нәрсә алган – бәләкәй өстәлләргә тезә. Шык-шык йомырка ватыла, гылт-гылт шешәдәге сөтләр эчелә. Розаның тамагы тук, әтисе Норлат ашханәсендә майда кыздырылган кәтлит ашатты. Алар каршындагы урында чәче кыркылган абый да ипи белән ит кисәген бөкләп салгач, уч төбенә генә кикереп:

– Тукландык, – ди. – Син, туган, бала белән икән. Кай яклардан?

– Аксубайдан... Олы кызым әзрәк дөнья күрсен дип иярттем.

– Әле кечкенә, күрер балакай, – ди абый.

Ике ир бик тиз уртак тел таба. Садретдин исемле Сәләнгеш кешесе дә фронтовик! Йөрәк турысында кыйпылчык минем, Свердлауга туганым чакыра, яхшы врачларга күрсәтмәкче, ди. Каһәр төшкән сугыш, бөтен исәнлекне бетерде, Җиңү көненнән соң сигез ел узды, әле дә колак төбендә пулялар сызгыра, ди.

Сугыш... Бу – җиде яшьлек Роза өчен иң куркыныч сүз! Чөнки ул олыларның да котын очыра. Тап-таза, сау-сәламәт Рәхмәтулла шунда исәнлеген калдыра, аның контузиядән шаулаган башын тотып ыңгырашуы өйдәгеләрнең дә төн йокысын качыра. Сугыш дигәнең Кармәт әбисенең дә тынычлыгын урлаган. Аның күз яшьләре Розаның йөрәгенә боз-сөңге кебек кадала. Матчада – саргайган «кыягазь»... «Галеев Вәли хәбәрсез югалды...» Бабасының йөзенә бер тапкыр бакмаса да, сагына аны кызчык, сагына! Күрше-күләнне әйтер идең!

– Вәлидән хәбәр-фәлән юкмы? – дип, әбисенең ярасын кузгатмасалар! Унбер елдан соң нинди хәбәр, ди?!

– Мәгәр кул-аягы өзелеп, госпитальләрдә ятса – күтәрепләр кайтыр идем. Җанвалид димәс идем, түремдә утыртып тәрбияләр идем!

Кайвакыт шулай такмаклап елый әбисе...

Тук-тук, тук-тук... Юлдаш абый белән әтисе чөкердәшепме чөкердәшә!

– Рәхмәтулла туган, бүтәнчә сугыш уты кабынмасын ие дөнҗаларында. Балаларга, оныкларга бирмә Ходай ул афәтне, – ди Сәләнгеш Садретдины.

Тук-тук, тук-тук... Вагон түбәсенә сиртмәле бишек элгәннәрмени, ул тирбәлгән саен йокы баса. Әтисенең тавышы тоныкланып, әллә кайдан – ерактан ук ишетелә.

– Амин, Садретдин туган, амин.

...Хыялдагы таулар! Урал таулары! Йа, алар әкәмәт биек, очлы түбәләренә кошлар гына очып кунадыр, мөгаен. Әйдә, дисәләр, Роза да менәр иде анда. Таулар, талантлы рәссам – табигать кылкаләмен аклы-каралы буяуга манып ясаган гүзәл сурәт рәвешендә хәтердә озак сакланыр. Ә инде елларны алга таба күчерсә...

...Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева җир күкрәген ярып чыккан тауларны юксынуын җыр аша белдергән.

Менәргә иде Урал тауларына,
Басарга иде кыя ташына.
Шул кыядан кушылып җырларга иде,
Урал бөркетләре тавышына.

Мәйданда Тукай бәйрәме... Язучыларны таный В.И.Ульянов-Ленин исемендәге университет студенты Роза Зәйнуллина. Әнә, Гөлшат апа! Ничек кенә аңа сүз кушарга икән? Оялса да, аның янына килә кыз. Ул:

– Исәнмесез, Гөлшат апа?! Мин сезнең Урал тауларына багышланган җырыгызны яратам, – дигәч, шагыйрәнең болай да көләч йөзе тагын да яктыра.

– Рәхмәт яусын, сеңлем! Аның өчен тәнкыйтьләп үтерделәр инде мине, җырмыни ул, диләр. Таулар кодрәтен сирәк кеше аңлый. Менә сез – яшьләргә ошый икән бит! Кайда укыйсың? Тумышың белән кайсы районнан? Аксубайданмыни? Якташың шагыйрь Хәсән Туфан турында беләсеңме?

«Хәсән абый минем кардәшем», – дияргә җөрьәт итми Роза. Аһ, бу авыл баласының тыйнаклыгы!

...Олылар юл газабы – гүр газабы, диләр. Нинди газап, ди! Бу сәяхәт тамчы да арытмый, пошкырган паровоз, тынчу вагонда шаулашкан-гөрләшкән абый-апалар, усал проводник – барысы да кызга матур төш кебек.

...Әтиле-кызлы Гадилә апаларның торагын да интекмичә таба. Авыл күчтәнәчләре белән чәйләр эчеп, бераз аяк ялы алгач, апасы олы кызы Флёра белән кунакларны Асбест бистәсе буйлап йөртә. Асбест... Телеңне сындырырлык исем!

«Экскурсия» менә-менә җимереләм дигән ике катлы иске агач бporактан башлана. Янәшәдә генә... төрмә. Аның да ниндие әле: бирелә әсир немец солдатларын тоталар икән. Ушлы кыз дикъкать белән олыларның сөйләшкәнен тыңлый.

– Илләренә генә кайтарып җибәрәсе лә, – ди Гадилә апа. – Сугыш беткәнгә ни гомер. Син, Рәхмәтулла, боларга нәфрәтләнерсең булыр. Мин җәллим менә. Дошман дисәк тә, адәм балалары бит.

– Без аларны чакырып китермәдек. – Әтисе «төрмә» ягына карамый. –

Тыныч кына яшәп ятканда, үзләре илгә бәреп керде. Без керсәк – икенче нәрсә. Кызгансаң да ярый.

– Ачлар, ябыклар, мескеннәрем. – Гадилә апа һаман үзенең «каймагы»н туглый. – Ашау начардыр, тамаклары туймыйдыр. Барактагы күршеләрем ансын-монсын биргәлиләр ярыктан. Минем ише ике балалы тол хатынның табыныннан ни артсын, ипи телеме инде бездән. Ходай ризалыгы өчен дим инде, ачуланма, Рәхмәтулла.

Туган апасы эшләгән зур гына карьерда асбест минералын казыйлар икән, кунаклар шул тирәләрне урый. Бөтен бистәгә бердәнбер кибет яныннан үткәндә, кызык өчен генә анда да сугылалар. Аһ, ул кибет! Никләр генә аның ябык чагына туры килми Роза?! Тартмалардагы ялтыравык кәгазьле кәнфитләр дә, кызыл билле прәннекләр дә кызыктырмый, ә менә киштәнең бер почмагында алсу күлмәкле, зәңгәр күзле ташкурчак! Аның матурлыгы! Әллә соң ул тереме? Әнәгенәк Розага кулын суза. «Ал мине», – диме?! Хыял бик тиз канат җилпи: «Безгә кайтабыз, яме? Үзигә, яме? Мин сине саклармын, беркемнән дә боздыртмам. Исем дә кушармын, яме?»

Аның нәрсәгә карап әсәренгәнен күргән кибетче хатын курчакны үтереп-үтереп мактый.

– Бите – ак, чәче – сары, күлмәге асыл ефәк, төймәсенә бассаң, «әни» ди. Папаша, кызың да курчак төсле чибәр, үзенә иптәшкә сатып ал!

– Әти ал, әти! – Розаның күзе ут яна.

– Кыйбат. Акчабыз юллык кына, кызым. Норлатта моның сыңарын карарбыз.

Карамый! Бары тик юата гына! Станцада мондый курчаклар юк та әле.

Иртәме, кичме, ташкурчак күз алдыннан китми йөдәтә.

– Флёра апа, теге кибеткә барыйкчы, – ди ул туганына.

– Нәрсә калган безгә анда?

– Ташкурчакка карыйм.

Унөч яшьлек үсмер Флёрага көлке:

– И бәби! Күз нурыңны шуңа түкмәле, яме? Сезне бүген кичке ашка дәшәләр. Тәмле макарон ашарсыз.

Макарон, макарон... Сугыш артыннан соң Асбестта үтә дә тансык ризык. Аны сирәк кенә, йә бәйрәмнәрдә, йә кадерле кунакларга гына кыздыралар. Бистәдә татарлар күп, чәчелгән-таралган милләт. Үзидән дә байтак кеше. Заманында читкә таймасын өчен крәстиәнгә паспорт бирдертмәгән хакимият, ә мәрхәмәтле колхоз рәисе Рәхмәтулла авылдашларын жәлләп, (хәерчелектән котылсын!) яшереп кенә белешмәләр ясаткан, менә хәзер, рәхмәт йөзеннән, аны ашка чакыралар. Һәрберсенең табынында иң тәмле сый – макарон... Кыстап-кыстап ашата хуҗалар! Розаны да:

– Ал инде, ал ташкурчакны! – дип кыстасалар икән!

Өч мәртәбә керә кибеткә ташкурчак белән хушлашырга ул. Җанлансын да сикереп төшсен иде киштәдән зәңгәр күз! Төшми шул, кибетче апа аны акча белән «богаулаган».

Иртәгә туган якларга кузгаласы. Туганнар җыйнаулашып, соңгы тапкыр бистә һавасы суларга чыга. «Ходай ризалыгы өчен» әсирләргә дигән зур гына ипи телеме Флёра кулында. Бу аның вазифасы икән. Ул бүлмәдә нәрсәдер оныта һәм тотып тор әле дип, ипиен Розага бирә, Роза исә аскы

катка йөгерә. Флёраны ник күтәргә ди, ул да ике куллы! Койма кырыенда ук озын буйлы галәмәт ябык әсир йөренә. Аны зил-зилә бөтереп, барак ишегалдына очыртыр кебек. Немецлар хор белән:

– Madchen, madchen, – дип кычкыра. «Кызый, кызый» дигән сүз икән ул.

Флёра ипине ерактан гына ыргытса, Розаны ниндидер көч койма кырыена ук атлатып китерә. Озын әсир, сабый алдында тез чүккәндәй, җиргә тезләнеп, ярыктан ипигә үрелә, һәм, күлмәк эченнән курчак алып кызга суза. Мизгел эчендә хыялның чынга ашуымы? Ташкурчак салам курчакка әверелдеме?! Монысы да искиткеч матур, һәр салам бөртегенә кояш нуры кушып үрелгән. Сабый аны яратып күкрәгенә кыса. Әтисе... әтисе ачуланмыймы? «Алар безгә бәреп керделәр...» Ачуланмый, аның күзендә нәфрәт тә юк, бары тик тирән сагыш кына... Күрәсең, кабат күңелендә сугыш хатирәләре яңара.

...Немец әсиренең бүләге – салам курчак озак еллар сеңелләренең буе җитмәс шкафта «яшәр». Роза илләр-җирләр гизгәндә, Балтыйк буе, Белоруссия республикаларыннан үз ишләрен җыеп, тулы бер коллекция дә туплый, ахырдан исә аларны дус-ишләренең балаларына өләшә.

Килер бер көн, дөньяда иң затлы курчак сатып алырлык акчага тиенер Рәхмәтулла кызы, ләкин балачакта ымсынган зәңгәр күзле, ефәк күлмәкле ташкурчакны берсе дә алыштырмас.

## 4. «Яз, син сәләтле, яз»

Урамда картлар да баш иеп сәламләгән абруйлы мөгаллимә капылт кына укытуыннан туктый. Авыл халкы өчен күңелсез хәбәр: Фигаль балаларга дәресен сеңдереп аңлата, аннары, укучы белән укытучы арасында җылы бар, ярату бар, бу сирәк хәл. Үсмер Роза инде аңлар яшьтә: әнисенә читен. Аның өчен таңнар иртә ата, ә кояш соңлап кына байый. Кышкы суыкларда ярты төндә мич ягып, ызба җылыту, сыер саву, казан асып ашарга пешерү, дүрт баланы тәрбияләү. (Алда бишенчесе, ә яман шеш белән авыруы ачыклангач табиб: «Әгәр тагын тудырсагыз, бу чирдән котыласыз», – ди һәм хатын алтынчысына тәвәккәлли.) Укыту бөтен вакытын суыргач, ул «укучыларга игътибарым кимер», дип борчылып, авыл китапханәсенә күчә. Яңа эше дә җиңел түгел. 60 нчы елларда халыкның бердәнбер белем чыганагы – китап. Китапханәдә кич буе ут сүнми. Әйтерсең анда дәресләрнең дәвамы: «Апа, миңа әкият кирәк! Апа, мин маҗаралар яратам! Апа, шигырьләр китабы бирегез әле!» Укыдым да кире тапшырдым түгел, Фигаль апалары әсәрнең эчтәлеген сөйләтеп тикшерә, бу Розага да кагыла. Кем китапны «су кебек эчә» дисәләр, алар икәү: берсе – ул, ә икенчесе – Кашапов Газизҗан. И-и, аның белән ярышырлыкмыни! Җиденче класста укыганда ук «Татарстан яшьләре»ндә аның мәкаләсе чыккач, мәктәп директоры Рәхимҗан абый Вафин иртәнге линейкада:

– Газизҗан – безнең горурлыгыбыз, – дип мактый. Кыяр-кыймас кына каләмгә тотынган Розаның да район газетасында язмалары еш басыла. Үзәк матбугатына ерак шул әле! Әмма авыл күзендә Зәйнуллина Роза – талант! Ул мактауларга эреп борын чөйми, бары тик үзен «бөек иҗатчы» итеп кенә тоя.

Әдәбиятка гашыйк шигъри җанлы әнисе китапханәдә нинди генә чаралар үткәрми. Хәтта ки, хатлар язып, Казан тиклем Казаннан язучы Мирсәй Әмирне китертә. Аның «Саф күңел» әсәрен кулдан-кулга йөртеп укыган укучылар өчен чын бәйрәм! «Кем язучы була?» Каләм тибрәткән һәрбер бала әлеге сорауга җавап эзли, әле аңа маңгаена шапылдатып әйткән: «Талантлысы», дигән сүз аңлашылмый һәм «беренче чиратта талантлысы» дигәндә дә, чиратның икенчесен, өченчесен, дүртенчесен санарга кирәк. Язучыдан киңәшләр ява гына! Нәкъ менә шуның берсе гомер буе Рәхмәтулла кызының үзәген өзәчәк: «Иҗат өчен вакытыгызны кызганмагыз!» Ул төзегән тәкъдирмени, ул язган язмышмыни, аның җилкәсенә олау-олау йөк аударачаклар. Күтәр, җигел, тарт! Зарланма һәм уфтанма! Дөнья мәшәкатенә күмелдең икән, язам димә! Каләмеңне читкә этәр!

Вакыт Галиҗәнабы газиз иҗат өчен минутларын-сәгатьләрен бүлеп бирәчәк аңа. Соң гына, бик соң гына...

Ә хәзер... Алар бәхетле, нинди зур язучы белән очраштылар. Иренмәгән Мирсәй абыйлары, Татарстанның иң ерак авылы Яңа Үзигә килгән. Шатлыгы шәфәкъ кызыллыгы төсле бит очына агылган Газизҗан нишләптер Розага иярә. Ә кыз элдертә генә, чөнки «юеш борыннар» – сеңелкәш-энекәшләр өчен ул күз дә, колак та.

– Мин дә киләчәктә танылам. – Егет (әлбәттә, егет! Үзидә җидееллык кына мәктәп, шуңа күрә ул Иске Ибрай авылында югары классларда укый) бүген үк үзенә якты киләчәк юрый. – Таш калаларда яшәп, шәп әсәрләр язачакмын, күрерсең, вәт!

Ташкала – Казандыр, мөгаен. Розага бүгеннән үк авыл тарайган, аның да җаны кысрыктан туеп, каядыр ыргыла. Кайда ул җан сыярлык киңлек-иркенлек, кайда?! Аны киләчәктә ниләр көтә? Әйдә, ул Кашапов кебек күрше авыл мәктәбенә йөрер. Барыр-кайтыр, барыр-кайтыр. Айлар, еллар буе шул ук сукмак, шул ук бертөрлелек! Язмалары район гәзите белән генә чикләнер. И Ходай, сиңа чиксез рәхмәт: аның эчтән генә сызлануларын әнисенең сеңлесенә белгерткәнсең. Чистай педагогия училищесын тәмамлаган Алия апасы Азнакай үзәгендә татар балалар бакчасы мөдире. Ул:

– Уйла әле, бәлки Азнакайның атаклы беренче мәктәбенә килерсең, бездә бөтенләй икенче төрле мохит, язучы Мәхмүт Хәсәнов әдәби түгәрәк оештырды, син дә катнашырсың, – дигәч, кыз шунда ук ризалаша. Роза риза, ә өйдәгеләргә «баш бала»дан аерылуы җиңелме? Алар бит уң кулсыз кала! Бердән, Роза бәләкәчләрне үстерергә булышса, икенчедән, әнисенең риясыз киңәшчесе. Яшь кенә булса да, кыз акыл тупламасы, гаиләдә «табак-савыт» шалтыраса – көйли-җайлый, һәркемнең күңелен йомшартырлык җылы сүз таба. Ләкин «кош» бит оясына сыймый, ул күкләр иңләп ят җирләргә очмакчы. Ничек аның канатын кисәсең дә, ничек хыял капкасын биклисең. Мәктәптән соң университетка керәм, ди. Фигальләр нәселендә халык уку дип егылган, нишләр хәл дә юк.

Азнакайда җан рәхәткә тара. Менә кайда кыз тансыклаган иҗат учагы дөрли икән! Түгәрәк җитәкчесе – алып гәүдәле Мәхмүт абыйлары җитмеш һөнәр иясе бугай, үзе режиссёр, үзе хәбәрче, үзе драматург. Ут борчасы диярсең, барысына да җитешә. Әллә аңардан чын язучы әвәләмәкче,

мәктәп тормышына багышланган ике пәрдәлек пьеса яз, ди. Язам дип ашкынган кешегә азык җитәрлек, аңа белем дөньясының эче-тышы таныш: «каһарманнар» итеп сурәтләрлек шук-шаян классташлар, кыска гына дәрестә дә гыйлем коесына тирәнрәк чумдырырга тырышкан җитди укытучылар үзеннән-үзе каләм очына сарыла. Караламасын буй-буй дәфтәр битенә күчереп, Мәхмүт абыйсына укырга биргәч, и ул курка-курка көтүләр? Ни дияр остаз, кульязманы аркылы-торкылы сызгалап: «Әсәр пешмәгән, әсәр чи!» – диярме? Ипле-җайлы җитәкче алай каты бәрелми иде дә... Юкка гына шомлана Роза, түгәрәк җитәкчесе «беренче шедевр»ның хата-кимчелекләрен күрсәткәч:

– Яңа драматург туа түгелме? – ди. – Тапкан бит шуннан күзгә кырып салырлык бер күренеш. Әйе, бер нәни генә күренеш. – Син сәләтле, Роза сеңлем, дәвам ит, язуыңнан туктама!

Әйе, Азнакайда бөтенләй икенче төрле мохит, көн дә яңалык, көн дә үзгәреш, көн дә ачыш! Әлмәт кул сузымында гына, аннан атна саен түгәрәк утырышларына Гариф Ахунов, Рафаил Төхфәтуллин, Шамил Бикчурин кебек әдәбиятта азау ярган олпат язучылар килә, алар яшь авторларның хикәя-шигырьләрен сүтеп-җыя. Ләкин беркемне дә бетереп атмый, алар яшьләргә хәерхаһлы, әдәбият мәйданында олысы-кечесе бил алышсын!

Берсендә Розаның хикәясе проза остасы Рафаил Төхфәтуллин кулына эләгә. Ул үтә дә яшерен серен чишкәндәй:

– Сеңлем, колагыгызга гына әйтәм, сездә мин талантлы язучы чаткылары күрәм, Әмирхан Еники йогынтысы көчле сездә. Кызганыч, киләчәктә сез иҗат мәсьәләсендә бик интегәчәксез, – ди.

Әдипләр җирдә туса да, җир кешесе түгел бугай, Бөек Идарәче аларны, гадиләрдән аерып, әүлиялык сыйфатлары белән арнамадымы икән? Киләчәктә диясе дә юк, хәзер үк интегә Роза. Алия апасы тикмәгә генә аны үзенә чакырмаган икән, Пушкинның Арина Родионовнасы дәрәҗәсендә булмаса да, туганының ике кечкенә баласына ул «няня».

Ни кушсаң – шуны җебен-җепкә ялгап эшләгән кызны мәктәптә комсомол оешмасы секретаре итеп тә сайлыйлар. Аңа әледән-әле төрле чаралар үткәрәсе. Укуына, җәмәгать эшләренә дә өлгер! Өлгерә анысы, тик җыелышларда чыгыш ясавы гына мең бәла. Ул сөйләргә керешсә, зал пырх-пырх көләргә тотына. Мишәрләрнең «ызба», «кияш», «оланнар»ы Азнакай татарларына мәзәк яңгырый. Аеруча Галиев Марсель исемле егет аска иелеп хихылдый. Ул – рәсем остасы, китаптан «Молодая гвардия» егет-кызларының сурәтен бермә-бер күчерә, кайсы фото, кайсы Марсель иҗат җимеше – аерылмый. Укытучылар аңа якты киләчәк юраган: «Укуын шул юнәлештә дәвам итсә, Галиев атаклы рәссам булачак». (Әмма Марсель аларның «өмете»н акламас, ул язучы һөнәрен (һөнәрме икән соң ул?) сайлар, һәм роман-повестьлары, «Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Нинди моң бар синең күзләреңдә», «Кайту» кебек популяр җырлары белән танылып, язучы данына күмелер.)

Әлегә ул мишәр телле комсомол секретарена өстән генә карый. Розага вазифасы буенча мәктәп укучыларын, бигрәк тә өлкән сыйныфларны төрле чараларда катнаштырасы. Тик Марсельгә орына күрмә! Егет, билгеле, күз карашы белән генә кисәтә: «Мине буйсындырырга маташма!»

Кисәтә дигәннән, түгәрәк җитәкчесе кызны бастырып-бастырып орыша:

– Зәйнуллина, кая берәр яңа әйберең? Каләмеңне күгәртәсең бит. Ник язмыйсың, ә?

– Вакытым юк, Мәхмүт абый.

– Шушы яшеңнән нинди вакыт сиңа?! Үкенерсең, Зәйнуллина! Вакытның койрыгы кыска – тоттырмас беркөн!

## 5. «Мәхәббәт – күкләр бүләге»

Шык-шык, шык-шык… Төн таңга авышканда кем шакып уятсын? – Зөлфәт! Менә ул тубал башын тыгып:

– Роза-а, чык әле, чык, – дип инәлә. – Шигырь укыйм.

Лекцияләрдән соң иптәш кызы Әнисә белән студентлар ашханәсе идәннәрен юа-юа арытыла, селкенерлек хәл юк. Стипендияне ай күрә, кояш ала, яшь чак, матур итеп киенәсе, өс-башны рәтлисе... Әти-әнидән матди ярдәм өметләнергә уңайсыз, авылда дүрт бала, бишенчесе яңа гына тәпи киткән. Эштән чирканмый, авыл кызы ла ул.

Ишетмәмешкә салышып юрган астына качып котылам димә, дуамал җиле белән барыбер коридорга суырып алачак. Тәүлекнең теләсә кайсы сәгатендә, төнме, таң зәрәсеме, – йә Зөлфәт, йә Мөдәррис илһам куагыннан өзгән «иҗат җимеше»ннән авыз иттерә. Риясыз дуслык ничек башлана! Мәктәпне «көмеш медаль»гә тәмамлаган Зәйнуллина Роза Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга кергәч, шагыйрь-шагыйрәләр чолганышында кала. Татар бүлегендә Харрас Әюпов, Ләлә Сабирова, Флүс Латыйпов, Рәшит Әхмәтҗанов, Рәшит Ягъфәров, Роза Мулланурова, Клара Булатова – төркемдәшләр. Ярыша-ярыша иҗат көймәсен әдәбият диңгезендә йөздерт! Розаның да «көймәсе» дулкыннар яра: үзәк матбугатында басыла. Ләкин... 1964 елда татар бүлеге үзенең егерме еллык бәйрәмендә яшь авторлар – студентлар арасында хикәяләр конкурсы үткәрә. Хөкемдарлар – Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Габдрахман Әпсәләмов. Розаның хикәясен Габдрахман абый анализлый.

– Сеңлем, нишләп син үз яшеңә туры килмәгән темага тотындың? – ди ул.

«Үз яшеңә туры килмәгән тема...» бармактан суырылмаган югыйсә. Роза әтисенең язмышы турында бәян итә. Сугыш төп геройны гаять дәрәҗәдә кырыслаткан, бәгырен катырган.

Мактавын да мактый анысы Әпсәләмов: «Сурәтләү чараларын оста кулланасың, җөмләләрең төзек...»

Розага өченче урын бирелә. Шуннан соң, һич сәбәпсез, иҗатка күңел сүрелә.

Курс эше язганда, ул Әмирхан Еники белән очраша.

– Рауза туташ (Әмирхан ага аны шулай атый) сез язудан тайчынмагыз. Хикәягезгә күз йөрткән идем, камил хикәя. Габдрахманның маңгайга бәреп тәнкыйтьләү гадәте бар, алай ярамый, әдәбиятның гомерен өметле яшьләр озайта, ә сез, мотлак, өметле автор, – ди әдип.

Аның каравы, әнә, Розалар бер курс укыгач, аларның бүлеген кемнәр генә үз итми! Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Рафаэль Хуҗин, Фәрит Гыйльми, Нур Әхмәдиевлар – һәммәсе дә татар әдәбиятының «алтын баганалары». Егетләрнең, аеруча Зөлфәт белән Мөдәрриснең кызны якын күрүе тикмәгә

түгел. Татар бүлеге дәррәү әдәби кичәләргә йөри. Тукай клубы шыгрым тулы, студентлар ярыннан ташыган елга кебек, баскычларга хәтле «җәелә». Сәхнәдә киләчәкнең «бөекләре» ялкынланып, шигырь сөйли! Кемнең генә бер җылы сүз ишетәсе килмәс, бигрәк тә кызлардан... Бигрәк тә сөйкемле Роза туташтан. Кыз ачылмаган чәчәк бөресе төсле, керфек каккан саен аңардан сер түгелә, ә инде бит очын чокырайтып елмайса – җаныңны эретә. Кайчан гына карама, ул уку залында. Мөдәррис аны көтеп-сагалап арый. Армый ни, кесәсендәге дүрткә бөкләнгән кәгазьдә гениаль шигырь кытыклана. Кем тыңлар? – Сабыр Роза. Кем бәяләр? – Туры сүзле Роза.

Йа Ходайгынам, туры әйткән туганына ярамаган, диләр. Кайчакта Әгъләмнең дә серкәсе су күтәрми. Шигырьне әз генә төзәткәлә, әз генә үзгәрт – син аңа «кара дошман». Беркатлы җан сабый бала кебек үпкәли. Әмма ул Роза белән исәпләшә, өч-дүрт көннән үпкәсен онытып, кызның кулына кәгазь сона:

– Мәле, укы! Өр-яңасы.

Кечкенәдән үк Тукай, Җәлил, Такташ иҗатына багынып, шигырьнең аһәңен, моңын, яңгырашын тойган «тәнкыйтьче» аңа яхшылык кына теләгәнен аңламас, ди, Мөдәррис Әгъләм!

Татар дөньясын шаулаткан бер вакыйгадан соң егетләр белән рухи туганлык җепләре тагын да ныгый. Язучылар корылтаенда университет студентлары яшьләр өчен журнал сорап, театр балконыннан залга листовкалар ыргыта. Система өчен бу гафу ителмәслек башбаштаклык! «Бунтарьлар»ны «Черек күл»гә төяп китәләр. Зөлфәт тә шулар арасында. Төнлә бүлмәгә ажгырып, Фәрит Гыйльми керә:

– Кызлар, уяныгыз, уян! Тамак ялгарга нәрсәдер әзерләгез! Егетләрне тегеннән чыгардылар!

Студентлар яшәгән җирдә тараканнар ачтан тәгәрәп үлә, дигән мәзәк алтмышынчы еллар азагында чынбарлыкка тартым. Авыл баласының төп ризыгы – бәрәңге.

Роза кызларны бүлмәләр буйлап йөгертә. Кемдер он, кемдер май, кемдер сөт табыштырып, өем-өем коймак кыздыралар. Җиңү яулаган батырларны тулай торак гөелдәп каршы ала... Шуннан соң сәяси мәсьәләләрдә дә «ышанычлы иптәш» – Розага хөрмәт тагын да арта.

Аны сер сандыгы итеп тә күрәләр бугай. Зөлфәтнең сабакташы:

– Роза, беренче катка төш әле, анда хуш исле тәмләткечләр салып, Зөлфәткә аш пешерә берәү, – ди.

Журналистика бүлегендә укучы авар кызы! Зөлфәт исемле ир-егеткә түгел, ә Зөлфәт атлы шагыйрьгә! (Кыз ил күләмендә танылган Рәсүл Гамзатовның туганы.) Сәхнәдә башын чөя-чөя, бөдрә чәч алкаларын уйнатып, күк төсендәге зәңгәр күзендә яшеннәр яшьнәтеп шигырь сөйләгән мәһабәт затка кем генә гыйшык тотмас икән! Икәүнең йөрәк эшенә кысыламыни Роза, хәер, «икәү»нең берсе – Зөлфәт авар чибәренә бөтенләй битараф, аны алда Ходай үз хәләле, сакчы фәрештәсе – Фираясы белән кавыштырачак. Иренең бөеклеген таныган хатын! Зөлфәт нык кына авыргач, Фирая аны хастаханәгә китереп табибларны аякка бастыра. Берсе танымыйча:

– Кем соң бу авыру? – дигәч, ул горурланып:

– Татарның Пушкины! – ди.

«Татарның Пушкины» «Сөю мәңгелек» дигән популяр җырын нәкъ менә Фираяга атап язачак.

Шик туса кинәт җанында әгәр,
Йә килсә сиңа куркыныч хәбәр
Мин йөргән яктан, ерак-ерактан,
Ышана күрмә – һаман яратам.

…Шык-шык, шык-шык…

Кыз бүлмәдәшләрен уятмас өчен аяк очына гына басып, коридорга чыга. Күпме илаһи сүз шаһиты – төнге тәрәзә! Йокыдан күз кабагы авырайса да, авыз ачып иснәргә ярамый. Гөнаһ! Чөнки кодрәти мизгел: яңа гына дөньяга шигырь туа, шигырь!

– Тыңлыйм, Зөлфәт…

Егет тыны-сулышы буылып укыганнан соң ярышта җиңгән чабышкы ат сыман урынында биеп:

– Ничек, ничек? – ди. – Дус икәнсең, дөресен әйт!

– Шәп! Син – талант!

– Нишләп син дә шигырьләр язмыйсың, Зәйнуллина!

– Исememне оныттың бугай, Маликов! Мин сезнең шедеврлар белән дә тук! – ди Роза, шаяртып.

– Без ни ул! Вәт сиңа мәхәббәт шигырьләре багышлаган шагыйрьләр солтаны – бәһасез! Туптан атып та алалмаслык нинди бастион син! Газаплама, җавап яз аңа!

– Син дә әгәр дус икән, бүтән миңа мондый киңәшләр бирмә.

Инкарь итми Роза, хак. Ул – шагыйрьләр солтаны. Кыз җиде тоем белән сизә: киләчәген дә әдәбият белән бәйләячәк. Чиста, якты, нурлы һәм искиткеч әдәпле-инсафлы егеткә нинди җавап кирәк? Дорфа гына читкә этәреп, күңелен кайтарыргамы? Мәхәббәт – күкләр бүләге, аның һәр төене ярату-сөелү белән төйнәлгән, шул төеннәрне үтмәс пычак белән кистеңтелдең ди, йә? Тик аның йөрәген яралап ни отарсың икән?

Бердәнбер юл – дәшмә! Әйе, әйе, бастион бул! Хисләр өермәсендә бөтерелер чакмыни, кызга иртәгәсен кайгыртасы. Университетны тәмамлагач, кая эшкә урнашыр, кайда яшәр? Тагын артыңнан чылбыр кебек тезелгән сеңелкәш-энекәшләр турында кайгыртасы… Редакция тирәләренә ымсынма, анда кызларны бик өнәмиләр, анда егет-җилән – «кыйммәтле товар». Ташкалада беркем дә аш сосып, авыл баласын көтеп тормаган, бөтен ышаныч үзеңдә. Үргә күтәрелгәндә кемдер култыклап менәр дип өметләнмә!

Түгелер, и, түгелер ак кәгазьгә аңа аталган шигырьләр. Бүген дә, иртәгә дә, аннан соң – еллар үткәч тә… Булыр да икән бетмәс-төкәнмәс ярату!

Җил-давыллап очкан кошлар
Акчарлак түгел микән?
Син киткәнгә мин түзәрмен,
Йөрәгем түзәр микән?

«Бастион кыз» – шагыйрьләр солтанының күңел ярына каккан хис дулкынында чайкалган акчарлак образында да сурәтләнер:

Сөйгән ярым китеп барды кулын болгап,
Кайтыр микән тагын миңа юллар урап.
Сау булыгыз, акчарлаклар, акчарлаклар,
Мәхәббәткә кирәк икән пар канатлар.

Егетнең кырыс еллар белән тоныкланырга тиеш мәхәббәт ялкыны киресенчә, күкләргә кадәр үрләр...

### 6. «Раббем, бир шундый кеше!»

Умарта оясындагы бал кортлары кебек гөжләгән студентлар тулай торагы белән хушлашу... Моңсу һәм ямансу! Хәзер аны: «Тор, шигырь укыйм! – дип, беркем дә йокысыннан уятмас. Сагыныр ул минутларны Роза, сагыныр. Пыяласына сүз кодрәтен сеңдергән төнге тәрәзә дә кызны юксыныр, мөгаен.

Кулда – «кызыл» диплом, эш урыны – телестудия. Яшәү – эшчеләр торагында. Монда халык романтикадан азат, монда әз генә хезмәт хакына гаиләне ашату кайгысы. Балалар өчен тапшырулар бүлеге редакторы Розаны Мәскәүгә – бер айлык курсларга җибәрәләр. Казанга кире кайтканда, купеда юлдашлары – мөлаем ике татар карчыгы юл догасы укып:

– Без өчәү генә, хәерлесе белән! – дигәндә генә купе ишеге ачыла. Поезд кузгалган иде ләбаса, вагонга сикердеме икәнни?

Төз гәүдәле, аксыл чәчле яшь кенә егет русча исәнләшеп (тегеләр кавеменнән бугай) өске катка менеп үк ята. Чәй эчәргә чакыргач кыстатмый үзе. Бәй, чеп-чи татар малае икән лә! Исеме дә чын үзебезчә – Миргалим. Әбиләр «бәбкәм» дия-дия сораша-төпченә, моның шәхесен «ачыклый». Егет Туладан икән, политтехника институтын тәмамлагач, Казан «Теплоконтроль» заводына юллама белән эшкә бара.

– Тула оеклары киеп, клубта биегән чаклар бар иде, иеме, ахирәт, – ди карчыкларның олырагы.

– Тула самавыры кайнатып чәй эчүләре соң, чәй эчүләре, – ди яшьрәге.

– Тула – шәһәр бит ул, әбиләр. – Егет аларның мәзәген чынга ала. – Минем әти-әниләр чыгышы белән Чүпрәледән.

– И-и, сәвсим безнең якныкы икән син, таем, – диешә карчыклар.

Тула немецлар чолганышында калгач, боларга: «Өйләре чиста» дип, немец офицерын кертәләр. Миргалимгә кадәр туган ничәдер айлык Розалим исемле абыйсы төннәрен көйсезләнеп елап, немецны йоклатмый, өй кечкенә, чаршау белән генә бүленгән. Берсендә акылдан шашкан фриц атарга дип сабыйның чигәсенә пистолет төзи...

Бу фаҗига сүзгә кушылмыйча тыңлап кына утырган Розаның йөрәгенәябыша.

– Нишләп син туып-үскән шәһәреңдә генә калмадың соң?

– Әнинең бөтен хыялы – мине татар кызына өйләндерү, – ди егет. – Казанда миңа дигәне бардыр дим.

– Сиңа әллә ни эзлисе дә юк, менә мин ул – татар кызы.

Бары тик шаярту, бары тик сүз уйнату. Шуның белән вәссәлам! Иртән һәркем үз юлы белән китә. Тула егете поезддан алдарак, әбиләрнең төенчекләрен күтәрешкән Роза соңрак төшә. Тиз-тиз юырткан егет

артыннан ул теләк теләп кала: «Үз насыйбыңны очратып, бәхеткә тиенеп яшә, татар малае!»

Ә беркөнне телестудиянең проходной ишеге төбендә Миргалим басып тора!

– Мин татар кызы таптым, – ди ул, көлеп.

– Котлыйм!

– Мин дә сине котлыйм! Ул син – Роза!

Көлә егет, шатлыгыннан көлә! Роза исә шул хәтле җитди, аның елмаерлык та рәте юк. Кечкенәдән үк сеңелкәш-энекәшләрен багып, иртә «олыгайды» бугай.囀штә дә җәлләмиләр, өчәр-дүртәр тапшыру әзерләтәләр. Вакыт – аңа, ул вакытка сыеша алмый. Нәрсә ди Тула егете? «Син ул, – ди. – Син...» «Раббым, бир шундый кеше, мине аңларлык, миңа терәк булырлык, мине җил-давыллардан сакларлык!» дип теләгән теләкләре кабул кылындымы икән? Чүлмәк эче тышыннан беленә: Миргалим – сабыр һәм төпле ир-егет, аның белән оя корып ялгышмый Роза. Тормыш күгендә бергә очасы уң канаты бар, шөкер!

Сау булыгыз, акчарлаклар, акчарлаклар,
Мәхәббәткә кирәк икән пар канатлар!

Шагыйрьләр солтанының бу шигырен көйгә салып җырларлар. Ул да парын очратыр... Һәркемнең бәхеткә хакы бар. Тик бәхет савыты кемнеңдер тум-тулы, кемнеңдер – буш. Туфитулловлар өйләнешкәч, башта тулай торакта яши. Ниһаять, Миргалимгә заводтан бәләкәй генә бүлмәчек бирәләр. Каяндыр адрес юнәтеп, Аксубай белән Чүпрәле туган-тумачасы төн кунарга гел аларга туктала.

Роза әле якташларының кемнәр икәнен чамаласа, Тулада туып-үскән ире – кардәшләре белән яңа гына таныша. «Мин фәлән-фәлән абыең яки фәлән-фәлән апаң», – дип тәфсилләп аңлата кайберсе. Әллә туган, әллә тукмак белән куган.

Кичләрен иңенә гармун асып килеп кергән Чүпрәле карендәше – университетның татар әдәбияты кафедрасы мөгаллиме Шәйхи абый Садретдинов – аеруча тансык кунак. Гармун төймәсенә басканда, Шәйхи абыйның калын бармаклары арасыннан үзәкне өзәрлек моң саркып чыга. Сәгыйть Рәмиевнең иҗатын өйрәнгән, үзе дә шигырь язган мөгаллим кайчакта хисләрен тыялмыйча җырлый да, елый да...

Күңелең киң икән, тар бүлмәләр дә иркенәя. Аллаһы Тәгалә: «Бердәнбер сиртмәле караватыгызга кунакларга урын җәеп, үзегез салкын идәндә күп йокладыгыз, мин сабырлыгыгыз өчен сезне бүләклим», – дигәндер, бүлмәдән фатирга күченә яшьләр. Кайда гына яшәмәсеннәр, адреслары билгеле. Туганнарга гына түгел, җиде ятларга кадәр. Күпме кеше аларның гаилә учагында җылына, күпме кеше алар табынында ризык бүлешә! Ярдәмгә мохтаҗ авыруларын хастаханәдә йөртү, табибларга күрсәтү, кыйммәтле дарулар табу – инде көндәлек бурыч кебек. Иртә-кич ябылмаган ишек, гозер-үтенеч, аһ-зарлар туйдырмыймы, Ходайгынам? Нишләсен, үзен үзгәртә алмый Роза, ул бит ачлык елларында авылдашларын үлемнән коткарган мәрхәмәтле Вәлиулла оныгы! Ул бит партбилетыннан колак какса

да, халыктан налог хисабына сөтен-йомыркасын җыюдан баш тарткан колхоз рәисе Рәхмәтулла кызы!

Ә каләм: «Бер-бер әсәр язасыңмы, юкмы?» – дип, очы белән бәгырьне тырный. Җир кешесе Миргалим аны әкрен генә хыялый шагыйрьләр иленнән чынбарлыкка кайтара шикелле. Ирексезләп түгел, Аллам сакласын! Иренең янәшәсендә аңа тыныч һәм рәхәт, бәхет өчен тагын ни кирәк?

Миргалим беркайчан да аңа үзенең фикерен көчләп такмаячак, әдәбият-сәнгатьтән ерак булса да, Розаның иҗат дөньясы аңа кызык: аны аңлар өчен гомерендә татарча китап тотмаган ир әүвәл татар язучыларының тәрҗемә ителгән әсәрләрен укый. Почта тартмасында исә гел татар матбугаты, алары да телне өйрәнергә бер кулланма. Әкрен генә татар китапларына чират җитә...

Роза: «Нишлим, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») гәзитенә эшкә чакыралар?» – дигәч, Миргалим:

– Журналистика – синең стихия, ризалаш, – ди.

Ә Роза Туфитуллова гәзитнең баш редакторы итеп сайлангач, язучы халкы кичә-бәйрәмнәргә чакыру китерә. Ике кешегә! Чөнки янәшәсендә Миргалим әфәнде утырачак. Гади инженердан генераль директор дәрәҗәсенә күтәрелгән Тула егетенең иҗат әһелләренә хөрмәте чиксез: абунәчеләрне журнал-гәзитләргә яздырту, юбилей кичәләре үткәргән шагыйрьләргә матди ярдәм күрсәтү, китап бастырганда булышу – барысы да ихластан. Танылган бер шагыйрь аңа: «Сездән күргән изгелекне мин беркемнән дә күрмәдем», – дияр. Әмма мәрхәмәт иясе «Мин!» дип күкрәк какмас, Роза кебек аңарда да: «Изгелек эшлә дә суга сал...»

...Хыялый шагыйрьләр иленә кабат аяк баса ул. Дуслары – Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт, Нияз Акмаллар үзгәрмәгән, алар шул ук, күктә җемелдәгән «йолдызлар». Алар кырыенда яңалары калка. Шуларның берсен, университет тәмамлаган егетне Туфан Миңнуллин баш редакторга алып килә.

– Роза, менә сиңа яшь язучы Ыркаил Зәйдулла, аны яхшы гына наструклап, тәртәгә кертәсе иде.

Туфан юк-бар кеше өчен кайгыртып йөрмәс. Егет әдәбият мәйданындагы чабышларда каләменнән ут чәчрәтеп алга ыргылачак гаярь акбүз ат булмагае әле.

– Мондый егетләрне кире борырга уңайсыз инде, Туфан абый, – ди Роза. – Миндә бит хатлар теркәүче хезмәткәр урыны гына.

– Аңа акчасы бик мөһим түгел, дөньяны танып белергә өйрәнсен! Шулаймы, бырат?

Ркаил килешкәндәй баш кага.

«Бөдрә чәч, зәңгәр күз» 1977 елда Мәскәүнең югары әдәбият курсларын түгәрәкләп кайтып, эшсез йөргәндә, Роза аны «Яшь ленинчы»га ала. Приказга кул куелган, Зөлфәт редакциядә утыра. Каян иснәнгәндер, өч хәрефле оешма вәкиле кабинетка иңә.

– Приказыгызны ертыгыз, – ди ул боерган тавыш белән. – Театрда листовкалар ташлаган Маликов безнең күзәтү астында!

Вәкилнең тел төбеннән шунысы да аңлашыла: «Тыңламасагыз, без сезне урыныгыздан очыртачакбыз!»

Курыккан ди сиңа Мәрҗән амазонкаларының нәселдәше! Партия өлкә комитетының матбугат секторы җитәкчесе Мөхәммәт Мозаффаров янына йөгерә Роза. Сектор җитәкчесенең «өскә бер шалтыратуы» барысын да хәл итә...

Хикмәт Рәхмәтулла кызы «киребеткәннәр»не, «энәле керпеләр»не, «үзсүзлеләр»не, «телчарлар»ны магнит сыман гел үзенә тарткан икән! Нәрсә өчен? – Талантлары өчен! «Ялкын» журналы баш редакторы Роза Хафизова яшь коллегасын чын-чынлап кызганып:

– Нигә боларны җыясың? Харап буласың бит, – дип кисәткәч, җавап кыска:

– Минекеләр сүз кодрәтен тоеп, сүздән шигъри энҗе тезгән затлар, алар – гений! Егетләрнең һәр язмасы мавыктыргыч хикәя кебек укыла.

Зөлфәт белән Мөдәррискә шаярырга гына куш, материалны тапшыргач, редакторның сыза гына ачык кабинет ишегенә карап:

– Әнә Туфитуллова елый башлады, димәк, мәкалә әйбәт, – дип кул чабалар икән.

Еламый, билгеле, бүлек мөхәррирләренең каләм көченә соклана...

Кызлар гынамы, егетләр дә «аулак өй» оештырырга һәвәс икән. Шкафта яшерелгән «каты чәй» «суына», шуның белән тамак төбен чылата-чылата шигырь укып утырачак алар, баш редактор белән җаваплы сәркатипнең генә коридор очында аяк тавышлары тынсын! «Азынулары»ның чик-чамасы юк: дивар гәзитәсенең читенә «Ниһаять, Роза белән Саимә (поэма) китте!» дип язганнар.

Яшьлек! Уен-көлке! Кайда сез, гамьле, ямьле көннәр?! Иҗат итәләр, басылалар, язучылар җыелышында макталалар, әйдә, шаярсыннар-көлсеннәр! Аның да зур әсәрләр язарга кулы кычыта да, тик мәрхәмәтсез вакыт: «Аннары», – ди. «Аннары» кайчан соң ул? Берсендә Роза Әлмәт мәктәбе укучылары белән очрашкач, беренче каләм тибрәткәндә киңәшләрен биргән Рафаил Төхфәтуллиннарга сугыла. Авыру фронтовик язучы аны күптән көткәндәй:

– Менә кемне күрәсем килгән иде, – ди. – Матбугатта мәкаләләреңне укыйм. Казандагы каләмдәшләрдән дә сораштырам. Сугыш чорында Олы Мәңгәр сыендырган латыш балалары турындагы публицистик язмаларың әйбәт. Ну ул журналистика, килешәсеңдер? Синдә иҗади куәт бар, тотын роман-повестьларга, Роза сеңлем.

– Сез Азнакайда миңа: «интегәчәксең», дигән идегез. Күрәзәче сез, Рафаил абый. Дөрестән дә, мин үземә вакыт табалмыйча интегәм. Газета – үзе бер йөк. Подпискасы, кәгазе, хезмәт хакы, гонорары минем өстә дигәндәй. Безнең «Яшь ленинчы»да шагыйрьләр оясы, һәркайсы – сандугач.

– Ишеттем, ишеттем, редакциягә сәләтле егетләр туплагансың. Үзеңне онытуың гына начар.

– Минем рухи көчем – талантларны барлау, үсәргә булышу, Рафаил абый.

Танылган татар шагыйре – «мәхәббәт җырчысы», Туфитулловларның гаилә дусты Рәдиф Гаташ Розага багышланган шигырендә:

Күпме шагыйрьне син алып килдең,
Татар Парнасының тәхетенә, –

диячәк әле, диячәк...

## 7. «Шаһгали» дигән журнал да бастыр!»

Гомер атын сиксәнгә таба чаптырса да, һаман картаймый! Инкыйлаб чордашы... Илдәге түнтәрелеш чорында аңа бер яшь. Тверь өлкәсендә туа. Бөек Ватан сугышына кадәр Казан химия институтында укый, һәм үз белгечлеге буенча ярты сәгать тә эшләмичә, китап нәшриятына урнаша. Әдәбиятка мәхәббәте дә шуннан, нинди генә язучылар белән аралашмый ул! 1958 елда аны «Азат хатын» журналына баш мөхәррир итеп билгеләделәр. Розаны кырык эшен кырык якка ташлатып фатирына китерткән бу мөхтәрәм ханым – Асия Хәсәнова. Әнә, җиңел сөякле хуҗабикә чәй табыны көйли-көйли үткәннәрне сөйли. Роза аны җитмеш җиде тапкыр тыңларга риза, зыялы, затлы ханым үзе бер тарих.

– Кырык биштә ябылган журналны унөч ел узгач кына кабат тергезәләр. Ник шул тикле өзеклек ясалган? – аптыраш. Миңа кырык алты яшь. Төрлесе булды: көенече дә, сөенече дә. Татарның яман гадәте – кемнедер яңа урынга утыртсалар – хуплаучысы аз, кер эзләүчесе хәттин күп. Беренче саннардан ук хатын-кыз авторлар җелегемне суырды. «Журналда ир-атларны бастырмагыз!» – дип шаулаштылар. Имеш басма алар өчен генә тәгаенләнгән. Исеме үк шар яра ич! Мин дилбегәне бушаттырмыйм, йомшак әйберләрне кире борам. Янә тавыш: «Азат хатын»ның безгә мөнәсәбәте тискәре», – диләр. Әйдә, чыксын инде дип чиле-пешле шигырьләр бирдек. Бүген дә хәтеремдә:

> «Каенлыкка барсаң – исең китәр,
> Анда шундый-шундый матурлык».

Гомәр ага Бәширов оялтты мине.

– Асия, сине әдәбиятны аңлый торган кеше дип уйлый идем, мондый нәрсәләргә урын бирүең гаҗәп, – диде әдип. Язучылар җыелышында да безне нык кына «пешерделәр»: әдәбиятта җенесләр юк, исеңдә тот, Роза! Җепшек әйберләр бастырма! Әрсез талантсызлар көенә биемә!

– Моңарчы берсененең дә көенә биемәдем, Асия Фәритовна. «Яшь ленинчы»да һәр авторның язмасын энә күзеннән үткәрдем. «Ялкын»да, баш редактор чагымда да, шул гадәтемне кудым: журналга чүп-чар керттермәдек. Монда да таләп зурдан булыр.

– Роза, син – «Азат хатын»ның җиденче хуҗасы. Изге сан, бел. Венера Ихсанова ялга киткәч, өлкә комитетында синең кандидатураңны яклап, мин дә сүз кыстырдым. Туфитуллованы үзем үстердем, лаек, дидем. Балалар гәзитәсенә яшь кенә кызны алганнар дигәч, кереп караган идем сине. Наив, беркатлы, самими җан иясе хатларга күмелгән. Әле дә шундый бугай син.

– Унөч ел балалар һәм үсмерләр матбугатын җитәкләдем. Саф, чиста, хөсетсез сабыйлар дөньясында эшләвем белән бәхетле идем мин, Асия Фәритовна. Шомарган, тәти сүзләр генә сөйли, димәгез, зинһар. Хактан да шулай. Ул дөньядан аерылуы кыен. Нихәтле планнар корган идем. Рәхмәт яусын, сез Олы Мәңгәрдәге латыш балаларының язмышы турында яздырган идегез. Автордашым, латыш язучысы Андрис Спрогис белән берлектә без аны латыш теленә тәрҗемә итеп бастырмакчы идек.

– Яшьлегең-чибәрлегең бар, анысына да өлгерерсең. Безнең планнар

кемгә кызык, Роза?! Система каты бәгырьле, үтенәм, фәлән вазифага алына дими, тели икән кәнәфигә утырта, тели икән, артыңа тибә. Миннән сиңа фатиха, журналны тагын да таныт. Бу карт апа акыл сата димә, сиңа соңгы киңәшем: һәрвакыт матур киен, акча җәлләмә, отпускалардан яңа күлмәк белән чык! Син журналның йөзе, җаныкаем!

Йөзе генәме, ул аның киләчәге дә түгелме икән әле? Басма, идәне-түшәме җәелгән йорт кебек, аны сүтеп-җимереп, яңадан корып булмый. Утыз елда анда һәммәсе дә үз җае-тәртибе белән урнаштырылган, аларның кайсысын кирәксез дип чыгарып ташлыйсың ди? Әмма журнал элеккечә дә кала алмый: ул бүгенге заман сулышы белән суларга тиеш! Әнә СССР дигән мәгърур илне вак-вак кисәкләргә бүлгәләп очырырга җыенгандай, дәшһәтле давыл җилләре исә… Тиздән якынлашыр кебек ул… Моңа әзер торасы… Кем белән киңәш-табыш итәсе дип утырасы юк. «Азат хатын»да каләмле язучы-журналистлар төркеме Марат Әмирханов, Роза Камалетдинова, Альмира Әдиәтуллина, Нурсөя Шәйдуллина, Рәйсә Юсуповалар белән тарих төпкелендә яткан иң катлаулы темаларны кузгатырга була. Ләкин беренче киңәшчесе ул – үзе! Әйе үзе! «Үзем» дип Рәхмәтулла кызының масаюымы соң, ә? «Мин-минлек» тә холкындагы бер кимчелекме? Бәлки. Ходай аны да фәрештә итеп яратмаган бит. Тик шунысы бар: журналның киләчәге – чытырман, аны ера-ера кем сукмак салыр да, абынып егылса, кем кыргый җанвар кебек яраларын ялмап төзәтә-төзәтә, торып басып, юлын дәвам итәрлек көч табар? Мәгънәсез сораумы? – Мәгънәсез, әлбәттә. Мең кәррә: ул, бары тик ул үзе!

Һәм менә язмыш баш мөхәррирне шул чытырман кырыена китереп бастыра. Мәскәүдәге «Совет хатын-кызлары комитеты» елына ике мәртәбә союздаш һәм автономияле республикаларда ханым-туташлар өчен чыгарылган басмаларның баш мөхәррирләрен чакырып, укулар оештыра. Бөтен милләтләрне дә совет халкы дигән корамалы юрган астына тыгарга маташкан заманнар... Тик горур халыкка гореф-гадәтләре, йоласы, әхлагы белән сырылган үз юрганы йомшаграк та, җылырак та шул. Бигрәк тә басмаларны җитәкләгән хатын-кыз мөхәррирләргә. Берсендә Грузиядән коллегалары затлы көмеш беләзекләр алып килә. Беләзекнең исеме Тамара икән. Аның матурлыгыннан күз камаша... Тот та күргәзмәгә куй! 1166 елда туган Тамара – грузиннар алиһә дәрәҗәсенә күтәргән патшабикә. Чыгышы белән Багратионнар нәселеннән. Әтисе – Георгий III, әнисе – Бурдухан (алан патшасы Худанның кызы). Тамара утыз бер ел идарә иткән чор – алтын гасыр санала. Әй горурланып, яратып сөйли ханым. «Без, – ди, – грузин хатын-кызлары арканы бөкрәйтеп тә йөри алмыйбыз. Без Тамарабыз кебек гәүдәне төз тотып атларга тиеш», – ди. Чү, татарның да ханбикәсе бар лабаса! Ул – аклык, сафлык, тугрылык символы булып ничә гасыр халык күңеленә береккән Сөембикә! Аның турында күпме бәет, риваять, легендалар яши. Күпме бәян-романнар языла. Казанның берәр урамына ханбикә исемен кушыйк, аңа һәйкәл куйыйк, дип, коллектив исеменнән югары оешмаларга әллә ничә хат юллаганнар иде, саңгырау колаклар ишетмәде дә, ишетергә дә теләмәде. Инде Мәскәүдән чигенмәслек карар белән кайта баш мөхәррир Роза Туфитуллова: журналны «Сөембикә» дип үзгәртергә! Бу юлысы ишекләрне

катырак шакырлар. Кемнән азат соң бүген татар хатыны, йә? Көлке һәм... кызганыч. Ул нәфис куллары белән рельслар сала, төзелешләрдә цемент ташый, заводларда станок артында тимер кайрый, аның гаиләсенә, балаларына вакыты да калмый. Хәер... нишләп үзгәртергә, ди, әле! Яңадан үзенең тарихи исемен кайтарырга. Шул гына. Ә бит балачакта зур әнисе Сөембикә бәетен сөйләп елата аны, Казанны канга батырган, гүзәл ханбикәне иленнән аерып тоткын иткән Явыз Иванга нәфрәт шул чакта ук кабына бугай. Кайтарырга дигәннән, беренче курста укыганда, алар төркеме фольклордан Мөхәммәт Мәһдиевкә имтихан тапшыра. «Зәйнуллина, син билет алып торма, мин сиңа «биш»ле куям. Шуның шатлыгыннан минем йомышны үтәрсең. Менә ике папка. Берсен Бауман урамындагы Язучылар союзына – Фәрваз абыең Миңнуллинга илтәсең, икенчесенең адресын теркәдем. Анысы Болак буендагы йортта яшәгән Зәйнәп апаң Хәсәниягә. Ул кем, беләсеңме? Белмисең. Бу укымышлы, гыйлемле бай кызы Тукайның дусты була, шагыйрь иң соңгы хатын аңа яза. Йөгер, Зәйнуллина!» Йөгерә, язмышына таба йөгерә студент кыз. Әмма егерме алты елдан соң «Сөембикә» журналының титул битенә баш мөхәррир Р.Р.Туфитуллова дип язылачагын да ул әле белми... Мөгаен... могҗиза иясе шулай-шулай дип юраса – ышанмас та иде.

...Келәм урынына диварлар китап-журналлар белән «тышланган» бүлмәгә борынны кытыклап, гөбәдия исе таралган. Мөхәммәт абый үзе килер дип көткән икән хуҗабикә. Камыры кәгазь калынлыгы хәтле генә мич ашының тәмлелеге! Каптың исә авызда эри! Күрәмсең, аралашуга сусаган сөйкемле карчык, Розага фотолар күрсәтә, кызык-кызык истәлекләр сөйли. Аның ире Әхмәтгәрәй Хәсәни «Гасыр» нәшрияты хуҗасы була. 1913 елның март аенда Хәсәниләр «Аң» журналы чыгара башлый. Болар шул басмада Сөембикә манарасы турында язма бастыру белән генә чикләнмичә, манара сурәте төшерелгән открыткалар да эшләтеп, бушлай тарата. Тагын бер пар – Әсма һәм Ягъкуб Хәлили хатын-кызлар өчен журнал тергезергә хыяллана икән. Милләтпәрвәр Ягъкуб әфәнде кыю журналист, талантлы нашир, ниятләгән эшен тормышка ашырмыйча туктый торган кеше түгел. Зәйнәп белән Әсма – ахирәтләр.

– Сердәшем открытканы күрде дә иренә: «Әйдә, журналга «Сөембикә» дип кушабыз, – диде. – Зәйнәп апа тәмам хатирәләренә чума. Тыңлый-тыңлый арса да, студент Розага кызык. Мөхәммәт абый халә-бала кешеләр белән аралашмас шул. – Ягъкуб ике куллап риза! Рөхсәт алу өчен күп аяк бетерде Хәлили. Патша самодержавиесе татарның аң-белемгә тартылуын кайчан хуплаган соң? «Сөембикә»нең беренче саны чыккач, и, ул сөенүләр. Хатын-кызларыбызны кузгатып җибәрде журнал. Кайлардан гына язмадылар аңа. Безнекеләрнең гыйлемгә омтылышы көчле иде инкыйлабка кадәр үк. Аны Бакый агагыз Урманче да соңра бу хакта горурланып әйтер иде: «Күпме гыйлемле кызларыбыз Урта Азиягә китеп янды. Үзе белемгә омтылып та башка милләтләрне яктылыкка чыгару нияте белән фаҗигале язмышка дучар ителде алар», – дип сызлана да мәшһүребез. Сине ялыктырмыйм, кызым. Соңгы сүзем: журнал исеме минем өемдә туды. Анда минем дә кечкенә генә өлешем бар дип шатлансам, бер үк күпсенмә Аллаһым...

Бусага төбендә саубуллашкан кызны беләгеннән тотып туктата Зәйнәп Хәсәния:

– Кызым, «Сөембикә»безнең гомере генә кыска булды, биш елдан ябылды журнал. Совет власте да татарга якты йөз күрсәтмәде. Ягъкуб Хәлилине, асыл затыбызны нахакка гаепләп, утыз җиденче елда кулга алып, үлем җәзасына хөкем иттеләр. Тарихның ак битләре белән кара битләрен дә онытмагыз, балалар!

«Онытмагыз...» Зәйнәп апаның аманәте үтәләчәк, боерса. Тарихның бер ак битендә – ханбикә... Аны ачарга, һичшиксез ачарга! Иҗат коллективы тарафыннан хупланган идея, әлбәттә, сер булып, редакция бүлмәләрендә генә посып ятмый, унике катлы матбугат йортының унике катын да айкап, урамга ташып чыга. Гайбәт катыш имеш-мимешләр тарала. «Азат хатын»да бунт! Элеккеге атамасыннан ваз кичмәкчеләр икән. Туфитуллованың башы икеме әллә?» Монысы – бер төркем фикере. «Дөрес эшлиләр. Хуплыйбыз!» Монысы – икенче төркем фикере. Шунысы аяныч, тарихчыларның бер өлеше уңга, бер өлеше сулга тарта, бердәмлек юк. Кайберләре Сөембикәне яклап, үлгәнче сугышырга әзер, кайберләре «ул сатлыкҗан» дип, аңа пычрак атудан тарсынмый. Рәхмәтулла кызы «сугышып үләргә әзер»ләр ягында. Үзе пешергән ботканы, янса-көйсә дә, ашарга аңа. Ул чактагы матбугат министры Шамил Хамматов ипле, җайлы җитәкче, аның белән «аңлашу» кыска-кыска диалоглардан гына гыйбарәт. Бернинди өстәл сугу, китәргә гариза язгыз дип, бугаз ертып акырыну-җикеренү юк. Югыйсә таякның калын башы беренче чиратта министрга төшәчәк. Мөхәррирләрнең эшгамәлләре өчен ул җаваплы.

– Роза ханым, исем алыштырабыз, дисез. Аның вакыты җитмәгән әле.

– Ә кайчан җитә соң ул вакыт, Шамил Шәмсиевич, кайчан?! Киресенчә, без әллә кайчан соңардык инде.

– Сез үзегезне кыен хәлгә куясыз, Роза ханым.

– Мин тәвәккәлләдем, чигенмим.

– Ай-һай, Роза ханым.

– Сез борчылмагыз, Шамил Шәмсиевич, монда сезнең катнашыгыз юк, мин барысын да үз өстемә алам. Хагын да, нахагын да үзем күтәрермен.

Редакциядә урак өстемени, рәссамнар арасында тышлыкка конкурс игълан итү, язмалар барлау. Көн саен яңгыр кебек яуган хатларны уку (Алланың рәхмәте, журналга исем сайлагыз дип игълан биргәч халык куба, җитмеш процент ханым-туташлар ханбикә исемен даулый). Олпат затларның фикерен барлау, фикерләр исә тирән һәм мәгънәле. «Уйлана торгач, сүздә зурдан дәгъвалар итүче һәм шактый ямьсез, акылсыз яңгыраучы «Азат хатын»ның – сугышчан надан чорыбыз истәлегенең – үзгәртелүендә әллә ни гаҗәп нәрсә күрмәдем. Чөнки бездә, әгәр мәгънәсез ялганга, икейөзлелеккә ябышып ятмасак, хатын-кызның чын-чынлап азат булганы юк... Сөембикә исеменә тукталу исә һәрбер хатын-кызыбызның сөемле-сөюгә сәләтле, сөелүгә лаеклы яисә сөенечле булырга омтылуыннан килә.

Әллә аларның моңа хаклары юкмы?

Тормыштан – тарихка, тарихтан – сәнгатькә, сәнгатьтән исә күңелләргә

күчкән, тамырланып ныгып калган мәгънәле, серле образ, хикмәти сүз-исем ул – Сөембикә», – дияр тарих фәннәре докторы, профессор Миркасыйм Госманов. Аның фикерен куәтләгәндәй, танылган халык язучысы Гомәр Бәширов язар: «Язмыш безнең белән мәкерле уен уйнаган, авыр тормыш, дәһшәтле зилзиләләр татар халкын тузгытып, Җир шарының төрле якларына тараткан. Ләкин кайда гына яшәмик – Казан артындамы, Агыйдел буендамы, Оренбургта, Алтайда, Әстерхандамы, яисә океаннарның аргы ягындагы көнгерәләр илендәме, яки небоскрёблар чарлагындамы – Сөембикәнең мәңгелек образы һәммәбезгә дә бердәй газиз, бердәй кадерле. Киләчәктә ул безгә тагын да якынайсын, уй-фикерләребезне бергә тупларга, бердәм булырга, рухи байлыгыбызны тагын да баетып, үзебез булып калырга ярдәм итсен иде.

Балага исем кушканда догалар укып, изге теләкләр телиләр. Яңа исем журналыбызга бәхет ишекләре ачсын, киләчәген якты, куанычлы, игелекле итсен».

Роза ишетеп белә, туксан яшенә якынлашса да, картаерга ашыкмаган төз гәүдәле, аек акыллы Гомәр агада бер җирдә дә кабатланмаган «Сөембикә» бәете саклана икән. Телефоннан гына хәл итәрдәй түгел, ул әдипне Язучылар Союзы коридорында очратып:

– Гомәр абый, сездә гаҗәеп хәзинә бар, диләр, – дип, ерактанрак уратып сүз башлагач, әдип елмаеп:

– Кайсы әсәремне хәзинә дип саныйлар икән? – ди.

– Бөтенесен дә, Гомәр абый. Сез укучыларның иң яратып укылган язучысы бит.

– Рәхмәт, рәхмәт, Роза ханым. Сезнең табышыгыз да сөендерде: газиз ханбикәбезнең исеме белән журналны атыйсыз. Мин дә теләкләремне хат белән юллаган идем.

– Без аны беренче санга билгеләдек. Мин сезнең архивыгыздагы «Сөембикә» бәете турында сорашмакчы идем, Гомәр абый.

Таякка таянган әдип диварга сөялгәч, баш мөхәррирнең йөрәгенә гүя учак җылысы үрли. Юк, дими, тәфсилләп сөйләргә җыена! Димәк, әдипнең күңел күленә кармак салынды! Алтын балык ни ул, бер карчыкның өч кенә теләген үти, ә монда миллионлаган халыкка барып ирешәчәк алтын тауларына биргесез хәзинә!

– Мин аны иске кулъязмаларым эченнән таптым. Унөч яшьлек мәдрәсә шәкерте чагымда каяндыр күчереп язганмын. Ханбикә турында бәетләр берничә, бусы үзгәрәк, эчтәлеге баерак. Бу нөсхәдә ханбикәнең фаҗигасе тирәнрәк сурәтләнә, укыйсыгыз килсә, рәхим итегез, Роза ханым.

– Гомәр абый, әйдәгез, без аны яңа санызда бастырыйк!

Йөрәккә үрләгән учак җылысы суынгандай тоела, чөнки язучы җитдиләнеп тамак кырып куя. Риза түгел! Чү, әдип кинәт бөтен йөзе белән балкып:

– Ул халыкныкы, халыкка кайтсын, – ди. – Берничә җөмлә дә өстәп, мин аны сезнең җылы кулларыгызга тапшырырмын, Роза ханым.

Вәгъдәсен үти Гомәр ага. Шактый гына күләмле кереш өлешен: «Журнал үзенә Сөембикә исемен алган көннәрдә «хуҗабикә»гә аның үзенә багышланган яңа бер вариантын бүләк итә алуымны үзем өчен зур бәхет

саныйм. Бу хезмәтем өчен гонорарны Балалар фондына тапшырам», – дип тәмамлый.

Тәкъдирдән бәндә узмый, бер Хода түзгәнгә –
Әҗерен Хода биргүче казага түзгәнгә.
Мең биш йөз унбиштә бу дөньяга килгәнмен,
Ата-ана дәүләтен китмәс диеп белгәнмен.
Ата-ана кулында бер кайгы да күрмәдем,
Бу кайгылар күрермен дип исәпләп тә йөрмәдем.
Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем яшь дәүләтем,
Сабый чагым, нурлы йөзем, морза кызы булган вакытым?..

...Иртән, балалар мәктәпкә, алар эшкә җыенганда сизгер ире Розаның кызарган күзен күреп:

– Төне буе нәрсәдер укып утырдың, тагын кем елатты икән сине? Нинди ярдәм кирәк? – ди. «Летучкалар» Туфитулловлар өендә дә булгалый. Ләкин анда иҗат мәсьәләләре түгел, анда Рәхмәтулла кызы җитәкләгән басмаларның матди ягы карала. Дәүләт финансласа да, ямыйсы тишек-тошыклар гел чыгып тора. Кемгәдер ярдәм итегез дип кул сузып барасы юк, иганәче өйдә. Роза аны шаяртып «Туфитуллов фонды» дип атый.

– Бүген аңа дога гына кирәк шул, Миргалим. Менә без журналны «Сөембикә» исеме белән атарга җыенабыз. Син ул турыда иң беренче ишеткән кеше. Ханбикәгә багышланган әллә ничә бәет укыганым бар, әмма Гомәр ага Бәшировның безгә китергән нөсхәсе иң көчлесе.

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем хан дәүләтем,
Хансарайда торган идек, бүген булдык әсир ятим.

Роза йөз дә беренче мәртәбә үзен ханбикә урынына куеп карый. Ул гынамы, эчендә җаны булган меңәрләгән татар хатыны Сөембикәгә илбасарлар кигезгән кара күлмәкне киеп сызланадыр. Редакциягә килгән хатлар шул хакта сөйли түгелмени?!

Иҗат төркеме нәкъ кырмыска оясы: синеке-минеке юк, бөтенесе дә яңа исем белән дөньяга туачак беренче сан тирәсендә мәш килә. Типография кәгазенә кытлык чор. Рәхмәт яугыры, газета-журнал нәшрияты директоры Дилбәр Хәйруллина әҗәтне соңрак түләү шарты белән тиз арада анысын да табыша. Бәясе кыйммәт матрица ясалган, тиражны бастыру көйләнгән. Инде «уф» дип тын алган көннәрдә генә янә министр шалтырата.

– Роза Рәхмәтулловна, иртәгә сезне Кремльгә чакыралар. Аңлыйсыздыр. Журналның исемен үзгәртү буенча. Ситуация төрлечә булырга мөмкин, әзерләнегез!

Баш мөхәррир әзер. Хан заманы калдыгы дип, аңа мөһер сугучыларга катгый сүзе дә әзер: «Сөембикә» исемле тарихи журнал кабат тергезеләчәк!»

Ул вакыттагы ТАССР Югары Советы Рәисе Минтимер Шәрип улы Шәймиев кабинетында да кайнар пар бөркелә. Илбашына әләкче-шымчылар, кайбер надан галим кисәкләре күпертеп-кабартып, ханбикәне иң кара буяулар белән буяп, әләк ташыган инде. «Биш йөз ел элек булган хәлләрне кузгатып, бер бунтарь хатын берничә сәясәт белән бәйләнмәгән

«Азат хатын»ның исемен үзгәртмәкче! Халык үтенече имеш! Зыялылар – язучылар, рәссамнар, артистлар теләктәш, имеш». Рәис ачулы. Аның да хәлен аңлый Роза: туксанынчы ел – Минтимер Шәрип улы өчен катлаулы ел. Татарстан суверен республика дип игълан ителде. Алда Союз Шартнамәсенә кул куясы, Мәскәү тарафыннан савым сыерына әйләндерелгән татар ватанын талауны туктатасы… Мәйданнар үзенә кызган табаны хәтерләтә әнә. Милләт телендә: «Азатлык, азатлык». Карагруһлар да кузгалган, алар татарны һаман кол итмәкче, астан да, өстән дә мәкерле эш йөртә. Боларга каршы торыр өчен генә дә илбашына чыдамлык һәм түземлек кирәк. (Әлбәттә, зирәк, акыллы Минтимер Шәймиев төрле провокацияләргә бирешмәячәк.)

Илбашы белән очрашу күңелсез тәмамлана. Аның фатихасын алалмый баш мөхәррир дип кенә әйтсәк, Роза ханымның хәлләрен шактый йомшартыр идек. Урамга чыга, янында кем уза – күрми. Гүя тирә-якны куе томан сарган. Елга булып, күзеннән яшь ага... Шунда кемдер аны беләгеннән тотып ала. Галим Миркасыйм Госманов! Ул:

– Нишләп йөрисез, Роза ханым? – дигәч, Рәхмәтулла кызы күз яше аша елмаерга тырышып:

– Биш йөз еллыкны хәл итәм. Ну, Минтимер Шәймиев миңа шәп аңлатты. «Журналны «Сөембикә» дип атарга уйлаганда нәрсәгә таяндыгыз, тарихчыларның бу шәхескә карата төгәл генә фикере юк бит», – диде. Без бит инде бөтен нәрсәгә заказ биргән идек, Миркасыйм абый.

Галим ипләп кенә аны култыклый да:

– Әйдәле, – ди. – Минем дә Минтимер Шәймиевкә килешем. Икәү керәбез. Тарихчы буларак мин аңа сүземне җиткерермен. Син елый-елый шешенгәнсең, бар, башта юынып чык. Көтәм!

Миркасыйм абый бакча баласы кебек җитәкләп, аны рәис кабинетына әйдәкли. Билгеле инде, илбашы: «Моңа тагын ни кирәк икән?» – дигәндәй, аңа гаҗәпләнеп карагач:

– Мин бу ханымны әле яңа гына чыгарып җибәргән идем, – ди.

Баш мөхәррирнең яклаучысы янәшә генә! Егылып калганчы, атып кал, диләр.

– Минтимер Шәрипович, Миркасыйм абый мине тыңлады да, тагын сезнең белән сөйләшеп карарга булдык.

И китә аягүрә баскан галим кызып, и китә! Йөрәге белән актара тарих катламнарын, актара! Булачак президент инде аны туктата алмый.

– Миркасыйм, утыр, Миркасыйм утыр, – ди. – Син безнең горурланырлык кызыбыз дигән бу кеше менә бит ниләр эшли. Башбаштаклык дими, ни дисең моны? Шамил белән килештергән идегезме, Роза Рәхмәтулловна?

Ничек министрга тел-теш тидертәсең?!

– Берничә мәртәбә бардым, вакыты тар иде, юл өсте генә әйткән идем, мөгаен, төшенмәгәндер дә.

Аңа коридорда утырып торырга кушыла, ә аяк атламый. Коточкыч стресс! Күренекле сәясәтче Фәндәс Сафиуллинның да Рәис янына килеп ятышы. Ирләр икәүләшеп, Роза ханымны кәнәфигә утыртып калдыра. Илбашы кабинетында кырык минут тора алар. Ул минутлар кырык ел кебек тоела. Билгеле, мөхтәрәм затларның илбашы белән хәл итәсе бүтән

проблемалары да бар, тик Сөембикә дип көн-төн сулкылдаган йөрәккә син шуны аңлатып кара! Аңа инде бәлки кан саугандыр, тизрәк чыксагыз иде, бәгырькәйләрем! Яхшы хәбәр белән куандырсагыз иде!

Чыгалар. Йөзләрендә елмаю... Миркасыйм абый Тукай сүзләрен үзгәртеп:

– Тор, мөхәррир, тор,
Алдыбызда бит Сөембикә! –

дип, агарынып кәнәфигә сеңгән Роза ханымны урыныннан кузгата.

– Да-а, – дип суза Фәндәс абый. – Ирләр белән бер дәрәҗәдә көрәшкән шушы батыр кызларыбыз яшәтә дә инде безнең милләтне. Роза, илбашыннан сиңа фәрман. Тиз генә телевидениедә опрос уздырып, халыкның фикерен сорасыннар, диде. Синең фараз: журналның исемен үзгәртү йөз процент хупланачакмы?

– Каршылар да бар, Фәндәс абый. Ләкин күпчелек хуплый.

– Сез җиңәсез, Роза ханым! – Миркасыйм Госманов аның кулын кыса. – Нык булыгыз, бирешмәгез! Ярдәм кирәксә, читенсенмәгез. Хәбәр итегез!

Соңгы очыш, соңгы! Канатлар гына талмасын! Ә бит күңелне бер уй тырнап уза. Китәргә! Әнә Милли китапханә директоры Разил Вәлиев аңа эш тә тапкан! Аһ, бу шайтан! Җилкәңә төшкән авыр йөктән котыласың дип котырта лабаса. Юк, яралы канатын бәйләп, ул тагын талпыныр, тагын талпыныр… Бүгенге вазгыятьтә үрнәк алырдай милли көрәшчеләр – егетләр-кызлар азмыни?! Җир дөрләп янардай эссе айларда Ирек мәйданында әнә язучылар-шагыйрьләр Фәүзия Бәйрәмова, Газинур Морат, Зәки Зәйнуллин, Рәшит Әхмәтҗановлар ачлык игълан итте. Аларга җиңел идеме, йә?

Менә ул хәлиткеч минутлар: телевизорда тамашачы белән турыдан-туры элемтә. Тапшыруны язучы, юмор остасы Камил Кәримов алып бара. Студиягә ул хатлар белән шыплап тулган ике капчык сөйрәп чыгара. Телефоннар туктаусыз шалтырый, телләрдә йөзләгән тапкыр Сөембикә исеме кабатлана, мөгаен ханбикәне халык хәтереннән сызарга маташкан хәсрәт әләкчеләр бу тапшыруны карап, үрле-кырлы сикергәндер. Журналның иҗат төркеме әзер санны яңадан үзгәртергә тотына. Олпат затларның фикеренә яңалары өстәлә. Тарих фәннәре кандидаты Равил Әмирхан: «Төкле аягың белән! – ди. – Икенче биләүдән төшеп, җиһанга яңа сыйфатта тәпи баскан журналыбыз, данлы исеменә лаек-муафыйк булып, халкыбыз өчен Сөембикәгә тиң гүзәл һәм каһарман хатын-кызлар тәрбияләүдә үзеннән өлеш кертсен иде».

«Сөембикә» симфониясен язган композитор София Әсгать кызы Гобәйдуллина телеграммасында: «Мин Сөембикәнең яңадан тууына шат, аның киләчәк юлыбызга нур сибүен теләр идем», – дигән. (Әсгать абзый вафат булгач, аның марҗа хатыны Розага ярдәм сорап шалтырата. Редакция коллективы җыелып, мәрхүмне «мәңгелек йорты»на озата.)

Минтимер Шәймиев үзенең котлавында моннан утыз ике ел элек ябылып, яңадан терелгән «Сөембикә»не «тынычлык, иминлек юлдашы» дип атый. «Журналның яңа исеменә килгәндә, дөресен әйтергә кирәк, ул

минем өчен көтелмәгәнрәк булды. Күрәсең, журнал редакциясе бу исемне сайлап, гомумкешелек кыйммәтләрен барлауны, кире кайтаруны күздә тотадыр», – ди ул.

Ә Уфадан аксакал шагыйрь Сәйфи Кудаш конверт эченә хат белән тылсымлы орлыклар сала.

«Роза җан! Тәвәккәллелегез алдында баш иям. Ни генә димәсеннәр, бүгенге татарның язмышы хатын-кызлар кулында. Юкка гына бөек Дәрдемәндебез «Сөт калыр, ватан китәр» димәгән бит. Барыгызга да зур иҗади уңышлар теләп калам. Сезгә бүләк итеп, безнең гаиләдә мин белә белгәннән бирле үсеп, тамырланып, чәчәк атып утыручы «Мәрьям ана» гөленең орлыкларын җибәрәм. Нишләргә икәнен үзегез чамаларсыз. Аны сезгә, Казанга баргач, кызым Сөембикә кертеп чыгар».

Мөхәрриргә беренче иң кадерле бүләк!

Хакыйкатькә ирештек, (Алланың рәхмәтләре яусын, Дилбәр Талип кызы элек эшләнгән матрица, буяулар яраксызга калгач әҗәтне түләттерми. «Сөембикә рухына сәдака дип санагыз», – ди.) инде тыныч күңел белән эшлик диясе дә… Тик кара эчле көнче бәндәләр һаман Рәхмәтулла кызының җанын тындырмый. Татарстанда шактый билгеле бер иҗат кешесе: «Сөембикә» белән рәттән «Шаһгали» дигән журнал да бастыр» дип үртәсә, «Вечерняя Казань» газетасы үз быгырдыгына үзе батып: «Азат хатын» тулысы белән азатлык алды. Моннан соң ул күбрәк фахишәләргә урын бирәчәк» дип язгач, бер көтү хезмәткәрләрен иярткән Роза таш-тау актарырлык ярсу көч белән аның хуҗасы Хасбулатовның кабинетына килеп керә. Каушап китә редактор әфәнде. Үзе дә килеш-килбәте, сабырлыгы, мөлаемлеге белән хан кызына охшаган, һичкайчан тавыш күтәреп, югары тонда сөйләшмәгән коллегасы, итагатьле ханым нишләп буран дулата?

– Хасбулатов, син бит татар баласы! Синең тамырларыңда татар каны ага! Ни оятың белән син милли басмага пычрак атасың! Судка эшне җиткертмә, таләп итәм: гафу үтенеп, газетаңда бастыр. (Ул таләп итәм дигән катгый сүз әле алдагы елларда күп әйтелер.)

Бастыра «татар баласы», бастырмый хәле юк.

«Мин» дип җитәкчеләр янында этелеп-төртелеп йөрмәгән Роза Туфитуллованы Ходай кабат Минтимер Шәрипович белән күзгә-күз очраштыра. «Сөембикә»нең җитмеш еллык юбилее уңаеннан Роза ханым әллә ниләр өметләнмичә генә Президент аппаратының матбугат үзәге җитәкчесе Әнәс Хәсәновтан безнекеләргә берәр исем-фәлән биреп булмасмы дип үтенә. Илбашы үзем «Сөембикә»гә киләм дигән. Кунак көткәндә, татар өендә идән-сәке юыла, мамык мендәрләр кабартыла, дигәндәй, «ханбикә йорты»нда да бүлмәләр ремонтлана, яңа җиһазлар кайтартыла. Ялт итә редакция! Киң күңелле баш мөхәррир газет-журналлардан коллегаларын чакыра. Матбугат өлкәсендә уртак проблемалар шактый, җайлы вакыт, гозер-үтенечләрен әйтеп калсыннар. Гаҗәеп хәтерле Президент һәрберсен тыңлый, үзен бик гади тота. Ул кыядагы бөркет кебек, каршында йөзләгән кеше басып торсын. Һәммәсе аның карашына сыя.

Роза ханым күршедә «Чаян» журналында хезмәт куйган дусты Зөлфәтне ничек «кода»сы белән күрештермәсен инде. Илбашы хезмәт юлын Мөслимдә шагыйрьнең туган ягында башлый лабаса. Зөлфәт кайчакта

Минтимер Шәрипович безгә кода тиешле, без туганнар дип әйткәли, алдашмый, аның ихласлыгына тамчы да шикләнми Роза. Әнә бит күреним дип, коридорга атылып чыкмый, тыныч кына бүлмәсендә утыра.

– Нәрсә инде бу? – ди Президент, аның аварга торган артсыз урындыгына төртеп. – Син зур шагыйрь ләбаса!

Ишегалдына кадәр озатканда, Минтимер Шәрипович Розага:

– Теге чакта мин бик үк хаклы булып җитмәгәнмен. Сөембикә исеме халык күңеленә бик тирән уелган икән, – ди. Әлбәттә, бу табышмак сүзләрнең ни-нәрсә аңлатканын тирә-яктагылар төшенми, аның «эчтәлеге»н Рәхмәтулла кызы үзе генә белә. Аяксызланган ул көннәр турында берәүгә дә чишелмәде бит ул. Ике шаһит – Миркасыйм абый белән Фәндәс абый да аны җилгә сипмәде, көлке ясап сөйләп тә йөрмәде. Әйдә, Туфитуллова җиңел генә тауга менде дисеннәр!

– Кайсыгызның кулы җылы
Бәйлисе бар йөрәкне, –

ди якташы Хәсән ага Туфан. Ә чынлыкта бит шагыйрь: кайсыгызның кулы ЧИСТА дигән әүвәл. Редакторлар төзәтте микәнни? Соңгысы дөресрәктер, мөгаен. Йөрәк ярасына шакшы кул белән кагылсаң, йогышлы чир йогарга мөмкин бит. Аның да йөрәген телгәләп тәм табучылар бар. Янәсе, ул тиражны киметте! Утыз җиденче еллар булса, халык дошманы дип сөргенгә сөрерләр, билләһи! Хак. СССР вакытында журналның абунәчеләр саны дүрт йөз меңнән арта. Илнең бөтен өлкәләреннән язылалар аңа. Ә Советлар Союзы таркалгач, республикаларда «Сөембикә»гә подписка туктатыла. Үзбәкстаннан гына да туксан мең укучысын югалта алар. Бер «Сөембикә»нең генәме, бөтен татар басмаларының тиражы упкынга тәгәри.

…Президент хушлашканда, Роза белән нәшрият директоры Дилбәр ханымның аркасыннан кагып:

– Кызлар, кулымда кәнфитем генә дә юк. Икегез дә тырышып эшлисез, рәхмәт үзегезгә, – дияр.

«Сөембикә» Россия белән генә чикләнми, ул Җир шарына сибелгән татар хатын-кызларының җан дустына әверелә. Чикләр ачылып, ата-бабаларның изге туфрагына аяк басарга мөмкинлек тугач та, журналның чит илләрдәге милләттәшләр белән бәйләнеше нык көчәя, гүя гасыр башында мәгърифәтме яки матбугат һәм әдәбият өлкәсендәме тирән эз калдырган – Маһруй Мозаффария, Мәхүпҗамал Акчурина, Заһидә Бурнашева, Фәрхелбанат Сөләйманияләрнең дәвамы, замананың үз ханым-туташлары пәйда була. Яңа исемнәр, яңа фикерләр, яңа идеяләр… Милләттәш туташ-ханымнар инде Венера апа Ихсанова баш мөхәррир чагында ук «Азат хатын» белән элемтәдә. Германиядән Фәридә Хәмит, Австралиядән Ләйлә Садри, Мөшәрәф Вәли, Америкадан Шәмсия Апакай, Финляндиядән Фәридә Низаметдин, Төркиядән Гөлтән Ураллы, Гөнүл Пултарлар белән якыннан аралашулар... Алар белән бергә кайчандыр иленнән куылган, кыерсытылган-җәберләнгән, чит-ят мәмләкәтләрдә гомер чигәргә мәҗбүр ителгән татар язмышлары, татар күз яшьләре, татар сагыш-сагынулары

кайта… «Сөембикә»нең ишеге һәрвакыт ачык, баш мөхәррир кабинетында самавыр кайнап тора…

Ә халык белән очрашулар? Төмән, Себер, Сургут сөембикәлеләргә килегез дип, чакыру арты чакыру җибәргәндә, ничек машинаңа журналларыңны төяп, юлга кузгалмыйсың! Рәсәйнең Роза Рәхмәтулла кызы булмаган төбәге… шул аюлар оясы тайга белән кыргый утрау гына калгандыр, мөгаен. Ул бит очрашуларда үзенең иҗаты турында кәлимә әйтә алмый, чөнки каләм бер читтә сыкрап ята… аңа кул тими, кул тияр өчен вакыт кирәк, ә Розаның йокы сәгатьләре дә кып-кыска, иртән эшкә чапса, кич өйгә ашыгу юк, караңгыга хәтле утырыла. Кызы Гөлназ шаяртып: «Әни, син өйгә кайтып торма инде, редакциядә генә йокла», – ди әнә. Әле җәмгыятьнең каймагы галим-голәмә, язучылар каршында да исәп-хисап бирәсе. «Нихәлләрдә ул «Сөембикә», бүген ниләр майтара?! – «Хәтер көне»нә багышланган конференциядә Роза Туфитуллова программага кертелгәч, зал тулы зыялылар аның чыгышын хәйран калып тыңлый. Язманың урта бер өлешен бүлеп, кадерле укучым, сиңа да ишеттерик әле.

«…1991 елның башында «Сөембикә» журналының яңа дәвере башланды. Бу изге исемне яңадан кайтарып, без үзебезгә тагы да зуррак вазифалар йөкләдек. Журналның концепциясе яңартылды. Ул үз үсешендә яңа баскычка күтәрелде. Соңгы ике-өч елда журналыбыз татар милләтен, татар милли гаиләсен саклау, аның генофондын ныгыту юнәлешендә эзлекле һәм җитди эш алып бара башлады. Аны даими укып-күзәтеп баручылар «Сөембикә»нең бөтен дөнья татар хатын-кызларын сәяси активлыкка әйдәүче мөнбәргә әверелеп баруын да кире кага алмаслар. Әгәр гасыр башы «Сөембикә»се татар хатын-кызлары өчен мәгърифәтчелек оранчысы булса, гасыр азагы – 90 еллар «Сөембикә»се армый-талмый хатын-кыз, ана һәм бала хокукларын яклаучы басмага әверелде. Ул татар иҗтимагый үсешенең хатын-кыз фикеренә нигезләнүе, хатын-кыз фикеренә колак салуы өчен тырыша. Җәмгыятебезнең гаилә кебек пар канатлы булуын тели. Дөрес, журналның бу юнәлештәге эшен күреп, күтәреп алырга торучылар аз. Моңа гаҗәпләнеп тә булмый. Чөнки XX гасыр тәмамланып килгәндә дә, хатын-кызның фикерен санга сукмау, аның нечкә дипломатиягә ия булган акыл сәләтен танымау гадәти хәл булып санала. Иҗтимагый аң, фикер үсеше бары тик ир-ат фикерләвенә генә корыла. Дөньяның акыл ияләре җәмгыятебезнең соң дәрәҗәдә рәхимсезләнүен, агрессив төс алуын, мәрхәмәтсез була баруын шуннан күрәләр. Әйе, исемсез җәмгыятебез бер канатта гына очарга талпынган кош хәлендә. Аңа бүген шәфкатьлелек, рухи бөтенлек, зирәклек җитми. Бүген тарих сабакларын хәтеребезгә төшергәндә, безгә бу хакта уйланырга кирәк иде. Ә бит тарихка күз салсак, кешелек җәмгыятенең үсешен алга этәрүдә кешелекнең гүзәл яртысы тик ятмаган, үз өлешен керткән. Бу бигрәк тә дәүләт белән идарә итүче хатын-кызларга карый. Мәсәлән, Англия королевасы Елизавета I коточкыч каршылыкларга карамастан, үз дәүләтен көчле диңгез державасына әйләндерә алган. Ә королева Виктория исеме белән Бөекбританиянең тулы бер эпохасы башланып китә. Әби патша Екатерина II нең дә Россияне нинди зур үрләргә күтәрүе һәркайсыбызга мәгълүм. XVI йөз башында бүлгәләнеп, таркалып беткән Испанияне берләштерү бары тик королева

Кастилия Изабелла I нең генә кулыннан килә. Алай гына да түгел, ул Христофор Колумбны дөньякүләм сәяхәткә рухландырып, аңа һәртөрле ярдәм күрсәтеп, Американы ачуда турыдан-туры катнаша.

Иң катлаулы чорларда – урта гасырларда дәүләт белән идарә итүче хатын-кызлар мөселман дәүләтләрендә дә булган. Аларның саны 20ләп исәпләнә. Алар арасында иң күренеклеләре Дәһли төрки мөселман дәүләтенең Солтаны Разыя хатын (1235–1240). Мисырда мәмлүкләр бәхритләр династиясенә нигез салган Мисыр Солтаны Шәдҗәрәт ад-Дур, Иранның көньягына урнашкан Котлогхан дәүләтенең патшабикәсе Түркән-хатын, Атабикләр дәүләтенең Солтаны Абиш-хатын, Ирандагы монгол ханнары династиясен дәвам итүче Солтан Сәтбик һәм, әлбәттә инде, безнең Сөембикә-ханбикәбез. Мөселман дөньясындагы хатын-кыз дәүләт башлыкларының эшчәнлеген өйрәнүче төрек галимәсе, тарихчы Бәхрия Үчүк әлеге хатын-кыз идарәчеләр арасында өч хатын-кызның эшчәнлегенә аеруча югары бәя бирә. Мисыр Солтаны Шәдҗәрәт ад-Дур, Казан ханбикәсе Сөембикә һәм Иранның төньягындагы Атабикләр дәүләте солтаны Абиш хатын. Аларның өчесенең дә язмышы фаҗигале тәмамлана. Әмма Сөембикә ханбикә язмышына уралган фаҗигаләр ачылыгы белән алардан аерылып тора. Бу яктан аны бары тик үзе белән бер чорда, бер елларда идарә иткән Шотландия королевасы Мария Стюарт белән генә тиңләп буладыр. Журнал менә алты ел дәвамында күңелләрдә тирән тетрәнү уяткан Сөембикә-ханбикә язмышына карата үз укучысында кызыксыну, һәм горурлык хисләре уятырга тырышып яши. Дәверләрдән-дәверләргә, легендалардан-легендаларга күчә-күчә безнең көннәргә килеп җиткән бу иманлы җан туачак буыннарның да акылын яулар, аларны да сокландырыр дигән изге уйлар белән эшли ул аны. Алда әйтеп узганымча, Сөембикә исемен кайтарып, без үзебезгә күп төрле вазифалар арттырдык. Яңа исем белән чыга башлаган елларда журналга эреле-ваклы кооперативлар, аракы сатучы киосклар, парикмахерскаялар, кибет, кафелар белән дә көрәшергә туры килде. Алар ике дә уйлап тормастан, үзләренең ширкәтләренә «Сөембикә» исемен куша башладылар. Шөкер, шәһәр идарәсе безнең протест язуларыбызны игътибарсыз калдырмады, Сөембикә исемен ваклауларга чик куелды шикелле».

## 8. «Галәмәт, барыгыз да зәңгәр күзле...»

– Син үзеңдәме? Төштән соң сугылам.

– Ярар, кил.

Телефоннан гына хәл-әхвәл сорашмады. Килгәч сөйләшерләр. Әле Розаның өстәлендә өем-өем хатлар. Ул шуларга чумган. «Азат хатын» чагында ук журнал хатын-кызның киңәшчесе, күңелен бушатырдай басмасы була. Ә инде «Сөембикә» дип үзгәртелгәч, аларга ханбикә үзе редакциядәге тәхетендә утырадыр кебек кабул ителәме икән әллә, көненә унар кешенең баш мөхәрриргә йомышы төшә. Берсен дә кире бормый ул. Хатларда да күбрәк үтенеч-гозерләр. Менә Буа балалар йортыннан тәрбияче яза: «Роза апа, исәнмесез?! Сезнең журналны көтеп алам. Бәлки безнең интернат турында да берәр әйбер яздыртырсыз әле. Бездәниләр дисәгез,

төрлечә, Роза апа. Ятимнәрне кызгандырып, нужа бабай елата да, җырлата да. Быел дүрт кызыбыз унынчыны бетерә. Чыгарылыш кичәсенә матур күлмәк тектерәсе иде дип хыяллана, җанкисәкләрем. Матди яктан авыррак бездә. Ни булганын киярсез инде, кызкайларым дим».

Әйе, ул да бер тапкыр үлеп хыялланган иде. Кибеттәге ташкурчак әле дә төшкә керә. Тормышка ашмаган балачак хыялы гомер буе бер әрнү булып озатып бара икән.

Баш мөхәррир гамәли хезмәткәр Альмира Әдиәтуллина бүлмәсенә керә.

– Альмира апа, син – мәрхәмәтлелек үрнәге. Мә, Буа балалар йортына почтадан акча сал әле. «Сөембикә»леләр исеменнән. Менә шушы хаттагы дүрт кызга затлы тукымадан күлмәк тектертсеннәр.

– Абау, бала (бала – Альмира апаның яраткан сүзе), ярдәм синең кесәдән генә буламыни?

– Альмира апа, зинһар моны берсенә дә белгертмә. Син үзең дә мәктәпләргә барсак, сумкаңа тутырган кәнфитләрне өләшәсең. Безне әни: «Юмартның күләгәсе киң», – дип үстерде. Изгелек җирдә ятмый, унга тапкырланып, кире үзеңә кайта. Ярый, миңа кунак киләсе иде.

Андый-мондый гына кунак түгел инде ул: авылдашы Газиз Кашапов-Үзиле, танылган язучы, «Сәмум җиле», «Солдат иртә ир була» повестьлары, Хәсән Туфан турындагы «Киек каз юлы» романы авторы. Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Фәнис Яруллин, Тәүфикъ Әйди кебек әдипләребез аның иҗатын зурдан бәяли. Газиз абый белән теләсә кем дуслашмас, Туфан Миңнуллин белән генә ничектер җеннәре килешә. Дуслар Хәсән Туфан сөргендә яшәгән Лысва бистәсендә дә аглый белән таглый кебек бергә йөреп кайталар. Бер үк чишмә сулары эчкән, бер үк болында тәгәрәшеп уйнаган, бер үк һава сулаган авылдаш соңгы вакытта аны өнәмәгән төслерәк. Әллә ялгышамы Роза? Бер казанга ике тәкә башы сыймый, диләр, ә авыл Казан түгел, аның күңеле иркен. Икесе дә сыя. Рәхмәтулла кызы Газиз абыйсы үрләгән биеклеккә дә дәгъва кылмый, аның өчен дан-шөһрәт, мактату-макталу һич кирәксез нәрсә. Ул бары тик гади журналист һәм гади баш мөхәррир. Якташ, аны үзенчә хөрмәт тә итә бугай: «Мин бердәнбер Фигаль апа кызы Розаның гына тәнкыйтен кабул итәм», – дигән бит әнә. Армиядән хатларын да яраткан укытучысына гына яза бит ул. Үпкәләр дими, Роза аңа турысын әйтә. Берсендә Чаллыда өстенә сырган бишмәт, аягына резин итек киеп, ләмдә бата-чума КамАЗ төзегән шәһәр партия комитетының беренче секретаре Рәис Беляев белән әләгешә бу. Икесе дә Аксубай егете, икесенә дә әйдаман сыйфаты хас. Артларыннан теләсә кемне ияртерлекләре бар. Кашапов – өлкә газетасының үз хәбәрчесе. Күрәсең, шәһәрдәге хәлләрне бизәми-чукламый турысын яза. Ул елларда яңа кала, яшь кала белән машина заводын төзергә илнең төрле почмакларыннан төрледән-төрле милләт балалары җыела. Халыкның бер төренә ул ошамый. Татар җиренә җыен әтрәк-әләм җыела, алар безнең гореф-гадәтләрне, туган телебезне санга сукмый, диләр. Ә кемнәрдер: «Ура!» Тарихта калырлык бөек төзелеш безнең җиребездә башлана», – дип кул чаба. Тирә-яктагы авылларның бетүе, аймакның чит-ятлар белән чуарлануы язучыларның эчен пошыргандыр, мөгаен. Ни булса да шул була, ике арыслан – Беляев белән Кашапов бәрелешә. Әлеге бәрелешнең «җиле» тәрәзә пыяласын

зыңгылдатып, Роза ханым бүлмәсендә и исә, и исә. Ул башта бүлдермичә сабыр гына тыңлый, әйдә, эчендәгесен тамчысына кадәр түксен Газизҗан! Ләкин язучы абыйсының ярсуын бастырмасаң, «җил» тәрәзәне ватачак... Рәхмәтулла кызы да һөҗүмгә күчә:

– Туктале, тукта, ник миңа Рәис Беляевны тиргисең? Мин кем әле аңа?! Менә син үзең дә, беребез белән дә килештермичә, фамилияңә Үзиле тәхәллүсе өстәдең әле!

Сыздырып, гармунда татар көйләрен уйнап җырлаган партия җитәкчесе Рәис белән әдәбиятка багынган язучы Газиз – ике риясыз, беркатлы җан, нишләп дошманлашсын ди, аннары очрашканда кочаклап күрешә егетләр.

Унынчы сыйныфны тәмамлагач, вузга керергә ашыкмый Газиз Кашапов. Ятимлек! Әби карчыкның тиен пенсиясен әллә ашарга тот, әллә кием бөтәйт?

– Кызым, Газиз абыеңны колхозда бухгалтер ярдәмчесе итеп куймакчылар, ди. Башлы малай, саннарда ялгышмас та. Жәл, югары уку йортына бармый, бик жәл. – Розаның әнисе яраткан укучысы Казан университетында укырга тиеш дип саный. – Син быел җиденче класста... Газиз анда өч ел укыгач син дә барыр идең. Бер-берегезгә терәк дигәндәй...

Дәрес әзерләгән Роза китабын битенә каплап көлә:

– Бөтен авыл кызларын Тукай шигырен ятлаттырып бетерә икән!

Кәнсәләрдә буш һәм кызыксыз саннар ялыктыргач, тракторда җир сөрә, анда да сөрәсен сөреп, күңелен бастыргач, Маһруй оныгы клуб мөдире булып эшли. Иҗат кешесе өчен иң рәхәт урын! Җырлат, биет, әдәби кичәләр оештыр! Бер күзле шайтан – телевизор сирәк йортта, халык һәр чарага ургылып йөри. Беркөнне Үзигә атаклы җырчы Рәшит Ваһапов концерты билгеләнә, Газиз алдан ук хәстәрен күргән: авылның аш-суга оста Закирә апа белән сөйләшкән, артистны ашату ягын да, кундыру мәсьәләсен дә җайлаган. Аһ, син, йөремсәк хатын! Имеш кәнсирт кичкә генә, анда хәтле ул күрше авылдагы туганнарына барып кайта! Юлдан соң юынып, ял итеп алам дип уйлаган Рәшит абый клуб янында көтеп утыра икән дә, юк йомышын бар итеп клубка әле берсе, әле икенчесе килә, һәм җырчы ачуын онытып (тәки фатирга урнашалмый!) аларны күзәтә. Шаккатырсың: барысы да зәңгәр күзле! Ул клуб мөдиренә карый: табигать монысының да битенә, аяз күк йөзеннән китеп, ике зәңгәр төймә уйган!

– Энем, галәмәт, барыгыз да зәңгәр күзле, – ди Рәшит абый. – Кич, билет тикшергәндә ишек төбенә басып, кергән берсен санап тор әле. Ничәү булырсыз икән?

Саный Газизҗан: утызга якын. Болары клубта гына, күпмесе килмәгән.

– Сез болгар токымы, энем, – дип нәтиҗә ясый җырчы.

Мәшһүр Рәшит Ваһапов – сирәк тавыш иясе, үзе дә тарих, менә дигән хикәялек тема! Газиз язам дип, дистә еллар аны күңелендә йөртә, әмма... гел генә дә киләчәген әдәбият белән бәйләргә тиеш егет, армия хезмәтеннән соң хәрби училищены сайлый. Нигә? – Роза моңа җавап тапмас. Курәчәкме? Чехословакиядәге чуалышлар вакытында совет гаскәрләре дә кертелә. Егерме алты яшьлек тап-таза, сау-сәламәт егетнең шунда башы яралана. Ничек кенә дәваласаң да, төнлә дә, көндез дә басылмаган әрнү-сызлану... Алай да сиздермәү, зарланмау, ыңгырашмау, җәлләтмәү һәм иҗатка

кайту... И бәндә баласы, бер башка ике язмыш юк, диләр шул. Кайбер каләмдәшләре аны: «Ник чит дәүләткә корал тотып кергән?» – дип гаепли. Соң, аннан сораганнармыни?! Яки бүген синнән-миннән сорыйлармы? «Ватан алдындагы бурычыңны үтә!» – ир балага бишектә үк шундый приказ чыгарыла. Чит илләр дә минем газиз ватанымммы? «Күп сөйләшмик, яме?»

Кадерле авылдашы шул хәлендә дә тормышка чат ябыша. Авылның иң акыллы кызы Фәһимә апага өйләнә. Башта кызның әнисе белекче Шәрипҗамал апа теше-тырнагы белән каршы төшә, ятим аларга тиң түгел, диме? Баш өянәге белән җәфаланып бер үлгән, бер терелгән егетнең гомере кыска булачагын сизенәме? Аннары, ризалыгын бирә. «Газизҗан кебек чибәр ирне култыклап урамнан бер узулары ни тора!» – ди әбиең. Зәп-зәңгәр күз, дулкын-дулкын чәч, мәһабәт буй-сын, каткан бәгыреңне дә эретерлек елмаю! Чыннан да чибәр! Ярата карчык җан җылымлы кияүне, аның гарәп хәрефләре белән язган хатлары һәрвакыт: «Улым, Газизҗаным!» – дип башлана...

Элпә белән капланмаган яралар сызлатса-сызландырса да, бәхетле авылдаш абый. Чүмәлә өстенә чүмәлә дигәндәй, әлеге авыруны көчәйтеп йөрәкнең чыгымлавы гына яман. Роза монысының сәбәбен бик яхшы белә. Туган авылын Газиз Кашапов өзелеп ярата һәм болын ягында җир алып, өй салырга хыяллана, Үзи аның өчен ул яшәп алган Әлмәт тә, хәзер төпләнгән Чаллы да түгел, ул газизләрдән дә газиз төяк... Юкка гына тәхәллүсе Үзилемени, ләкин...

Розаның уйлары бүленә: ишектә Газиз Кашапов, гүя җәйге күк йөзенең зәңгәр буявы күзенә йоккан: бүлмә яктыра, нурлана. «Ләкин» дә калган күңелсез уй үзеннән-үзе таралгандай була.

Исәнләшүе үзгәрәк аның, күрешергә кул сузмас, кочагын җәеп кочакламас, йомшак кына иңнән сыйпап алыр. Якын итеп, сеңлесе кебек яратып... Язучының учында туган якның тансык җылысы сизелер, күңел нечкәрер...

– Уз, Газиз абый, мәтрүшкә салып пешергән чәй эчәбез хәзер. Үзидән җибәрделәр.

– Рәхмәт, сеңел. Мин синдә күп сыйландым. Күп зарымны сиңа түктем. Сиңа барысы да сыйды. Без бит синең белән ничәнчедер буын туганнар, шәҗәрә төзесәм, ачыклыйм әле моны.

– Газиз абый, яшерен-батырын түгел, син миңа гел кырын карыйсың шикелле иде. Әһә, дим, бер авыл казанына язучы белән журналист башы сыймый, ахрысы.

Язучы каушап, куеныннан тартып чыгарган кульязмасы белән битен җилләтә.

– Ялгышасың, сеңел, мин сине хөрмәт итәм, талантыңны таныйм, матбугаттагы язмаларың шәп синең. Төчелек юк аларда. Журналны «Сөембикә»гә әйләндерүегез – зур батырлык. Май санын Фәһимә китапханәдән апкайтты. Журнал шәп!

Баш мөхәррир авылдашының кулындагы кәгазьгә ымлый.

– Рәшит Ваһапов шаккаткан зәңгәр күзләләр иле турындагы хикәяңне безгә китердеңме әллә? Какраз яңа санны әзерлибез.

– Юк, сеңел, мин аны Мәгъсүм Хуҗинга саттым. Кызыкты да Мәгъсүм.

Хикәяләр остасы ул, язар мужыт. Монысы сезгә бармый, синдә бастырган булсак, талап үтерәләр иде үзеңне. Теге елда «Казан утлары»на биргән идем мин аны. Мәкалә «Фаҗига» дип атала. Синең игелекле бабаң Зәйнулла Вәлиулласын да телгә алдым. Егетләр май аенда бастырды.

– Исеме авыррак түгелме, Газиз абый?

– Минем дә, Үзинең дә фаҗигасе турында ул. Ишеткәнсеңдер, бер төркем куштаннар – адәм актыклары авылда йорт салдыртмады, сеңел! Җир бирдертмәделәр, каршы чыктылар! Йөрәгемә кан саудырды алар, сеңел!

Газиз абыйсының күзендә мөлдерәмә яшь, бөтен булмышы белән горур ирнең кинәт кенә нечкәреп китүен беренче тапкыр күреп, Роза чамасыз тетрәнә. Берсенә дә нәфрәтләнми Маһруй карчыкның ятим оныгы, аның бары тик гаделсезлектән бәгыре генә тетелә... Менә кайда тишелде Розаның «ләкин» дигәне... Авылдаш кул арты белән күзен сөрткәч, кульязмасын өстәлгә ташлый:

– Моны сиңа калдырам.

– Мин аны укыган идем инде, Газиз абый.

– Кабат укы! Гыйбрәт өчен! Гафу ит, ир-ат башым белән җебедем.

Йә, аны ничек юатасың? Аңа кушылып авылдашларын тиргисеңме? Әйтмәде түгел, әйтте ул миһербансыз ир-атларның йөзенә бәреп, әллә ничә мәртәбә әйтте Роза. Яратмадылар...

Сүз елгасын бүтән якка борып котылыргадыр, ахрысы.

– Газиз абый, син Хәсән абый турындагы «Киек каз юлы»ның икенче өлешен язам дигән идең.

– Язам! – Язучы иңбашларын сикертеп ала. Канатлана! – Эзләнәм, түл җыям, сеңел. Ундүрт яшьлек Луизаның шәхси көндәлеген тапкач шатланганнарым, сеңел. Кызның хәтта анда.. – Авылдашы уңайсызланып кына: – …күреме кайчан башланганына хәтле теркәлгән иде, – ди. – Миңа кызыклырак, яңарак табышлар кирәк. Туфанга рәхмәт, Миңнуллинны әйтәм. Лысваны икәүләп айкадык. Ул Хәсән әзи турында пьеса язмакчы. Анда марҗа карчыклары Хәсән абыйны елап искә төшерде. Әүлия иде, диләр. Безнең сәяхәтнең ахыры гына күңелсез бетте. Чүт кенә Миңнуллин абыеңны югалтмадым мин... Әгәр Чаллы хастаханәсенә кайтарып өлгермәсәм... Уф... – авылдаш язучы йөрәк турысын угалый: – сразу реанимациягә салдылар дусны. Аллага шөкер, коткарды табиблар Туфанны ул чакта! Йә, син эшлекле ханымны ялыктырмыйм тагы. Зур кеше бит син хәзер. Бөтендөнья Татар Конгрессының рәис урынбасары... О-о, шыпырт кына «Ак Калфак» дигән хатын-кызлар оешмасы да төзегәнсез икән. Син – җитәкчесе. Руслар әйтмешли: «Надо же!»

– Шыпырт кына түгел инде, күмәк көч белән. Бөтен татар кызлары берләшеп оештырдык. Зинһар, мине дә зур димә бүтән. Үз буем хәтле генә мин.

– Бигрәк җитди син, сеңел. Шаяртам бит инде! – Газиз абый сикереп тора да, Розага шикле караш ташлап: – Син минем иҗаттан бихәбәр кебегрәк, канәтем, – ди.

– Газиз авылдашым Газиз Кашшаф-Үзиле. – Роза көлә. – Сиңа дустың Туфан абый сүзләре белән җавап бирәм. «Укыдым гынамы, ятладым». Шигырьләреңне бигрәк тә. Арадан берсен аеруча.

... Күзләреңдә диңгез төсен күрәм,
Чәчләреңә көмеш сибелгән.
Син яратсаң, бүген ярат мине,
Безгә гомер бик аз бирелгән.

Аның кемгә багышланганы да мәгълүм миңа, карендәш әзием. Казанга килгәнсең икән инде, берочтан аны да күреп кит!

– Сеңел, син «безгә»не «миңа»га төзәт. Дөресрәге: «Миңа гомер бик аз бирелгән...»

Соңгы көрешү... Соңгы сүзләр... Бусага төбендә соңгы елмаю... Моңсу зәңгәр күз... Лифтка кадәр озатканда, иңбашына соңгы мәртәбә кагылган кул җылысы...

– Бәхил бул, сеңел...

– Туктале, ник син хуш кына димисең, ник бәхилләшәсең, Газиз абый?! – Роза лифт эченә чумган язучыны тартып алырдай булып талпына. Әмма өлгерми, чыжылдап ишек ябыла.

«Ләкин»нең эчтәлеге исә тулысы белән өстәлгә ташлаган язмада сурәтләнә. Яңа сан әзерләгәндә, һәр минут исәптә, баш мөхәррир аны бүленеп-бүленеп кенә укый. Чынлап та авылдашының каләм очыннан тамчы-тамчы фаҗига тама, журналдан ашыгыбрак укылган, күрәсең, элек ул болай ук тәэсир итмәгәндер.

«...Минем авылдан чыгып киткәнемә утыз ел тулды. Дөрес, мин ел саен кайтып йөрдем, башта еракта чакта елга бер мәртәбә, аннары инде Татарстанга әйләнеп кайткач та, елга берничә мәртәбә әйләнә идем. Минем хәтта туган авылымны сагынып кайтып, урман буенда басып, аның манзарасына карап торып, яңадан борылып китеп барган чакларым да булгалады. Кызганычка каршы, кайткан саен мин аның сыкранып-әрнегән яраларын күрәм, дәшмичә калмавым, газеталарга язып, телеэкраннардан сөйләвем, әлеге яра салучыларны фаш итүем өчен авылның җитәкче урыннарда эшләгән, үзләрен «түрә» санаган кайбер якташларым мине дошманга санау дәрәҗәсенә җиттеләр. Хәзер инде мин аларда заман чире – аллергия кузгатучы бер яман затка әвереледем бугай». «(...) Мин бу юлысы намуссыз бәндәләргә кире кагарга һич тә мөмкин булмаган дәлилләргә таянып язарга уйладым. (...) Безнең авыл Аксубай районының иң матур, оҗмах бакчасына охшаган төшендә иде. Аның һәр ягы – урман, елга-күлләренә балык тулган! …Каһәр суккан патша заманасында кайдан гына акча тапканнар да, ничек кенә башкарып чыкканнардыр – авыл янына берне генә түгел, өч күл казыганнар. Билгеле, кул көче белән, көрәкләр белән. Баштагы «Кәрәкә» исемлесен 1914 елда – Беренче Бөтендөнья сугышы башланган җәйдә – бер төркем ир-егетләр казыган. Алар Мөгыйн, Куян Шәрифулла, Тычкан Фарзалый, Хөсәен, Сәмигыл Гыйләҗетдине, Бай Шәрифулла, Зәйнулла Вәлиулласы, Мөхсин, Минабетдин» «(...) Күл суының чисталыгы. Салкынлыгы! Төбе ялтырап күренеп тора. Кәрәкә балыгының иге-чиге юк! Аның ян-якларындагы чишмәләр типкән җирендәге куе камышлар арасында киек казлар, кыр үрдәкләре, хәтта аккошларның бала чыгарганын әле мин дә күргән идем...» (…) «1957–1960 еллар арасында «Верный путь» колхозы

җитәкчеләре, бик зурдан кубып, хатын-кызларны көчләп дигәндәй, шушы күл янына җыйдылар. Кәрәкә күлен иң «авырткан» җиреннән – Сөлчә елгасына таба төшә торган биек ярыннан ерырга керештеләр. Китте Кәрәкә күленең суы, китте безнең әби-бабайларның шатлыгы агып, күл саекты, балыгы бетте». (...) Шул ук «түрәләргә» Мүкле күле дә ошамаган. Алар аңа да теш кайрап йөргәннәр икән. …Колхозның кәҗәдән азрак сөт биргән сыерларын елның ел шул күл тирәсендәге сазламыкка куып чыгаралар һәм күл буйларын издерәләр, таптаталар, нәҗес белән тутыралар. Ул үле күл инде».

Өченче күл – Бикчабарның аяныч язмышы турында укыганда, Розаның тамагына утлы таш бөялә. Үзен үзе адаштырган һәм ахырдан «сәерлегең бар» дип чеметелгән нәни кызчык Розаны шуның кырыендагы чишмә яныннан табалар бит! Күрәсең, язманы Газиз абый аңа махсус китергән. Ул: «Авылның әкиятләрдә генә тасвирланырлык табигатен ботарлап аткан имансызларның исемнәрен атамасам да, син аларның кемнәр икәнен яхшы беләсең. Тик син аларның битенә төкермәячәксең, чөнки син нечкә күңелле: «кеше рәнҗетермен», – дип куркасың. Ә мин табигатебезне мәсхәрәләгән бу бәндәләрне камчы белән суктырыр идем, – димәкче, ахрысы.

«Кичер, абый канәтем... Язмаңда: «Ягыбызның иң зур байлыгы – Олы Сөлчә! Мин синең, Сөлчә, кайткан саен яннарыңа төшеп, алларыңа тезләнеп мәрхәмәтсез түрәләр кылган җинаятьне кичерүеңне теләп ялварам», – дисең. «Фаҗига»не син бүлмәмдә утырганда ук өр-яңадан укырга иде миңа! Икәү тезләнер идек! Хәер, дөнья безне күп тезләндерер әле...» – Роза үзалдына шулай сөйләнә. Монысы да күз яшьләре аша авылдашына соңгы эндәшү...

...Август аенда җанны айкаган хәбәр: кырык тугыз яшендә, ир-атның тимер бөгәрлек иң куәтле чагында, ерак сәфәргә – мәңгелек иленә киткән Газиз Кашшаф-Үзиле. Ул бит Туфан абыйга: «Мин упкын авызында асылынган килеш. Аска мәтәлмәс өчен өстәге зәгыйфь кенә куакка тотынып яшим», – дигән була. Яшәр дә яшәр... куак чыдатыр иде әле... әгәр дә ки авылда йорт төзү хыялын үтереп, йөрәгенә кырык бер шырпы кадамасалар....

Газиз Үзиенә кайта ул, кайта. Зиратта ике метр җир казылган... Анысын да күпсенсәләр тагы...

> ...Син яратсаң, бүген ярат мине,
> МИҢА гомер бик аз бирелгән...

Сизенгән икән...

## 9. «Ак калфак»ның табылган чагы...»

«Нәрсә җитми сиңа? Гаиләң, балаларың, дау белән яуланган «Сөембикә» журналың. Һәрберсе энҗе бөртегенә тиң иҗат төркемең – Роза Камалетдинова, Альмира Әдиәтуллина, Саимә Ибраһимова, Марат Әмирханов, Зәлидә Әкбәрова, Рәйсә Юсупова, Филисә Хәкимова, Нурсөя Шәйдуллина, фотохәбәрче Дмитрий Бунтуковлар... Ике гаиләң синең, берсе өйдә, икенчесе – редакциядә. Артык йөк сөйрәмичә, үз-үзеңне кадерләп, законлы отпускларыңда ял итеп, тыныч кына яшә! Язардай күләмле әсәрең

юкмыни, йә?! Ничек юк?! Бар! Күңелеңдә ул! Вакыт тап, вакыт, дип тыпырчына. Их, син Рәхмәтулланың үҗәт кызы, җилкәңне уеп-сыдырачак тагын бер камыт кимәкче. Үз акылыңа кил дә, тәкъдимнәрен кире как».

Кемдер аны төштә үгетләп уята, әле таң да атмаган. Йокы кача. Өч көннән тарихи вакыйга: 1992 елның 19-21 июнендә Казанда узачак беренче Бөтендөнья Татар конгресы корылтаена Җир шарының төрле кыйтгаларыннан милләттәшләр чакырылган. Инде аларның байтагы башкалада. Тукай музее, Ак Кирмән, Сөембикә манарасы тирәләре ана телебезне ватмаган-сындырмаган, рус сүзе кыстырып чүпләмәгән саф ана телендә сөйләшкән чын татарлар белән тула. Аларга һәр таш кадерле, алар елый-елый манараның диварын сыйпый, алар ханбикә рухына дога багышлый, алар Казанны канга батырган Явыз Иванга нәфрәтләнеп, бәддога да укый...

Ә төш – ул чынбарлыкның кайтавазы. Конгресс рәисе Индус Таһиров, аның өч урынбасары Римзил Вәлиев, Разил Вәлиев һәм Роза Туфитуллова, хезмәткәрләр аяктан калып, олуг мәҗлескә әзерләнгәндә, бер төркем оештыру комиссиясе әгъзалары – тарих фәннәре кандидаты Тәэминә Биктимерова, фольклорчы галимә Флора Әхмәтова-Урманче, шагыйрә Лена Шакирҗанова, табибә Руфина Фәттахова Конгресс канаты астында татар хатын-кызлары берләшмәсе оештыру турында киңәшә. Биектән алдырта кызлар! «Ул Казан яки Татарстан – Рәсәй белән генә чикләнмәсен, Бөтендөньяга сибелгән татар хатын-кызларының уртак бишеге булсын!» Әйдаманы әлеге дә баягы, арбасына күпме генә йөк өйсәң дә, зарланмыйча тартучы Рәхмәтулла кызы, кәнишне. Иң әүвәл аның авызыннан чыккан идея ләбаса! Конгресста дистәдән артык секция эшләячәк, берсе «Сөембикә» журналы мөхәрриренеке, әйдә, шундагы чыгышында изге ниятебезне белдерсен».

Секция утырышын тулысы белән «Сөембикә»ләр үзләре әзерли. Роза ханымның докладын бастырылган, төп шигарь уйланылган: «Сөт калыр, Ватан китәр». Тирән мәгънәле Дәрдемәнд сүзләре. Бакый ага Урманченың хәләл җефете Флора ханым аксакалдан:

– Синеңчә безнең милләтнең иң бөек хатын-кызы кем ул ? – дип сорагач, акыл иясе:

– Татар анасы, – ди. Такташ та әниләребезне зурлап: «Хатын-кызның бөтен матурлыгы ана булуда», – дигән ләбаса.

Секциягә шулай ук мәртәбәле әдипләребез Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники чакырыла. Аллага шөкер, барсын да көйләдек-җайладык, хәтта Министрлар Кабинеты Рәисенең беренче урынбасары Мансур Хәсәновтан утырыш планын раслаттык дигәндә генә, гүя йодрык белән Роза ханымның башына тондыралар. Янәсе, «Сөембикә»ләр бары тик корылтай бизәге булып кына утырачак. Нindидер инструктор шалтыратып та боера.

– Берни дә үткәрмисез!

Курку! Көчәерләр, кузгалырлар, милли мәсьәләләрдә үз хокукларын дауларлар дип сагаюмы! Имеш, нишләп соң әле ул оешма татар хатын-кызларын гына тупламакчы, нишләп анда бүтән милләт вәкилләре юк!

Телефоннан гына чыбыкласак, җиңә алмабыз дигәннәр, ахрысы, «өстән» шапылдатып камчы «төшерәләр». Татар фамилияле түрә ханым кәперәйми,

эреләнми, үзен бик гади тота. Камчы белән дә суктырмас кебек, йомшак җәеп, катыга утыртмакчымы икән?

– Роза Рәхмәтулловна, сез – зур шәхес. Без сезне хөрмәт итәбез. Сез талантлы журналист, талантлы җитәкче.

Кара син, ничек тасма телләнә! Сәгатьләр буе мактасагыз да, аны изрәтә алмассыз! Ул төче сүзләрегезгә мохтаҗ да түгел! Мәрхүмә әбисе: «Мактау бер Аллаһка гына», – дияр иде.

– Йомышыгыз ни…( фәләновна)? – ди Роза ханым. Сорау артык инде монда: аңлашыла бит, куркытырга җибәрелгән.

– Безгә сөйләшергә кирәк, Роза Рәхмәтулловна. Сез Конгресс көннәрендә ниндидер җәмгыять оештырмакчы икән дип ишеттек, нәрсәгә ул сезгә? Безнең Россиядә дистәләгән хатын-кызлар комитетлары, оешмалары, шулар белән элемтә урнаштырыгыз. Дуслашыгыз, фикерләшегез! Барлык хатын-кызларның да бер үк проблема.

– Татар хатын-кызларының проблемасы икенчерәк. Шуңа да безгә бер йодрыкка тупланауыбыз кирәк, (фәләновна)!

– Конгресс узсын, аннары бергәләп уйлашырбыз, Роза Рәхмәтулловна.

– Бу Президентның боерыгымы?

– Юк.

– Димәк, безнең өчен, шәхсән сез хәл иткәнсез?

– Мин сезгә яхшылык теләмәкче идем, – ди түрә.

Мондый «яхшылык» яманлык белән бер үк дәрәҗәдә шул.

«Яхшылык теләүче»нең эзе суынырга өлгерми. Тик монысы йөрәккә ятышлы зат – Диләрә Тумашева. Тере легенда! Розаның диплом җитәкчесе. Университетның татар бүлеге студентлары өчен өлге-үрнәк. Ничек аңа сокланмыйсың! Салкын Себер якларында туып-үскән Гариф кызы Мәскәү университетының төрки бүлеген тәмамлый. 1909 елда атаклы Сорбонна югары уку йортында укыр өчен Парижга барган Сара Шакулова кебек Диләрә дә берничә тел өйрәнә. Кирәк икән төрек, кирәк икән алман яисә француз белән иркенләп аралаша ала ул. Мәскәүнең өйрәсе куе: ашы белән даны – бергә. Көмеш кашык белән сос! Һәр милләтнең маңгаена «Совет кешесе» дигән тамга чәпәргә ашкынган шовинист сәясәтчеләр, әлбәттә, татарның талантлы балаларын ил күләмендәге зур мәйданнарга чыгарырга ашкынмый... Бу җәһәттән Себер кызына кояш саран гына елмая бит. Йолдызлы башкалада калырга рөхсәт! Ура кычкыра-кычкыра бие, сикер! Ләкин Диләрә апабызның инде әллә кайчан күңеле Казанда. Иң ягымлы-сөйкемле тел дә – татар теле... Чит җирләрдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул, диләр. Тик бу әйтем Гариф кызына карата әйтелмәгән: Тумашева татарда беренче академик хатын- кыз! Ленин ордены иясе! Аның мәйданы – татар мәйданы офыкларга кадәр җәелгән, искиткеч киң. Ул ничәмә ничә фәннәр докторы, кандидатлар үстереп, Томск, Абакан, Чаллы, Алабуга югары уку йортларына тарата!

...Озак еллардан соң укытучының шәкерте белән очрашуы күңелле хәл. Йомыш белән килүеме икән? Олы башын кече итеп, дигәндәй... Конгресс беткәч, Роза үзе барыр иде әле. Әгәр... әгәр аны теге түрә ханым кебек илче сыйфатында үгетләргә җибәрсәләр! «Бернинди хатын-кызлар җәмгыяте оештырма!» Әй, бу тыюларның бәгырьгә тиюе! «Китәсе иде агып,

башларны салга салып», дигән әнә дөньясыннан, сүзеннән, гайбәтеннән гарык берәүсе. Юктыр, бу мөхтәрәм кешене милләткә кагылган мондый четерекле мәсьәләләрдә илче итмәсләр. Оятлары булса!»

«Миннән ачык чырай белән такта чәй».

Бу Мәликә әбисенең сүзләре. Карчык резин итек белән пуфылдата-пуфылдата көлен очыртып күмер самавырын кайнатыр да, шытырдавык кәгазьгә төргән такта чәен калай чәйнектә күпертер һәм, дәва өметләнеп сәкегә тезелгән апаларны сыйлар иде. Андый чәйләр бүген юк. Аның каравы чит илнекеләрдән кибет киштәләре сыгыла. Тәме генә бүтән. Менә ул да тефаль чәйнеген кабыза. Чырае ачык, ап-ак фарфор чәйнектә борынгы такта чәйнең алмашы – һинд чәе дә пешә. Диләрә Гариф кызы һаман чибәр! Хәер, студентлар арасында кайнаган педагогка алтмыш алты яшь пүчтәк инде ул! Аның өчен «карт аю» урманда! Сирәк кешенең эчтәге нуры йөзендә чагыла. Әнә ул утырмага куна ук килдем дигән кыяфәт белән кәнәфи култыксасына терсәге белән таянып, шәкертен күзәтә.

– Роза, – ди кунак, – нәрсәдән тотыныйм икән?

«Хат башы, яз каршы...» Тагы әбисе хәтер сүрүен ерта. Аның читтәге кызларына яздырткан хаты иң әүвәл шулай башлана иде.

– Сүз башы – әйт каршы, диегез, Диләрә Гарифовна!

– Безнең сөйләшү әллә ниләр әйтешүдән тормас. Хәтерлисеңме, кулыңа диплом алгач, сиңа нәрсә дидем? Зәйнуллина, аспирантурада укуыңны дәвам ит, дидем. Син тюркология өлкәсендә танылган галимә булачак идең. Тыңламадың, телестудиягә урнаштың. Аннары матбугат капкасыннан кереп адаштың.

Роза көлемсери:

– Ник адашыйм ди, Диләрә Гарифовна! Мин – журналист, язам-сызам дигәндәй.

Кунак сызланып кына:

– Язсаң-сызсаң гына икән. Бунт күтәрәсең, бунт! – ди. – «Сөембикә»нең баш мөхәррире Конгресста ниндидер төркем укмаштырмакчы, диләр.

Әһә, оялмыйлар, шушы мөхтәрәм апабызны үгетләргә җибәрәләр.

– Төркем ул ике-өч дистә кеше. Безнеке берләшмә. Миллионлаган татар хатын-кызларының уртак йорты. Алла бирсә, Җир шарының төрле почмакларында аның йөзәрләгән-меңәрләгән бүлекчәләрен ачарбыз. – Рәхмәтулла кызының хыялы гүя кош, күкләр иңли. – Әгәр без моны бүген эшләмәсәк, азактан кызыл кар явачак. Соңрак, соңрак, диләр, безне кысалар. Моның өчен бит татарның җыелыр урыны кирәк. Милләттәшләрнең: «Хуплыйбыз!» – дип әйтүе кирәк. Аны урамга чыгып кычкырып йөреп эшләмиләр.

Кунак касәсендәге чәйгә өрә.

– Борынгылар ни диләр? Бер авызың пешкәч – өреп кап, диләр, әйеме? Син, Роза акыллым, журнал исемен алыштырганда нык кына пештең түгелмени? Сабак булмаган, ахры, сиңа. Мин шәкертемнең юлына бүрәнә тәгәрәтергә килмәдем. Ялгышмыйсыңмы гына димәкче идем.

– Татар җанын аңлар өчен бәлки мин күп тапкыр ялгышырмын әле, Диләрә Гарифовна.

– Алайса алдагы көннәреңә әзер тор! Саф алдыннан атлаган лидерларның

дәрәҗәсеннән, абруеннан көнләшкән хөсетлеләр әзме? Алар сине хурлар, яла ягар, бәгыреңне яралап тоз сибәр. Көчсезләнсәң (барыбыз да картаябыз), теле белән тибеп китүдән дә тайчынмас.

(Бер «пырдымсызы» көчсезләнгәнеңне дә көтмәс. «Сөембикә»дән куыгыз дип Матбугат һәм мәгълүмат министры (1992–1999 еллар) Ислам Әхмәтҗановка керер. «Туфитулловага бәйләндертмим, лутчы үзем эштән китәм», – дияр Галиәхмәт улы.)

– Сезнең алда яла-шикаятьләргә әзер, эткәләсеннәр, төрткәләсеннәр, тел белән кыйнасыннар дип әтәчләнсәм, алдашыр идем, мин дә бит – ике бала әнисе, мин дә – хатын-кыз. Күңел кылдан да нечкә, тиз яралана. Әмма мин күз яшьләремне күрсәтмәм, качып елармын. Әйдә, Туфитуллованың тиресе калын, йөрәге – таш, дисеннәр. Чәегезне яңартыйммы?

– Рәхмәт, туклandым. Агымга каршы йөзмә дип киңәш бирмәкче идем, файдасыз, син барыбер йөзәсең икән. Уңышлар, Роза!

– Сезне дә секция утырышында көтәбез, Диләрә Гарифовна!

– Һичшиксез, киләм!

...Бәйрәм! Илаһи бәйрәм! Ак татар, пакь татар, иманлы татар, ерак бабалары дәүләт тоткан мәгърур татар оныкча-туруннар бергә җыела!

Кунак каршылауның рәтен белгән «Сөембикә»леләр табынга милли ризыклар тезә. Бүген олы Ил-йортка кадерле кунак төшерә алар.

Иң күп делегат – Розалар секциясендә! Бигрәк тә чит илләрдән. Чөнки алар рухына якын тема: «Милләт. Хатын-кыз. Гаилә». Милләт, тел, гореф-гадәтләр беренче чиратта гаиләдә саклана. Әнә ирләр ташкыны уртасында утырышка галим Надир Дәүләт килеп керә. Романнар язарлык аяныч язмыш... Большевиклар тырнагыннан котылып, Кытай Маньчжуриясендә тереклек иткән Ибраһим Дәүләткилде белән Рокыяның Надир исемле малае туа. Аңа бер яшь тулганда, Совет гаскәрләре Маньчжурияне басып ала. Мөһаҗир татар тынычлыкка тиенәмени! Ерткыч бүреләр иснәнеп, аны җир астыннан да таба. Ибраһим белән Рокыяны Себер төрмәсенә илтеп ябалар. Мөгаен, малайны да берәр балалар йортына аткарырлар иде дә, миһербанлы күршеләре Әхтәм белән Гайниҗамал яшереп өлгерә. Сер ул балигъ булгач кына ачыла: аны уллыкка алып үстергәннәр, ул Ильясов түгел, ул Ибраһим улы Дәүләткилде икән. Туксанынчы елларда гына картайган әнисе һәм тоткынлыкта туган сеңелесе Фәридә белән Казанда очраша Надир әфәнде. Җаны Төркиягә генә сыймыйча минем газиз Ватаным дип санаган татар иленә гомеренең соңгы көннәренә хәтле кайтып йөрер шушы морза баласы.

Әнә елмая-елмая тагын берәү керә. Ул Кытайда туып, Төркиядә үскән Фәридә Валрус – милләт болынындагы гүзәл чәчәк – Фәридә Хәмит тәхәллүсе алган. Алты телдә иркен аралаша, фин дипломатына кияүгә чыга. Ирекле илдә иркен сулап яшә генә! Ә Фәридәгә Татарстан якын... Алты тел арасында газизләрдән газиз – Тукай теле...

...Роза чыгышын: «Без – татар хатын-кызлары кемнәр? Татарлыгыбыз нидән гыйбарәт?» – дигән сорау белән башлый. – Изелгән-кыерсытылган яки горур, батыр, уңган, тырышмы без? Кемнәр дигәндә, безнең күп сөйли торгач, татар хатын-кызы югалткан сыйфатлар шактый җыела икән шул. Бездә беркайчан да ир хатыны дип түгел, ә бала анасы дип йөртелгән татар хатыны. Бу аны югарырак статуска күтәргән...»

Чыгышлар арты чыгышлар... Тәкъдимнәр арты тәкъдимнәр... Сүз боткасы түгел, куе сүз каймагы. Кинәт залда тынлык. Ярты гына секунд сулама, һәркемнең йөрәк тибеше сизелер... Тиздән газап кичерә-кичерә, җанда яралган «бала» туачак... Ул милли көебез белән өретелеп җырларда җырланган «Ак калфак»... исеме белән аталыр. Бакый ага Урманченың хәләле – Флора Урманче табышы. Аклык, сафлык билгесе.

Ак калфакның табылган чагы
Туганнарның сагынган чагы...

Татар хатын-кызларының күңел бишегендә тирбәләчәк «сабый»га ихлас теләкләр... Тизрәк тәпи бас, үс, ныгы, даның-шөһрәтең дүрт кыйтгага таралсын...

Ахырдан яңа берләшмәнең идарә составы сайлангач та нокта куелмый әле. «Ак калфак»ны кем җитәкләр? Лаеклылар күп, Татарстан булдыклы татар ханымнарына корымаган. Роза аулакта гына шуларның берсе – шагыйрә Лена Шакирҗанованың кылларын чиртеп карый.

– Лена, син – танылган әдибә. Сине халык белә. Әйдә, берләшмәнең рәис вазифасына ризалаш. Без – идарә әгъзалары – сиңа ярдәм итәрбез.

Нәрсәдер ошамаса, очкын кебек кабынган Лена мондый очракта хәтер саклыймыни, ул:

– Аһ сез, хәйләкәр төлкеләр! Мине җәмәгать эшенә күмеп иҗатымнан читләштермәкче буласызмы?! Язмасын, дисезме, дошманнар! – дип, тетмәне тетә. – Кырыкмаса кырык хатынга кем ярап бетсен! Кырык кынамы, миллионнар белән исәпләнәчәкбез, дисез бит!

– Бу әле минем генә фикер. Мине генә дошманың сана, – дип көлә Роза.

«Революционерлар» анда инде җитәкченең кем буласын уйлаган. Табибә Руфина Фәттахова: «Иң кулай кеше – Роза Туфитуллова», – дип тавышка куеп, кул күтәртә! Ник ул соң, ник? Дәлилләре бик көчле дәлил икән лә:

– Журнал күптән чит илләрдәге ханым-туташлар белән дус. Рәхмәтулла кызы чикләр ачылган мәлдә үк алар белән элемтәне җайлаган. Күрдек бит, конгресска океан артыннан хәтле апа-сеңелләребезне чакырткан. Җырдагы:

Ай, әле ерак идек без,
Җитмеш чакрым җирдән килдек без, –

дигән юлларны җитмешкә тапкырласаң да, таман гына. Ил-көн күзендә абруе зур. Бөтен җирдә сүзе үтә. Бикле ишекләрне дә ачтыра. Аңарда татар хатын-кызларының бөтен асыл сыйфатлары бар. Эшләсен!

Менә нокта. Күп-күп ноктала… Йә, берәрегез аның җанына бактымы? Ниләр турында хыялланасың дип сорадымы?! Гаиләңә вакытың каламы дип кызыксындымы?! Әллә ул «син тиеш» ролендә генәме?

Эшләр, әлбәттә. Милләт, милләт дип кычкыруы җиңел ул, ә син кычкырма, аңа берәр файда китерерлек гамәл кыл. Әйтәләр бит, караңгыда бер шырпы булса да кабыз. Дөнья яктырыр… «Татар гаиләсе. Татар Анасы. Анам теле. Татар баласы» – болар Розаның күңел дәфтәрендә. Әнә рус галиме Лев Гумилёв үзенең әңгәмәсендә: «Татар кавеме үзенең югалмавы белән Татар Анасына бурычлы. Бу халыкның барлык уңышлары

– балаларын зирәк итеп тәрбияләү, гыйлемгә омтылдыру», – ди. (Балкар шагыйре Кайсын Кулиев исә Казанга килгәч: «Татарларны нигә яратам? Алар туган телләрен Ана телем дип йөртә. Моны затлы халык кына шулай әйтә» дияр.) Ә хәлләр ал да гөлме, әй милләт?! Мактатып-макталып кына яшәргәме сиңа?!

Чирен яшергән – үлгән, диләр. Икенче Бөтендөнья татар конгрессы корылтаенда Роза, бизәкләп-чуклап күзгә төтен җибәрмичә генә, мөнбәргә менеп, чын хакыйкатьне ярып сала: «…Милләт Анасы дигән тирән мәгънәгә ия төшенчә дә татар лексиконыннан күптән төшеп калды. Һәммәбез дә зарыгып көтеп алган «Татарстан халыклары телләре турында»гы законда да. Татарстан халыкларының телләрен саклау һәм үстерү буенча Дәүләт программасында да аналар һәм гаилә турында бер генә дә сүз юк. Телгә өйрәтү үзеннән-үзе, табигать кушканча бара дип уйлаучылар белән берничек тә килешеп булмый. Дәүләтебезнең тел сәясәте дә, гаилә сәясәте дә Аналардан башланырга тиеш». «...Тагын бер аяныч күренеш: чит милләтләр белән гаилә корган татар үз йөзен югалта. Кызларыбызның кырык дүрт, егетләребезнең кырык ике проценты башка кавемнәрне пары итеп сайлый». Еллар узган саен бу чыгышлар тагын да кискенрәк яңгырар...

Рухи күтәрелеш кенә әз. Нишләргә? Туфан Миңнуллин белән икесенең уйлары кисешкән чак: татар кызлары өчен гимназия ачарга! Туфан абый шәһәр җитәкчеләренә тынгы бирми: «Бина кирәк, бина!» Роза ханым: «1916 елда Иске татар бистәсенә халык җыеп, хәтта ки губернаторны, шәһәр башлыгын китертеп беренче татар кызлары гимназиясе ачтырган мөгаллимә Фатиха Аитова исемен йөртәчәк ул», – ди. Аңардан көлә берәү: «Тумаган тайга атланып билен сындырма», имеш. Бәлки аның иң авыры – милләт дия-дия син нәрсәдер эшләргә тырышасың, шунда кемдер сөйрәгән арбаң тәгәрмәченә таяк тыга, кемдер «хыялый җүләр» дип теш агарта, ә кайсыныңдыр көнләшүдән бавыры «әчешә»: Туфитуллова дан артыннан куа, аның гел түрәләрнең күз уңында буласы килә, янәсе.

Әй, үзен күрсәтер өчен ник ишекләре икешәр катлы кабинетларның бусагасын таптасын икән ул! Россия төбәкләренә генә сыймыйча чит илләрдә дә оеша башлаган «Ак калфак»чылар, урынбасарлары Лена Шакирҗанова белән Тәэминә Биктимерова, Конгресс рәисе Индус Таһиров, сәясәтчеләр, иҗат әһелләре, рәссамнар, язучылар, артистлар, журналистлар, гади халык – менә кемнәр алар көндез дә, төнлә дә шакый алырлык «затлы кабинет» хуҗалары.

Гимназия ачыла. Аңа Фатиха Аитова исеме дә бирелә.

Инде «милләтнең комсыз кызы» Туфитуллова моның белән генә тынычланмый. Мәркәзебез уртасындагы татар балалар бакчасын япканнар! Ауган-җимерелгәнне төзәтергә акча юк, ди.

Терек-терек... Терек-терек... Җир шарының бозлы сукмагында таеп егылмыйм дигән сыман вак-вак кына атласа да, һәр адымы берәгәйле Розаның. Бакчаны кабат тергезер өчен ул иганәчеләр эзли.

Кайсыгызның теле генә түгел, җаны да милләтем дип өзгәләнә соң?! Туфан абый, әнә инкыйлабка кадәр татар байлары мәктәп-мәдрәсәләр ачтырган, безнең замана миллионерлары шулар үрнәгендә берәр татар мәктәбе салдыртса (дәүләтләре кимемәс!) исемнәре тарихта калыр иде,

ди. Мөгаен, ул берәрсенә сүз дә кушкандыр, ләкин тегеләрнең татарлыгы чамалыдан да чамалырак, ахрысы, аксакалның гозерен санга сукмыйлар. Димәк, «акча капчыклары»на ялынмаска! Хәерле сәгатьтә дип, берәр изге эшкә керешсәң, Аллаһы Тәгалә җир-күкләрне иңләтеп, фәрештәләрен дүрт тарафка очыртамы икән әллә? Германиядән Фәридә Хәмит шалтырата:

– Роза ханым, безнең татар бабайларыбыз балалар бакчасына акча китерде! Безнең дә өлеш керсен, диләр.

Бабайлар – сугышка хәтле һәм сугыштан соң совет хакимиятенең эзәрлекләве нәтиҗәсендә туган иленнән аерылып, алман илендә яшәргә мәҗбүр ителгән, исемнәре дә билгесез милләттәшләр. Роза ханымның күңеле тула... Бәлки бу картлар соңгы телем ипиен авызыннан өзеп җибәрәдер... Аларның бит байлыгы ташымый. Алар үзләре ярдәмгә мохтаҗдыр.

Менә Америкадан Шәмсия Апакайдан сәлам:

– Роза ханым, без булышабыз! Зинһар, ярты юлда туктама, яптыртма татар балалар бакчасын!

Кузгала чит илләрдәге «Ак калфак»лылар, дәррәү кузгала! Австралиядән Ләйлә Садри, Сан-Францискодан Гөлчирәләр хәбәр сала: «Без дә кушылабыз!» Татарстанда исә Балык Бистәсеннән эшмәкәр Рәшит Сөләйманов үзе Рәхмәтулла кызын юллап килә.

– Апа, мин сезнең укучыгыз, – ди егет. – Сез мәктәптә практика үткәндә безне укыттыгыз. Киемегезгә хәтле хәтерлим әле. «Чыбыксыз» телефоннан ишеттем: балалар бакчасына матди ярдәм кирәк икән. Мине дә химаячеләр исемлегенә языгыз, апа! Тиенен дә кызганмыйм, ремонтлап курчак өе ясыйм, валлаһи, апа!

Ил төкерсә – күл генәме, диңгез җәелә икән. Төзекләндерелгән, матурайган, нурланган татар балалар бакчасы милләтпәрвәрләр ярдәме белән яшәвен дәвам итә. Чиратта – бала тудыру бүлекчәсе... Гадәттәгечә аңа: «Сиңа ни җитми?» – диярләр. Җитми! Монда «Ак калфак»ның бер таләбе үтәлергә тиеш: ул халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары һәм әхлакый кануннары нигезендә ачылсын! Татар Анасы сабыена бишек җырын иң әүвәл шушы бинада ук көйләсен!

Тагын ниләр? Зур-зур залларда шаулатып, «Гыйффәт туташ», «Киленбикә», «Ак сөт, ак биләү, ак күңел», «Буыннар чылбыры» кебек тел, дин, иман, милләт анасы, милләт баласы турында бәйге-тамашалар уздырганнан соң, «Ак калфак» матбугатта мактлган да, чеметелгән дә. «Чеметелгән» дигәннән... Аксак кырмыска урамнан:

– Җәмәгать, анда филне кыйныйлар, мин дә берне китереп типтем әле, – дип сөенә-сөенә кайтып бара икән. Розага да үзебезнең «татар кырмыскалары» тибеп киткәндер. Моңа һич гаҗәпләнәсе түгел. Кайберәүләр барган атның башына сугарга ярата. «Ярар, – дияр анысы Рәхмәтулла кызы. – Ярар, маңгай күзләре сукырлар эшемне күрмәсә-күрмәс, мин бит байрак тотып ура кычкырып, без – алгы сафта, без – җиңүче, дип лаф ормыйм. Сызлануларым да җитәрлек. Аерым бер сусау һәм тыелгысыз бер дәрт белән эшкә керешсәк тә, асылыбызга кайту максатының җиңел булмавын тиз аңладык. Югалтуларыбыз күп, рухи кыйммәтләребезнең тирән катламнарын күтәрү өчен теләк, рух күтәренкелеге генә җитмәве көн кебек

ачык иде. Шуңа «Ак калфак»ның туган телебезне, гореф-гадәтләребезне, татар хатын-кызларының әхлакый сафлыгын саклау өчен сарыф ителгән көч-егәре еш кына җилгә дә очкалады...»

Аның мамыгы гына очкандыр, чеметем генә мамыгы! Берләшмә берни дә майтара алмаса, шул еллардагы Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, мөхтәрәм ил агасы Индус Таһировтан мондый бәяләр ишетер идеңмени?!

– Үземә йөкләнгән вазифаны башкарганда, бик күп кешеләр белән аралашып яшәргә туры килде. Аларның иң якыннары һәрвакыт янымда булдылар. Болар – рәис урынбасарлары: «Сөембикә»нең баш редакторы, «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасын бар итүче Роза ханым Туфитуллова, күренекле журналист Римзил Вәлиев, Татарстан Дәүләт Советының мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе Разил Вәлиев. Монда Роза ханымның эшчәнлегенә махсус бәя бирергә кирәк. Ул берләшмәнең җирле оешмаларын төзеп, конгресс эшчәнлегенә бик күп татар хатын-кызларын җәлеп итте...

Төрки халыклары хатын-кызларының «Евразия» дигән ассамблеясы төзелгәч, «Ак калфак» аның тулы хокуклы әгъзасы була. Мәскәүдә югары кимәлдә узачак беренче съезд... Монда кемнәр генә юк! Төрек, кыргыз, таҗик, казакъ, азәрбайҗан, үзбәк ханымнарының аллы-гөлле күлмәкләреннән күз камаша. Корылтай рәисе казакъ хатыны, юридик фәннәр докторы Раушан Канапьянованың катнашучыларга мөрәҗәгате Рәхмәтулла кызының йөрәгеннән сызылып үтә.

– Әйдәгез, беренче сүзне татар хатын-кызлары әйтсен! Алар борын-борыннан безнең олуг остазларыбыз булды, – ди рәис. Зал хуплап, озаклап кул чаба... Баксаң, берничә ел эчендә «Ак калфак»ның даны еракларга таралган икән. Бу да хезмәтеңне бәяләү ләбаса!

Берсендә аңа танышы:

– Нишләп баш-аягың белән җәмәгать эшенә чумасың, үзе түләүсез, үзе сәламәтлегеңне какшата. Ташла ул берләшмәсен-ниен, киләчәктә барыбер исемең онытылачак, – ди. Кызгана...

Андый «кайгыртучы» танышларга Розаның җавабы күптән уйланылган:

– Мине онытсалар онытырлар... Аның каравы «Ак калфак» тарихта калыр...

## 10. «Мөгезле» татар?»

«Ай-яй, ул үткән чакрымнар, үлчәсәң, Җир шарын ике мәртәбә уратыр иде». Индус ага әйтмешли: «Ак калфак»ны бар иткәнсең икән, сез еракта шул, димә. Рәсәйнең өлкә-крайларында оешкан һәр бүлекчә белән барып таныш! «Ник һаман безгә килмисез?» – дип үпкәләүчеләргә үпкәләмә! Кырыкка ярылсаң-ярыл, ләкин алар белән очраш!»

Эчтәге «мин» әнә ничек камчылый! Рәсәй киңлекләре белән генә чикләнсәң, тагын әр-битәр... «Сөембикә»ләр чит ил кунакларын каршылап кунак иткән илларда ук алар: «Без дә сезне көтәбез», – дип чакырмадылармыни?! Чакырдылар! «Ак калфак» Бөтендөнья хатын-кызлар берләшмәсе дип аталган икән, ул үз казанында гына кайнамасын, бүтән

милләт ханым-туташлары белән аралашсын, фикерләшсен, бәхәсләшсен!»

Малайзия, Һиндстан, Ливан, Төркия чакыра. Кайчан мине кулыңа алырсың икән дип кыбырсыган каләм кинәнә: Роза һәрбер сәфәреннән хикәя кебек мавыгып укырлык язмалар алып кайта. 1996 елда Истанбулда Берләшкән Милләтләр Оешмасының «Хабитат-2» халыкара конференциясе уза. Җыенны ачканда трибунага шәм тотып чыккан Генераль секретарь Удди Н-Дау:

– Бу шәмне мин конференциягә килгән хатын-кыз делегатларның үтенече белән кабызам. Һәм кешелек дөньясына ут табып биргән, аны һәлакәттән коткарып калган гүзәл зат алдында башымны иям, – ди.

«Журналда сезнең «Афәрин, ханымнар, афәрин!» дигән күләмле язмагызда һәр җөмләсе кәгазьгә чигелгән бизәк сыман, сыгылмалы һәм нәфис телегезгә сокланып туялмыйсың», – дигән Чаллыдан татар теле укытучысы Әнисә Низамова. – Балаларга да укыдым. Яраттылар».

Ак, кара, сары чырайлы меңәрләгән милләт баласы катнашкан җыенда халык саны, торак, шәһәр-калалар, тирә-як мохите хакында сөйләшергә тиешләр. Ә ул Җир шарындагы барлык хатын-кызга мәдхия уку белән башлана. «Бу минутлар миңа таң алдыннан күргән төш сыман тоелды», – ди Роза. Мәдхия татар хатын-кызларына да багышлана. Аны аеруча «Ак калфак»ны милләт бишегендә тирбәткән кулдашлары Тәэминә Биктимерова, Флора Урманче, Лена Шакирҗанова, Руфина Фәттахова, Дания, Гөлзада, Камәрия, Сурия, Нәҗибәләргә дә ирештер, Аллаһым!

Иң нык истә калачак сәяхәт алда икән. Матур җәй аенда Казанга Ливаннан Гарәп мәдәниятен үстерү үзәгенең Генераль секретаре, Триполи шәһәренең Аналар җәмгыяте рәисе доктор Нәдә Әл-Әюби аяк баса. Ул – затлы токым килене. Ире – Ливан Президентының хокук мәсьәләләре буенча киңәшчесе Рәхиф Әл-Әюби, заманында ил башлыгы булып, хакимлектән куылган Әл-Әмир Җамалетдин Әл-Әюбинең кече улы. Башта аңа туганнары Нәдәгә өйләнергә рәхсәт бирми, чөнки кыз түбән катламнан, безгә тиң түгел дип саный. Аһ, бу мәхәббәт! Баймы син, ярлымы – аңа ике кәнди – бер кашык: ярамыйга карамый, яшьләр гаилә кора. Өч малайлары туа. Икесе хәтта Казан университетында укый. Инде безнең милләт кызына гашыйк шуның берсе. Татар белән туганлашкан Әл-Әюбиләр Татарстанда да ишәер дигәндә, кызганыч, яшьләр аерылыша.

Ике атнага сузыла әлеге визит. Кадер-хөрмәт күргән Әл-Әюбиләр яратып китә гүзәл татар илен һәм безнең: «Кунак ашы – кара-каршы» дигән әйтемне үзләренә яраклаштырып:

– Роза ханым, хәзер сез безгә киләсез! – диләр.

Ливан бакча артында гына түгел, чыгып чабалмыйсың. Барасың икән... турист сыйфатында илнең табигате, җир-суларын күреп хозурланасы түгел. Максат – бүтән: Татарстанны таныту. Юлдашы, Конгресс рәисе Индус Ризак улы да шул фикердә. Аңа әллә ни коралланасы юк. Докладьы әзер, татар тарихы аның йөрәгендә. Рәсәй – Татарстан арасында Шартнамә төзегәндә академикның кире каккысыз дәлилләр белән чыгыш ясавы рус сәясәтчеләрен шаккатыра бит.

...Зарыктырып көттергән кунаклар, ниһаять, Ливанның әкияти Триполи шәһәрендә. Уңга-сулга борылырга вакыт юк, беренче көнне үк Минәдәге Сәнгать сараенда күргәзмә оештырасы. Роза тыныч, ни кирәге – чигүле

калфак, түбәтәй, камзуллар, шәмаилләр, сафьян читекләр, көмеш алка-беләзекләр, фотосурәтләр Казанда ук чемоданнарга салынган, тез дә куй гына, ә менә Нәдә ханым:

– Бездә татарларны монголлар дип беләләр, зинһар, үтемле итеп, ышандырырлык итеп сөйләгез! – дип борчылып йөри. Безнең татар «түрә» дип атаган Ливан җитәкчеләре чарабызны ошатырмы-юкмы икән дип борчыла бугай ул. Ошатмаган кая! Күңелләрне җилкендереп ике илнең Дәүләт гимннары яңгырый, залга хөкүмәт членнары, депутатлар, сәнгатькәрләр, язучылар, галимнәр агылыпмы агыла. «Нинди зурлау, нинди хөрмәт сиңа, милләтем! Кайчандыр син дә шанлы-данлы дәүләт тоткансың. Французлар коллыгында изаланган Ливан көннәрдән бер көнне ирек тәмен татый. Ә син...»

Йа Аллаһым, шушы тантаналы минутларда берни турында уйлама югыйсә, ә Рәхмәтулла кызының җанын сагыш сара. Син, милләтем, кайчан бәхеткә тиенерсең дип, гасырлар тузанын кагып кайсыгыздан сорыйсы. Кайсыгыздан?!

Сынатамы соң алар! Индус аганың: «Кемнәр ул татарлар?» дигән чыгышын тын да алмыйча тыңлыйлар. Тылмач егет тәрҗемә итеп кенә өлгерсен! Мәдәният дөньясы исә Роза колач салып йөзгән тирән диңгез. Нәдә ханым шат: «Булдыра татарлар...»

Әл-Әюби җитәкләгән «Аналар җәмгыяте» дә «Ак калфак»ның игезәк сыңары кебек, аларда да үзәктә – хатын-кыз мәнфәгате. Роза белән очрашуга карты-яше җыела, тик бер сәер нәрсә аны аптыраштa калдыра. Олырак яшьтәге әби-апаларның кергән берсе аның башыннан сыйпый. Ни хәл бу? Яулык бәйләмәгән дип бәйләнәләрме? Ә бит түтиләрнең күбесе яланбаш... Муеныңдагы шарф белән чәчемне каплыйм дигәндә, Нәдә ханымның Казанда укыган студент улы Алләм елмаеп:

– Алар сездә мөгез бармы-юкмы дип тикшерә, – ди. – Татарлар кыргый, алар – әкиятләрендәге урман шүрәлесе, дигән уйдырманы кемдер тараткан инде. Үпкәләмәгез, Роза ханым.

«Мөгезле...» Җитмәде шул татарга мөгез! Үткен очы белән эләктереп, әллә кайларга чөя-чөя, килмешәк «җанварлар»дан ил-урманын чистартыр иде татар!

Ливан карчыкларының кулы кайнар... Әгәр бөтен милләт Аналары бергә кушылып, Җир шарын сыйпаса, планета җылынып, сугыш-үтерешләр, кан кыюлар туктамасмы икән?

### 11. «Сезнең өстән шикаять бар...»

«Вазифалар гөле Роза...» Йә, монысы ни инде? Дусты Рәдиф Гаташ яратып, аңа шундый кызык исем куша. Бер бинада эшләгәч, гел күзгә төртелә икән бит: баш мөхәррир бүлмәсенең эчендә дә, тышында да кеше. Язмамны журналда бастырыгыз дип килгән каләм халкы түгел болар. Болар – йә берәр бәлагә тарган, йә кемдер тарафыннан җәберләнеп, яклау өмет иткән гап-гади кешеләр. Авыллардан, районнардан... Хикмәт шунда ки, Туфитуллованы  тагын бер җәмәгать эше белән «баеткaннар». Ул Татарстан Президенты каршындагы ярлыкау комиссиясе әгъзасы итеп сайлана. Чынлап та, «Вазифалар гөле!»

…«Сөембикә» тугызынчы катта. Лифт кырыендагы тәрәзә төбенә тәмәке тартырга дип, Зөлфәт килеп басты исә, төтен исен сизепме, өстән дә, астан да каләмдәш дуслары җыела. Матбугат йортын дерелдәтеп, әй, шаулашагөрләшә егетләр! Бүген Зөлфәт нишләптер үзе генә. Зәңгәр күзен күккә төбәп, уйга чумган. Роза ярлыкау комиссиясе утырышына бик ашыкса да, аның янына туктала.

– Нихәл, Зөлфәт?

– Искечә, күрше бүлмәдәш! Синдә кеше дә кеше. Арыйсыңдыр.

– Төрлечә, Зөлфәт.

– Студент еллары сагындыра, малай. Сине төнлә уятып, шигырь укыган чаклар. Син бер дә ачуланмый идең. Фираям да синең сыман, кара таңнан торгызам, йокылы күзен уа-уа, минем шедеврларны тыңлый.

– Хатының – чын мәрхәмәт иясе. Кадерен бел, Зөлфәт.

– Икегез дә бер иш. Безнең подъездга бомж ияләште. Фирая шуны ашата, сабын-мунчала, сөлге тоттырып, күмәк мунчага озата. Дөресме, сез Саимә Ибраһимова белән Әгъләмне уллыкка алгансыз икән. – Зөлфәт чәчрәп көлә! – Мөдәррис үзе сөйләде. Саимә апа белән Роза миңа импортный раскладушка җүнәтте, теләсә кайсы вакытта мин аларда кунам, ди. Кысан фатирларын зурайткач, миңа бүлмә дә әмәлләрләр әле, ди.

– Миргалим Мөдәррисне аеруча якын күрә. Хәтерлисеңме, җитмешенче елда аның имән яфрагы хәтле генә «Кыңгырау» исемле беренче китапчыгы басылды. Ул аны миңа: «Роза! Тулай торакта яшәгән елларның бер күңелле истәлеге булсын, туганың Мөдәррис», – дип язып бүләк иткән иде. Чынлап та, туганым ул минем, рухи туган. Айдарыбыз аны бездән дә ныграк ярата. Сабыйлар чиста, ихлас кешеләргә тартыла бит. Уллыкка алгансыз, дисеңме? Син «Чаян»да эшләп мәзәкчегә әйләнгәнсең инде. Йөгердем, Зөлфәт!

Йөгертә дөнья, йөгертә... Төштән соң комиссия әгъзалары Козловка төрмәсендәге тоткын хатын-кызларның яшәү шартлары белән танышачак. Монысы Рәхмәтулла кызының тәкъдиме. Чөнки иң күп хатларны шуннан язалар. Төрмә башлыгыннан белеште ул: ябылуда татар кызлары да бар икән. Әллә соң җинаять кылучыларның милләте юкмы? Алар барысы да бер чыбыктан сөрелгәнме? Син монда татар хатын-кызлары әхлакый яктан үрнәк булсын дип тырышып йөр дә, менә сиңа мә, йөрәгеңә үк терәгән хурлык таягы... Иптәшләр: «Төрмәгә бармасак та була», – ди. Ярый, комиссиягә Туфан абый Миңнуллин да сайланган, танылган драматург:

– Роза кызык эзләп йөрми, барабыз! Без ир-атларга караганда, аның сүзе үтемлерәк тә була, – ди.

Әй андагы хаталанган, абынган, сөрлеккән бичаралар... Алар дөньяны матурлар өчен яратылган нәфис затлар югыйсә.

– Мине аерым гына берәр хатын-кыз белән сөйләштерегез әле, – дигәч, төрмә башлыгы «дело»сы белән олы яшьтәге татар апасын китертә. И Аллам, утырып еларсың, баш түбәсендә ап-ак калфак. Хорда җырлыйм, ди. Комиссия әгъзаларына концерт күрсәтмәкчеләр икән. Каушый, сез мине озак тоткарламагыз, без сәхнәгә тезелә идек, ди.

– Без тамаша карарга килмәдек, апа җаным. Статьяң куркыныч, иреңне үтергәнсең икән? Әчтеме, кыйнадымы?

– Тырнак белән дә чиртмәде, мәрхүм. – Чандыр гәүдәле, ябык татар

карчыгы күзен тутырып-тутырып, аңа карый. – Таныдым төсле. Син Роза Туфитулловамы?

– Әйе, мин.

– Әгәр серемне сыйдырсаң, чын дөресен сөйләр идем, сеңлем.

– Сыйдырам, апа.

– Бабасын кияү суйды. Күз алдымда. Талаштылар да... Кызымның тормышы бозылмасын, парлы булып яшәсен, дидем. Балам хакына ялган күрсәтмә биреп, кияүнең җинаятен үземә алдым. Сигез елга хөкем иттеләр мине, сеңлем. Хурлыгы ни тора. Азнакайдан мин. Кешеләр «үтерүче» дип миңа нәфрәтләнәдер, апаем.

Карчык, битен каплый да сытылып-сытылып елый. Корыган агач ботагы кебек нәзек бармаклары арасыннан яшь саркый, гүя ул яшьләр Рәхмәтулла кызының йөрәгенә тама... Авыр! Ник алай эшләдең дип тиргәүдән ни файда?! Коткарырга кирәк, шул гына.

– Туфан абый, бер апаны иреккә чыгартыйк әле. – Кире кайтканда ук сер төенен чишә ул.

«Әниләр һәм бәбиләр» пьесасы белән татар Анасын илаһи биеклеккә күтәргән драматург та төрмәдәге хәлләрдән тетрәнгән. Гадәттә, ул юлда уен-көлке сөйләп бара иде, ә бүген җитди, куе кашлары бергә тоташкан. Калын күзлеге дә парланган.

– Да-а, – дип суза язучы. – Оештырдың син безгә экскурсия, Роза. Яз син моны. Гыйбрәт итеп.

– Юк, Туфан абый, мондый фаҗигаләрне тагын бер тапкыр йөрәк аша уздыралмам шул.

Бер мәлгә язучы, кайнарланып, чыбыркы шартлатып ала:

– Балам хакына диме? Сукыр ярату бит бу, җанкисәкләрем! Намазын укып, догасын кылып, йомшак түшәкләрдә ятып йоклыйсы әбиең кызым ир белән яшәсен дип, төрмәдә иза чигә! Коточкыч! Давай, коткарырга икән, коткарырга. Мин – «за». Комиссиядә карап, Президент исеменә хат әзерләрбез. Тынычлап йокла!

Вәгъдәсе нәтиҗәсенә берекмәсә йоклар сиңа Туфитуллова!

...Өч айдан редакциягә килә апабыз. Төенчегендә тарыдан пешергән кыстыбый. Әле дә аның күз яшьләре кипмәгән. Розаны кочаклап, тын гына елый, тик бусы шатлык яшьләре.

– Үләм дигәндә сез коткардыгыз, апаем. Күпме генә рәхмәт дисәм дә, әз, изгелегең мең өлешкә тапкырланып үзеңә кайтсын, апаем.

– Хәзер син дә тормышыңа куанып яшә, апа.

Карчык уфтанып:

– Куанырлыгым юк инде, сеңлем, – ди. – Мин төрмәдә чакта эзвир кияү кызымның канын эчкән, берсендә чүт үтермәгән, күршеләребез генә аралаган. Аерылдылар. Кызымның шуңардан тапкан баласын – оныкны яратмыйм түлке. Кияүнеке бит. Ничекләр яшәп бетәрбез, апаем.

Димәк, фаҗига дәвам итә... Ялгышларның койрыгы озын, бәндә артыннан сөйрәлә дә сөйрәлә икән.

Кайбер очракларда суд хөкемдарлары артык кырыслана бугай. Дәүләт казнасыннан миллиардлар чәлдергән караклар нишләптер судан коры чыга, ә өч тиенлек әйбер урлаган абый-абзыйлар күзгә кылчык булып кадала.

Марҗа хатынының комиссиягә язган хаты Рәхмәтулла кызын янә көрәш мәйданына ташлый. Күмәк хуҗалыктан рөхсәтсез-нисез дуңгыз алган өчен гаилә башлыгын җиде елга утырталар. Өйдә исә берсеннән-берсе кечкенә өч бала, эшсез авыру хатын. «Бер мыркылдык өчен шундый каты җәзага тартыргамы соң! Гаиләне харап иттермәгез, үтенәм, булышыгыз», – дип үтенеп, Россия ярлыкау комиссиясе рәисе язучы Александр Прохановка юллаган хаты, Алланың рәхмәте, чүп савытына ташланмый: кайта өенә «угры» агай, мөгаен, сабак алып кайта: «Банк басканга да, инә урлаганга да – каталашка икән. Моннан ары колхозның салам бөртегенә дә тимәм».

Әй язмыш, язмыш! «Җиде ятларның, ярдәм өметләнеп янгыр төсле яудырган хатларын күп укыдың. Ә монысына җавабың бармы?» – дип үртиме соң ул, беркөнне Президент Аппараты җитәкчесенең сәркатибе шалтырата:

– Роза Рәхмәтулловна, срочно килегез, сезне Халәф Мөхәммәдович чакыра!

Сине ни-нәрсә көткәне түрәнең күз карашыннан беленә. Каш астыннан гына сөзеп караса, һич уйламаган берәр гаебеңне казып чыгарып, бәгыреңә төшәчәк. Ә Халәф Низамовның йөзендә аптырау катыш көлемсерәү. Менә ул өстәл тартмасыннан конверт ала.

– Роза, синең Гадилә исемле апаң бармы? – ди түрә.

– Бар. Атна элек кенә хәбәрләштек. Әтинең апасы ул.

– Ире сугышта үлгән, ике кыз үстергән. Күченеп, авылда тора икән. Өе бик сәләмә, ди. Фронтовик хатынына яңа йорт төзергә беркаян ярдәм юк, ди. Туфитулловага бөтен җирдә ишекләр ачык, нишләп ул җитәкчеләр катына «туганыма булышыгыз дип үтенеп керми?» ди автор. Мин аның кем икәнен әйтмим. Ул хөрмәтле кеше, үзе дә сугыш ветераны. Нигә син безгә мөрәҗәгать итмисең? Сиңа бу кыен эшме? Безнең тарафтан район хакимиятенә бер звонок җитә.

«Кыен эшме?» Кыен, билгеле. Синең һәр адымыңны күзәтмиләрме әллә? Әнә, урыныннан файдаланып, «туганына өй салдырды, оятсыз!» дип җелеген киптерәчәкләр бит.

– Беркая да шалтыратмагыз... Халәф Мөхәммәдович, хатамны үзем төзәтермен. Апа өйле булыр.

...Төзелеш материаллары белән шыплап тулган ике «КамАЗ» машинасы Аксубай якларына кузгала. Миргалимнең юмартлыгыннан файдаланмый чараң юк.

«Автор дигәннән... Кызык та, кызганыч та хәл бит анысы. Энесе Рөстәм Зәйнуллин Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлагач, Ленино-Кокушкинога эшкә билгеләнә һәм бөтенләйгә әти-әнисен үзенә алдырта. Гомер иткән нигезеннән җиңел генә купмагандыр алар. Әмма еллар рәхимсез, картайтып, тычкан төсле кетер-кетер исәнлегеңне кимерә. Кичә син шау чәчәктәге алмагач идең, бүген – кайрысы туналган шәрә куак... Сугыш яраларыннан сызланган фронтовик атага даруы да, якында гына хастаханәсе дә, әлбәттә инде, тәрбиясе дә кирәк. Ә Рөстәмнең тормышы җитеш, агроном егетне ярты елдан кошчылык фабрикасы директоры урынбасары итеп билгелиләр. Иң сөендергәне – Розаларга якын. Атна саен кадерле картлачларың белән күреш! Әтисе бигрәк тә Миргалимгә шат:

кияү белән сөйләшсә – дөньясы түгәрәкләнә. Берсендә Роза Питрәчтән кайтышлый Кокушкинога сугыла. Бусагадан ук әнисе:

– Гөлназ белән Айдар оланнар кая соң? – дисә, әтисеннән гадәттәге сорау:

– Миргалим юкмыни?

– Әти, киләсе ялда сезне үзебезгә алып китәрбез, киявең белән туйганчы чөкердәшерсез, мин юл уңае гына кердем.

– Ашыкма әле, кызым. Карчык, син чәй куй, безгә мишәйт итмә. Розага сүзем бар. Исән чакта әйтәсен әйтим, гомерләр бик кыска.

Картаймыш көннәренә хәтле күңелендә ниләр асраган соң әти кеше?

– Роза, мин сезгә – балаларыма кырысрак булдым. Безнең заманда ир-атлар оланнарын тезенә утыртып иркәләми иде. Кара эштә ватылып катыландык без. И-и хәзерге ирләр! Баласын имезми генә! Коляска тартып, урамда йөри, юеш чүпрәген алыштыра, имезлектән ашата.

– Әй, әти, сезнең буын ир-атларының берән-сәрәне генә баласын ташлаган. Бүген әтисез үскән ятимнәр – ярты ил!

Әтисе аны ишетми төсле, ул үз коесыннан су тарта:

– Сиңа, мәйтәм, үскәндә күбрәк эләкте авыл нужасы. Баш бала дип эшләткәнбез инде, кызым. Әниең Розабыз потлы чиләкләр белән чишмәдән су ташый иде, ничек җилкә сөяге сынмады икән дип җәлләп елый беркөнне. Мине үзенә бер үкенеч көйдерә. Хәтерлисеңме, ташкурчакка кызыккан идең. Якташлардан бурычка акча җыеп ал гына да шуны. Кырыс идем шул мин.

– Үзеңне битәрләмә, син кырыс булсаң да... мәрхәмәтле идең, әти.

Әтисе күңел коесына соңгы чиләген төшерә:

– Карыйбыз әнкәң белән, телевизордан Туфитуллова фәлән-фәләнгә булышты дип рәхмәт укыйлар, радиодан сөйлиләр, гәҗитләрдә мактыйлар. Чит-ятны кайгырта, мәйтәм, туганына шымытыр. Тоттым да Низамов иптәшкә хат яздым. Ачуланма инде, Роза.

«Баш бала» елмаеп:

– Ул кыю авторның син икәнен белдем инде мин, әти. Ачуланмыйм. Дөрес иткәнсең, – дигәч, карт җиңел сулап куя.

...Газизкәйләре куанып, җәннәти ояда яшәгәндә генә кара болыт сыман ишелгән кайгы туганнарны аяктан ега: кырык бер яшендә йөрәк белән Рөстәм энекәш якты дөньялардан китә...

Розаның күз алдында мәңге җуелмаслык сурәт кала: кечерәеп, урталай бөгелгән ике гәүдәнең көл сыман агарган йөзе, нуры сүнгән күзләре...

Бала хәсрәтеннән бәгырь җепселләре шартлап өзелгәндер, озакламый әтисе дә гүр иясе була...

«Кортка, сине кайгы утында яндыра-яндыра гомереңне озайтам. Киләчәктә сиңа олы кызың адәм ышанмаслык бер хәбәр китерер. Көт!» – дигәнме әллә Аллаһ, әнисенең гомерен туксанга җиткәндә генә чикләр мәлик әл-мәүет.

## 12. «Балалар өлешенә кермәгез!»

– Можномы?

Туфан абый! Тайга хуҗасы аю кебек кызыл келәм җәелгән баскычтан дөп-дөп басып менәр, аның тавышыннан Дәүләт Советы бинасының түшәмнәре

селкенер. Көн дә шулай: ул «яшь депутат»ның хәлен белешә. Аларны бәйләгән дуслык җепләре нык, чөнки дошмани затлар әйтмешли «икесе дә тел, милләт тегермәненә су коя». «Татар кызы» дигән нәсеренең башына драматург «Танылган җәмәгать эшлеклесе, журналист, «Сөембикә»нең баш мөхәррире Роза ханым Туфитулловага багышлыйм» дигән. Рәхмәтулла кызының илле яшенә, орден-медальләрне төссезләндерерлек бүләк иде ул! Роза аны талисман итеп әле дә саклый. Нәсернең һәр җөмләсендә татар кызын олылау һәм хөрмәтләү!

«Бу язмамны ике бала анасы, ир хатынына багышласам да, мин аны «Татар кызы» дип атадым. Чөнки татар кызы дигән сүз, минем өчен, җыелма образ буларак, тирән мәгънәгә ия. Татар кызы дигәндә, мин һәрвакыт инсафлы, чибәр, акыллы, пөхтә, чая, сабыр, өзелеп ярата һәм яраттыра белгән асыл затларны күз алдына китерәм».

«…Татар кызы! Тарих сәхифәләрен кат-кат актарып, Синең язмышың турында уйланганда, Сиңа сокланып туя алмыйм. Әнә Син ат өстенә менеп алгансың да, ирекле кош булып, иксез-чиксез далалар буйлап җилдерәсең, әнә иң биек тауның иң биек түбәсенә баккансың да илеңнең иминлеге сагында торасың. Синең ирең – ил башы, тәхетендә утырып, ил агалары белән чит мәмләкәттән килгән илчеләр белән дөнья хәлләре турында сөйләшкәндә, бәхәсләшкәндә, Син аның янәшәсендә утырып, акыллы киңәшләреңне биргәнсең. Син ханбикә булып, Илне үзең идарә иткәнсең».

«...Татар кызы! Син һәр чорда татар гаиләсендә әхлак нигезләрен саклаучы хуҗа булдың. Ирне ир итә белү серләрен Син тумыштан ук белә идең. Шуңа күрә башка милләтнең бик күп зыялы ирләре Синең кулыңны сорап килделәр. Син аларга даһилар үстереп бирдең. Кызганыч, әмма синең бу бөеклегеңне кайбер милләтләр оныталар. Югыйсә алар Сиңа һәйкәл куярга тиешләр иде».

«...Татар кызы! Син беркайчан да надан, томана булмадың. Үзең укымышлы булдың, балаларыңны укымышлы иттең».

«...Татар кызы! Син төрле дәрәҗәдәге мөнбәрләргә менеп, үз сүзеңне өзеп әйтәсең!»

Ике битлек нәсернең ахыргы юлларында кисәтү. Сине, мине, безне Татар кызларын!

«...Татар кызы! Синең колагыңа гына әйтерлек әрнүле сүзләрем дә бар минем. Ләкин аларны әйтеп күңелеңне яралыйсым килми. Минем өчен аларны сиңа әдәпле, аңлаешлы, акыллы, үтемле итеп әйтә белүче затлы кызларыбыз бар. Шуларның берсенә багышладым мин бу язмамны. Иң изге теләкләремне телим мин аңа!»

...Кәгазь өеменә чумган Роза документларын читкә эткәләп, урыныннан тора. Туфан абый ял иттермәсә, өстәленә берегер иде, мөгаен.

– Можно, можно, Туфан абый!

Шаяртуга каршы – шаярту.

– Халык депутаты ни эшләр бетерә? Каты җилдертәсең бугай, Роза!

– Мондагы проблемалар таныш бит, Туфан абый. Алар «Сөембикә» белән «Ак калфак»тан үзем белән ияреп килде.

«Ияртмәсәң ни! Тарткан йөгеңне бушатып калдырсаң ни! Тавык та чүпләп бетермәслек җәмәгать эшләреннән котылсаң ни!» Әгәр берәрсенә

зарланса, менә шулай тиргәлер иде ул. Чынлап та, көйләнгән-җайланган журналында гына эшлә дә... Ә ул сай җирдә генә йөзәргә теләмичә, һаман тирәнгәрәк керә... Гаделлек белән дөреслек тирәндә – төптә ята, аны өскә чыгарып күрсәтәсе-аңлатасы, без бит упкынга тәгърибез дип, чаң сугасы килә. Халык эчтән җимерелә: гаиләләр таркала, «гражданский брак»лар модасы башлана, ирләр «зәңгәрләнә», ятимнәр арта, коточкыч диагнозлар белән авыру һәм гарип балалар туа. Сөрәсе «басу» җиде кат туфракка кадәр туңып каткан, аны йомшартыр өчен биниһая көч, түземлек, үҗәтлек, хәтта ки кайбер очракларда киребеткәнлек кирәк булачагын белсә дә, Рәхмәтулла кызы депутат роленә ризалаша. Татарстан Югары Советына сайлаулар вакытында кандидатларның күбесе үзенең программасын гомуми сүзләр белән чуарлаганда, ул, яшәешнең төп нигезе – икътисад, дип тәкрарлаган кайбер җитәкчеләрнең баш мие эшкәртә алмаслык шигаре белән шаккатыра: «Кеше – табигатьнең таҗы, кешенең таянычы – гаилә, бишеге – туган җир». Сөрәсе «басуы» – социаль мәсьәләләр, балалар һәм яшьләр эшләре комиссиясе, аның рәис урынбасары да әле... Икеләтә җаваплылык! Җиңеңне сызганып, кайсы өлкәдән башларга соң? Демография хәлләре Розага күпмедер дәрәҗәдә таныш, әмма бәллүр «савыт» болай ук чатнап ватылган дип уйламый ул. Элекке чакырылыш депутаты, батыр йөрәкле ханым Сүрия Усманова аны сессияләрдә кузгатып карый, тик әлеге дә баягы «аңа акча каралмаган» белән авыз томалана. Бер фактны ачыклый «яшь депутат»: илдә туучылар санына караганда үлүчеләр күбрәк икән! Менә сиңа киләчәкнең фаҗигасе! Йа Аллам, зур-зур саннарны кем җәмәгатьчелеккә белгертсен, ди! Билгеле, кәгазьдән кәгазьгә күчеп, алар кечерәя һәм соңгы отчётларда лупа аша да күренмәслек ноктага әверелә: «Иптәшләр, безнең хәлләр шәп икән лә!»

Әүвәл ул «досье» туплый. Монда да «мә» дип тормыйлар, республиканың Статистика идарәсе әйтерсең чынбарлыкны «совершенно секретно» дип, сейфка бикләгән, мәгълүматларны таныш-белешләре аша Россия Сәламәтлек саклау министрлыгыннан соратырга туры килә. Парламент тыңлауларына демография мәсьәләләрен куйдырткач, районнардан сайланган берничә хаким депутат анда катнашмый. «Туфитуллова үҗәт кеше, әллә ниләр казып чыгара». «Кычытмаганны кашый» диючеләр аңлыймыни! Яра бит бу, чарасын күрмәсәң – үлекләячәк яра! Шөкер, теләктәшләре Туфан Миңнуллин белән Индус Таһиров аны «кыйнарга» ирек бирми. Индус Ризак улы:

– Әлеге җитди проблеманы без Конгресста ук ассызыкладык. Бу Роза ханымның титаник хезмәте, җентекләп өйрәнде ул аны. Без галимнәр, фән эшлеклеләре, педагоглар, тарихчылар, табиблар фикерен дә ишеттек. Докладчының сүзләренә игътибар итмичә ярамый, – дисә, Туфан абый кискен генә:

– Бәлки биредә демографиянең эчтәлеген аңлаучылар юктыр, җәмәгать, – ди. – Роза Туфитуллова иң авырткан җиребезне ачыклаган, әйдәгез, чирне яшермик!

Бюджет дигән түм-түгәрәк тәмле «бәлеш» сессия табынына куелгач, һәр тармак зуррак һәм майлырак кисәкне үзенә бүлдерергә тырыша. Чү, агайлар, «үҗәт кеше» нәрсәләр әзерли икән, кайсыгыз белә? Әллә ул

парламент тыңлауларыннан соң тынычланып калганмы. Тынычланмаган! «Бәлеш» гадел бүленмәсә – сүз эзләп, кесәгә кермәс! Сессия башланганда, ярдәмчесе аңа ялвара:

– Роза Рәхмәтулловна, сез миңа ниндидер чуман-чана турында әйттегез! Тагы шуны чыгып сөйли күрмәгез! Сезне коллегаларыгыз аңламаячак. Озын телле дип, җитәкчеләр бүтән депутат итеп сайлаттырмаячак.

«Алай эшләмә, болай эшлә», дигән киңәшләрне үз гомерендә күп ишетә ул, әгәр барысын да тыңласаң, өеңдә генә посып утыр. Менә сиңа «бәлеш»: Буа спирт заводына миллионлаган-миллионлаган акча, ә «Татарстан балалары» программасына – сукыр бер тиен. Монда ничек түзмәк кирәк! Рәхмәтулла кызы трибунага чыгып баса:

– Японнарда гына түгел, бездә дә шундый риваять яши, – ди депутат ханым. Зал тып-тын... – Берәү картайган әтисен чуманга, чана инде ул безнеңчә, утыртып урманга адаштырырга алып бара. Ирнең җиде-сигез яшьләрдәге малае:

– Әти, кире кайтканда чуманны онытып калдырма, картайгач, ул сине илтергә кирәк булачак, ди. Башыма сыймый, спирт җитештерүне үстерү балалар язмышына караганда мөһимрәкмени?! Әгәр бюджет кабул иткәндә сабыйларны ярык тагарак янында калдырабыз икән, безне дә чуманны яңадан алып кайту афәте көтә. Балалар тумаса, яшь буын турында кайгыртмасак, киләчәктә кем кулына калабыз? Бүген үк пенсионерлар җәмгыяте төзеп ятабыз түгелме соң?! Әйдәгез, балалар өлешенә кермәгез!

– Ну син маладис, – ди соңыннан Туфан Миңнуллин. – Тәки спирт заводының акчасын кистереп, балаларыңа өстәттең.

– Әй, Туфан абый, елап сөйләдең, диләр миңа. Еламадым мин, гаделсезлек күңелемә тиде. Ир-атлар аудиториясендә чыгыш ясау җиңел түгел. Әле алда карурманнар ерасы бар. Ике закон проекты әзерлим, шуларны үткәрәсе иде. Бездә медицина хәерчеләнгән, гади халык чит ил клиникаларында дәвалана алмый, чирләсә, аңа үзебезнең табибларга килеп егыласы.

Һай, ишекләре икешәр катлы кабинетларны ачу белән «без проблем!» дип, итәгеңә миллионнар салсалар икән! Татарстанның барлык балалар тудыру йортларына кайтартылган егерме өч миллионлык УЗИ аппаратлары, балалардагы лейкоз авыруын дәваларга утыз биш миллион акча могҗиза белән күктән төшми, әлбәттә. Розаның ашалган нервысы хисабына табыла. «Кыңгырау тагылган депутат» диярсең, тавышы әллә кайларга хәтле чыңлый: «Дәүләт Советында Туфитуллова фамилияле тынгысыз хатын бар, ул нәрсәгә генә тотынса да, очлап чыга, ди». Валлаһи газыйм, әкиятләрдәге тылсым иясе! Финанслау җитмәү сәбәпле, республика перинаталь үзәге төзелеше тукталган. Баш табиб йөгерә депутат Роза янына: «Сез – соңгы өметебез!»

Кайчакта җитәкчеләргә дежур сүзләр чеметем дә тәэсир итми. Күрәсең, алар да рәсмилектән туядыр. Ә татар телендә туң йөрәкләрне дә эретерлек гыйбарәләр дөнья хәтле!

Шуның берсеннән, мөгаен, Премьер-министрның күңеле хушлангандыр.

– Ханнан бала олы, баладан ана олы, Рөстәм Нургалиевич. – Менә хәзер иплəп кенә йомышыңны йомышлыйсы. – Перинаталь үзәкнең функциясе

башка хастаханәләрдән аерыла. Анда катлаулы диагноз куелган көмәнле хатыннарны китерәчәкләр. Аларны исән-имин бушандырасы иде бит. Зинһар, бу мәсьәләне гадәттән тыш хәл дип карагыз әле!

Рәхмәт, хөкүмәт җитәкчесе шунда ук финанс министрына боерык бирә. Киләчәктә бу үзәк тарихына кемнәр исеме язылыр соң? Андыйлар табылыр... Бездә теле белән алдан, «эше» белән арттан чабучылар әзмени! Ә ул каядыр исемен теркәтер, каядыр сурәтен мактау тактасына элдертер өчен алар арасында буталмас. Бәлки бу аның ялгышыдыр, ә? Үзәкнең соңгы кадагы кагылмыйча тынычланмаган, көн дә тикшереп торган депутатны ачылыш бәйрәменә чакырмыйлар! Кунаклар исемлегендә Роза Туфитуллова юк! Хәтерсезлекме? Тантана мәшәкатеннән зиһеннәре таралганмы? Берәр әрсезе чакыру-фәлән көтмичә: «бу мин!» дип күкрәк киереп күзләренә кадалыр иде!

Дөп-дөп, Туфан абый баскычтан менә. Әрләвен күр син!

– Роза, нишләп син мондый чараларга йөрмисең? Без җыйнаулашып бардык менә.

Әле гарьләнү бетмәгән...

– Мин – кечкенә кеше, сез йөрегез, Туфан Абдуллович!

– Әһә, Абдулыч... – Коллега калын пыялалы күзлеген сөртә. – Абдулыч алайса. Туфан абый дип йомшак кына әйткәнеңне яратам мин. Кәефең ник кырылганын чамалыйм. Үзәк ачылу тантанасында лентаны син кисәргә тиеш идең. Вәт башсызлар, кәләштән башка гына туй уздырдылар. Сине рәнҗетсәләр, иманнарын укытырга да күп сорамас Мәрәтхуҗа егете. Давай, яса әле миңа сөтле чәеңне!

...Иманнарын укытмас анысы Туфан абый, әмма телефоннан гына «якаларыннан тотып селкер». Берничә сәгатьтән Сәламәтлек саклау министры Камил Зыятдинов шалтыратыр.

– Роза Рәхмәтулловна, кичерегез! Безнең мәгънәсезлек бу! Хатабызны төзәтәбез. Без бит сезнең белән әйбәт мөнәсәбәттә. Дустанә калыйк!

«Дустанә калыйк...» Ләкин демография буенча парламент тыңлауларындагы фикерләр каршылыгы, фикерләр бәрелеше араларны суыта кебек. Министр үзенең чыгышында күккә «чөйгән» тәти саннарны Роза тар-мар итә ләбаса.

...Икенче көнне Дәүләт Советына үзәктән чәчәк букетлары күтәреп, тулы бер «делегация» килеп ята. Хата төзәтергә! Ярдәмчесе тузынып: «Кабинетыгызга кертмәгез, рәхмәтләрен кичә бәйрәм вакытында әйтсеннәр иде», – ди.

Борын төбендә генә ишекне ябаргамы?

## 13. «Бер сүз әйт син татарны яклап, ике сүз әйт!»

...Өстәлдә нибарысы кәгазь белән каләм генә...

«Җитәкчеләр сезне бүтән депутат итеп сайлаттырмаячак». Юкка борчылдың, ярдәмчем? Ул анда үз теләге белән ыргыламыни, ә? Шунысы гына тәшвишләндерә: берүк ятим һәм авыру балалар хакын хаклап төзегән закон проектлары тукталмасын. Бүгеннән кичәге «кыңгыраулы» депутат азат! Кайберәүләрнең төртмәле сүзләреннән, ачулы күзләреннән, чытык йөзләреннән, кырын карашларыннан... Барысы да һәр гамәлеңне хуплаган

Туфан, Разил, Робертлар түгел шул. Үзе өчен янса-көйсә икән! «Усал хатын» дигән даны шәт ДәүСовет диварларына сыланып калгандыр. Озакламый сөртелер анысы. Аңа язарга вакыт!»

Өстәлдә нибарысы кәгазь белән каләм генә...

Иҗат кешеләренә мөкиббән киткән, аерата язучылар белән танышып-дуслашкан, алар белән аралашырга, сәгатьләр буе гәп корырга яраткан Миргалим, Розасының ничекләр каләм тансыклавын күрә һәм аның өчен борчыла, җәмәгать эшләрен ташла да, әдәби әсәрләр яз дип тә үгетли, хәтта ки бистәдә йорт тергезеп, эш бүлмәсе дә ясаттыра. Биек-биек хан сарайлары янында Туфитулловларның өе җыйнак кына, бәләкәй генә. Хикмәт зурлыктамыни, җаныңа җайлы булсын. Җан бит ул тарсынып иксез-чиксез галәмгә дә сыймаска мөмкин. Балалар белән оныклар шат: үзләре кунакка киләме яисә әни – дәү әни аларга барамы, ул буш!

Иртәрәк куанышканнар икән. Россия җәмәгать палатасына Татарстаннан вәкил сайлау конкурсына Рәхмәтулла кызын да кертәләр. Кырыклап оешма үз кандидатурасы өчен көрәшә икән. Конкурстан үткәрсәләр дә, бармаячак.

Кем белән үз туганыдай якын күреп киңәш-табыш итсен, әле дә мәгарәдәге акыл иясе – Туфан Миңнуллин бар! ДәүСоветта Разил Вәлиев белән аларның бүлмәсе кара-каршы, ике милләт әйдаманы берьюлы ишеген ачса, маңгайга-маңгай бәрелерләр кебек. Разилнең дә күңеле киң, тыңлар, боргаламый-сыргаламый үз фикерен белдерер. Ачуланмас! Ә Туфан абый орышыр, ләкин аның орышуы мактау белән бер дәрәҗәдә: күңел кителмәс.

– О-о, экс-депутат! Безне сагынып килгәнсең, ахрысы. Сагышың күзеңнән тама, – дип, гадәттәгечә, уен-көлке белән каршылаган Абдулла улының вакытын «урламас» өчен (кабул итү бүлмәсендә тагын өч кеше депутатка чират тора) Роза ханым «үгезне» мөгезеннән эләктерә:

– Россия Иҗтимагый палатасына тәкъдим итсәләр, баш тартырга уйлыйм, миннән лаеклырак иптәшләр күп Татарстанда. Сездән «дөрес эшлисең» дигән сүз ишетмәкче идем.

Туфан абый кулындагы каләмен әйләндереп, өстәлдә «биетә». Менә хәзер ул:

– Ихтыярың, Роза. – дияр. – Аргансыңдыр, инде үзең өчен яшә, – дияр. – Әй, – дияр сиңа!

– Синме соң бу, Аксубайның чая, батыр мишәр кызы?! Сине алмаштырмаганнардыр бит? Ничек баш тартасың? Барасың Мәскәүгә! Безнең милләтне төрле яктан таптарга маташалар, әгәр без тәгәрмәчләренә таяк тыгып тормасак, изеп-сытачаклар. Палатада бер сүз әйт син татарны яклап, ике сүз әйт, безнең халыкның барлыгын, зурлыгын искәртеп, теңкәләренә тиеп бет. Синдә дипломатия көчле, ул яктан да алдырт.

– Барасың дисез дә, монысын кичермәсләр инде. Тагын аңа дан җитми, карьеристка икән, диярләр.

– Кемнәр? – Туфан абый өстәл кырыендагы киң яфраклы гөлләренә инде икенче тапкыр су сибә. – Булдыксызлар, мескеннәр, ялкаулар, вак җаннармы? Маһы бирмә! Әңгәмәләреңдә: мин бу урынга кирәклегемне тоеп бардым, дип чатнатып сөйлә. Алдан ук вазифаң белән котлыйм, Роза бырат!

Илбашы исә Туфан сыман үгетләми, аның сүзе кыска:

– Анда сезнең кебек милли мәсьәләләрне яхшы белгән тәҗрибәле кеше кирәк.

«Кирәк... Кирәк...» Югыйсә ул каләменә ныграк кирәк! Кардәше Хәсән ага Туфанның котылгысыз мәхәббәтләре турында язам дия-дия гомер узмасмы? Нәрсә соң ул котылгысыз мәхәббәт дип аптырар укучы. Шагыйрьнең Лулуны югалтканнан соң кичергән самими хисләре имеш-мимешләр йомгагына гына чорналган, җебен чуалтмыйча шуны сак кына сүтәсе дә сүтәсе.

...«Тотса мәскәүләр якаң...» И әүлия Тукай.. Синең теге гасырда ук кисәткән сүзләрең һаман искерми. Якасыннан тоттырмыйсы иде Розага. Җәмәгать палатасында җәмгысы йөз егерме җиде әгъза, кырыклап милләт вәкилләре. Рәхмәтулла кызын Мәдәни һәм рухи мирасны саклау комиссиясенә билгелиләр. Утырышлар залында һәркемнең шәхси урыны. Уң ягында Лев Толстойның ничәнчедер буын оныгы Владимир Толстой, сул ягында Михаил Шолоховның улы – Михаил Шолохов. Ике даһи язучының нәсел дәвамчылары «без кем» дип эреләнми, һаваланмый. Ялларга Казанга кайткан хатынын еш кына озата бара Миргалим... Иртән Мәскәү вокзалына «Татарстан», ә унбиш минуттан «Тихий дон» поездлары килеп туктый. Шолоховның улы белән ирен ни-нәрсә дуслаштырганмы? Әдәбият! «Сезнең әтиегезнең «Тихий дон» әсәрен Гариф Ахунов татарчага тәрҗемә итте», дигәч, и, Михаилның сөенүләре! «Әти әле озак яшәр иде, – ди ул. – Көнләшеп, йөрәк итен чукымасалар тагын берничә роман язасы иде». Бу дуслык палатадан киткәч тә дәвам итәчәк: Михаил Роза ханымны өч тапкыр язучының туган җиренә – «Шолохов укулары»на чакырачак. «Сезнең кебек риясыз татар дусларым булса иде», – ди ул бер шалтыратканда.

Ә менә татарны вак-вак төркемнәргә бүлгәләп, тарих битеннән сызарга хыялланган Толерантлык һәм намус иреге мәсьәләләре комиссиясе рәисе, этнограф Валерий Тишков белән «ботка пешми». Күрәсең, ул бу ханым ике елын театрларда спектакльләр карап, музейларны тамаша кылып, кибетләрдә йөреп һәм палатадагы хатын-кызлар белән кафе-рестораннарда күңел ачып уздырыр дип уйлагандыр. Кыяфәте дә, әкрен генә, ашыкмыйча гына сөйләшүләре дә аның басынкы, күндәм икәнен күрсәтә, янәсе. Җыелышларда да дәшмәс, бүтәннәр фикеренә пичәт сугып шыпырт кына утырыр, янәсе. Хактан да, «күрсәтә» Роза Туфитуллова, тик гел киресен күрсәтә. Мәдәният турындагы закон проектларына егерме ике төзәтмә кертеп, комиссиядән дә, палатадан да үткәрттерә. Тышкы кабык ни, эчтә татар кызының ялкыны, эчтә! Нинди генә мәсьәлә каралса да, аның чыгышы әзер һәм ул чыгышларда татар дөньясы, татар тарихы... Колгали, Кашгарый, Мөхәммәдьярлардан башланып, Тукай, Такташ, Җәлил, Алишлар дәвам иткән меңьеллык татар әдәбияты. Россиядә күпмилләтле халык, алар тигез хокукка ия, берәү дә үз Ватанында килмешәк тә, артык җан да түгел, беркем дә «иноверец» дигән мыскыллаулар ишетеп яшәмәсен! Россия халыклары телендә гомумроссия телеканалы һәм радиостанциясе оештырырга дигән пункт юкка чыккач, Роза Тишковка:

– Мин сездән бу пунктны кире кайтаруыгызны таләп итәм! – ди.

Кайсы комиссиядә милли мәсьәләләр карала, Рәхмәтулла кызы шунда катнашырга тырыша. Берсендә Тишков:

– Без сезне чакырмадык, – ди.

– Ә мин чакырмасагыз да керәм, сездән рөхсәт сорап тормыйм.

Ике ел буе татарны күпсенгән кешегә «каныга» Роза ханым. Тишков күрше бүлмәдә генә, форсатны кулдан ычкындырма!

– Нигә сез шул хәтле татарларны яратмыйсыз, Валерий Александрович?

– Сез керәшеннәрне аерым милләт итеп танымыйсыз.

– Без – бер халык! Хәзер милли мәсьәләләрне этнографлар хәл итәмени? Сез – тарихчымы? Урыныгызны белегез!

– Керәшеннәрем әледән-әле зарланып, миңа хат яза, Роза Рәхмәтулловна!

– Гафу итәсез, алар сезнеке түгел, безнеке!

– Ә нишләп сезгә – татарларга гына мөстәкыйльлек кирәк? Башка милләтләр тып-тыныч.

– Онытмагыз, Россия дәүләтен күпчелек татарлар төзегән.

Тамчы тама-тама ташны тишә, диләр. Татарны күралмаганнар таштан мең тапкыр каты, кәйлә белән чокысаң да тишелмәс, ләкин баш миләренә әзрәк шом салыныр: «татар ничә гасыр көрәшә, татар бирешми».

Инде Рәхмәтулла кызы Мәскәү белән саубуллашкан, инде ул гап-гади пенсионер, этнограф абзаң Казанга килгәч:

– Мине Роза Туфитуллова белән очраштырсагыз иде. Палатада ул миңа каршы төшкән, минем белән бәхәсләшкән бердәнбер оппонентым иде, – ди.

– Минем аның белән сөйләшерлек уртак сүзем юк, – ди Роза.

– Ул хатыны белән үзе өегезгә килмәкче. Үтенәбез, каршы алыгыз, – диләр.

«Чакырылмаган булса да, капкаңа орынган кешене өеңә керт, алдына тозикмәк куй», – дияр иде Мәликә әбисе. Татар киң күңелле шул! Миргалим ирле-хатынлы Тишковларны бакчада һава сулатып йөрткәндә, хуҗабикә телеңне йотарлык өчпочмаклар пешерә. Этнограф Мәскәүгә кайткач, мөфти Равил Гайнетдингә:

– Кай арада камыр ризыгы әзерләп өлгерде икән ул? – дип шаккатып сөйли.

Балачакта апасының «сәерлегең бар» дип әйтүләре дөрескә чыга, ахрысы. Саубуллашканда исә Тишков Розага:

– Милләттәшләрегезнең байтагына сездәге кебек татар җаны җитми, – ди.

Кайсыларына? Ана телен оныткан, ата-баба динен алыштырып, иманын саткан татарларда, гомумән, җан бармы икән соң ул?!

## 14. Котылгысыз мәхәббәт...

«Милләт хадимәсе»ниләр бетереп ята?

Милләт хадимәсе... Монысы шагыйрь Равил Фәйзуллин кушкан матур «кушамат». Розаны зурлап һәм бәяләп! Безнең татар ниләр эшлисең дисә, гадирәк булыр, ди, бугай, телгә бай бит без, ниләр бетереп ятасың дип сорауга киңрәк мәгънә салабыз. Ул сорау әллә ничә тармаклы: ничек яшисең? Ниләр уйлыйсың? Ниләр кырасың? Яшәгәне, уйлаганы, кырганы – шагыйрь Хәсән Туфан! Аның мәхәббәте турында ничек язарга – шул

хакта озак баш вата Роза. Бу четерекле эшкә ашык-пошык тотынырга ярамый: Каләм Хәсән абый үзе гашыйк яисә аңа гашыйк кызларны күкләргә чөеп, буявын сыеклатмасын, танылган рәссам, мөгаен, киндергә иң башта шагыйрь сурәтен ясар, аннан соң гына арткы планда аны тулыландырган йөзләрне сызгалар. Сызгалар гынамы, һәркайсына җан өрер. Алар исә төрле-төрле, бер-берсенә охшамаган. Аларның яратуы да төрле-төрле. «Ничек язарга?» дип баш кына ватарлыкмыни монда! Ничек хакыйкатькә хилафлык китермәскә? Шунысы да уйлата лабаса! Яшь Туфанны чордашлары шагыйранә матур иде дигәннәр. Ир уртасы яшендә дә ул матурлык җуелмый. Шагыйрьләр ямьсез булмыйдыр ул, Җиркүкләр хуҗасы аларны хиссиян нур белән коендырып, дөньяга тудырадыр. Адәми затлардан аерып, серле дә итәдер ул аларны. Хәсән Туфанның җиде кат йозакка бикләнгән сер сандыгында ниләр саклана – аңа гашыйк чибәрләрнең шуны ачып актарынасы килмимени? Җитмәсә шагыйрь әүлиялар өммәтеннән, күләгәсе ышыгында басып кына торсаң да, аңардан сирпелгән нурга коенасың. Сөргендә ялгыз Туфан... Япа-ялгыз... Кыстыйлар бит аны, берәрсенә йортка кер, диләр, авылда сугышта ирләрен югалткан тол хатыннар яшертен генә аңардан наз-сөю дә өметләнә, ләкин шагыйрь аларга битараф, чөнки Казанда Луизасы бар. Тик анда аны көтмиләр шул инде, сөйгәне вафат, әйтерсең соңгы истәлеге: бәләкәй редикюльдә кан тапшырган кәгазьләре... Менә нинди акчага ул авызыннан өзеп, төрмәдәге Хәсәненә посылкалар җибәргән икән.

...Сыкратып-сызландырып, тормыш дәвам итә. Шагыйрь тугры дуслары һәм берсеннән-берсе чибәр туташлар чолганышында... Аның котылгысыз мәхәббәт җәтмәсенә эләгүе табигый: ул корычтан коелган һәйкәл түгел лә, ул – тере җан! «Хәсән абыйны рухи яктан нәкъ менә хатын-кызлар күтәрде», – язучы башта ук әсәргә шундый оеткы сала. Лүзия, Клара, Гөлсемнәр шагыйрьне иҗат итәргә илһамландырган һәм Туфан шул чорларда гаҗәеп шигырьләр язган. Розага сенсация кирәкми, ул чәчәк таҗларына кунган күбәләк кебек гүзәлкәйләрнең хисләренә сак кына, бик сак кына кагыла.

Әсәргә җим җыяр өчен озак кына сөйләшеп, үткәннәрне искә алып утырганда, Гөлсем апа:

– Роза, мин Хәсән абыйны үлеп яраттым, тик син мин әйткәннәрнең чиреген генә керт, зинһар, тирәнгә кермә, язма бөтенесен дә ачыктан-ачык. Мин бит Әхмәт абыең Исхак хатыны бүген, ул да шагыйрь, аңардан да куркам, – дип үтенгәндә, ничек капчыгыңны дөньяга чыгарып селкисең! И, ул телевидение режиссёры Гөлсем Билалованың чибәрлеге, и ул зәвык белән киенүләре! Гүзәл ханым «җылы тәнеңдә тузсын», – дип теләк телители Туфанга җылы свитерлар, шарфлар бәйли. Шагыйрь тапшыруга килсә, пультка кереп, аның тавышын тыңлый да:

– Менә, рәхәтләнеп еладым әле, – ди.

Клара-Тәнәкә белән Туфан-Искәндәр мәхәббәте анысы инде качупочулардан азат. Анысының кайтавазы озак елларга сузылыр, феноменаль хәтерле Клара ханым: «Мин Туфанны үзе онытып бетергән шигырьләрен ятлап караттым. Ул чагында Хәсән абый ялгыз иде, ялгызлыктан интегеп яшәгән чагы иде», – дип искә төшерер.

Әйткән идең: «Әгәр сөя калсаң
Миннән башка берәр бүтәнне,
Сөй... бары тик миннән яхшыракны,
Сөймә ләкин миннән түбәнне».

Юлыктым мин, Лулу, бер чәчәккә,
Көтмәгәндә, уйламаганда.
Нәкъ синдәйгә, синең шикеллегә,
Әйтерсең лә синең дәвамга...

«Нәкъ синдәйгә» – ул үзенә җитмештән артык шигырь багышлаткан Тәнәкә!

Каләм сынатмый, «Бәйлисе бар йөрәкне» дип аталган мәхәббәтнамә, ниһаять, укучы кулында. Яшерен әйбер, гадәттә, кызыксыну уята. «Ни бу? Нәрсә бу?» – ди кеше. Әсәрне укыгач, кемдер соклана, кемдер битараф кала, ә кемнеңдер ачу ташы чыжылдый.

– Роза ханым, мин сезне моңарчы хөрмәт итә идем, – дип, бер журналист шул ташка беренче су бөрки. – Сез Хәсән абыйдан секс-бомба ясагансыз!

Роза ханым аклансынмыни инде? Ркаил Зәйдулла әйтмешли: «Безнең күбебез шагыйрьнең музасы берәү генә, бердәнбер генә була дигән күрсәтмәгә күнеккән».

Әнә икәүне кәрзин тоттырып, Җир шары буйлап чыгарып җибәргәннәр, ди. Аларның берсе чүп тутырып кайта, берсе – аллы-гөлле чәчәкләр... Кем нәрсә күрә!

«Роза! Халкыбызның бөек улы, горурлыгы, эталоны Хәсән ага Туфан турындагы «Бәйлисе бар йөрәкне» дигән китабыгызны бер сулыштан укып чыктым. Бу бәяләүгә лаек хезмәт. Сезгә зур рәхмәт! – Отставкадагы хәрби Рубис Зарипов «кәрзинендәге» чәчәкләр. – Хәсән Туфанның гаилә фаҗигасе минем тормышым белән дә бәйле кебек. Егерме дүрт ел бергә яшәгән сөекле хатыным, беренче һәм мәңгелек мәхәббәтем Рафиям рактан мине ташлап китте. Күзен йомар алдыннан: «Рубис, мин сине һаман сөям», – диде. Аннан башка, нәкъ Туфанча, газапта яшәдем. Өйләнеп тә карадым, зур мәхәббәткә берсен дә ябыштырып булмый икән. Хәсән абый ул җылы эзләгән, ләкин тапмаган...»

Язучы Марат Әмирханның күләмле бәяләмәсе исә: «Автор бик нәзакәтле теманы үзенә генә хас нәзакәтлелек белән ачуга ирешкән.

...Безнең өйдә моңа кадәр дә «Юксындырсаң, нишләрмен» җыры көн саен яңгырый иде. Әлеге китап аны яңа сихри төсмерләр белән баетты.

Сөбханалла, Роза ханым, күз тимәсен, сөендердең», дип тәмамлана.

...Шакмаклы дәфтәргә эре-эре хәрефләр белән кулдан язылган чираттагы хатның җылысы, мөгаен, озак еллар сүрелмәс. Аның көне-сәгатенә хәтле билгеле: «21 июнь, 2012 ел, Мәскәү – Алехново». Ул диңгезче-әдип Миргазиян Юныстан. Роза ханым күз алдына китерә: менә язучы дәфтәр битен икегә бөкләп, конвертка тыга, менә нык адымнары белән Җир шарының үзәгенә басып, почта тартмасына илтә, менә тартманың уентыгыннан хатны аска шудыра... Йөзендә сөенеч... Әйе, әйе, сөенеч! Ул бүген җаны теләгән эш эшләде. Ә бит аның «усал телле» дигән даны бар. Кайберәүләрне, исем-дәрәҗәләренә карамыйча, өтә-яндыра диңгезче

Миргазиян! Аның «Идел» журналында басылган «М.Кәримнең изге горурлыгы» дигән тәнкыйть мәкаләсен хәтерли әле каләм халкы. Мостай аганың:

> «Рус түгелмен, ләкин россиян мин,
> Россиянең суын эчкәнмен.
> Чагылларда имән ничек үссә,
> Үз җиремдә шулай үскәнмен,

– дигән шигъри юллары татар әдибенең саруын кайната.

«Роза ханым! Каләм кыймылдатучыларга илһам, иҗат дәрте бирә торган онытылмас Нәширә! – Нәширә! Нинди матур исем! – «Бәйлисе бар йөрәкне» алган көнне, төнне һәм икенче көннең төш вакытына кадәр, ашарга туктап, тәнәфессез, ялсыз йотлыгып укып чыктым. Нәрсә тетрәндерде мине? Полиграфик нәфислек, Алсуның нәзберек талантының тулысынча чагылышы, әсәргә җан өрә алуы. Хәсән абыйның моңа кадәр кулланылмаган яңа позициядән, саф күңел күзе белән карап, шаблонга, комфортлык хастасына баш бирмичә, гаҗәеп төгәл ихласлык белән язылганлыгы. (...) Кереш сүзне Ркаил Зәйдулладан яздырту да китапның затлылыгын, аның кыйммәтен күтәргән. Татар әдипләре арасында хәсәнтуфанлык сыйфатларына иң бай шагыйрь бит ул Ркаил... Шундый үзенчәлекле һәм Хәсән абыйның әдәбиятта һәм җәмгыятьтә калдырган эзләрен тулы, ачык, дөрес күрсәтә алгансыз икән, урысча әйткәндә, и карты в руки. Аның турында ЖЗЛ сериясе өчен китап әзерләргә тиешсез Сез. Бу эшне сузарга ярамый. Материал Сездә җитәрлек. Мәсгут Гайнетдиннең тапканнарын да өстәргә була. Мәсгут чиктән тыш бай эрудицияле, гадел, эзләнүчән галим. Андагы китапханә башка галимнәрдә бармы икән? Бер кечкенә кимчелеге бар, белгәннәрен, теләгәнен язмаларына сыйдыра алмау. Бәлки миңа гына шулай тоеладыр. Әйттем исә кайттым! Иң иманлы, иң нечкә, ихлас күңелле шагыйребезгә багышланган ЖЗЛ сериясенә яңа китап язганда, мин әйткән сүзләр уңыш китерер дип ышанып калам.

Уңышларың белән котлап, М.Юныс».

Китапның соңгы бүлеген автор ни өчен «Сөю планетасы» дип атый соң? Әллә Хәсән Туфанның мәхәббәте җирдән кубарылып күкләргә үк ашканмы? Могҗиза инде бу дөнья! Беркөнне галәм шакката: галимнәр аның куенында яралган күк җисеменә тап була. Кечкенә әле ул, сабый гына, ә үзе нинди тере! Һәр яңалыктан хәбәрдар Рәхмәтулла кызы шунда: «Их, аңа Хәсән Туфан дигән атама бик килешер иде», дип хыяллана. Хыял күңелдә генә бикләнми, тиз арада Роза чарасына керешә. Кәнәфие биек, ә үзе тәбәнәк бер түрә исә:

– Нигә кирәк ул безгә? – ди.

– Планета ачып, шуңа исем кушу миллион сумнар тора! Бу бит бушка! – дигәч, түрә шаркылдап көлә:

– Бигрәк наив кеше сез. Бушка шайтан ялчысы гына чаба! Акча сорап, миеңне черетәчәкләр.

– Сорамаслар, дөньякүләм танылган астрофизик Наил Сәхибуллин үзебезнең милли җанлы татар кешесе, ул безнең үтенечебезне кире какмас.

– Туфаныгыз әлләкем диярсең.

– Ул әлләкем түгел, ул – татар шагыйре!

– Аптырыйм, сезгә тагы нәрсә җитми, Роза Рәхмәтулловна? Пенсиядә дә тыныч кына яши белмисез икән.

«Сиңа тагы ни җитми?» – дип, күп битәрләделәр аны. Шәхсән аңа җитә! Тормышы түгәрәк: сабыр, акыллы ире – Миргалиме белән җитәкләшеп гомер күпереннән атлый, кияргә киеме, өстәлдә ризыгы бар. Капкадан кеше өзелми, дуслары, туганнары, нәсел дәвамы – оныклары килә. Шөкер, балалары иманлы-тәүфыйклы булып үсте, кызы Гөлназ Петербургның Репин исемендәге данлыклы сәнгать академиясендә чит ил студентларына инглиз телендә лекцияләр укый. Улы Айдар федераль университетта эшли, профессор, икътисад фәннәре докторы. Ә менә халыкка һаман җитмәскә тиеш. Милләтне үтерим-бетерим дисәң, аның мәшһүрләрен хәтер бакчасыннан төбе-тамыры белән йолкып ат. Аннары «бакча» үзеннән-үзе корыячак. Йолкый кайбер көнче һәм тар күңелле «татарымыз», «Азат хатын» журналына «Сөембикә» исемен кушканда күрде инде күрәсен Рәхмәтулланың баш баласы. Әй, уйласаң, уелыплар китәрсең. Нахакка гаепләнеп, башта үлемгә хөкем ителгән, аннары җәза сөрген белән алыштырылган шагыйрьдән шушы планетаны да күпсенәсеңмени, түрә абзыкай!

Рәхмәт яугыры, Наил Сәхибуллин, гәрчә әдәбият-сәнгать тирәсеннән ерак торса да, шагыйрьнең биеклеген чамалый. Юкка гына галәм хәтле галәм белән эш итми шул галим! Ул Миркасыйм Госманов белән аралаша икән, Миркасыйм абый:

– Роза Туфитуллова – бик абруйлы ханым, гозеренә колак сал әле, – дип тә өстәгәч, Наил әфәнде хәтта, иренмичә, Туфанның иҗатын өйрәнә!

«Шуның белән булды» дияргә иртәрәк икән әле. Авызыңны күккә күтәреп: «Сиңа, дога укып, исем куштык, йолдыз җаныкаем», – дип, битеңне сыпырсаң икән! Табылдык планеталарга исем бирү елына ике мәртәбә Американың Гарвард шәһәрендә урнашкан халыкара комиссиядә карала. Тәкъдим ителгән шәхес лаек икәнен раслап, инглиз телендә унбер юллык язма әзерлисе. Хәсән Туфан турында романнар язсаң да таман гына, ә монда нибарысы унбер юл! Барган саен галим:

– Бу сүзләр белән мин шагыйрьнең лаек икәнен берничек тә дәлилли алмыйм , – дип, Розаны кире бора да кайтара, кире бора да кайтара.

Язмыш аңа киртәләрне әз кормый, кайберсен ул әрнеп-рәнҗеп сикереп үтә, кайберсен соңгы көчен җыеп... Монысын да җиңәргә тиеш Рәхмәтулла кызы, тиеш! Җиңә дә! Иксез-чиксез галәм киңлегендә «Hasantufan» йолдызы балкый. Мәңге яначак бу йолдызчык Йолдызлар картасында теркәлгән, таныклыгы кулда, ул татар кызы Роза белән татар улы Наилнең шау-шу куптармыйча, «мин-мин» дип шапырынмыйча милләткә тапшырган бәһасез бүләге. Ә бит Хәсән ага сиземләп исән чагында ук язып калдыра:

Планеталар арасына китте
Саубуллашып учак утларым.
Мәңгелекнең берәр почмагында
Очрашырбыз әле без тагын.

«…Яшен яшьнәтеп күкрәп алгач, тынар, бүтән каләмгә тотынмас».

Шулай уйлый кайберәүләр. Әнә Америкалы ханым Маргарет Митчелл бер роман белән генә чикләнә. Ялгышалар, Роза Туфитуллова күңелендә кош сыман очарга әзерләнеп, тагын бер әсәр канат яра...

## 15. «Сез түгел, туташ, язмыш мине үзе дә җәлләмәгән...»

«Соңламасам ярар иде, соңламасам...»
Ничә ел шик-шөһбә белән яшәлгән, ничә ел!
«Соңламасам ярар иде, соңламасам...»
Гомер сәгате бит туктамый, яшь барган саен тизрәк текелди.

Никахлар әүвәл күкләрдә, соңра гына җирдә укыла», диләр. Мөгаен, язучының хәлләре дә шул чамадыр: әсәр башта җанында тумыйча, ак кәгазьгә төшми.

...Хәтерендә, конгрессның иң беренче җыелышына Оренбургтан чакырылган мәгърифәтче, галимә Мәдинә Рәхимкулова хатын-кызлар секциясенә кереп утыра. Роза ханымның чыгышын дикъкать белән тыңлаган кунак тәнәфестә аны бер читкәрәк әйдәкләп:

– Ханым, минем сезгә бер шелтәм бар, хәтта мин аны кисәтү дә дияр идем. Аны мөнбәргә менеп әйтмим, колагыгызга гына пышылдыйм, – ди. – Сез Тукайның дусты булган Ольга Лебедова-Гөлнар турында кызыклы мәгълүматлар бирдегез. Хак, ул унөченче-ундүртенче елларда Германия һәм Италияләрдә татар хатын-кызларының бала тәрбияләү ысуллары турында докладлар ясаган. Ә аңа чаклы татар кызлары Балкан сугышында яраланган төрек сугышчыларын дәваларга Төркиягә бара. Бу хакта белми идегезмени, ханым?

– Оят, белми идем, Мәдинә апа.

– Аңлыйм сезне, эшегез күп. Менә хәзер белдегез инде. Шуларның берсе – Өммегөлсем Камалова.

– Мин сезнең шелтәгезне кабул итәм, Мәдинә апа. Аның турында «Сөембикә»дә язмалар бастырырбыз, Алла бирсә.

Әйткән сүз – аткан ук, ишанның олы кызы Кәлимәтениса оныгы тарихчы Равил Әмирханов әлеге гаилә тарихын кузгатып, мәкаләләр китерә башлый, Мәсгут Гайнетдиновтан да саллы-саллы язмалар килә. Аларның барысын да Мәдинә Рәхимкуловага юллый баш мөхәррир. Ләкин, ләкин... галимәдән тагын шелтә, тагын...

– Роза, нишләп үзегез язмыйсыз?! Гөлсем язмышына битараф бугай сез!

«Битараф бугай сез...» Бәгырьне борып-борып чеметәсең лә, галимә апа! Юк, битараф түгел! Аның өчен һәрбер татар хатыны, татар кызы – энҗе бөртеге. «Тотынам» дип, күпме генә җилкенсә дә, ул чакта исеменә хәтле уйланылган романга тотынмый шул, чөнки җәмәгать эшләре төягән арбасы чамасыз авыр була...

Гөлсем Камалова – карурман, аны аркылыга-буйга ерып чыгар өчен никадәр түземлек һәм сабырлык кирәк. Хыялый әдәби әсәрләр язуы җиңелрәк, Каләм өстәлгә кадаклап утырта да кузгатмый, ә монда хәлләр икенчерәк, фаразлар, юраулар, уйдырмалар кулланып, чынбарлыкка хилафлык китермәс өчен күп йөрисе, күп эзләнәсе, күп кенә документлар өйрәнәсе, архив тузаннары йотасы, ишан токымының исән онык-

оныкчалары белән очрашасы, кайчакта алардан кулъязмалар теләнәсе... «Уф», – дияр укучы. Уфылдама, дускай, боз кузгала... Әлегә безгә шунысы мәгълүм: инкыйлабка кадәр Чистай шәһәре мәдрәсәсе хуҗасы Мөхәммәдзакир Камаловның икенче хатыны Фатыйма абыстай Әминә, Кәлимәтениса, Гарифә, Җәваһирә, Әсма, Шәмсениса, Хәтимә, Гөлсем исемле сигез кыз һәм Ибраһим исемле бер малай тудыра. Язучының күз уңында, билгеле, Гөлсем...

Кызлары Гөлназ үзе кебек сәнгать белгече Денис Әмиров белән гаилә корып, Питер каласында төпләнгәч, Туфитулловлар ул якларга да сукмак яңарта. Оныклар сагындыра! Бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына дигәндәй, шәп бит әле бу, заманында ишанның Әсма исемле кызын, ягъни Гөлсемнең апасын дин галиме Муса Бигиевкә ярәшәләр. Мәрхүмнәрнең төпчек кызы Фатыйма әби исән-имин генә шушы шәһәрдә яши, ди. Чал тарих вәкиле белән дүрт тапкыр күрешә Роза. Карчык ак чүпрәккә төреп, әнисенең көндәлеген саклаган икән.

– Сеңлем, мә, алыгыз, укыгыз. Монда әнинең тормышы. Тулысынча түгел, чиреге генә. Бик изге эшкә тотынмакчы икәнсез, зинһар, тукталмагыз, ахырга хәтле барыгыз, – ди ул.

Мәскәүдә тереклек иткән туксан ике яшьлек Шифа Акчуринаны да таба язучы.

Эзләнә-сораша башлагач, язмышлар дәфтәренең тәүге битләре ачыла... Гүзәлләрнең гүзәле Гөлсем Камалова Петербургның Бестужев курсларында укый. Курсистка! Чынлап та ул дус кызлары белән Төркиягә яраланган төрек солдатларын дәваларга китә. Нинди йөрәк белән, ә!

Эзләнүләрнең дәвамы – серле хат. Гөлсем Камалова кодачасы Мәрьям Бигиевага Тукайның сулышы киселәсе соңгы сәгатьләре турында тәфсилләп язып җибәрә. Аның эчтәлеге туган-тумачаларга да билгеле. Андый нәрсәне ничек яшерәсең, ди! Шуңа күрә хатны буыннан-буынга тапшырып саклыйлар да. Розаның төн йокылары кача. Табасы иде ул хатны, табасы! Кемнәрдә икән энҗе-мәрҗәннәрдән дә кыйммәтрәк мәктүб? Татар дөньясы өчен искиткеч ачыш ла бу!

Айларга гынамы, елларга сузыла эзләнүләр. Бактың исә, ул кулдан кулга күчеп, ахыр чиктә, дөньякүләм танылган гарәп теле белгече Әнәс Халидовка эләккән икән. Тимерне кызуында сук, суынса – эш харап! Галим әле үз аягында, үз акылында, диләр, язучы адрес буенча ул яшәгән йортка ашыга. Тик тар гына, кысан гына фатирга кергәч, Роза телсез кала. Карават дигәнең юк, ятак урынына – матрас, идәндә тау-тау китап, тау-тау кулъязмалар... Нәкъ мәгарә! Әнәс Бакый улы кеше танырлык түгел, ул җирдән аерылып, күкләр белән тоташып, Коръән тәрҗемә итә! Таш яусын, зилзилә купсын, диңгез-океаннар ташысын, аңа барыбер! Өстәлдән башын күтәрмичә генә сөйләшүе дә кырт-мырт кына:

– Мин Коръәнне тәрҗемә итеп бетермичә кәгазьләремдә актарынмыйм!

– Сез эшләгез, Әнәс абый, без кызлар белән үзебез архивыгызны карарбыз, – дигәч тә күнми мәгарә хуҗасы:

– Аптыратмагыз!

– Бир инде шул хатны, Әнәс, – дип ялынган Миркасыйм Госмановка да кискен җавап:

– Комачауламагыз әле, мин изге китап белән утырам!

Борынгылар: «Сабыр төбе – сары алтын», диләр дә… Аның бит тора-тора бакырга әйләнүе дә ихтимал. Әсәргә мәгълүмат туплаганда, ашыгыбрак йөрсәң дә, таман гына. Шаһитлар бүген исән, ә иртәгә кем белгән...

Озак-озак көттергәннән соң бәхет кошы иңнәргә куна кебек: Әнәс Халидовтан рөхсәт! Роза иртәдән кичкә кадәр «кыягазь тавы»ннан шул серле хатны эзли, тик берни дә табалмый. Шунда галим башына сугып:

– Кара, оныткканмын, мин архивны өчкә бүлеп тараткан идем. Аның бер өлеше аерылган хатынымда, бер өлеше – университетта, бер өлеше – дәүләт архивында, – ди. – Гарәп язуы булгач, ул хатны миңа китергәннәр иде. Анда нәрсәләр язылганын белмәкчеме сез?

– Туганнары сөйләгән иде инде...

– Сез шуның белән канәгать түгелме?

– Гөлсем Камалова турында материал җыям, Әнәс абый. Туфитуллова фантазёр, әсәрен әллә ниткән әкиятләр белән бизәгән дип җанымны талкымасыннар өчен хатның оригиналы кирәк.

Галим бармагын өскә кадап:

– Аллаһ күрүче, аңа тапшырылыгыз да, ни ишетсәгез, шуны языгыз, – ди.

Аксакал белән килеш тә, тынычлан югыйсә. Ә ул һаман эзли, архивлардан запрос ясата, Халидовның аерылган хатыны Питер тумасы икән, танышлары аша аны таба. Эре җептән тукылган тәкәббер бичә бирми хатны. Роза:

– Һич югы күрсәтегез, тотып кына карыйм, – дип ялварса да, киресенә ката. Мөгаен, ул иренә үчегеп, аны чүплеккә ташлагандыр, мөгаен, шул явызлыгын танырга теләмидер.

Язылачак әсәрнең бер кылы өзелгәндәй тоела... Ләкин кулдан Каләм төшми. Тик әле ул аптырауда: романны ничек башларга? Чәчәктән чәчәккә очып, бал суырган умарта корты сыман, вакытын да, сәламәтлеген дә аямыйча, бер шәһәрдән икенче шәһәргә күчеп, берәмтекләп җыйган истәлек-хатирәләрнең чуты юк! Һәркайсы – кыйммәтле табыш. Ак төннәрендә бигрәк тә Питерның Казанский урамын урарга ярата Рәхмәтулла кызы, чөнки анда – бишенче йортта «Казанский» кунакханәсе, чорына яраклаштырып әйтсәк, мосафирханәсе урнашкан. Биредә меңтугыз йөз уникенче елның апрель аенда Тукай яшәп киткән. Менә кайда әсәр укучыны үзенә суырып алачак! Каләм яз!

Яза каләм, милләттәшләрнең аяныч язмышлары, түнтәрештән соң атаклы татар фабрикантлары Акчуриннарның мал-мөлкәте таланулар, күренекле дин галиме Муса Бигиев нәселе кичергән төрмә газаплары – барысы да әсәргә сыячак. Түз генә, ак кәгазь! Болар укучыга таныш та кебек... Ә менә Тукай белән Гөлсем Камалованың мәхәббәте – сенсация! Алар бер-берсен яраткан дими язучы. Артык гади сүз лә ул!

«...Ни кызганыч, Рәсәй башкаласын иңләп-буйлап йөрү, зиннәтле сарайларын, музей-театрларын күрү насыйп булмый шагыйребезгә. Петербургка килгәч, аның үзәк бәгыренә төшкән үпкә чире тагын да көчәя төшә. Шәһәрнең җелекләргә үтә торган дымлы, салкын һавасы шагыйрьне көннәр буе мосафирханәдә утырырга мәҗбүр итә. Дөрес, биредә яшәүче дуслары аны ялгызын калдырмаска тырышалар.

Шагыйрьне күреп, танышып калырга теләүчеләрнең дә саны көннән-көн арта бара.

Тик әлегә шагыйрь берәүнең дә ишек шакуын теләми. Аның гадәтенчә, кулларын баш астына куеп, күзләрен йомып, Муса Бигиевларда үткәргән кара төннең ак фәрештәсен генә күңеленнән кичереп, янә бер юанасы килә. Ни хикмәт, шушы яшерен-тансык хыялый бер мизгел аның каһәрле ютәлен, авыруын, туңуларын оныттырып торадыр кебек.

...«Дөнья читлегеннән» очып чыгарга җыенган чарасыз шагыйрь йөрәгенә кинәт, сак кына ак фәрештә килеп «орынасы» итте. Фәрештә күзгә күренеп йөри башласа, билгеле инде... Төн фәрештәсе «ак томан» эченнән «йөзеп чыгып» телгә килде. Нинди йомшак, моңлы, иркә тавыш:

– Тукай әфәнде, зинһар, кичерә күрегез. Башкача түзеп торырлыгым калмады. Ютәлегез бигрәк көчле. Сезнең өчен җаным парә-парә килә... Шушы мәтрүшкәле кайнар сөтне эчеп карагыз әле. Шифасы тимичә калмас. Савыга күрегез! – диде дә, элгәре ничек пәйда булса, шулай ук «эреп» юкка да чыкты.

Дивар аша гына шагыйрьнең шул дәрәҗә газаплануын ничек тыныч күңел белән тыңлап ятсын Өммегөлсем? Аның тыю-чикләүләргә буйсынмаган, ни гомер сөю утында дөрләгән кайнар йөрәге бар бит әле. Яраткан Тукаен савыктырыр өчен аның бер уе, бер сүзе, бер сулышы җитәр төсле иде. Аһ, хыял белән чынбарлык арасы нинди тирән упкын икән.

Өммегөлсемнең кодачасы, дус кызы Мәрьямнең дә җаны үкси, тәне дерелди, ул, шылт иткән тавыштан да сискәнеп, ишек катында кизү тора. Өммегөлсем өйдәгеләр күзенә чалынмасын да, Муса әфәнде генә уяна күрмәсен. Ходайның рәхмәте, ул бүген балалар янында йоклый. «Оят, гарьлек, син ничек җөрьәт иттең?» – дип, күзен дә ачырмаслар. Тукайны да кыен хәлгә куярлар. Аңлатып та, акланып та өлгерә алмассың...

– Ихлас, фәрештәдер! – дип уйлады Тукай, үзен яшәү белән үлем арасында тоткан бума ютәле басыла төшкәч. Ләкин шунда ук бу «кирәксез» тойгыга бар күзәнәкләре, вөҗүде белән карышты

– Күр, бу курсистканың кыюлыгын, тәвәккәллеген. Җәлләгән... Сез түгел, туташ, мине язмыш үзе дә җәлләмәгән. Кирәкми дә. Минем максатым, юлым башка. Мине кызганганнарны сөймим мин, туташ. Сез нык ялгыштыгыз...

Монысы ниткән өн тагын, язгы чирәм төсле кантарлы юл читендә баш калкыта?

– Шагыйрем, син үзең бу минутларда яныңда яраткан бер җан иясенең булуын теләгән идең түгелме соң?! Менә «мәхәббәт сакчысы» аны синең хозурыңнан тыймады.

Бәхеткә, «хикмәтле төн» тагын кабатланасы итте. «Соңгы сулыш» алганда, тагын теге «ак фәрештә» иңде.

...Гөлсемне шагыйрь белән күрешү алгысыта. Шәһәргә якынлашкан саен, иркә тайның йөрәге поезд алдыннан чабар дәрәҗәгә җитеп ярсый, ашкына. Хәерлегә генә булсын...

Ә монда, вокзалда, Хәтимә нишләргә белми өзгәләнә. Ул алдан төшкәнгә карап кына поезд алдан килми шул.

...Ниһаять! Йә Алла! Күзенә генә күренәме, каршысына Гөлсем йөгерәме?!

– Хәтимә!

– Гөлсем, иркә таем! Аллага шөкер, исән-сау!

Елашып, кочаклашып күрештеләр. Хәтимә әле дә исе-һушы китеп, извозчик чакырырга да онытып, мөлдерәмә күзләре белән Гөлсемгә багуында.

– Карашың бигрәк тә моңсу, ул-бу булмагандыр бит? Барысы да исән-саулардыр? Тукай ничек?! Нигә бер сүз дә әйтмисең?

Хәтимәнең авыр көрсенүе тышына ук бәреп чыкты.

– Хәле шәптән түгел шул. Инде айга якын Клячкин хастаханәсендә ята.

– Син фатирыңа кайта тор, ә мин шунда йөгердем.

– Акыллым, иртәнге briштә сине кем кертсен анда? Чәйләр эчкәч, икәүләп килербез.

Кая инде ул хәзер Хәтимәне тыңлап тору? Әмма ул хаклы булган. Хастаханә ишеген ачтыру җиңел эш түгел иде. Сукранып ишек ачучы олы гәүдәле, яртылаш йокымсыраган марҗа шактый акча төрткәч кенә, йомшап, аны кизү торучы шәфкать туташы янына алып килде.

Анысы ишетергә дә теләмәде.

– Күреп торасыз, мин үзем дә – шәфкать туташы, Ольга...

– Ольга Николаевна. Ә сез элегрәк кайда идегез соң?

– Төркиядә. Сугыш кырында. Яралы солдатларны карадык.

– Чынлапмы?

– Әйе, чынлап. Ольга, хөрмәтлем, зинһар, рөхсәт итегез, мин әле поезддан гына төштем, ул – минем өчен бик-бик кадерле кеше.

– Кызык сез татарлар. Кергән берегез, шагыйрьне иң якын, иң кадерле кешебез, туганыбыз, ди. Шаккатам, шулай кадерле булгач, нигә аны «Печән базары»на алып килеп сатканнар соң?! Нигә алданрак дәвалау юлларын эзләмәгәннәр? Нинди яшь килеш китеп бара...

Гөлсем, тагын да илтифатлырак булырга тырышып: «Ольга Николаевна, хөрмәтлем, үтенәм сездән», – дип, йомшак кына кулын тоткан атлы булып, мәрҗән кашлы алтын йөзеген кидереп тә өлгерде.

Бу минутларда ишек янында торучы «мәхәббәт сакчысы» да Гөлсемгә хәерхаһ иде. Ни дисәң дә, Гөлсем, Тукай фаразлаганча, «ак фәрештә». Ә фәрештәләрнең «үз теле». Ул хәтта кызның тапкырлыгыннан, үҗәтлегеннән елмаеп та куйды кебек. Кизү торучы шәфкать туташы да авыз чите белән генә көлемсерәгәндәй итте дә Гөлсемне кирәкле палатага алып китте. Һәм пышылдап кына, Тукай янында утыручы яшь бер ир-атның чыгып торуын үтенде. Тегесе сүзсез генә ишеккә юнәлде. Ак халат белән ак башлык кигән Гөлсемгә әллә ни игътибар итмәде бугай.

Тукай биек ак мендәр өстендә күзләрен йомган килеш ята. Йоклаганга охшамый. Гөлсем аяк очларына гына басып, ятакка якынрак килде.

Карават башында элеп куелган кәгазьгә күзе төшеп, йөрәге жу-у итте.

> И мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
> Син сынасың, мин сүнәмен, аерылабыз, ахрысы!..

Тукайның үз кулы белән язылган һәр юлыннан, һәр хәрефеннән моң, сагыш сарка. Утлар-сулар кичеп, үлем белән күзгә-күз очрашкан каһарман туташ бер мәлгә гүя бу дөньядан юк булып торды.

– Нигә Тукай, нигә башка берәү түгел?.. Тукай...

Кыз, аеруча бер саклык белән, кулын шагыйрьнең маңгаена куймыйча булдыра алмады. Әйтерсең Гөлсемнең үзен ут алды. Шагыйрь бик югары температура белән ята, дөресрәге, яна иде. Менә Тукай, шактый авырлык белән, күзләрен ачты. Каршысындагы «ак фәрештә»не таныгач, сискәнеп киткәндәй булды.

– Син?!

– Мин, Тукай...

Кыз ридикюленнән нәфис кулъяулыгын алып, юешләтеп, шагыйрьнең маңгаена куйды. Аннары иелә төшеп, балаларныкы кебек кеп-кечкенә калган кулларын әле бер як битенә, әле икенчесенә куеп торды. Кызның ихтыярсыз тамган күз яшьләре шагыйрьне тагын телгә китерде.

– Петербургтан киткәндә, син мине озатырга килмәгән идең. Ә бу юлы ерак диңгезләр кичә-кичә кайтып җиткәнсең... Күргәнеңчә, минем поезд инде кузгалырга тора. Урыным азаккы вагонда... Хуш...

– Хуш, Тукай... Син минем күңел күгендәге якты кояшым, нурлы аем булдың. Ишетәсеңме мине?!»

Кодачасы Мәрьямгә юллаган хатта шушы хушлашу мизгелләре язылыр...

Бүтән күрешмәс алар...

«... һәм 15 апрель иртәсе белән үзәк өзгеч хәбәр таралыр. Тукай вафат.

Бу хәбәрдән җирләр, күкләр иңрәп куяр. Дөньяның бар сазлары ачы хәсрәт көен уйнар. Кырлай урманнары, шүрәлеләр үксер... Гөлсемнең Тукайга бинибая гашыйк җаны гынамы, Галәм йөрәге елар...»

Бигиевларның кече кызы Фатыйма апа дүртенче очрашуда:

– Рауза, балам, Тукай авыру булмаса, кәефе икенчерәк булса, Гөлсем аны беркемгә дә бирмәс иде, – ди.

Әсәргә бу сүзләр кертелми. Чөнки Зәйтүнә – легенда, аңа кагылырга ярамый! Тукайның исеме янәшәсенә икенче берәүне кую җинаять саналачак. Язылмаган канун буенча Муса Җәлилдә – Әминә, Хәсән Туфанда – Луиза гына... Бетте-китте!

Озакламый журналда басылган «Язмыш җиле» романы төрекчәгә тәрҗемә ителеп Төрек дөньясын шаулата. Әсәрне «Гөлсем» дип атасалар, Рәхмәтулла кызына Гөлханым дип дәшә кардәшләр.

Бак, французлар да романны үз теленә аударган икән бит. Афәрин, Татар кызы турында укып сокланасыннар әле!

«Гөлсем аны беркемгә дә бирмәс иде...»

Йа Аллам, ник бу кадәр аларнын җанын өшетеп искәнсең икән син, язмыш җиле?!

## 16. Мәхәббәттә кирәк икән пар канатлар

– Данга күмелдең инде син хәзер... Ике саллы китабың унысына торырлык.... Ханбикә Сөембикәне журнал тәхетенә кайтарып, «Ак калфак» берләшмәсе оештырганнан соң сиңа мәшһүр тамгасы суктылар. Ә синең алай әйттерәсең килми инде! Гади генә Аксубай кызы мин, дисеңме? Кыланасың гынамы соң?

– Гафу, танымадым. Сез кем әле?

Телефон чыбыгы очындагы тавыш кетер-кетер көлә:

– Танымассың да. Меңнәрнең берсе мин. Яшьрәк вакытта «Ак калфак» уздырган кичәләргә йөри идем. Син бер тапкыр миңа игътибар да иттең, конкрет миңа түгел. Башымдагы чигүле калфагыма. Борынгы, дидең. Әбинең сандык төбендә ята иде, алдым да кидем.

– Сөйләм телегез матур, саф татарча, ханым.

– Китап сулышын сулап, кырык ел китапханәдә эшләгәч, тел шомарган. Яратам татар язучыларын, шул исәптән сине – Туфитуллованы да. Соңгы укыган әсәр – синеке. Телефоныңны Язучылар берлегеннән сорап шалтыратуым иде. Затлы Акчуриннар килене Гөлсем апа Тукай бәгырькәен үлгәнче онытмагандыр, иеме? Бүген нәрсә язасың? Туйдырмадымы язу? Тагын нинди темаларны кузгатасың?

Әйтерсең каләм автоматка көйләнгән, ул көн туктамый, төн туктамый «кыягазь» кыштырдатырга тиеш. Сандамыни хикмәт! Сигез капканчы – симез кап, диләр, кибет киштәләрен кеше укымаслык дистәләгән китап белән тутырганчы, бер сыйфатлы әсәрең белән укучының күңелен яула!

Телефондагы мини-әңгәмә өзелә. «Тагын нинди темаларны кузгатасың?..» Аңа мондый сорауны еш бирәләр. Балачактагы хыялы үтәлмәде – шул йөрәкне тырнап-тырнап ала. Югыйсә күчер дә куй, әле дә хәтер нүешенә үрмәкүч пәрәвез сармаган.

– ...Әни, укытучы апа инша язарга ди иртәгә. Җиңү көненә багышлап. Сезнең гаиләдә кемнәр сугышта катнашкан, барлап килегез ди. – Мәктәптән кайткан Роза букчасындагы китапларын бушата. Бу укытучылар кызык та кешеләр инде, дөньяда аларның гына фәне диярсең, һәрберсе тутырып-тутырып, өй эшләре бирә. Тиз генә дәрес әзерлисе. – Әти турында язган идем, тагы кабатламамдыр, әни. Вәли бабайны бөтенләй белмим, синең әтиеңне, әни. Әгәр аны инша герое итсәм? Сөйлә дә син миңа.

Әнисе тәрәзәгә карый-карый кызны тыңлый. Мич куенындагы казанда быгыр-быгыр шулпа кайный, төшке аш вакыты, Рәхмәтулласы урамда күренүгә токмач салып кабартасы.

– Нәрсә диим икән, кызым? 1902 елның ноябрендә Кармәттә туа бабаң. Иске Кармәттә мәктәп директоры була, бронь бирсәләр дә, беренче көннәрдә үк үзе теләп сугышка китә. Әбиегез Фәсигыйльбәянга: «Балаларны сакла, мин алар бәхетенә әйләнеп кайтырмын», – дисә дә, кайтмый бабаң. Әй, кызым, аның турында авыр шул сөйләргә...

– Кем турында сөйләргә авыр, Фигаль?

Контузиядән интеккән әтисенең кайчакта колагы ачыла бугай, әнә ул бусагадан атлар-атламас ишеткән дә.

– Роза инша язам ди, Вәли бабасы турында. – Әнисенең тавышы сагышлы. – Кырык икедә «хәбәрсез югалды» дигән «өчпочмаклы» хат килә безгә. Андый солдатларга нинди генә кара якмыйлар ул чорларда. Әсирлеккә төшкән, сатылган дигән сүзләрне әнигә җиткермиләр, дисеңме, Рәхмәтулла. Моны балага ничек аңлатасың, бер Аллам?

– Ник аңламасын ул, аңа унике яшь! Сал ашыңны, колхоз атлары болында иде, аръякка таралмасыннар.

Әнисе:

– Кызым, оланнар тыкрыкта уйный иде, ашарга чакыр, – дигәч, әтисе кашыгы белән өстәлгә тукылдатып:

– Туктале, мин әйтмәдем, – ди, – дары исе иснәмәгән тыл күселәре нәстә димәс! Алар үзләре сатлыкҗан! Кече политрук Галеев Вәли Мәскәү өлкәсенең Клин шәһәре янында һәлак булды дип полкташ якташы сезгә хат язамы, яза, Фигаль. Морозов соңынтын тоже үлә.

– Морозов шулай диган дә бит... Нишләп соң кырык икенең июнендә әнигә военкоматтан «хәбәрсез югалды» кәгазе тапшыралар?

Әнисе, бәлки, гомер буе шушы сорауга җавап эзләр, ә Сталинград өчен сугышкан фронтовик Зәйнуллинга ул әллә кайчан ачыкланган:

– Мәскәү астындагы тәмугтан вряд ли кем исән калган. Көн дә япь-яшь малайларны поездга төяп, Мәскәү астына җибәрәләр. Туктый япан кырда эшелон. Кулларына мылтык тотарга да өлгерми солдат, бөтен җир ап-ачык бит, фашистның тәреле козгыннары боларны шунда ук кырып сала. Тагы малайларның яңаларын китерәләр, тагын кыралар.

– Ул чакта әтигә кырык яшь, малай түгел лә.

– Сугыш яшькә карамый, Фигаль.

– Әти кесәсендә ниндидер документ йөрткәндер лә, бер Аллам! Коммунист бит ул.

– Кеше танырлык булмагандыр анда. Өсләренә көлтә-көлтә ут койсыннар да. Күбесенең гәүдәсе янып күмерләнгәндер, документы-ние белән.

Учы белән яңагына таянып, тын да алмыйча олыларны тыңлаган Роза:

– Вәли бабай хәбәрсез югалмаган. Үскәч, мин аны табам, шуннан соң аның турында чын хикәя дә язам әле, – ди.

Әтисе белән әнисе бер-берсенә карап куя. Янәсе, кызкай саташмыймы икән?

– Аша да әниеңә булыш! – Әтисенең талканы коры. – Булмастай нәрсәләр белән хыялланма!

Әнисенең күзендә исә өмет чаткысы: «Сабыйның теләгенә амин дисен фәрештәләр, амин…»

…Бүтәннәрнең «йомышы»н үтәү чиреннән арынмагач, үзенекен артка чигерә-чигерә яшәлгән шул. Студент елларында Мәскәү өлкәсенең хәрби комиссариатыннан бабасын эзләтә Роза, чирек бит кәгазьдә ике генә кәлимә: «Хәбәрсез югалган». Кибәнгә чумган инә, диярсең! Бервакыт төш күрә ул. Балачак, балачак кынамы, яшьлек хыялларыннан да китеп, гомер иткәндә гаҗәеп төш күрә. Сыкрану-сызлану, сөенү-шатлану түшәлгән юл… Шундый озын ки, очы-кырые юк. Юл икенче-өченче төндә янә кабатлана. Төшлек куйган мәрхүмә Мәликә әбисе:

– Өч мәртәбә күргән бер үк әйбернең хикмәте бар, – дияр иде.

Питерның матурлыгына сокланып, оныкларын – иркә тайларын сөеп-иркәләп кенә кире Казанына китсә икән! Ленинградның татар блокадачылары төркеме аны очрашуга чакыра. Йөз егерме җиде татар! Бу дуслык дистә-дистә елларга сузыла. Ду китереп, Розаны вокзалдан каршылыйлар, ду китереп озаталар.

– Без сине беренче көнне Ольга Берггольц дип кабул иттек, – диләр яңа дуслар. Йә, кем белән чагыштыралар! Корней Чуковский: «Киләчәкнең иң талантлы шагыйрәсе» дип санаган Ольга – репрессия корбаны, утыз

сигезенче елда аны Ворошилов белән Ждановка каршы заговор оештырган дип, кулга алалар. Төрмәдә бик каты кыйналганнан соң хатын үле бала тудыра... Үзен шул кара елларга күчереп карый Рәхмәтулла кызы: яклар идеме икән шагыйрәне ул – яклар иде... Ике елдан Берггольцны азат итәләр. «Пычрак куллары белән җанымны актардылар, битемә төкерделәр, мәсхәрәләделәр дә, бар, яшә, дип, чыгарып җибәрделәр», дип язар ул ахырдан. Күп кенә мемориаль такталарга чокылган «Никто не забыт, ничто не забыто» («Беркем дә онытылмады, бернәрсә дә онытылмады») дигән канатлы сүзләр аныкы...

Кеше данына кызыгамыни Рәхмәтулла кызы! Үзенеке җитәрлек! Ярата Питер әбиләре-апалары аны, үз туганыннан да артык ярата шикелле.

– Син безне татарлыгыбызга кайтардың, без – татарлар – бөек милләт, дип аңлатып, бездә горурлык хисе уяттың, – дип рәхмәт кенә укысалар бер хәл, барысы да кул куеп: «В память 300-летия Санкт-Петербурга» медаленә тәкъдим иттергәннәр! Ә аларның изгелеге! Сугыш чорында Ленинградта Розаның әбисе белән бертуган Нурулла абыйның дүрт яшьлек кызы Дилә гаип була. И ул әнисе Фигальнең үпкәләүләре!

– Кызым, шул Питерыңда юкны бушка аударып йөрисең, Дилә апаң хакында ник белешмисеңдер.

Менә шунда татар төркеме дәррәү «югалмыш»ны эзләргә керешә. Кайсы архивта актарына, кайсы әкиятләрдәге кебек «дүрт тарафка дүрт күгәрчен очырта». Күмәк көч белән таш-таулар актарасың икән: табалар чәчләре чаларган «сабый-карчык»ны! Ни кызганыч, блокадачы әбиләрнең сафлары сирәгәя, бүген аларның унысы гына терек...

Төш дигән идек, төш. Кызы белән киявендә кунакта вакытта очраклы гына ача ул телевизорны. Хәер, очраклы гынамы икән? Сизенү пульт төймәсенә бастыртмыймы? Диктор яңалыклар сөйли. Петербургта атаклы Врангель фон Гюбентальның мирасын саклау һәм өйрәнү оешмасы Псков өлкәсенә экспедиция оештыра. Анда Себеж районының Чайка авылында бу нәселнең дәвамчысы, сугыш ветераны Юрий Брамбеус яши икән. Аның турында телевизион фильм төшергәндә фашистлар белән бәрелештә һәлак булган солдатларның исем-фамилияләре язылган мемориаль тактаны кат-кат күрсәтәләр. Утырган җиреңнән аркан егыл! Исемлектә Галеев Вәли дә бар! Адәм ышанмаслык хәл! Мәскәү астында югалган бабасы ничек Псков өлкәсендә күмелгән? Адашы гына түгелме икән?

Тән чымырдый, йөрәк сикерә... Тизрәк ачыклыйсы иде, тизрәк!

Роза телевидениегә шалтырата. Аңа:

– Ул якларга юл бик начар, ничек барырсыз икән? – диләр. Юл, юл... Төштәге озын юл... Эстония белән чиктәш Чайкага Питердан бер мең ике йөз чакрым.

– Машина белән барабыз, әни! – Әнә Денис кияү тәвәккәл, Миргалименә әйтәсе дә юк, ул хәләле өчен җир читенә китәргә дә риза. Кояш уянып, алсу яулыгын офыкка таратып җәяргә өлгерми, таң зәрәсе белән сәфәргә кузгала өчәү. Иллалла Себеж үзәгенә җитәләр, ә ары таба чокыр-чакыр, саз-баткаклык, каядыр машинаны трактор белән өстерәтеп, каядыр этеп-төртеп, Чайка авылына керү белән, сораша-сораша Брамбеус картның өе каршысына туктыйлар. Күрәсең, аңа районнан татар журналисты килә дип

хәбәр иткәннәрдер, тәбәнәк кенә буйлы хуҗа капка төбендә көтә, мөгаен, ул чакырылмаган кунакларга ияләнгәндер, кеше аңа тик торганда гына юл сабамыни, кемнеңдер бу җирләрдә баласы, кемнеңдер атасы, кемнеңдер ире, кемнеңдер сөйгән яры мәңгегә күзен йомган...

Машинадан төшүгә баш әйләнә. Әйтерсең башка планетага эләгә Роза: тирә-якта шомлы тынлык белән өретелгән сүлпәнлек, моңсулык, сагыш-моң... Һавасына хәтле үзгә: сулаганда күңел нечкәрә... Бу төбәктә меңәрләгән-меңәрләгән ир-ат гәүдәсе туракланган бит, бәлки шул елларда ук кан исеннән табигатьтә үзгәрешләр башлангандыр... Әй, син, иң асыл егет-кызларыбызның гомерен өзгән каһәр суккан сугыш!

Сиксән алты яшьлек Юрий сөйли-сөйли аларны авыл буйлап сәяхәт иттерә. Аңа мондагы һәр карыш җир изге, Эстония аркылы фашистлар бәреп кергәч, ул беренчеләрдән булып кече ватанын якларга ташлана. Ә күргәннәре... Аяк басарга куркыныч, тирә-як кеше мәете белән тулды, ди.

– Әгәр исән калсам, бөтенесен дә кулларым белән җыештырып күмәм дип ант иттем мин шунда, – ди карт. – Мәктәп директоры идем, укучыларымны җәлеп иттем бу эшкә. Алар укуларын тәмамлап читкә таралса да, тугызынчы майга җыелалар иде. Өч мең дә утыз сигез солдат мәетен җирләдек без. Әнә теге күлне күрәсезме, яртылаш сазлык ул, аның да исеме Чайка, водолазлар яллап, аннан да күпме сөяк чыгарттырдым. Аларны да күмдек. – Мемориаль такта янына туктагач, Брамбеус:

– Сезне Татарстаннан диделәр. Кемне эзлисез? – ди.

– Аны... – Әнә ул, кул сузымында гына бит! Роза тактаны сыпыра. – Аны... Галеев Вәлине. Мин – аның оныгы... Бабам турында сездә мәгълүмат юкмы, Юрий Александрович?

– Монда исеме язылгач нәрсәдер булыр, әйдәгез, безгә кайтыйк, – дип, карт аларны өенә чакыра. Ярты гасырлык калын-калын кенәгәләр саргаеп тузган, ачкан саен битләре уала. Немецларга хас төгәллек белән фамилияләр алфавит тәртибендә тезелгән.

– Вот бар андый кеше. Ну-ка, нәрсә дигәнмен? «Гимнастёрка кесәсендә гарәпчә язылган язу табылды. Партбилетын пуля тишкән».

– Ул партбилет кайда икән?

Миргалимнең соравы урынлы. Адашмы, түгелме – шушы документтан күренәчәк.

– Псков музеенда сакланырга тиеш. Мин андагы хезмәткәрләр белән элемтәдә. Хәзер белешәбез, – дип, карт телефонга үрелә.

Җавапны тиз бирәләр. Партбилетның хуҗасы – Галеев Вәли Вәлиевич... Аның бабасы...

– Бер табышмакны чишегез әле, Юрий Александрович, Галеев ничек Мәскәү астыннан сезнең якларга күчерелгән икән?

– Монысы хәрби сердер аның. Разведчик итеп озатылмадымы икән?

– Әби аны үлгәнче көтте... Хәбәрсез югалды дигәнгә ышанмады...

Брамбеус карт:

– Зинһар, мине гафу итегез, мин күмгән мәрхүмнәрнең күбесе исемсез иде. Исеме булып та, адресы күрсәтелмәгәннәрнең берсе – бабагыз, димәк. Ил буенча андый билгесез җаннар миллионлаган. Әле җыясы сөякләр бихисап. Мин хәлдән килгәнен эшләдем, балакайлар.

Кечкенә генә агач ызбага кыздырган балык исе тарала. Хуҗабикә Антонина әби табынга коштабак белән ярмалы бәрәңге куя.

– Бәрәңгесе – бакчадан, кәрәкәсе – күлдән, үзем кармак белән каптырам, – ди карт. – Кыстатмагыз, тәмләп ашагыз.

Тамактан ризык үтәмени, әдәп саклап, бәрәңгене чеметем генә каба Роза. Ә балыгын... Чистартылып бетмәгән күл төбендә «хәбәрсез югалганнар» әле дә ләмгә батып ятамы икәнни, йа бер Аллам?..

Хуш, бабай... Оныгың син кан түккән туфракка тезләнеп, рухыңа дога кыла... Рәнҗемә, мин сине әллә кайчан табарга тиеш идем, рәнҗемә...

Чакрым саен күз яшьләре коела... Әрнетеп-әрнетеп елата. Язам дигән иде, йөрәгеңә сыймаган бу хәлләрне кәгазь күтәрә алмас шул...

Картайган әнисенең сөенүе-көенүе бергә:

– Бер Аллам, әти турында ишетер көннәрем дә бар икән! Әбиең белеп китсә иде соң «мәңгелек йорты»на! Кимсенепләр яшәгәндер, мәрхүмәкәем. «Мин – уң канаты сынган ялгыз акчарлак», – дияр иде боекканда. Тугызынчы майларда фронтовик хатыннары, аллы-гөлле күлмәкләрен киеп, түш киереп, клубка – бәйрәмгә барганда, йөрәге сулкылдагандыр, бахыркаемның. Без – ятимнәргә ике ел пособие дә бирмәде хөкүмәт. Югалган солдат балалары идек без, килмешәкләр. Сөендерден бу хәбәрең белән, кызым. Пар канатың сынмасын, кияү белән тигезлектә гомер ит, миннән теләк сиңа.

...Көзге бакчаның үз матурлыгы: сары суккан агач яфраклары, саран кояш нурларына манчылып, алтынсу төскә керә. Ә гомер көзе нинди төстә икән? Акмы ул, яшелме, әллә шушы яфраклар төсле җете-сарымы? Арттагы елларга кул селтәп: «Мин һаман да унҗидедә», дип очынган күңел киндеренә буяуның кайсысын сайлыйсың бит! Аныкы – ак. Яшәлгән кадәресенә – шөкер, алдагысына да – шөкер...

– Җиле салкын, өшемә...

Миргалим иңнәренә җылы шәл яба. Илле өч ел элек бу асыл ир-егет белән очраштырган өчен рәхмәт сиңа, Раббым! Аның: «Бир шундый кеше, мине аңларлык, миңа терәк булырлык, мине җил-давыллардан сакларлык!» дигән теләген кабул кылдың...»

Сау булыгыз, акчарлаклар, акчарлаклар,
Мәхәббәткә кирәк икән пар канатлар.

Кирәк икән шул, кирәк...



Нәҗибә
Сафина

# ГОМЕР БУЕ КӨТКӘН УЛ ЯКТЫ ТАҢ...

## Әйтелмәгән сүзләр...

Әйтер сүзе калган кебек кышның, –
Буран туктамады, төнгә калды.
Кара түгел бу төн – ап-ак һава, –
Тоташ тузан кебек ак кар ява.

Каплап куя барлык сукмакларны,
Булмагандай югалалар эзләр.
Ә бит кемдер җылы җәйдән түгел,
Яшьлекләрен ап-ак кардан эзләр.

Әйтер сүзе калган кебек кышның, –
Тирәк башларына карын өя.
Кыш алдында гаепләре бардай,
Урман-кырлар кышка башын ия.

Әйтер сүзе кала һәр фасылның, –
Кышның, язның, җәйнең, көзләрнең дә...
Әйтелмәгәннәре серләрәк шул
Әйтелергә тиеш сүзләрнең дә.

Әйтер сүзе кала һәр кешенең,
Киткән чакта гомер көзләрендә. –
Чәчләре – кыш, күзләре яз кебек,
Көз сарысы була йөзләрендә.

Әйтелмичә калган сүзе җәйдер,
Яшеренгән кереп йөрәгенә...

---

Нәҗибә САФИНА (1949) *– шагыйрә, публицист. «Әгәр дә уйлаганда...», «Без – шигырь, тормыш – проза», «Кан хәтере» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Бүген буран

Бүген – буран, шундый йомшак буран, –
Кыш иркәли йомшак җиле белән.
Бүген урам ак-карадан тора, –
Кошлар күтәрелә иле белән.

Бүген кышның язга борылышы, –
Бер атнадан бар да үзгәрәчәк.
Бер атнадан таллар кызарачак
Һәм... офыкны каплар үзгә рәшә.

Бүген, буран – ак сулышы белән
Бөреләрне үбә, гүя кышны.
Туй күлмәген көчкә-көчкә генә
Тотып тора гүя яз сулышы.

Бүген – буран, ябалак кар түгел,
Ап-ак тузан гына туза икән.
Авыр кулъяулыгын болгый-болгый,
Дөнья шулай язга уза икән.

## Иртәгә – яз

Төнге Сабантуйда җиңгән батыр, –
Төн чыкканчы җиргә кайткан яз!
«Әпипә»гә бии тамчылары,
Ахры, болар гына язга аз...

Карлар авырайган, хәлсез ята,
Әллә көрәшкәндер язга каршы.
Тирәк өсләрендә карлар да юк,
Шуып төшкән икән инде барсы.

Иртәгә – март, иртәгә яз инде, –
Салкын салган эзләр җуелганнар.
Миләш чыпчыклары кабарынып,
Язгы киңәшмәгә җыелганнар...

Кыш белән яз алышынган мәл бу.
Карлар, бозлар тиздән эреп бетәр.
Җырчы кошлар кайтырлар да илгә
Куакларны сәхнәләре итәр...

Урман шаулап, кошлар сайрап торыр,
Язгы ташу кайтыр ярларга.
Төн көзгесе күккә йөзеп чыгар,
Тагы гашыйкларны барларга...

Бер уйласаң, берни үзгәрмәгән, –
Алсу таң да ата үз мәлендә...
Минем җанда гына башка халәт, –
Нишләтергә аны бу хәлендә?

Карлары да, бозлары да исән,
Яз ярсуы, җәйнең чилләсе дә.
Көзнең сары яфракларын ерып,
Син каршыма минем киләсең лә.

Төн чыкканчы алышынган дөнья, –
Тамчы тама җиргә тып та тып.
Синең хакта уйларымны гына
Булмый алыштырып, туктатып...

## Сәер халәт

Кара төннәрнең дә таңнары ал
Һәм кояшлы икән көндезләре.
Һаман шулай яктырталар икән
Төннең күген мең-мең йолдызлары.

Кара көннәрдә дә кешеләрнең
Күңелендә якты өмет яна.
Һаман шулай яраталар икән, –
Һәркем өчен иске сөю яңа.

Кара көннәрдә дә урман яшел,
Кара урманнарга нурлар үтә.
Үтә алмас урман сукмаклары
Язмышларны киләчәккә илтә.

Кара көннәр каплый алмый күкнең
Кояшын да, йолдыз вә аен да.
Аклыкларга кара таплар ята,
Кара таплар бөдрә ак каенда.

Кара көннәр уза вакыт белән,
Вакыт – тукталышсыз хәрәкәтме?..
Кара таплар ак, саф күңелләргә
Салып китә икән җәрәхәтне.

Сәер халәт: җәрәхәтле җаным,
Киләчәкне кара томан каплый.
Гомер буе көткән ул якты таң...
Гомер бетеп килә, һаман атмый.

## Бер көн – бер гомер

Бер кешене әгәр бер көн уйламый торсам,
Башка сукмак буйлап йөрү планын корсам, –
Исеп барган җил абына, кояш сүрелә.
Нидер керә дә кадала күңел түренә.

Бер көн әгәр җыр язмасам аңа багышлап,
Ишетергә теләсәмме башка тавышны, –
Бар тавышлар буталалар бергә өелеп,
Тамак төбемә утыра нидер бөелеп.

Бер көн, бары бер көн генә чыкса уемнан, –
Кире кайтам, барам диеп чыккан юлымнан.
Талгын гына сукмагыма этәрә җилләр.
Юл читендә миңа карап елмая гөлләр...

Бер көн әгәр шул кешене уйламый калсам,
Аның хакында тик бер көн уйламый алсам, –
Нишләр иде кояш, ае, җилләр, тирәкләр?
Әнә шулай уйлата шул сөйгән йөрәкләр.

Кояш-ае, тирәк-гөлләр бәлки үзгәрмәс.
Күңел күзе сукырлар да берни дә күрмәс,
Бу дөньяның гүзәллеген, агы-карасын...
Ярый, туктатты уйларым: кая барасың?

Аннан башка китеп барсаң, китеп барырсың.
Әмма һич тә көтелмәгән хәлгә тарырсың.
Әле ярый, узган юлга борылып карадың.
Чәчләреңне җылы куллар гына тарады...

Бер генә көн дә мин ансыз яши алмыймдыр.
Җилләр нидән тынып калды? – Хәзер аңлыймдыр.
Мәхәббәтенә абынып егыла җил дә.
Мәхәббәт тартып торгыза, егылгач, гел дә.

Бер көн... беркем белә алмас: гомер – ничә көн?
Көне дә гомер икән бит, чынлап сөйсәң син.

## «Дуадак кыз»дан Мөдәррискә

Миңа бер дивана кирәк! – Никләр син киттең?
Дөньямны сукыр, саңгырау һәм телсез иттең...

«Дәшмиләр» дип, тирәкләргә булмый үпкәләп.
Якындагы әрәмәдән йөрим үткәләп.
Җырлыйм... Алар тыңлап тора, җилләр пышылдый,
Безнең бөтен булганыбыз, диеп шушындый.
Чишмә суын җил күтәреп сибә йөземә.
Кабул итәм, рәхмәт, диеп, әйткән сүземә.
Күбәләкләр килеп куна минем иңемә.
Колак салалар җырларның иң, иң, иңенә!
Әмма өнсез каеннарның кара күзләре.
Ник әйтмиләр икән алар миңа сүзләрен?
Миңа бер дивана кирәк, барсын аңларлык.
Күңелдәге серләремнең барсын барлардык.
Ник киттең син, белгән килеш шулкадәр серне?
Кемгә калдырып китәргә белмим бу Җирне...
Җавап бирми тирәкләр дә, агымсулар да.
Юкса барсын сөйләп торам инде шуларга.
Дөнья синсез, дөнья телсез, дөнья саңгырау. –
Дөньясында нигә миңа ялгыз каңгырау?!
Дуадак каз түгел, түгел, дуадак кыз мин...
Беркем кулына алалмас сүрелмәс куз мин.

## Кеше булсагыз...

*(Г.Тукайның «Әллүки»енә ияреп)*

*Кичә Г.Камал театры*
*мөнбәреннән пышылдап кына*
*«Без исән», – дип «кычкырдылар».*

Ишеттем мин, кичә берәү сөйли,
Чыгар-чыкмас кына тавышы:
– Онытмадыгызмы? – ди шикелле. –
Милләт исән, дигән тавышны.

Мәйданнарда без кычкырган идек,
Сөрән салган идек ул чакта!
Йөрәкләрдә ялкын исән иде,
Утлар дөрли иде учакта!

Бүген инде, бүген кычкырмыйбыз, –
Тавыш юлларыбыз ябылган...
Җыелмаска, берни сөйләшмәскә
Пандемиясе дә табылган...

Бүген инде кануннар да башка, –
Үзфикерле булу тыела,
Чыдый алмый, сүз әйтүче бик тиз
Зинданнарга ябып куела.

Шуңа күрә Кеше дигәнебез
Тешен кысып кына ысылдый:
Мин кешемен, ләкин аңлагыз, ди,
Кеше булырга бит кушылмый...

Ишеттем мин кичә берәү җырлый.
«Яңа җыр» бу, түгел «Әллүки».
– Нинди көй бу? – диеп сорамадым, –
Әфьюн эчкән кебек «бәллү» көй.

Әллә тирә-юньдә һәммәсе дә
«Афәрин!» дип тора чәбәкләп? –
Әгәр башка көйгә күчә калсаң,
Кичектерми тора әләкләп...

Һәм... яңадан, тагы иске юлдан...
Тәпи-тәпи түгел, автозакта
Барачаксың яңа ГУЛАГка син,
Шуңа күрә авыз гел йозакта...

Шуңа күрә, әйе, пышылдыйлар,
Еланнардай гына ысылдыйлар.
«Цирк аренасы гүя яшәү,
Шул көтүгә син дә кушыл», – диләр.

Нишлим? Кушылыйммы? Кушыламын!
Тик көтүгә түгел, һушымда мин!
Кушыламын Тукай рухына,
Тугры калып шагыйрь бурычына!

Алсалар да, утка салсалар да,
Кусалар да ГУЛАГ юлларыннан,
Үз-үземә, барыбер, кайтачакмын,
Ата-бабам салган юлларымнан!

Кеше булып Җирдә яшәүләрнең
Башка юлы юк бит: ы-ша-ны-гыз!
Әгәр киләчәксез калмыйк, дисәк,
Кеше булсагыз сез, кыймшанысыз!

## Сора, тарих!

Ишетегез, миңа шундый авыр, –
Җанга баскан йөкне ни дип атыйм?
Гасырларча бастырыклап төеп,
Төялгәннең кем соң белсен атын...
Чиркәү диварларын тотып торган
Кабер ташларының авырлыгы,
Чукынудан качып, салкын судан
Чыкмый батканнарның сабырлыгы,
Тезләнгәнче, җиргә сеңим диеп,
Шуышмаган җаннар кайнар каны,
Танк чылбырлары арасына
Кереп тулган күзләр карашлары –
Барысы да җанны басып тора.
Шул хәлләрдә һаман ничек тере,
Ничек үлмәдең дип, сора, сора!
Сора, Тарих! Сора, җавап бирәм:
Мин Тарихка мәңгелеккә килгән.
Оча, йөзә, җәяү йөри беләм.

Хыял күгем йолдызларга җитә.
Саным – җирдә. Җаным күккә китә.
Җан – мәңгелек!
Мәңгелеккә килгән татар җанын
Кемнәр соң ул бүген үтермәкче? –
Үзен батырмыйча тотып торган
Рухи көймәләрне бетермәкче?
Мәңгелеккә алар туптан ата.
Ә мәңгелек шундый, тарих битен
Актара да тагын җиргә кайта.
Тарих китабыннан төшеп кала
Мәңгелеккә төбәп аткан туплар,
Бомба, ракеталар һәм танклар.
Җырлап ага бары тик Таныплар.
Җирне саклаганнар, сатмаганнар,
Бары Җир Китабын өйрәнгәннәр
Тарих Китабында сакланалар.

Сорамагыз инде минем хәлне...

## Беренче кар...

Кышка кергән көннәр... Беренче кар...
Соңга калды, ахры, карлары да.
Кышка кергән көннәр гомеремдә, –
Соңладылар, ахры, ярлары да...

Тылсымнары бардыр бу карларның!
Сихерләре бардыр, сихерләре!
Күктән җиргә төшеп каралалар, –
Җир-шагыйрьнең, ахры, шигырьләре!

Кышка кергән мәлләр, ап-ак карлар
Соңламады, сарды чәчләремә.
Җиргә төшкән карлар ташкын була,
Чәчкә төшкәннәре – яшьләр генә.

Язга кергән чакта елыймы җир?
Ташкын ташый, барыбер, ярын эзләп.
Мин – кыш башлы, яз йөрәкле ташкын, –
Утырамын һаман сине күзләп,
Тәрәз аша гына... Ә син ничек?
Очрашырбыз, дисәң, әгәр «анда»,
Мин барырга әзер «бүген күчеп».



Фирдүс
Гыймалтдинов

# ШОМ*

ПОВЕСТЬ

*И не в том ли дело, что предубеждения,*
*страх, ненависть*
*сужают планету до размеров стадиона,*
*на котором все зрители заложники,*
*ибо обе команды, чтобы выиграть,*
*принесли с собой ядерные бомбы,*
*а болельщики,*
*невзирая ни на что, орут: гол, гол, гол!*
*И это и есть планета.*
*А ведь ещё перед каждым человеком*
*стоит неизбывная задача – быть человеком,*
*сегодня, завтра, всегда.*
*Из этого складывается история.*
Чыңгыз Айтматов. «Плаха», 1986

*Ни пычакка андый ярыш безгә,*
*Ни пычакка андый дөньясы?..*
*Аяк өчен баш җаваплы түгел! –*
*Уен кыры – сугыш кыры ул! –*
*Безнең өлеш – җиңеп, күккә ашу,*
*Сезнең – җәһәннәмдә кырылу!*
*Дәррәү кубып күтәрелик кенә,*
*Дошманнарның тезе йомшарыр.*
*Бездән бер гол, бердәнбер гол кирәк!*
*Без – чемпион! –*
*Безнең туп – Җир шары.*
Рүзәл Мөхәммәтшин. «Матч-реванш», 2022

Ул танк чылбырларының шалтыравыннан, һавада самолётлар гөрелтесеннән сискәнеп уянып китте. Татлы йокыга гына талган кебек иде бит, бу хәсрәтләр кайдан килеп чыкты?!

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Татарстан Язучылар берлеге үткәргән әдәби конкурста «Повесть» номинациясендә беренче урынны алган әсәр.

Фирдүс ГЫЙМАЛТДИНОВ (1980) – *Татарстанның атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре; «Буа», «Урда ханы Үзбәк» китаплары авторы. Казанда яши.*

Хәер, хәсрәт дип атау килешмәс. Тимер атларын иярләгән, корыч кошларга ябышкан бу бәндәләр хәтәр, моны Ул бик яхшы белә. Озак көттермәсләр – танкларының әллә кая кадәр сузылган озын борыныннан ут көлтәсе ыргылып чыгар. Мизгел дә үтми, Аның болай да һич кызганмый каезланган сыртын снаряд актарып керер дә тирә-юньне дер селкетеп ярылыр. Бусы тынды гына дигәндә, һавадан сызгырган тавыш ишетелер, аның артыннан ук корыч кош салып калдырган «йомырка» килеп төшәр...

Аны элек Җир-Ана, тереклек бирә торган сулыкларын да истә тотып, Җир-Су дип кадерләп атап йөртәләр иде. Кешелекнең төрле чорын күрде ул. Бишектәге вакытын да, аннан арысын да. Тик менә бер нәрсәне генә һаман аңламый – адәми затлар, шушы гомер җир йөзендә яшәп, җитлегә алдымы? Үз тирәсендәге мохиткә һәм үзенә тиң башка кешеләргә карата дөрес мөнәсәбәтне җайларга акылы җиттеме? Әллә инде аның бишектәге, сабыйлык чоры – сагынып искә алырлык, чын, ихлас вакыты идеме?!

Танк чылбырлары аның мәсхәрәләнгән, болай да изелгән тәнен тагын да ныграк җәрәхәтләргә маташа шикелле. Үлем алып килүче бу әкәмәт тимер кабыкларда япь-яшь, мыегы тибә генә башлаган егетләр утыра. Менә алар, аның өстенә килеп кергәч тә, янәдән үзләренә генә аңлаешлы уеннарын башлар. Нигәдер ул уен һәрвакыт җимерү, юк итү, туздыруга корылган. Бөтен Җир шары буйлап сузылган җепселләре аңа җиткереп тора – биредә кыланганнары бары тик шаяру гына. Монда тәҗрибә туплагач, шушы бәндәләр чынлап торып кеше үтерергә чыгып китә, җиһанның әле бер почмагында, әле икенчесендә канлы бәрелешләр бер генә көнгә дә тынып тормый. Берсе туктадымы, икенчесе дөрләп кабына. Чиксез зиһен, белем, акыл иясе булган адәми зат, күрәсең, яшәү көчен әнә шулай – үзенә тиңнәрнең җанын кыеп салудан аладыр...

Берара тыныч кебек иде Аңа. Аны оныткан төсле дә булдылар. Кайчандыр атом бомбасы ярылган урынны хәтерләреннән чыгармас өченме, кечкенә генә бер һәйкәл корып куйдылар. Кешеләр үзләре «туксанынчы еллар» дип аталган чорда биредә бер мәлгә туплар ату, хәрби техника гөрелтесе, солдатларның «ура» кычкырып йөгерүләре тынып торды. Тик теге һәйкәл очындагы кыңгырау гына, биредә кылынган хәтәр җинаятьләрне искә төшереп, җилле көннәрдә чыңлап куйгалый иде...

> Кешеләр һәр нәрсәгә исем бирергә гадәтләнгән.
> Кайчандыр ул Җир-Су, Җир-Ана иде.

Олы Җир-Ананың бер кыйпылчыгы гына булса да, Ул хәзерге заман кешеләренә моны аңлатып бирә алмады.

Кешеләрнең дә төрлесен күрде. Үзенә табынганнарын да. Бер ишләре аңа үзенең сый-нигъмәтеннән өлеш чыгара торган иде. Суын эчкәнче, башта Аны сыйлый. Җир-Ана дип ихтирам белән эндәшә. Икенче берләре, басуда табын корсалар, «Җир иясе, син дә безнең белән ашарга утыр», – дип эндәшәләр иде. Үзгә бер ишләре аны Умай-Ана дип тә атап йөртте, бар тереклекне тудырган зат итеп күзаллады. Җир куенындагы мәгарәләрне ана карынына тиңләделәр. Шушы якларга күп гасырлар элек килеп чыккан кешеләрнең нәселе үзенең дошманнарыннан бары тик шул мәгарә эченә

качып кына котылып калган икән. Шуңа да куышларны изгеләштерү дәрәҗәсенә барып җиткән кешеләрне дә күрде Ул...

Аны хөрмәт итәләр, аннан куркалар да иде. Берәрсенең билдән түбән әгъзалары авырып китсә, «җир тоткан» дип хафага кала торган кешеләрне дә очратты. Ялгыш гамәлләре өчен гафу үтенүчеләр дә бар иде.

«Ай кайта, көн кайта.
Җир иясе – җирән сакал,
Су иясе – суган сакал,
Күк иясе – күгән сакал.
Ай кайта, көн кайта.
Каян килдең анда кит.
Икмәгем, тозым белән сорый килдем,
Үзең ярдәм кыл!
Калдыгы-колдыгы шунда булсын».

Шушындый җырлары да хәтеренә сеңеп калды. Кешеләргә «җыен ырым-шырымга ышанмагыз, мин сезгә чирегездән котылырга булыша алмыйм!» дип кычкырасы килә иде Аның. Тик теле генә юк. Ярдәм итү теләге дә зур. Ни гаҗәп, кайберләренә әллә шул ырымнар чыннан да сихәт китерә – терелеп куйганнары да булды. Шул ук вакытта, чиреннән котыла алмый, Аның куенына кереп ятып, соңгы сыену урынын табучылар да...

Дөньяның төрле чагын күрде ул. Исемнәре дә үзгәреп торды.

Ә көннәрнең берендә аңа Полигон дигән кушамат тактылар. Бу атаманың нәрсә икәнлеген ул озак та үтми бик яхшы аңлады. Шул ук адәми затлар аңлатты үзенә. Мәңгегә онытылмаслык итеп. Үзәгенә үтәрлек дәрәҗәдә.

Заманында Көнчыгыштан аның кунакчыл далаларына күчеп килгән бәндәләр идеме ул, әллә үзгәләреме?

...Үзенә килеп кадалган бомба аны хатирәләреннән айнытып җибәрде. Полигонда чираттагы хәрби өйрәнүләр башланды...

* * *

Будильник шалтыраганда, мин уянган идем инде. Гадәттә, уяну белән будильникны сүндерәм, әмма бу юлы ничектер башка килмәде. Мин һаман шулай – билгеләнгән вакытка нәкъ биш минут кала күзләрем ачыла да куя, йокы да әллә кая кача. Мондый халәт миндә генәме, әллә инде үзгә кешеләр өчен дә табигыймы – һич белгән юк. Һәрхәлдә, таныш-белешләр арасында сораштыру үткәрергә кирәк, йә булмаса интернетта актарынып карарга дип, үз-үземә максат куйсам да, урыннан тору белән әлеге мөһим мәсьәләгә ачыклык кертү кирәклеге онытыла да китә.

Телефонның будильнигы шалтырады, дидем бит. Башны чатнаттырып үтте. Кулым белән капшап, телефонымны алдым да, «стоп» төймәсенә бастым. Аннан соң капшана-капшана телевизор пультын таптым. «Россия 24» телеканалын кабызып җибәрдем.

Хәзер минем һәр иртәм әнә шулай башлана. Уянып китеп, телефондагы будильникны сүндерәм дә телевизорда яңалыкларны кушам. Моңарчы мин «Россия 24» телеканалын бар дип тә белми идем. Мин соңгы хәбәрләрдән башка да бик рәхәт яшәп ятканмын икән. Ә хәзер?! Нигә мин сихерләнгән

төсле шул канал төймәсенә басам? Сәбәбе бер генә – өмет дигән бер чаткы. Бәлки, менә бүген җиңгәнбездер, бәлки, менә бүген тегеләр җиңелгәннәрдер. Бәлки, бәлки, бәлки...

Тик өмет чаткысы янәдән пыскырга да өлгерми сүнде. Экрандагы дикторның кыяфәтендә бер генә үзгәреш тә юк иде – аның йөзеннән җиңүгә ишарәләгән нурлар бөркелмәде. Телевизорга аслы-өсле язылган хәбәрләрдә дә шатлыклы сүзләр күренмәде. Барысы да элеккечә. Фәлән төштә фәлән кадәр нацист үтерелгән, төгән кадәр техника юк ителгән, әллә ничаклы ракета бер яктан икенче якка очып килгән. Кем генә ул ракеталарны, мәетләрне, шартлатылган танкларны санап утыра икән? Бигрәк авыр һәм шул ук вакытта үтә дә күңелсез эштер ул...

Алып баручы алмашынды, аның урынына күзлекле һәм корсаклы бер агай чыгып, һава торышы турында сөйләргә кереште. Әмма сүзе, атмосферадагы үзгәрешләрдән бигрәк, дошман җирендәге атом-төш шартлавына багышланган иде. Ул, әгәр әлеге шартлау була калса, агулы болытларның кай якка юнәлеш аласын фаразлады. Аңа ышансаң, үлем китерүче яңгыр, һичшиксез, Европа илләренә таба китәргә тиеш. Бер дә безнең якка түгел. Шатланырга да, кайгырырга да белми, телевизорны сүндердем.

Кухня ягында хатынның савыт-саба белән шалтор-шолтыр килгәне ишетелде. Минем уянганлыкны белеп, йокы бүлмәсенә керде.

– Хәерле иртә, – диде ул, гадәттәгечә, миңа борылып карамый, киемсалым шкафындагы чүпрәк-чапракларга багып. – Бүген Наиләләргә кунакка барасы, онытмадыңмы?

– Онытмадым. Сәгать берләргә түгелме соң?

– Бергә.

– Алайса мин бераз ятып торыйм әле. Өлгерербез.

– Нәрсә кияргә дә белгән юк, – диде хатын, кием шкафында чаштыр-чоштыр казынып. – Бер юньле күлмәк тә юк бит, ичмасам!

Мин, үрелеп, аның тарафына күз салдым. Киң шкафның ишекләре ачылып куелган. Рәт-рәт булып хатынның күлмәкләре, туны, кофталары, тагын әллә нәрсәләре тезелеп киткән. Бер почмакка минем биш-алты күлмәгем белән ике пинжәгем елышкан. Миңа башта – алар, аннан үзем кызганыч булып китте. Хезмәт хакымның күпме өлеше хатынны киендерүгә китеп бара, ә аңа һаман җитми!

– Әллә кем түгелләр, нәрсә кисәң дә ярый, арт саның гына ялтырамасын, – дип мыгырдандым мин, башымны юрган астына яшереп.

– Сиңа кызык... – Хатын, мине чыгырымнан чыгарыр өчен юри лаплоп басып, тәрәзә янына атылып килде, бөжраларының сызгыруы тешкә тиярлек итеп, кисәк кенә эленгеләрне як-якка тартты. – Әнә, беренче кар яткан... Ул эреп бетәр инде. Иртәдән салкын, көндез җылы, кичен янә салкын... Синең сүзне тыңлап, Наташадан теге күлмәкне дә алмадым, ичмасам! Нәкъ бүгенге көнгә яраклы иде...

Мин дәшмәдем. Бу тагын да ныграк ачуын китерде. Хәтта калын юрган аша да хатынның үземә текәлгән усал күзләренең зәһәр утын тойдым. Берәү булса, бу очракта «аның сүзсез карашыннан куырылып килдем», дияр иде. Юк, куырылмадым. Табадагы тавык йомыркасы түгел лә мин куырылырга! Күнегелгән, ничә ел бергә яшәп...

Хатын, янә лап-лоп басып, бүлмәдән чыгып китте. Әлбәттә, тәрәзә эленгеләрен ачык калдырды. Миңа үч итеп. Ишекне дә. Чөнки боларның икесе дә миңа ошамый, мине җенләндерә, чыгырымнан чыгара.

Хатын исә билгесез сәбәпләр буенча вәхшиләрчә башлаган иртәнге һөҗүменең икенче өлешенә күчте. Ул кухняда торган көе улыбызны тиргәргә кереште. Көне буе компьютер каршында утыра, рәтләп укымый, чүп ташларга да иренә, тузан суырткыч белән бүлмәләрне җыештырырга кушканнан бирле күпме вакыт үтте – ник селкенсен, һәм башкалар, һәм башкалар. Бу нисбәттән улыбыз кемгә охшагандыр – хатынның сүзен колагына да элми, туктаусыз тиргәүгә һич исе китми, тыныч кына компьютерында уйнавын дәвам итә. Ә тегесе аның саен кыза бара, тавышы күтәрелгәннән-күтәрелә. Гадәттә, андый очракларда, мин, түземлегемне җуеп, баланың бүлмәсенә йөгереп керәм дә, күзләремне акайтып, «Ишеттеңме юкмы, анаңны?!» – дип кычкырам (төрле очракка һәм минем күңел халәтемә карап, «анаңны» сүзе алдыннан өтер куелырга яисә куелмаска мөмкин). Шуннан соң гына теге малай актыгы кушканны эшли. Теләмичә, кирелеген күрсәтеп, әмма эшли. Хатын бүген дә әнә шулай өтерле «анаңныларга» җитәрлек итеп өянәгем кузгалыр дип өметләнә. Ә мин ишетмәмешкә салышам. Бүген гадәттәгечә булмас. Тик кычкырсын шунда...

Хатын бүген иртәдән болай кыланырга тиеш түгел бит. Аның дусларына кунакка барасы – димәк, ул миңа бурычлы. Наилә – дус кызы. Мин Наиләне үлеп сагынган кеше түгел. Киресенчә, аны күрмәс өчен күп нәрсәне бирер идем. Әмма аны чыннан да күрмәс өчен бер генә юл бар – хатыннан аерылу. Ә мин моңа әзер түгел. Һәм эш баланы үстереп, аякка бастыру яисә түләнеп бетмәгән ипотекага гына килеп терәлмәгән. Болар, әлбәттә, үтә дә җитди сәбәпләр. Алар хәтта «аерылсам, әни нәрсә әйтер?» дигән хәтәр сораудан да болайрак борчый. Юк, яратам мин хатынны, бары шул гына. Ничек бар – шулай яратам. Шуңа аерыла алмыйм. Ә ул Наиләдән аерыла алмый. Миңа түзәргә туры килә.

Наилә – бик сәер хатын. Мин хәтта аңардан куркам да. Белеме буенча ул – архитектор. Дөресрәге, ул үзен бу дөньяга архитектор итеп яратылган кеше дип саный. Теләсә кайсы кешенең үзе турында шулай уйлавы, минемчә, психик диагноз күрсәткече. Беркем дә әзер хезмәт кенәгәсен йомарлап тоткан килеш тумый бит. Тик Наилә белән бу хакта бәхәсләшү, әлбәттә, зур мәгънәсезлек. Гомумән, аның белән бәхәсләшү түгел, әллә ни җәелеп китеп сөйләшү дә мөмкин түгел. Ул үзе белән әңгәмәдәше арасында баштан ук җимереп булмаслык дивар салып куйган төсле. Күзгә карамый, сорауларга җавап биргәндә дә «әйе» белән «юк»тан ары китми, минем хатын кебек озаклап ләчтит сатарга, кирәксә-кирәкмәсә төрле чигенешләргә чумарга яратмый. Аның елмайганын да мин бик сирәк күрәм. Йөзе һәрвакыт та битлек артына яшеренгән төсле. Бик сагышлы, уйчан, вакыт-вакыт кызганып куярга мәҗбүр итә торган битлек ул. Бәлки, моңа аларның балалары булмау сәбәпчедер? Ул кадәресен мин әйтә алмам. Әмма без бит Наилә белән аларның туеннан ук, Фаил белән өйләнешкән көннәреннән бирле таныш. Наилә ул вакыттан бирле миңа нәкъ шушындый күңел халәтендә истә калган.

Ире Фаил да, хатыны төсле үк, архитектор. Алар Казан дәүләт архитектура-

төзелеш институтында укыганда танышканнар. Наилә Фаилдән бер курска өлкәнрәк. Фаил тумыштан ук әлеге һөнәр иясе буларак яратылганмы, әллә инде бу аның кәсебе, тамак туйдыру чарасы гынамы – бу кадәресен үк мин бер дә әйтә алмыйм. Тик ул шулай ук үзенең сәерлеге белән хатынына нык охшаш. Кыяфәте килбәтсезрәк – олы гәүдә, зур баш һәм шул ук вакытта бик юаш, нәзберек күңел. Чәчләре җирән төстә, уттай янып торалар. Бите вак-вак сипкелләр белән чуарланган, алар, елның кайсы фасылы булуына карамастан, һәрвакыт мулдан, беркая да югалмыйлар. Күзләре калын пыялалар артына яшеренгән. Әгәр Наилә белән Фаил бер пар буларак бер-берсенә туры килгәнлеген исбатларга кирәк икән, бу әллә ни авыр түгел. Зифа буйлы, чем-кара чәчле, чибәрлеге белән еракtан теләсә кемне җәлеп итәрлек Наилә, текәлебрәк караганда, якынрак аралашканда, үзенең салкынлыгы белән күңелне кайтара, синнән өстенрәк торырга маташуы белән читләшергә мәҗбүр итә. Һәрбер әйткән сүзеннән җылылык, ачыклык, миһербанлык бөркелгән, кешегә беркайчан да каты бәрелмәгән Фаил исә үзенең җирән аюга охшаш кыяфәте белән сөйкемсезгә әйләнә дә куя, аның белән шулай ук бик якынаеп эш йөртәсе килми. Шушы капма-каршылыклы сыйфатлары бәрабәренә алар, һичшиксез, бер-берсен тулыландыра. Шуңадыр да, балалары булмаса да, унбиш елдан артык бергә яшәп яталар...

Наилә белән Фаилнең безне кунакка чакыру сәбәбе миңа яхшы мәгълүм. Алар үзләре өчен бер юаныч чарасы таптылар – Казанда тиңе булмаган проектлар буенча коттедж салып, шунда бер-ике ел яшиләр дә, аны сатып җибәреп, яңасына күчәләр. Ягъни өй туен үткәргән вакытта төзүчеләр инде чираттагы коттеджның нигезенә керешә. Моның ни дәрәҗәдә отышлы бизнес икәнлеге миңа билгеле түгел. Әмма мондый сәер гамәлләрендә мин аңлап бетермәгән серлелек һәм хәтта могҗиза да бар иде. Бүген алар чираттагы коттеджларын күрсәтер өчен дусларын җыялар. Хатын сүзләренә ышансаң, шунда төпләнеп калырга ниятлиләр икән. Үзләренең күңелләренә чыннан да хуш килгән, хыялларында күзаллаган йортлары әзер, димәк. Наилә белән Фаилне күрергә бик атлыгып тормасам да, ике шашкан архитекторның иҗат җимеше белән танышу теләге күңелне кымырҗытып тора иде, әлбәттә...

«Британиянең элеккеге Премьер-министры Лиз Трасс ике дә уйламый атом бомбасын кулланырга әзер икәнлеген һич тартынмый әйтте бит!» – дип кинәт кычкырып җибәрде кухнядагы телевизор. Хатын, тавышны тизрәк бастырып, мин кичә кичтән караган каналдан «Мәйдан»га күчәргә ашыкты. Тик Филүс Каһировның «Киек каз юллары» бер иртә эчендә икенче тапкыр ыргылып кергән шомны тарата алмады. Һавада кошлар тезмәсе түгел, каядыр очып киткән ракетадан калган төтен эзе күзалланды. Шайтан алгыры!

Боргаланып куйдым. Әллә ничә ел буе рәхәтләнеп йоклаган урын-җирем уңайсыз тоелды. Авылдан әни җибәргән тоташ каз мамыгы тутырылган мендәр дә кинәт кечерәеп калды сыман. Әйтерсең мамыгы эреп югалды. Ләкин бу – бары тик шул мендәрне һәм тирә-юньдәге чынбарлыкны минем кабул итү рәвешем үзгәрү бәласе генә. Кайдан килә соң бу шом, бу гасабилану, үзәкне өтеп ала торган курку?!

Бер көнне кухняда кичке ашка утырдык. Түрдә, әлбәттә, телевизор. Стенага эленгән, шуннан салынып, безгә текәлгән. Дөресрәге, миңа. Янә

сугыш күрсәтәләр. Экрандагы диктор чираттагы шәһәрне ракеталардан утка тоту хакында бәян итә. Әллә тегеләрнең коралы безнең торак йортларны җимергән, әллә безнекеләр тегеләрнекен. Анысын һич аңламассың. Йорты гел үзебезнекенә охшаш. Аларда да шул, бездә дә. Кешеләре дә. Анысы мөһим дә түгел. Ракетаның әллә ялгыш, әллә махсус рәвештә күп катлы торак йортның иң өстәге фатирларын җимереп үткәнлегендә хикмәт. Моны ишеткән улым шунда ук миңа шелтәле караш ташлады.

– Зерә без тугызынчы катны сайлаганбыз, – диде ул, әлеге ракетаның бертуганы һичшиксез безгә очып килеп җитүенә тамчы да шикләнмәгән тавыш белән.

– Бу ни дигән сүз тагын?! – дип чәчрәп чыкты хатын. – Сиңа аерым бүлмә булсын өчен без муеннан бурычка чумдык, рәхмәт әйтәсе урынга...

Улыбыз тынычлыгын җуймады, әнисенең чәпчүеннән үзенә генә мәгълүм тәм табып, бераз көлемсерәп, экранга төртеп күрсәтте:

– Әни, ракеталар башта шәһәр йортларының өстәге катларына эләгә! – диде ул, борын астыннан төртелеп чыккан беренче мыек йоннары аша елмаеп.

– Эләксә ни?! Анда эләгә! Ә без... Без монда бит, еракта, бездә сугыш юк, без... Без...

Хатын, яклау табарга өметләнеп, миңа ялварулы караш ташлады. Мин аны күрмәмешкә салыштым, Белгород шәһәрендәге шартлау-һөҗүмнәр хакында корреспондент бәянына кереп чумган итендем.

– Әйт инде шул мәгънәсезгә! Көне буе компьютердагы дошманнары белән сугышып, тәмам акылын җуйды бит! Авылга әбиең янына җибәрәсе, белер идең! – дип, хатын аның да, минем дә тирән йокыга талган вөҗданымны уятырга маташты. Ләкин минем бу бәхәскә кушылырга тырнак очы кадәр дә теләгем юк иде. Улыбыз исә киресенчә уйлый икән.

– Әни, син уйлап кара инде. Әнә тегендә Казан авиация заводы, «Аккошлар» дип йөртелгән бомбардировщиклар шунда ясала, шушында ремонтка кайталар. Икенче якта вертолёт заводы, анысы да гел хәрби техника җитештерә. Оптика, радиоэлектроника, тегесе-монысы... Сугыш өчен Казан күпме әйбер эшләп чыгарганын беләсеңме? Киров районында итек басу комбинаты гына эшләми, гәрчә итекләр хәзер бик кирәк булса да. Шуңа күрә, алай-болай була калса, безнең шәһәребез...

Бу юлы инде мин дә имәнеп киттем. Улыбызның көлемсерәп әйткән әлеге сүзләренә бигрәк тә куркыныч һәм чәчләрне үрә торгызырлык хакыйкать салынганлыгы йөрәкне чәнчеп үтте.

– Җитәме сезгә, юкмы?! – дип өстәлгә сугып, табыннан тордым. Тегеләр тындылар кебек.

Бу – бер ай чамасы элек булган вакыйга. Ә бүген?! Улым әйткән күңелсез фаразлар миңа һаман да тынгылык бирми, бимазалап тора. Башымдагы әлеге мәгънәсез уйларны читкә куарга тырышып, игътибарымны янәдән бүген көтелә торган вакыйгага – архитекторлар гаиләсе белән очрашуга кайтарырга маташтым.

Тик баш эшләмәде. Хатынның улыбыз белән «бәрелешләре» исә йокымны тәмам качырды. Мин, аптырагач, телефоныма үрелеп, каһәр суккан Телеграммга кереп чумдым.

«Санкт-Петербургны атом-төш ракеталары белән утка тотарлармы?! – дип сорау алырга кереште миннән беренче күзгә ташланган хәбәр. Аннан соң язылган сүзләр үзләренең ышандыру сәләте, хакыйкатькә яман дәрәҗәдә якын торуы белән тәмам котны алды: – Бүген американнарның B-52H «Стратфортресс» бомбардировщигы төньяк башкалага ракеталарын юллау буенча хәрби өйрәнүләрдә катнашты. Ул Санкт-Петербургтан 200 чакрым ераклыктагы Готланд утравына кадәр үк килеп җитте, аннан, кисәк кенә борылып, Литва ягына китеп югалды. Атом-төш коралы йөртүче әлеге очкыч, хәрби өйрәнүләрнең легендасы нигезендә, Россия шәһәрләрен, шул исәптән Петербургны юкка чыгаруга әзерлеген тикшерде».

Юк, йоклап булмый! Торырга кирәк! Көтеп алынган ял көнемнең яме тәмам югалган иде инде...

Кухняга кереп утырдым. Хатын борылып та карамады, плитә каршында кайнашуын дәвам итте.

«Син елмаеп озатып кал, ә мин елмаеп китәм», – дип, телевизордан җыр сузды Әнвәр Нургалиев. Яңа гына төшерелгән клибында хәрбиләр йөгерешә, мобилизацияләнгән егет гаиләсе, сабые белән аерылыша. Пультны алып, каналны күчердем. Ни гаҗәп, сугыш, атом бомбасы һәм башка шундый нәрсәләр турында сөйләми торган каналны таба алдым. «Культура» дип атала иде ул. Чит илдә төшерелгән документаль фильм Мисыр фиргавеннәре турында сөйли.

– Фиргавеннәр турында барысын да белеп бетердек бугай инде, – дип мыгырданды хатын, телевизор экранына беравык текәлеп карап торгач. – Шөкер, хет аларның тарихын ачыклый алдык шикелле, үзебезнекен генә белгән юк.

Хатынга, нигәдер, каршы дәшәсе килмәде. Әллә сүзләре чыннан да хак булып тоелды, әллә бәхәскә керерлек кәеф булмады. Хәер, хәзер тарихыбызны чынлап торып өйрәнергә керештек димәкче идем диюен. Әмма әлеге теорияне аңлатып тору артык озакка сузылыр кебек иде.

– Наиләләр күп кеше җыямы соң? – дип, сүзне икенчегә бордым.

– Күп түгел, син дә, мин дә, башкалар. – Хатын, гадәттәгечә, миңа аркасы аша гына җавап кайтарды. – Курыкма, сиңа эчәргә кеше табылыр.

– Син рульгә утырасыңмыни?

– Кунача барабыз.

Киеренкелекне киметә төшеп, кухняга улыбыз керде һәм урынына барып утырды.

– Сез танк полигонына бардыгыз түгелме? – дип, капылт кына исемә төште.

– Әйе, бардык. – Улыбызның тавышы төссез, битараф иде.

– Ну, нәрсә күрдегез инде анда?

– Мылтыктан аттык. Алты патрон бирделәр.

– Алай икән. – Әнисе балабыз каршына йомырка тәбәсе салынган тәлинкәне куйды, тостердан көйдерелеп чыгарылган ипи кисәген дә өстәде. – Чын патрон түгелдер, шәт?

– Ник чын булмасын, чын. Безгә автоматлар тоттыргач та, командир кисәтеп куйды: «Уңга ата күрмәгез, анда аэропортка илтә торган юл, сулга ата күрмәгез, анда бакча йортлары», – диде...

– Әстәгъфирулла... – Артык динилеге белән аерылып тормаган хатынның, чыннан да, коты чыкты бугай. – Унынчы класс баласына чын автомат бирәләрмени?!

– Ку-ку, әни! Сугыш бара, син күрмисеңме әллә? – дип, улыбыз анасын үртәп куйды.

– Сугыш түгел! Түгел, ишетсен колагың! Операция дип йөртелә!

– Ил язмышы – ир өстендә, улым, дөрес әйтәсең. – Мин дә улым ягына бастым. – Без яшь чакта ул хәрби уеннардан кайтып керми идек. Автоматны күзне йомган көе сүтеп җыйдырталар иде. Ә противогаз киеп, өчәр чакрымлы марш-бросоклар?! Мәктәптә тир бар иде, чып-чын, нефтьүткәргеч торба кисәгеннән. Бер башыннан кереп атасың, икенче башында мишень кәгазе эленгән. Атагыз һәрвакыт бик төз атучы иде! Синеке ничегрәк, улым?!

– Полигондагы командир «стрелок булырсың», – диде...

Моны ишеткән хатын берара һуштан язып торды бугай, тәмам сүзсез һәм хәрәкәтсез калды. Аннан, авыр сулап, урындыкка килеп утырды.

– Аркылыны буйга алып салмый торган булып үсәсең бит, балам! Рәзве шулай ярый?! Кем андый чакта төз ата, кем ыштаныннан сикереп чыгар дәрәҗәдә тырыша, йә, әйт әле?! Унсигезеңә озак калмады, мине шулай яшьли гүргә кертүме ниятең?!

– Рәхмәт, тамагым туйды, – дип, улым әнисен ишетмәгән кыяфәт белән табыннан торып китте.

– Ярый, нәрсә син шулкадәр йөрәгеңне бозасың?! – Үзем дә кинәт уңайсызланып, хатынны тынычландырырга маташтым. Кызганып куйдым! Иргә эшләп түгел, кешнәп ярыйсың, дип юкка гына әйтмиләр, анысын булдыра бит, каһәр! – Яшьтәшләре янында сыната алмый бит инде ул. Әни кушты дип, кыек атсынмы?! Аннан соң, унсигезенә кадәр вакыт бар әле, аңа кадәр дөньялар мең төрлегә әйләнер... Әйтәм бит, безне дә...

– Сезне дә?! Үзе ахмакның сүзе ахмак, ди, син дә – шуларның сыңары! Әллә сезне хәрби полигоннарга китереп, чын автоматлардан аттырдыламы?!

Хатын кулындагы тастымалын ачу белән өстәлгә ыргытты. Мин, аңа күтәрелеп карамыйча гына, табыннан тордым. Кунакка барырлык кәеф калмаган иде инде. Кырынырга, җыенырга кирәк. Бәлки, бераз вакыт үтү белән хатынның да күңеле үз урынына кайтыр...

* * *

Полигон... Үзенә шундый кушамат белән эндәшә башлауларына бер гасырга якын вакыт, ә ул һаман да ияләшә алмый. Бәлки, теге, беренче кешеләрдән калган тәэсирләр аның күңелен шулай нечкәрткәндер?

Алары да әллә ни сабыр, тыныч, дустанә күңелле дип әйтерлек түгел үзе. Атка атланган көе даланы иңләп, бер-берсе белән шактый чәкәләштеләр, канкоеш та хәйран булды. Әмма ул үзгә низаг шикелле иде. Аларның дошманлыгында гаделлек бар төсле тоелды. Әлбәттә инде, дошманлыкка «гаделлек» төшенчәсе туры килерлек булса...

Канлы бәрелешләрдә көндәшләрен аямадылар. Әсирлеккә төшкәннәрне дә чамадан тыш кырыс итеп җәзалыйлар иде. Бер-берсенә мондый

мөнәсәбәт белән бергә, җир-суга, тереклек ияләренә бөтенләй икенче төрле мөгамәләдә булдылар. Йорт хайваннарын бик кадерләп тоттылар, аеруча атларга карата ихтирам-хөрмәт зур иде. Дөрес, иң шәп атны бер сәбәпсез үтереп ташлап, тиресен агачка тарттырып киптерү очракларын да күрде. Ләкин кешеләр моны мәрхүм малкайга аерым бер илтифат күрсәтү билгесе дип кабул иттеләр, Җир-Суга табынган төсле, шул кипкән ат кабыгына да табынып яттылар. Сәер инде ул кешеләр. Ни дисәң дә, кешелекнең дә бишектәге чагы, сабый чагы иде бит ул... Самими вакыты, усаллыктан, явызлыктан, мәкердән азат булып яшәгән чоры...

Аның тирә-юне танклар гөрелтесенә, алардан чыккан сөремгә чумды. Бу мәхшәрдә колаклар да тона, сулыш та буыла шикелле. Әмма тимер тартмаларга кереп поскан бәндәләр ничектер түзәләр, сер бирмиләр. Үзләренә генә мәгълүм, күренми торган көндәшләрен, ягыларын юк итәргә ниятләре нык боларның.

Алар бит яралганнан бирле дошмансыз яши белмәде. Сугышмыйча бер генә көн дә тормадылар шикелле. Һәм бу тәртип, нигәдер, гасырлар буе дәвам итә. Алай гына да түгел, бер-берсен юк итү ысуллары торган саен шомара, камилләшә бара.

Ул әле укларны, сөңгеләрне хәтерли. Аннан соң кирмән диварларын җимерер өчен зур ташлар ата торган җайланмалар уйлап таптылар. «Грек уты» белән бер-берсен яндырдылар, көйдерделәр. Тимер төкерүче көпшәләр уйлап таптылар. Ул көпшәләр торган саен зурая барды, алар салган яралар да тирәнәйде. Тик адәм затларына бусы гына җитми иде. Кеше, бөтен булган акыл көчен җыеп, үзеннән соң бернинди тереклек тә калдырмый торган корал уйлап чыгара алды. Әлеге коралның агуы, полигонның яралар белән телгәләнгән тәнендә әле дә саклана...

Ул үзенең күренмәс җепселләре белән бөтен Җир шары белән тоташкан. Ул белә – аның шикелле полигоннар бихисап, һәм әле анда, әле монда Ходай бәндәләре хәрби уеннардан һаман да арына алмый.

Аның өстенә янә танк чылбырлары ябырылды, ул янәдән онытылырга, хатирәләр чоңгылына төренеп, аз гына булса да йокыга талырга маташты...

* * *

Күпме генә үгетләмик, улыбыз безнең белән бергә барудан катгый рәвештә баш тартты. Өйне җыештырып чыгарга да, әллә никадәрле китап укырга да, башка төрдәге чамасыз корбаннар китерергә дә әзер иде ул – тик кунакка гына өстерәп бармагыз! Ахыр чиктә безгә хатын белән күнәргә туры килде. Әнисе суыткычка ризык тутырып, кайсын ничек җылытасын, нинди тәртиптә ашарга тиешлеген кат-кат аңлатырга кереште. Буе үзеннән дә биегрәк дәүмәткә болай күрсәтмәләр бирү читтән карап торганда көлке тоелды.

Хатынның, «алдыңа бер карасаң, артыңа биш кара» дигән, үлемсез тормыш кагыйдәсе нигезендә йөз тапкыр газны, утны-суны тикшереп, улыбызны әле башыннан сыйпап, әле тиргәп, ниһаять, җыенып та беттек шикелле.

Лифттан чыккач та, хатын игъланнар тактасы каршында төртелеп калды. Зур кызыксыну белән нәрсәдер укыганын күргәч, үземнең дә күңелгә коткы керде.

– Нәрсә, әллә кайнар суны бетереп торалармы? – дидем, аның иңе аша үрелеп.

Тик теге тактада ЖЭУ игъланы күренмәде. Инде ярты елдан артык эленеп торган плакат иде бу. Анда, әгәр бомбага тоту турында кисәтү ишетелсә, ни эшләргә тиешлеге язылган. Документ-фәләннәреңне җыярга, бала-чага, туган-тумачаны эләктерергә, бер тәүлеккә җитәрлек ризык алырга... Әлеге плакат әллә бик күптән бастырылып, складта аунап яткан, әллә инде аны шактый олы яшьтәге кеше ясаган – рәсемнәре хәзерге чынбарлыкка мыскал гына да туры килми. Лампалы телевизор, хан заманындагы радиоалгыч – барысыннан да совет чоры «исе» аңкып тора. Ямау төсле ябыштырылган кәгазь кисәге безнең өйнең бомбадан саклану урыны күршедәге Сибгат Хәким урамындагы икенче бер йортта урнашканын хәбәр итә.

– Син нәрсә, әллә беренче күрәсеңме? – дип, мин әлеге плакатка ымладым.

– Элек тә бар идемени?..

– Бер елга якын эленеп тора бит инде.

– Һич игътибар итмәгәнмен... – Хатын куркуга төшкән төсле тоелды, мин аны янә кызганып куйдым. – Бу нәрсә дигән сүз соң? Безне бомбага тоталар дигәнне аңлатамы?

– Теориядә. Хатын, син нәрсә инде? Инде кайчаннан бирле илебез дошман белән көрәшә, ә син?!. Айдан егылып төштеңме әллә?! Көн дә шушыннан үтеп йөреп...

– Соң, бомба төшсә... Сибгат Хәким урамында котылу урыны, ди. Без анда барып җитә алмабыз бит!

– Бомба ул, ничек дип әйтим, самолёт шикелле. Очып килә. Шап итеп кинәт кенә килеп төшми, аңлыйсыңмы?! Америкадагы шахтадан чыгып киттеме, безнекеләр күреп ала да бөтен илгә сөрән сала. Син инде ашыкмый гына җыенасың да китәсең шул саклану урынына!

Хатын миңа усал карашын ташлады.

– Сиңа көлке бугай! Баланы аякка бастырасы бар! Ул саклану урыны берәр подвалдыр инде. Котылып калдың ди, бар... Бала мәктәптә чакта булса?

Мин хатынның чынлап торып куркуын аңлап тынычландырырга ашыктым.

– Йә, ташла инде! Без кемгә кирәк?! Аның кадәресенә үк барып җитмәс, куркалар безнең илдән, – дип, хатынны тизрәк теге плакат яныннан ишеккә таба әйдәдем.

Китеп барганда янә бер әйләнеп карадым – бомбага тоту очрагында нишләргә кирәклеген шәрехләүче әлеге белешмә өстендә икенче бер игълан эленеп тора. Анысы законны бозмый гына хәрби билет алырга ярдәм итүче юристлар компаниясен рекламалый иде. Армиягә барып тору кирәкми, янәсе, акчаңны түлә дә запаска теркәлеп куй. Ике каршылыклы мәгълүматның шулай бер урында очрашуы безнең хәзерге тормышыбызның бик аңлаешлы шәрехләмәсе иде...

Хатынның исә буыннары ук калтырана әйтерсең ул әле генә сугышның ни икәнен аңлаган, моңарчы телевизордан күрсәтелгәне кайдадыр еракта, аңа үрелмәслек арада кебек тоелган. Ә хәзер шушы плакат аны айнытып җибәрде, күңеленә инде безнең җиңү игълан ителгәнче сакланырлык авыр тойгы салды шикелле...

Урамда беренче кар эреп тә беткән, аяк асты чак кына дымлы иде. Хатын, таеп егылмас өчен, мине култыклап алды. Рәхәт булып китте. Тирә-якка карадым – күршеләр күрәме, янәсе?! Яхшы ир белән хатын хур булмый, әнә шулай кадер-хөрмәттә, таянычына сарылып яши. Безнең йортта моның белән мактанырлык хатыннар бармак белән генә санарлык шул...

– Кайда, Салмыч ягындамы? – дип сорадым мин, машинаны кабызып җибәргәч тә.

– Юк, бу юлы бөтенләй дә шәһәр яны түгел. Тору урынын ерактан сайлаганнар. Бакча-Сарайдан арырак, Матюшино авылыннан соң.

– Нинди Матюшино, «Хәерчеләр авылын» әйтәсеңме?!

– Анысы нәрсә тагын?

– Соң, Идел буенда, Боровое Матюшино бар бит...

– Ә, юк. Бусы да Идел буенда, тик уң як ярда, нәкъ каршыда. Бер-берсенә карашып утыралар.

Мин телефонымдагы картага кереп чумдым. Навигатор барасы юлны сызып та бирде. Сызгырып ук куйдым – бер сәгатькә якын сарыф итәсе! Бигрәк ерак кереп качкан болар...

Юл безне Ульян юнәлешенә таба әйдәде, аннан соң Кама Тамагы ягына борылдык. Аз гына үтү белән, янә сулга, бу юлы Иделгә таба.

Биредәге манзара һушны алырлык иде! Ике як басуда кукраеп утырган көнбагыш кәрзиннәре өсләренә өелгән кардан бөтенләй салынып төшкән. Бу аклы-каралы дөнья һөҗүмгә баручы әкияти карачкылар армиясен хәтерләтә. Аларның караеп калган озын сабаклары, әйтерсең, таҗларны югарыга, яктылыкка күтәреп чыгарырга омтыла, әмма хәлләреннән генә килми. Без әллә ничек өстән, гүя, һавадан барабыз, ә аста – иксез-чиксез Идел елгасы җәелеп ята! Ул чыннан да җәелгән, аның өстендәге дәү баржалар биредән кечкенә шырпы тартмалары шикелле генә күренә. Иделнең ике ярын да агачлар басып алган. Чыршы-нарат үскән урыннар ямь-яшел, калганнары инде яфракларын да коярга өлгергән. Нәкъ каршыбызда, елганың аргы ягында Казаныбыз. Көннең иләслеге аркасында аның бинаалары әллә ни аермачык күренми, әлбәттә. Ләкин, шулай да, туристлар өчен бастырылган магнитлардагы сурәтне абайларга мөмкин. Тикмәгә генә Тау ягы түгел шул бу!

Асфальт юл кинәт таш җәелгән җиргә чыкты, аннан соң тәмам сары балчыкка калды.

– Шушы тирәдә булырга тиеш, – дип, телефонына текәлде хатын. Анда эзләнеп утырудан рәт чыкмагач, иптәш кызын җыеп, бик озаклап сөйләште дә, кая барасын күрсәтте.

Идел буйлап шактый гына сузылган авылга да, аннан якынрак урнашкан бакчаларга да түгел, бөтенләй читкә ишарәләде ул. Мин, ялгышмыйсыңмы дип, сораулы карашымны аңа төбәгәч тә, ул, кушканны эшләргә өндәп, башын гына какты.

Наилә белән Фаилнең архитекторлыктан кала башка бер генә кызыксынуы да, шөгыле дә юк иде. Мин аларны ничек кенә өнәп бетермәсәм дә, бер нәрсә белән килешергә тиешмен – икесе дә – үз эшләренең осталары. Аларның проект-сызымнары нигезендә салынып чыккан коттеджлар бер үк вакытта зур, җыйнак, матур һәм хәтергә уелып кала торган. Һәрберсе – җитди иҗат җимеше, күңел биреп эшләнгән архитектура һәйкәле. Бөтен

тирәбезне басып алган дүртпочмаклы кызыл кирпечтән ясалган зинданнар түгел инде. Без бу юлы да шундыйрак шедевр, гайре табигый корылма күрергә өметләндек. Һәм... ялгышмаганбыз икән!

Алда безне бормалы-сырмалы урман юлы көтә иде, ике якта да биек наратлар, нәфис чыршылар тезелгән. Озак та үтми, юл тимер капкага килеп төртелде.

– Җиттек, ахрысы, – диде хатын, үз сүзләреннән үзе шикләнгән тавыш белән.

Мин кыска гына итеп машина клаксонына бастым. Коймадагы капка акрын гына шуышып, читкә кереп югалды.

Ишегалды кечкенә һәм кысан. Аның уртасында бетон шакмаклардан төзелгән сәер корылма. Ул тәбәнәк, тәрәзәләре аз һәм бәләкәй, ә диварлары калын икәнлеге әллә кайдан абайлана. Җиргә сеңгән бу нәрсә хәрби дот яисә берәр төрле саклану чарасын хәтерләтә иде.

Өстенә килешсез фуфайка һәм чит-читләре салынып төшкән эшләпә кигән, икенде күләгәсе төсле буйлы Фаилне күргәч, җиңел сулап куйдым. Дөрес килгәнбез икән. Тегесе әллә ничек, гаепле кеше сыман елмайды да машинамны каярак бастырырга икәнлеген күрсәтте.

Коры гына исәнләштек. Фаил елмайган итте, әмма бу, гадәттәгечә, зур тырышлык белән сытып чыгарылган мимик хәрәкәт кенә иде. Наилә хатынны каршылады, миңа сәламен ташлады да, алар өйгә кереп киттеләр. Мин тәмәке кабыздым.

Шундый кешеләр бар, алар янәшәсендә нәрсә әйтергә белми интегәсең. Дәшәсе дә килә, әмма ничек сүз башларга – һич аңларлык түгел. Һәм шул сүзсезлектән уңайсызланасың, теләсә нәрсә хакында әйтеп куясың, кызарасың, бүртенәсең, тирлисең. Фаил нәкъ шундый әңгәмәдәш иде.

– Беркем дә килмәдеме әле? – Алай да, җаена тәңгәл соравым табылды кебек.

– Сез беренче.

– Бик үзенчәлекле коттедж килеп чыккан.

Фаил, артына борылып, корылмага карады да үзенә генә мәгълүм бер сер белгән кеше сыман елмаеп куйды. Тарттырылмаган, чын елмаю иде монысы.

– Әйе шул. Бу юлы артык та тырышып ташлаганбыз, ахрысы.

Мине коткарып, урам якта машина тавышы ишетелде, ул да түгел, капкада «Ниссан» автомобиле күренде. Аның хуҗасы Рамил, безгә әллә ни игътибар бирми, тимер атын минеке янына куйды, ашыкмый гына нәрсәләрдер эзләде, казынды. Ул арада хатыны Сания, җәһәт кенә арткы ишекне ачып, башта кечкенә кызчыгына төшәргә ярдәм итте, аннан, сумкасын алып, ишеккә юнәлде. Кызы әнисенең кулына чытырдап ябышкан.

– Сәлам, егетләр, – дип кул болгады ул безгә, кыска итәге астыннан күренеп торган мул аяклары белән вак-вак баса-баса. – Ник кермисез, салкын түгелме сезгә?

– Сәлам, Сания. Без әлегә монда. Кызлар өйдә, керә торыгыз!

– Бу өймени? Мин берәр төрле лофт дип уйлаган идем. – Сания, архитектурада гына түгел, гомумән, наданлыгын кабат исбатлап, баш миенә сыланып калган матур яңгыраучы «лофт» сүзен «черт» итеп төкергәндәй әйтеп салды.

– Сания, хатыннарга күз-колак бул, лофтта исерешеп бетмәгез тагын, – дип күз кыстым. Тегесе миңа гаурәтемне уятып җибәрердәй караш ташлады да кызын иярткән көе ишектә юк булды.

Күз читем белән генә Фаилгә карадым – ни гаҗәп, ул да Саниянең бәдәннәренә текәлгән иде. Дөресен әйткәндә, мондый карашны аңарда беренче тапкыр күрүем. Йөзе дә җанланып киткән, авыз читендә елмаюга охшаш нәрсә шәйләнә... Рамил күрмиме икән дип борчылуым бушка булып чыкты – аның бездә дә, җилбәзәк хатынында да кайгысы юк иде.

Рамил ашыкмый гына төште, машинасын әйләнеп чыкты, көпчәкләренә типкәләде. Бик кадерле әйберенең исән-имин икәнлегенә инангач кына, безгә таба атлады.

– Ни хәлләр? – дип, дәү кулын сузып исәнләште.

Рамил Казандагы бер югары уку йортындамы, фәнни-тикшеренү институтындамы, хезмәткәр булып эшли. Кайсы юнәлешкә карыйдыр – һич әйтә алмыйм. Әмма ул бик акыллы булып күренергә тырыша, бөтен нәрсәне дә белә шикелле, еш кына төзәткәләп куярга, үзенең чиктән тыш даһи икәнлеген күрсәтергә ярата. Бәхәскә керә калсаң, беркайчан да баш бирмәс, үз дигәненнән чигенә торган кеше түгел.

Елга кимендә бер тапкыр ул яңа эш эзли. Хезмәт хакының бик аз булуы хакында без аңардан һаман да ишетәбез, бу Рамилнең авырткан сөяле. Елга бер ул әлеге хәерчелектән котылырга вакыт икәнлеген искәртеп куя да... янәдән шул элек эшләгән урынында утырып кала.

Хезмәт хакының азлыгыннан зарланса да, ул беркайчан да мохтаҗлык күрмәде. Өсте-башы бөтен, йөргән машинасы ялт иткән. Саран, кысмыр, төче... Мин кинәт кенә Рамилне бер генә яхшы сүз белән дә тасвирлый алмавымнан оялып куйдым.

Рамилнең хатыны Сания – аның киресе. Тышы мут, эче ут дип, аның кебекләр хакында әйтәләрдер. Һаман елмаеп торучы ачык бу кыз теләсә кем белән уртак тел таба ала. Бигрәк тә ир заты белән.

Рамил соңарып өйләнде. Хатын сөйләгәнгә ышансаң, ул яшьли бер кызга гашыйк булган да, тегесе моны кабул итмәгән. Башкага кияүгә чыккан. Тәүге мәхәббәтен оныта алмый Рамил, шуңа да озак кына өйләнә алмый каңгырап йөргән, имеш. Башка ярга барып бәрелергә күңеле кушмаган, янәсе. Мин, әлбәттә, мондый әкияткә ышанмыйм. Саранлыгына күрә, иртә өйләнеп, артык чыгымнарга батудан курыккандыр ул. Рәхәтләнеп гүләйт итәсе дә килгәндер.

Ә Саниягә өйләнеп, ул отты гына. Тегесенең әти-әнисе – хәлле кешеләр. Рамилнең ыспай киемнәре дә, затлы машинасы да шуларның ярдәме белән алынган, күрәсең. Икенче яктан, хатынына сүз әйтергә дә куркып калтыранып яшәве аның итәккә ныклап бәйләп куелуы турында сөйли...

Рамил бик белдекле кыяфәт белән корылмаларны күзләп чыкты.

– Йортыгыз кайда? – дип сорады ул, озаккарак сузылган тынлыкны бозып.

– Шушы инде...

– Бу нәрсә соң? – Рамилнең дорфалыгыннан мин уңайсызландым. – Нинди таш тартмалар төзедегез монда?!

Фаилнең әлеге сүзләргә исе китмәде.

– Архитектур яңалык бу, Рамил, – дип ихлас елмаеп та куйды.

– Мин архитектурада берни дә аңламыйм, димәк. Хәер, заманасы хәзер... Камал театрының яңа бинасы тирәсендә дә кара төнгә кадәр бәхәсләшкәннәр. Әллә нинди өчпочмаклардан корылган проект сайлаганнар.

– Өчпочмак – татарның яраткан ризыгы, театр да милли рухта булсын, дигәннәрдер. – Мин дә сүз кыстыру җаен таптым.

– Ник бәлеш формасындагысын сайламаганнар соң?! Бәлеш тә татарлык билгесе түгелмени?! – Рамил бүген дә теләсә кайсы сүзгә каршы төшеп, бәхәсләшергә әзер иде.

– Белмим, безнең якта бәлеш сирәк ризык булды, балачакта бөтенләй дә хәтерләмим. Булса, шул кабак бәлеше белән баланныкы гына. Аларын җенем сөйми иде...

– Татар – стереотиплардан иң күп зыян күргән халыктыр, мөгаен, – дип элеп алды Рамил. – Өчпочмак, пәрәмәч, бәлеш, кәләпүш, Сабан туе... Татар кешесе нинди була? Иртән торып, битен юа да чигүле сөлге белән сөртенә. Сөембикә манарасы төшерелгән намазлыкта намазын укый. Аннан соң чәчәкле касәдән чәй эчеп, өчпочмак белән тамак ялгый. Түбәтәй белән камзулын эләктереп, чигүле читекләрен шыгырдатып, ат җигәргә ашыга. Ә киштәдән тоташ Тукай китаплары тезелешеп озатып калалар.

Көрсенеп куйдым. Килешми мөмкин түгел иде бу сүзләр белән.

– Бәлки, үзебезнең дә гаеп бардыр?! – Мин күптән түгел генә Россиянең бер төбәгеннән кабул иткән кунакларымны искә төшердем. – Без үзебез ул стереотипларны тудырабыз. Казанны карагыз – рәсемдәге кәртинкә төсле, ялт иткән шәһәр. Хәтта Мәскәүдән килүчеләр дә шакката. Җыйнак, матур, пөхтә, юллар шәп, кая карама – чәчәкләр үсеп утыра. Ял итәргә, күңел ачарга, корсак күпкәнче ашап-эчәргә бөтен мөмкинлекләр дә бар. Безгә килгән кунак бөтен татар иле әнә шулай уйнап-көлеп, өчпочмак, чәкчәк ашап кына яшәп ята дип уйлый. Башкалабыз үзәгеннән биш-алты чакрымда хәрби самолётлар, авиация двигательләре, вертолётлар җитештерелеп ятканын, химия ярдәмендә төрле материаллар ясалуын, көймә-кораблар, «КамАЗ» һәм башка төр машиналар җитештерелүен, басуда иген игелгәнен күз алдына да китерә алмыйлар. Казанның мондый матурлыгы күктән төшкән дип уйлыйлар. Әле кайберләре «Безнең хисапка типтереп яшәп ятасыз!» – дип тә әйтергә тартынмый. Безнең гадәтебез шундый инде – кунакка иң шәбен, иң тәмлесен генә чыгару, үз мәшәкатеңне үз көчең белән ерып чыгу гадәте гасырлар дәвамында канга сеңгән. Башка төбәктә яшәүче берәр кешедән юри генә «Татарстан нәрсә ул?» дип сорап карагыз. «Ооо, казылык, чәкчәк, «Ханская»!» – дип, авызын ерачак...

– Ә ирләр турында ни уйлыйлар? – Рамил үзенең авырткан җирен исенә төшерде бугай. – Татар ире хатынын көн дә кыйнап тора, ә хатыны исә моңа разый, ир кулы тигән урын кыямәт утында янмый дип ышана, имеш! Кыйнарсың, бар, хәзерге хатыннарны!

«Син хатыныңнан бигрәк тә уңдың, үзеңне кыйнап торса да, сүз әйтмәссең», – дип өстәмәкче идем дә, кинәт Фаил кырт кисеп куйды:

– Матур булачак.

– Нәрсә?

– Театр. Казандагы яңа мәчет. Безнең яңа йортыбыз. Замана белән бергә атлыйбыз. Хәзерге трендлар – минимальлек һәм...

– Һәм нәрсә?!

– Иминлек. – Фаилнең күзләре кинәт ялтырап китте. Йөрәк чәнчеп куйды, хуҗа кеше кыска гына бу төшенчәне үзенчә аңлый иде бугай. Һәрхәлдә, миңа шулай тоелды. – Әнә Ильяслар да килә...

Ильяс мунча зурлыгындагы джипта йөри иде. Тәбәнәк кенә буйлы, ябык гәүдәле булганга, ул бүксәләре чыккан машинасы янәшәсендә бигрәк тә мәзәк күренә. Хәзер дә, «Тойота»сын ничек эләкте шулай бастырып калдырып, руль артыннан җиргә сикереп диярлек төште һәм, авызын колакларына тикле ерып, уң кулын болгап сәлам юллады. Алай да, башта хатынына һәм улына төшәргә булышты.

Ильяс күптән түгел бер бай гына оешмага җитәкче итеп билгеләнде. Аның затлы кәнәфигә утыруы очраклы гына килеп чыккан, дип сөйлиләр. Ике бик тә кодрәтле түрә әлеге урынга үз кешеләрен куярга ниятләгән. Үз канаты астындагы кандидатураларны төртү белән мавыгып китеп, теге түрәләр Олы Абзыйның нык кына ачуын чыгарган. Тегесе тоткан да бөтенләй көтелмәгән кешене – безнең танышыбыз Ильясны билгеләгән. Ике көндәш түрәнең миләш дип капка违ннары балан булып чыккан.

Әгәр дустың түрә кәнәфиенә утырса, аның белән яңадан дуслашырга кирәк, диләр. Ильяс белән сирәк очрашсак та, аралашу рәвеше нык үзгәрде. Ул эреләнде, атлап йөрешләре үк башка төсмер алды. Чырае да танымаслык, әйтерсең битлек кидергәннәр. Бер кашын югарырак күтәргән көе һәр нәрсәгә усал караш ташлый, елмайган чаклары сирәк. Хәер, җылы кәнәфи аның аты-юлы белән сүгенү гадәтен берничек тә үзгәртә алмады, авызыннан чыкканны эт җыймас булып калды. Һәм болай сүгенү сәләтен яңа эш урыны арттырды гына шикелле. Кайбер кешенең тәмсез сүзләре килешле яңгырый, андыйларны шактый очратканым бар. Ә моныкы ничектер урынсыз, ясалма, кирәксә-кирәкмәсә кыстырылган төсле. Әллә шулай сүгенеп кыска буйга бәйле комплексларын сыта, әллә үзгә сәбәп бар...

Хатыны кырыс Ильясның. Күрәсең, ул ягы да аның холкына йогынты ясыйдыр. Ире кебек сүгенгәнен ишеткәнем юк, әмма әйтсә, шунда ук колагың шиңә, башка аның белән булашмаска кирәклеген бик тиз аңлыйсың. Шөкер, бу юлы Альбина безнең белән сөйләшеп тормый гына өйгә узды, баш кагып кына исәнләшкән булды.

Ильяс һәммәбез белән дә исәнләшеп чыккач та, тәмәкесен кабызып җибәрде.

– Юллар әшәке, – дип, озын-озак сүгенү җөмләсен кыстырды да, черт итеп төкереп тә куйды. Алдан ук кисәтим – мин атлаган саен «Ильяс сүгенде» дип искәртеп тормам, сирәк очракларда гына моны ассызыклармын. Аның «мәкаль-әйтемнәре» белән бу язмамны чүплисе, укучының кәефен җибәрәсе килми. – Кичә генә шофёрдан машинаны юдырдым, бүген кара син, нәрсәгә әйләнде!

– «Тойота». Яңа кузовта. Бу хәзер күпме тора инде?!

Рамилнең соравы Ильясны бер мәлгә каушатып та калдырды шикелле. Бит алмаларына кадәр кызарып чыкты. Аннан, ихтыяр көчен җыеп:

– Февральгә кадәр алынган ул... Дөресрәге, түләп куйган идек. Иске бәядән. Менә кайтты.

– Беркемнең дә нигәдер «Москвич»та йөрисе килми. – Рамил, күрәсең,

Ильяс мисалында Россиянең бөтен чиновникларыннан үч алырга ниятли иде. Миңа уңайсыз булып китте, нигәдер Ильясны яклыйсы килде.

– «Москвич» ни бит инде ул, җитәкче йөри торган машина түгел...

– Ә аның нәрсәдә йөрергә тиешлеге кайсы законда язылган?! Бәлки, Конституциядә аерым маддә бардыр?! – Рамил, кинәт ике кулын бөерләренә терәп, корсагын киерде: – За сим повелеваем государевым мужам на «Тойотах» ездити!

Аннан пырхылдап көлеп, дуслашу билгесе итепме, болай да куырылып килгән Ильясның кабыргасы астына төртеп алды.

– Йә, ярый, шаяртам гына инде! Йөр, рәхәтен күр! Башкасы булмагач, нишлисең? Шәп машина, иминлек ягыннан да бик ышанычлы дип мактыйлар... Ә бездәйләргә әнә шул «Москвич»... Ә, оныттым, «Аурус» бар икән әле тагын!

Ильяс Рамилнең бу кыланмышларын әллә ни аңлап бетермәде, «аптыратма әле», дигән төсле, телефонына кереп чумды.

– Анасын, иман тактасын шулай итим! – дип кинәт кычкырып җибәрде ул. Мин сискәнеп үк куйдым. – «Сармат» ракетасын шартлатып караганнар!

– Кайда шартлатканнар? – Ильясның ни турында сөйләгәнен бик үк аңлап бетермәсәм дә, йөрәккә кереп утырган иртәнге шом яңарган төсле булды.

– Камчаткада. Бик уңышлы барып чыккан дип язалар.

– Тинтәк булмагыз инде! – Рамил янә сүзгә кушылды, һәм бу юлы да Ильяс белән каршылык аермачык чагылды. – Ракетаны сынау вакытында аны шартлатмыйлар. Өйрәнүләр өчен махсус блоклары була, шулар, шахтадан очып чыгып, билгеләнгән урынга барып төшеп сибелә.

– Үзең син тинтәк! – Ильяс бу юлы инде бирешергә теләмәде. – Әнә бит, Рогозин әйткән – «Сармат» ярты континентны берьюлы юк итәргә сәләтле дигән.

– Кайсы континентны? – Ни гаҗәп, бу сөйләшү кинәт Фаилгә дә кызык булып китте кебек, ул әйтерсең тирән йокысыннан уянды.

– Ник, кайсы икәне билгеле бит инде! Кайсы безгә йодрык күрсәтә соң?!

– Европа, Азиянең теге ягы, Австралия...

– Америка, юләр! Америка! – Ильяс Фаилне бүлдерү белән, тегесе, оялып, янәдән үз кабыгына кереп бикләнде шикелле. – Американың шулай тетмәсе тетеләсен кайдан белгән ул?! Әлбәттә, бомбаны шартлатып карап кына!

– Кайда шартлатканнар соң аны? – Рамил бүген Ильясны тәмам бимазаларга ниятләгән иде кебек.

– Соң, кайда икәне билгеле инде! Әнә, Камчаткада, Плесецк полигонында!

– Плесецк полигон түгел ул, космодром. Архангельск өлкәсендә. Ә Камчатка илнең икенче башында.

– Үзең син Камчатка, анаңны, дененңне, кабер тактаңны!..

– «Сармат»ның егәрлеге 50 мең килотонна, – дип, кинәт әллә нинди тоныкрак, үзәккә үтәрлек куркыныч тавыш белән эндәште Фаил. Аның күз карашы кайдадыр бик еракта урнашкан билгесез ноктага текәлгән иде. – Хиросима белән Нагасакига Америка ташлаган бомбаларныкы 15 һәм 21 килотонна булган.

Бу саннарны башыбызга сыйдыру өчен вакыт кирәк иде. Без һәммәбез

дә тынып калдык. Бер нәрсә мине ихлас шатландырды – миңа ияреп килгән шом, һичшиксез, Рамил белән Ильясның да күңеленә иңгән иде. Фаил өчен әйтә алмыйм – ул үзенең сәерлегендә тамчы да үзгәрешсез калды.

– Атом-төш коралын сынау тыелган, егетләр. Ярты континентмы, әллә тулысы беләнме – болар барысы да математик хисаплаулар ярдәмендә исәпләп чыгарылган саннар гына. Керик, әйдәгез, туңгансыздыр! – диде ул, һәм, безне үзе артыннан ияртеп, гайре табигый йортының мәгарә авызы төсле ишеге бусагасыннан атлады...

* * *

Адәм баласына җирнең һәр карышы кадерле иде. Җир йөзенә яралганнан бирле кешеләр Аны бүлгәләргә, тарткаларга кереште, үзенә тиешлесен чикләр белән аерып куйды. Бусы минеке, тимәгез, янәсе! Тик, нигәдер, акыллы гына күренгән бу затларның күңеленә хөсетлек, комсызлык кебек гайрәтне чиктерә торган сыйфатлар да салынган. Бер-берсе билгеләгән чикләр белән килешмичә, канкоеш аша үзләренә тереклек мәйданын киңәйтергә керештеләр. Һәр карыш җир өчен аяусыз сугышлар башланды, кешеләр бер-берсен гаиләләре, алай гына да түгел, ырулары белән суеп чыгарга гадәтләнделәр. Ерак гасырлардан бирле Хода бәндәләре бертуктаусыз үтерү һөнәрендә осталыгын чарлады, көндәш-ягыларын уздыра-уздыра коточкыч кораллар уйлап чыгара торды...

Ә бер көнне... Бер көнне ул бәндәләр шундый корал ясады ки, аны сынау Җирнең бөтен тармагында сизелде, үзәгенә үтеп керде, урталай ярылырдай халәткә җиткерде. Атом бомбасы дип атап йөртелгән әлеге галәмәтнең үтә дә куркыныч икәнлеген шул чакта ул бөтен барлыгы белән тоемлады. Тик кеше дигәнең генә моны аңламады шикелле. Алар, алларын-артларын карап тормый, бомбаларының куәтен арттыра тордылар. Шартлау ни дәрәҗәдә көчлерәк булса, шатлыклары да шул дәрәҗәдә күбрәк иде. Кешелеккә, үзләренә никадәр зыян салуларын белдеме икән болар? «Бомбалар патшасын шартлаттык!» – дип шапырынганда, аның сөреме бөтен Җир шарын берничә мәртәбә әйләнеп чыкканын сизделәрме?

Гомумән, Ул белгән адәм затларымы соң болар? Аның куенына өннәр казып, шунда тыгып шартлатып карадылар бомбаларын, һавадан да ташладылар, тагын әллә нишләтеп бетерделәр. Һәр сынау вакытында Ул тетрәнеп, яман ыңгырашып куйса да, моңа берсе дә игътибар итмәде.

Ә бит кешелекнең дә самими чагы бар иде... Аннан теләктәшлек өмет итеп, куенына бомба түгел, тавык йомыркалары салалар иде. Имеш, шушылай итеп Җир-ананы юмаласак, уңышы да мул булыр, игеннәр күкрәп үсәр...

Җир атасы – Җирән сакал!
Җир анасы – Асылбикә!
Түбәсенә туклыгын бир,
Ил өстенә муллыгын бир,
Ил эчендә безгә дә бир!
Башлыйк теләкне,
Күтәрик беләкне, –
Кояш, шаһит бул!...

* * *

Фаилләр коттеджының бусагасын атлап керү белән, йөзгә кайнар мунча һавасы бөркелгән төсле булды. Күрәсең, көзнең дымлы салкыны калын диварлар аша үтә алмый, эчтәге җылылык та беркая да китми. Диварлар чыннан да нык иде, кирмән, диярсең! Эчтә шактый кысан булып чыкты. Йорт дигәненең аралыклары бик тар, бер-беребезгә этелә-төртелә атларга туры килде.

Кухня зал белән тоташтырылган, ул да бик җыйнак. Икесенә бер тәрәзә, анысы да бик кечкенә. Зал ягына ике ишек чыга – мөгаен, йокы бүлмәләредер. Берсенең ишеге ачык, идәндә утырган көе Рамилләрнең кызлары белән Ильясларның уллары уенчыклар белән маташа.

Уенчык?! Тукта әле, нинди уенчык?! Фаилләрнең балалары юк лабаса! Йөрәк янә әллә нинди куркыныч бер хистән кысылып куйды.

Әллә соравымны кычкырып әйттем инде – Наиләнең үтә дә кырыс карашын күреп, имәнеп киттем. Ул миңа текәлгән, гүя уйларымны укый кебек.

– Апалар килгән иде, балаларының уенчыклары ул, – диде тегесе, юеш кулларын алъяпкыч итәгенә сөртеп. – Әйдәгез, мантый пешергән идем, суына.

Табынга утыргач, киеренкелек бераз кимеде шикелле. Фаил шәп кенә көмешкә чыгарды, хәтта үзе дә аз-мазлап авыз итеп утырды. Ни гаҗәп, Наиләсе аңа җикеренми, ут чәчрәгән күзләрен төбәп, рюмкадан ераграк торырга кушмый.

Шулай да, табынга җан кергәнче хәтсез вакыт үтте. Телибезме, юкмы, барыбер һәрберебез ирле-хатынлы архитекторларның иҗат җимешен өйрәнүдән туктый алмадык.

– Эчтә дә минимальлек икән, – дип сузды Рамил, ике генә комфоркадан торган газ плитәсенә текәлгән көе. – Моның берсендә Фаил, синңа, икенчесендә Наилә үзенә ашарга пешерәдер, әйеме?

– Без икебез дә бер үк нәрсәне ашарга өйрәнгән, – диде һич кенә дә үпкәләмәгән Фаил. – Газны экономияләргә дә бик җайлы.

– Ә нәрсәгә экономияләргә соң аны?! – Ильяс, эчелгәннән «җеби» төшеп, утырган урынында җәелеп үк киткән иде. – Кемгә кирәк синең ул газың?!

– Кирәк инде... Кытай ала, ди, Төркия, Һиндстан...

– Алыр да шул. Шалкан бәясеннән! Бездә ул газ беткәнме?! Себер шуның белән тулган. – Ильяс, кулъяулыгын чыгарып, маңгай тирен сөртеп куйды.

– Тулса ни?! – Рамилнең Ильяс белән адым саен бәхәскә керүе ачуны ук чыгара башласа да, түзәргә туры килде. Кысылсам, миңа да ябышачак, көт тә тор. – Әнә, берничә ел элек... Хәзер инде кайчан икәнлеген хәтерләмим... Лениногорск районында бер хатын биш баласы белән өйләрендә янып үлде! Биш бала! Янгын чыгуның сәбәбен беләсезме? Тимер-томыр, чыбык кисәкләреннән электр белән җылыта торган бер нәрсә әмәлләгәннәр. Кибетнеке түгел, үзләре ясаган. Төнлә кыска ялганыш булып алган да, ут чыккан. Ник өйләрен электр белән җылытканнар? Җавабы гади – җәй көне үк, газга бурычлары җыелуны сәбәп итеп, боларның торбаларын кисеп киткәннәр. Биш бала гомере хакында уйлап та бирмәгәннәр!

– Биш түгел, алты, – дип аваз салды минем хатын. Шөкер, аның да, Рамил

төсле, белмәгән нәрсәсе юк. – Алтынчысы кунакта булган, шуңа гына исән калган. Хәер, бу очракта исән калуга шатланыргамы, юкмы, белмәссең... Әнисе утызга да җитмәгән кыз иде...

– Кай арада шулкадәр бала табарга өлгергән! – дип тел шартлатты Сания.

– Эчкәннәр, имеш. «Неблагополучный» диләрме әле?

– Андыйларга Ходай балаларын да өеп бирә, кайберәүләргә әнә... – дип, үзе дә сизмәстән сүз башлаган Альбина кинәт тотлыгып калды. Наилә, үзенә карата киная төсле әйтелгән бу сүзләрдән кызарып чыкты, әмма сер бирмәскә тырышты, табындагы ризыктан авыз итәргә кыстый башлады.

Альбинасына ярдәмгә Ильяс ашыкты – берни булмагандай, баягы сүзен дәвам итте:

– Менә безгә телевизордан Европа халкы кышын катып үләр дип, көн дә тукып торалар. Имештер, өсләренә җылы киемнәр киеп йоклыйлар, утын сатып алалар, басудан сыер тизәге генә җыймыйлар инде! Әйтерсең безгә андагы фрау белән мамзельләрнең ничек кыш чыгуы кызык! Нигә берәр төрле Курск яисә Тамбов өлкәсендәге авылда гомер итүче баба Валяның хәлләрен белешмибез?! Россиянең бөтен төбәкләренә дә газ кертелгән дип уйлыйсызмы? Юк, чыннан да сыер тизәге җыеп ягучылар да җитәрлек. Бигрәк тә Урал аръягында.

– Газ бетәр дип куркалардыр, күрәсең...

– Себерне күз алдына китерәсезме? Очы-кырые юк бит аның! Мин Якутиягә очканда самолёт, иллюминаторыннан карап барам – аста ник бер юл әсәре күренсен, шәһәрләр хакында әйткән дә юк. Офыкка кадәр бушлык сузылган. Җәй көне иде, кая карама – яшелле-мөшелле төсләр, тайга-мазар булгандыр, күрәсең. Ул елгалар, мин сиңайтим! Әле бит ул самолёттан караганда шундый зур күренә, без җирдән ун чакрым биеклектә... Вәт. – Ильяс сүзенең очын җуйды бугай. Аңлашыла инде – кичәгедән соңгы махмыр моның. Бер чәркәдән ук тир бәреп чыкты. Тир чыга дип, чир чыга... – Шунда мин үз-үземә сорау бирдем, җегетләр, мин әйтәм, сез, тинтәк көтүе, шушындый илне җиңәбез дип уйлыйсызмы?! Үзебезнең дә аның кайбер почмакларына барып җитә алганыбыз юк, сез шушы киңлекләрне ансат кына кулыгызга төшерергә ниятлисезме?!

– Барысы да синең төсле ватанпәрвәр булса иде... – Рамил кинәт кенә тирән уйга батып калды. Әллә көмешкә галәмәте, әллә чыннан да, фәлсәфәгә кереп китеше...

– Барысы да була алмый, – дидем мин, үзем дә сизмәстән боларның сафсатасына бирелеп. – Элек тә булмаган, хәзер дә була алмый. Кулдагы бармаклар да төрле, кешене әйткән дә юк. Адәм баласының яшисе килә шул. Аллаһы тарафыннан салынган бу табигый тойгыны бер генә нәрсә белән дә юкка чыгарып булмый... Инстинкт дип атала ул...

– Мобилизация игълан ителгәч тә, көтүләре белән чит илләргә агылган бәндәләрне дә шул тойгы белән акларга, дисеңме? – Рамил хәзер минем белән сүз көрәштерергә әзерләнде бугай.

– Мин беркемне дә акларга да, гаепләргә дә җыенмыйм. Һәркемнең үз язмышы, ул аны үзенә бирелгән тәрбия, белем һәм башка бик күп нәрсәләргә таянып, үзе билгели. Кемгәдер мобилизация дә кирәк түгел, ул инде күптән үз теләге белән тегендә, сугышта. Чөнки тумышы белән сугышчы, аның

язмышы шулай язылган. Аңа акча да, дан-шөһрәт тә, орден-медальләр дә кирәк түгел. Ул үлемнән дә курыкмый. Яу кырында һәлак булу – аның өчен иң олы бәхеттер дә әле. Ул яугир язмышын сайлаган. Гомер-гомергә андый кавем бар, алар милләткә карап бүленми. Шул ук вакытта бу дөньяга шагыйрь булып яралган кешеләр дә бар бит. Ә шагыйрь – гуманист дигән сүз. Игенчесе дә кирәк, итекчесе дә. Теге син әйткән качаклар – аларны һич кенә дә гаепләргә ярамый. Кешенең тормышында әллә нинди хәлләр булып ятарга мөмкин, без аларның барлык нечкәлекләрен дә белмибез. Һәрхәлдә, мин аларның язмышына кызыкмыйм...

– Да, безнең үзгә ватаныбыз юк шул, кайбер милләтләр төсле, запас тоткан җирләребез дә булмады, – дип көрсенде Ильяс. Һәм бу сүзләрендә шул үзгә ватанлы кешеләргә кызыгу чалымнары ялтырап китте төсле.

– Үзгә ватан кирәкми. Үзебезнеке бар, Аллага шөкер. Ә запас дәүләт тотучыларга килгәндә... Әллә син аларга анда бик ансат дисеңме? Хәзер моннан качып китүчеләргә диюем. Ул җирләрдә дистәләрчә еллар буе төпләнеп яшәгән милләттәшләре өчен алар, хәзер качып килгәннәр, килмешәк рәвешендә кабул ителә. Чөнки монда рәхәт чакта берсе дә анда талпынмады бит. Шул ук яһүдләрне алсаң, алар Израиль дәүләтен сугышып төзегән, андагы фәләстиннәр белән аяусыз көрәш алып барган. Бүген ул җирләр ал да гөл, ә элек ком чүле җәйрәп яткан. Язга чыккач, яһүдләр үстергән яңа бәрәңге ашыйбыз бит. Ком чүлендә ансат кына уңыш алып булмыйдыр, күп хезмәт куелгандыр. Су сибәр өчен дистәләрчә чакрымга сузылган арыклар төзелгәндер. Һәм менә хәзер, әзергә бәзер дип, безнекеләр килеп төшә... – Болар мине аңлыйлармы икән дип, табындагыларга текәлдем.

– Сагыш, – дип, Наилә әллә минем сүзләремне куәтләде, әллә үзенең фикерен алга сөрергә ниятләде. – Беркем аңлатып бирә алмый торган хис бит ул. Кендек каны тамган урынга тартыла кеше. Мин, туган авылыма кайтып килсәм, әллә ничек көч җыйган төсле булам. Кәефләрем күтәрелә, күңелне биләп алган шом тарала... Бу арада ул шомлану тагын да арта төште кебек...

– Шомланырсың да шул, – дип куәтләде аны кинәт ире. – Тыныч яшәргә телисең икән – сугышка әзерлән дигән гыйбарәгә нигезләнеп гомер итүче кешелек дөньясыннан нәрсә көтәсе?! Бүген генә дә җир йөзендә илледән артык кораллы бәрелеш бара. Һәрбер сугыш солых белән төгәлләнә, дисәк тә, бу хакыйкатькә хилафлык шул. Төтәп яткан конфликтларга берәрсе чак кына һава өреп җибәрә дә, ул янәдән дөрләп кабына. Үзебез тирәсендә генә дә күпме бит алар! Ә инде тыныч урын эзләп, ватаннарын ташлап китүчеләргә килсәк... Кая качып котылырга уйлыйлар соң? Картаны ачып карасагыз, иң күп кораллы бәрелешләр нәкъ менә җылы якларда, җәннәт төсле тоелган урыннарда тупланган. Гомер-гомергә шулай булган...

– Безнең болгар бабаларыбыз үз заманында, монда тынычрактыр дип, салкын кышлы якларга күченеп китсә дә, дәүләтләрен тар-мар ителүдән саклап кала алмаганнар... – Рамилдән дә бер юньле сүз чыгу минем йөрәгемә сары май булып ятты. Ләкин гомер-гомергә аз сүзле Фаилне бу мизгелдә туктатырлык түгел иде, ул йомыкый, оялчан кешедән ялкынлы ораторга әйләнде дә куйды.

– Кешелек дөньясы бер-берсен үтерү чараларын шулкадәр чарлаган ки, планетабызның бер генә почмагында да котылып калу мөмкин түгел. Шуңа күрә әллә кайларга кубарылып күченеп китүчеләр ахмактыр, минемчә!

– Туктале, – дидем мин, эчемә җылы йөгерүен тоеп. Иртәнге хәтәр тойгы янәдән баш миемне бораулап алды. – Син нәрсә, дөнья күләмендәге җитәкчеләр шул дәрәҗәдә ахмак дип уйлыйсыңмы? Атом-төш коралын куллануларына чынлап торып ышанасыңмы? Әгәр алай итсәләр, беркемгә дә котылу юк бит...

– Күрмисеңмени син, хәзер бара торган уенда ни дәрәҗәдә югары ставкалар икәнлеген?! Ике арадагы күперләр яндырыла, вәгъдәләрнең, халыкара килешүләрнең кирәге сукыр бер тиенгә калды. Бу кадәр кылануларның ахыры-чиге булыр кебек. Әмма ул бер дә уртага салып сөйләшү рәвешендә тәмамланырга охшамаган...

– Ә нәрсә?! – Рамилнең йөзендә усал елмаю иде. – Нәрсәгә кирәк соң ул атом-төш бомбасы?! Күпме акча, күпме көч түгелгән, күпме кеше гомере бәрабәренә ясаганнар бит аны. Тик кенә ятсын өченме?! Арт саннарын көйдереп алсак, белерләр иде безнең болай сөйләшергә ярамаганлыгын!

– Куркытып утырма әле, зинһар өчен! – дип кинәт чәчрәп үк чыкты Сания, һәм, табыннан сикереп торып, җил-җил атлап, баласы янына ашыкты.

– Без барыбер җиңәчәкбез, – дидем мин, табындагы шау-шуны бераз басарга тырышып. – Безнең башка чарабыз юк. Бәһасе зур булыр, әмма җиңү таңы һичшиксез килер. Сез әйткән атом-төш коралы белән түгел, андый гамәлне безгә беркем дә кичермәс. Җиңелүне дә кичермәс. Балаларым, оныкларым мескен халәттә гомерләре буена хәерчелектә репарацияләр түләп ятуын теләмим мин. Атом-төш бомбасын кулланырлык ахмаклар хәленә төшүебезне дә теләмим. Ә җиңүнең бәясе бар, анысы бәхәссез. Һәм ул аналар кайгысы булып әйләнеп кайта... Күптән түгел Кавказдагы бер төбәктә булдым. Сәхнәгә яу кырында батырларча һәлак булган каһарманның әнисен чакырдылар. Озын буйлы, ябык кына гәүдәле, гел кара киемнәрдән. Куллары белән йөзе генә күренеп тора. Башын горур тота. Аягында биек үкчәле түфли. Үзе дә япь-яшь кенә, утызның аргы ягына чак кына чыккандыр. Ул еламады. Ул бик гади, бик тормышчан сүзләр әйтте. Сез аның йөзен күрсәгез... Ул – әйтеп бетергесез Ана кайгысына һәйкәл төсле иде. Әйтерсең мәрмәр таштан оста сынчы уеп ясаган. Күзләре тирән сагыш чоңгылына төшеп, төпкә баткан. Биредә аның сурәте генә, шәүләсе генә сыман, ә җаны... Җаны мәрхүм улы янында, Ана үзе дә күптән мәрхүм төсле. Әмма сер бирми, башын горур тота. Бер генә урында аның күзеннән яшь тамчысы атылып чыкты. Шул мизгелдә генә ул безнең яныбызга кайтты шикелле...

– Әниләр газап чикмәс өчен атом бомбасы уйлап табылган да инде, – дип, мине дорфа рәвештә Рамил бүлдерде.

– Тартып керик, егетләр. – Бу киеренке хәлдә минем башыма бүтән тәкъдим килмәде.

Баласы янында кайнашкан Саниягә күз ташладым. Янәшәдә үк уенчыклар аунап ята. Барысы да өр-яңа, әле генә тартмаларыннан чыгарылган. Төрле-төрле һәм бик күп. Гаҗәпләнеп, табында утырып калган Наиләгә борылдым.

Ул миңа бораулап карый, карашымның кая юнәлгәнен күргәне әллә кайдан сизелә. Ут сирпегән карашы җанымны өтеп алган төсле булды, бу сүзсез дә аңлашыла торган электромагнит сигналы төсле иде. Әйтерсең Наилә минем уйларымны укып бара, минем гасабилануымны тоя, куркуымны сизә...

– Апаларның балаларына дип шулай күп итеп уенчыклар алып куйдык, – диде ул, сүзләрен бик саран гына теш арасыннан диярлек кысып чыгарып. – Берничә көнгә кунакка калган чаклары да булгалый. Аллага шөкер, уенчык алырлык кына акча эшләп торабыз...

Мин дәшмәдем, тик Наиләнең бу сүзләре аңлатудан бигрәк аклануга тартым иде. Янә бер тапкыр йорт эчен күздән кичердем. Аркам буйлап каз тәне йөгерде. Башымны түшәмгә бәрергә курыккан төсле иелә төшеп, ишеккә таба атладым.

Урамда инде эңгер-меңгер. Тирә-якта тынлык хөкем сөрә. Кара көзнең дә үзенә генә хас матурлыгы бар, бигрәк тә синең урының җылыда булса. Урамга чыгып, бераз чирканчык алып, мич ягылган өйгә керүгә ни җитә?! Әле, җитмәсә, түбә калайларына тып та тып яңгыр тамчылары да тамгаласа...

Чыгып, иптәшләрем янына чүмәштем. Кайдандыр килеп чыккан җил тирә-юньдәге агачларга бәрелде, аларны шаулатып, урман өстеннән Иделгә таба йөгереп китте.

– Бүреләр күптер монда? – дип аваз салды Рамил.

– Юк. Бүреләр биредә күптән юк инде. Аларны атып бетергәннәр. Дуңгызлар гына калды. Кабан дуңгызлары. Урманга чыккач, актарылган җирләрне күрсәгез, ул аларның эше булыр. Ә бүреләрне бетергәннәр... – Фаилнең тавышында мескен ерткычларга карата кызгану хисе тоемланып китте. Мин янәдән аның нык үзгәргәнлеген шәрехләдем. Юк, дөньядан гали архитектор түгел бу хәзер. Философ диярга дә мөмкин. Шушы халәткә керерлек дәрәҗәдә үзгәрер өчен кешенең башы нәрсә кичерергә тиеш икән?!

* * *

Җир-Ана буларак, ул үзен һәрбер сөяме, андагы һәрбер тереклек өчен җаваплы итеп тоеп яши. Аны хафага салырга мәҗбүр иткән күренешләр озын-озак гомерендә бик күп.

Тик ул кадәресе үк булырга мөмкин дип уйламаган да иде.

Гөмбә төсле күккә ашкан бомба шартлавыннан соң аның куенында бик сәер бүреләр дөньяга килә башлады.

Телсез бүреләр...

Бүренең дә теле бар. Алар бик акыллы, күмәкләшеп яши торган җан ияләре бит. Бер-берсе белән ау вакытында аралашырга, дошман якынлашуы турында хәбәр итәргә кирәк. Ягыларының иң хәтәре, әлбәттә, адәм заты.

Телсез туган бүреләр үзләрен яклау чарасыннан мәхрүм ителде. Баксаң, аларның төп коралы үткен тешләре түгел икән! Телсез калгач та, алар күмәкләшү мөмкинлегеннән колак какты. Бер-берсен аңламаган мәхлуклар, ялгышып, куркыныч янаган урыннарга барып чыктылар. Кешеләр аларны бик ансат кына кырып бетерү, ә юаш, умырткасы сыекларын исә маэмайга әйләндерү җаен күрде.

Телсез бүреләр очраклы гына килеп чыкмады.

Бүгенгедәй хәтерле Полигон – аның кыл уртасына ап-ак хач төшерделәр.

Зурны, әллә кайдан күренеп тора торганны. Аннан соң якын-тирә авыллардагы кешеләрне читкәрәк күчерделәр. Хәер, барысын да түгел. Озакламый үткәреләчәк коточкыч эксперимент өчен җитәрлек күләмдә гади халык калдырылды.

Туплар, танклар, самолётлар китереп куйдылар. Окоплар казытып, әле кичә генә малай-шалайлыкта йөргән егетләрне шунда шыплап тутырдылар.

Теге хач тирәсенә әле анда, әле монда ат, сыер, сарыкларны бәйләп куйдылар. Мескен малкайларның, күзләрен акайтып, берни аңламаган хәлдә кешнәүләре, мөгрәүләре, бәелдәүләре әле дә хәтерендә аның.

Бу тамашаның нинди максат белән корылганлыгы соңрак аңлашылды. Күктән тимер кош – самолёт очып килеп, хач өстенә атом бомбасы ташлады...

Үз гомерендә бик күп гарасатларны күрде ул. Аларның кайберләреннән соң җәй чорлары кышка алмашынды, чәчәк атып утырган гөлбакчалар боз чүленә әверелде. Әмма боларның барысы да Табигать галиҗәнаплары, йә булмаса, Галәм кылган гамәлләр нәтиҗәсендә эшләнде. Ә бу шартлауны, бу тетрәнүне кеше үз куллары белән ясаган иде.

Бомба ярылудан күтәрелгән агулы «гөмбә» котны алырлык булып чыкты. Аның өстендәге бер генә вулкан да бу кадәрле зыян китерми иде. Бомба шартлаудан соң аның давылы берничә тапкыр Җир шарын әйләнеп чыкты. Якын-тирәдәге, Полигонның үзендәге хәлләрне исә сүз белән генә әйтеп аңлатырлык түгел иде...

Урманнардагы агачларны әйтерсең чалгы белән чабып чыктылар. Күккә күтәрелгән тузан бик озак һавада эленеп торып, үзенә бомбаның барлык зарарлы матдәләрен җыйнагач, үлем өләшә торган япма булып, Полигон өстенә сарылып төште. Полигон, окопларда, танк, машина эчләренә поскан япь-яшь егетләр, аларны күрә торып әҗәл, белән очрашуга алып килгән командир-җитәкчеләр өстенә...

Аннан соң шул мескен егетләрне атакага җибәрделәр. Алар, «ура» кычкырып, бомба шартлаган урын аша үттеләр. Әнә шулай итеп кешенең атом-төш коралы, радиация белән көч сынашу сәләтен сынадылар. Хәер, ул вакытта радиация хакында үзләре дә рәтләп белмиләр иде. Бары тик санаулы бәндәләр генә аның ни дәрәҗәдә куркыныч икәнлеген аңлый иде кебек... Радиация мизгел эчендә кешеләрнең сөякләренә, эчке әгъзаларына, тәненә сеңеп калып, ашыкмый гына үзенең кара эшенә кереште.

Кырык мең чамасы хәрби, кырык мең яшь егет, тормышка өмет һәм хыяллар белән яшәүче тап-таза, имәндәй нык ир заты. Алар барысы да берьюлы үлмәде. Акрынлап, иза чигеп, куркыныч авырулар белән чирләп, берәм-берәм Җир куенына керә тордылар...

Ә атлар, сыерлар, сарыклар?! Аларның бәйдән ычкынып качарлык хәлләре юк иде шул. Бомба шартлагач та, баскан көе пешерелделәр, итләре мизгел эчендә сөякләреннән аерылды. Болары – шартлау урынына якын торганнары. Ә ерактагыларына исә кешеләр кулыннан суелып, лабораторияләрдә тикшеренү материалына әверелү «бәхете» тәтеде.

Шартлаулар Полигонны каезлый торды. Телсез бүре балалары әнә шул вакыйгалардан соң туа башлады да инде. Күрәсең, радиациянең йогынтысы аларны да урап узмагандыр.

Озак барды ул өйрәнүләр. Бигрәк тә шул бүреләр күпләп яшәгән төбәкләрдә. Иблис коралын хәрби максатлардан тыш, фәнни тикшеренүләр өчен дигән булып та шартлатып карадылар.

Ниһаять, көннәрнең берендә тындылар шикелле. Һәм менә хәзер янәдән шул афәт тирәсендә кайнаша башладылар бугай...

* * *

– Кирәк бит, ә! – Рамил тел шартлатып ук куйды. – Кем уйлаган?! Ковид чире башлангач, дөнья бетә икән дип уйлаган идем, ялгышканмын... Аннан да куркынычрагы көтеп торган бит...

– Нәрсәне әйтәсең?

– Соң, Украинаны инде. Уйламаган җирдән...

– Уйланган булгандыр ул, – дип, мин дә сүзгә кушылдым. – Бик төптән уйланган булырга тиеш. Дистә еллар дәвамында әзерлек алып барылгандыр.

– Бертуганнар бит югыйсә... – Ильяс уфтанган итенде.

– Бертуганнар арасындагы гауга, гадәттә, иң тавышлысы була да инде. Тарих андый мисалларны бик күп белә. Хәер, көндәлек тормышта да җитәрлек алар. Ветераннарга бирелгән фатирларны бүлешә алмыйча, күпме агай-эне үзара талашып, бер-берсе белән сөйләшмәс дәрәҗәгә җитте... Һәрбер низагка керосин сибеп торучылар бар. Төп гаеп нәкъ менә аларның өстендә. – Шаулап искә төшкән хатирәләрдән әллә нишләп киттем. Балачагым, өй артында күрше кызы Сәлимә белән уйнап үскән вакытларга кайткандай булдым. – Менә минем күрше кызы бар иде. Миннән бер яшькә генә зуррак. Балачактан бергә уйнап үстек, һәр эштә бергә идек. Ул елларны үзегез беләсез бит, бәрәңгене дә башта күршеләрнекен җыелышып аласың, аннан соң алар сиңа ярдәмгә керә... Туганнар да алай якын яшәми. Менә шул кыз үсеп җитте, әле студент елларында да күрешкәләп, аралашып тордык. Аннан соң ул кияүгә чыкты. Кырымда яши, диделәр. Минем аның ирен күргәнем булмады. Кинәт безнең мөнәсәбәтләр кискен рәвештә үзгәрде. Дөресрәге, аның миңа карата мөнәсәбәте. Салкынайды, ерагайды, сирәк кайтуларында аралашу рәвеше бөтенләй алмашынды. Мыскыллы, усал итеп сөйләшә бу минем белән. Соңрак Киевка күчеп киттеләр болар. Аның өчен мин генә түгел, Россиядә яшәгән туганнары да дошманга әверелде. Янәсе, без шушы тәртипләргә буйсынып, ә минем очракта хакимияткә дә хезмәт итеп, аның исәпләвенчә, олы җинаять кылабыз... Берничә ел эчендә кызыбызны алмаштырып куйдылармыни?! Гомерендә тарихның нәрсә икәнлеген белмәгән авыл баласы ул мәсьәләдә дә, халыкара сәясәттә дә белгечкә әйләнде. Кеше башын әйләндерү системасы анда бик оста эшли, конвейерга куелган...

– Бездә дә бардыр инде ул баш әйләндерүләр... – Рамил, гадәттәгечә, каршы төшсә дә, бу очракта сүзнең ни хакында барганлыгын шәрехләп тормады.

– Бар! Һәм бик күп! Тик аларда бөтен нәрсә дә гади һәм аңлаешлы. Ак һәм кара, дус һәм дошман, яхшы һәм начар. Бу – иң җиңел, иң үтемле идеология. Теләсә кайсы секта шуңа корылган. Нацизм идеяләре үзәгендә дә әнә шул гади, һәркемгә аңлаешлы гыйбарәләр торган. Игътибар итегез – алар өчен бер генә милләт бар. Бер генә тел. Бу бәргәләш исә безнең

көчебезнең төрлелектә икәнлеген янә искә төшерде. Яу кырында татары да, чечены да, буряты да, чукчасы да. Мәскәүдәге түрәләр бу хакта авыз тутырып әйтә башлады. Тегеләрдә бер генә «мова», бездә исә төрлелек! Илебезнең төп көче төрлелектә икәнлеген кабат искә төшерделәр бит!

– Авызыңа бал да май диләрме әле? – Ильяс миңа тилегә караган төсле караш ташлады. – Бер телеграмм каналны күзәтеп барам. Анда җыен тузга язмаган нәрсәләрне чәйнәп утыралар. Шунда берәү төрекмән милләтле таксистның үзенә язган хәбәрен элеп куйган. Табигый, теге таксист русча рәтләп белми. Хатасыз язу осталыгы хәзерге рус егетләренең үзләрендә дә чамалы, ә чит ил кунагыннан нәрсә көтәсе? Кыскасы, җиде хәрефтән торган бер сүздә алты хата. Шул хәбәр астына меңнән артык кеше комментарий язган. Аларны укысаң, колагың шиңәрлек. Нәрсә генә әйтеп бетермәгәннәр! Әйтерсең теге мескен таксист олы бер җинаять кылган. Үзләре башкарырга теләмәгән кара эшкә алынган бер хезмәтче генә бит ул югыйсә... Берәү: «Пушкин телен болай ботарлау – кыргыйлык һәм җинаять!» дип тә өстәп куйган. Ә теге хаталы язмадан соң икенче бер хәбәр урнаштырылган. Костромада яшь гаиләдә гауга чыгып, ир белән хатын сугышканда, ялгыш кына алты айлык балаларына китереп сукканнар. Теге бала, мескен, җан тәслим кылган. Болар нишләгәннәр, дисез? Балаларының мәетен тураклап, иттарткыч аша чыгарганнар да суыткычка тыгып куйганнар. Үзләре, балабызны урладылар дип, полиция чакыртканнар...

Әлеге вакыйганы күз алдына китерүдән күңел болганып китте. Ильяс исә алга таба дәвам итте:

– Тегеләргә «Менә бу – кыргыйлык һәм җинаять!» дип язып җибәргән идем, дәшмиләр...

– Безнең милләтебезгә дә мөнәсәбәт үзенчәлекле инде, – дидем мин, күптән уйлап йөргән фикерләремне әйтергә җай чыгуны кулдан ычкындырмаска ашыгып. – Шул ук вакытта үз-үзебездән оялган очраклар да җитәрлек, анысы тагын да ныграк борчый. Хәзер заманалар үзгәрде бит, ни уйласаң, шуны кычкырып әйтергә мөмкин. Социаль челтәрләр, һәртөрле интернет мәйданнары... Шуларда үзебезнең татар кешеләренең кайбер фикерләре мине кайвакыт олы хафага сала. «Татарның рәтле-юньле китабы да юк, спектакльләре дә карарлык түгел, татарча тапшыруларны әйтеп тә тормыйм. Шуңа күрә мин китап укымыйм, театрга йөрмим, телевизор карамыйм!» Үзебезнең татарлар әйткән сүз бу. Тартынмыйча, кычкырып, бөтен дөньяга ишетелерлек итеп шәрран яралар. Кем өчен файдалы соң бу мәгълүмат? Һәрхәлдә, татарлар өчен түгел. Никадәр асыл затыбыз үзенең кардәшен татар мәдәниятенең, сәнгатенең мескенлегенә инандырырга маташа. Аларга нәрсәгә кирәк соң мондый гамәл? Белмим, һәрхәлдә, уйлап эшләнмидер, эмоциональ рәвештә генә чыгып киткән сүзләрдер дип ышанасы килә.

Берәр татар уңышка ирешсә, милләте өчен берәр төрле хезмәт күрсәтеп дан казанса, аңа шунда ук ябырылып, тетмәсен тетәләр. Әлеге татар кешесен күптәннән белгән, хәтта дус-ишкә санап йөргән бәндәләр аны юкка чыгаруны аеруча зур тырышлык белән, тәм табып башкара. Ничек инде фәләнне шулай зурлаганнар?! Фәлән генә бит ул! Әйе, заманында миңа күп ярдәме тиде, киңәшчем, сердәшем иде, әмма миннән узып, мондый

нәрсәгә ирешүгә ни хакы бар?! Таптарга, изәргә, юк итәргә! Һәм тотына инде – эчә икән, алай икән, болай икән...

Татарлар бүген үзләре арасыннан кешене үстерүне зур бәлагә саный. Исемле кешеләр калкып чыкса, эчләре поша башлый. Яшертен һәм яшертен булмаган рәвештә интернеттагы социаль челтәрләрдә «олы эш» башлап җибәрәләр. Йомшак күңелле кешенең канатлары да сынарга мөмкин, бар өметләре шуңа...

Сине танысыннар, яратсыннар, мактасыннар өчен ике генә юл бар. Беренчесе – мескен булу, икенчесе – үлем. Мескеннәрне кызганалар, ләкин бу – уен гына. Ярар инде, язмыш моңа болай да кирәген биргән, йөрсен шунда, янәсе... Ә үлгәннәр, үзегез беләсез, ачу китереп йөри алмый. Их, тагын бераз яшәгән булса! Шулкадәр күп планнары бар иде, гел халкым, милләтем дип янды!..

Мин ниндидер махсус уйланылган мәкерле теорияләргә һич кенә дә ышанмыйм. Ләкин үзләре белештермичә милләтен кимсетүчеләр төркеме барлыгы мине нык борчый. Аларга бер генә нәрсә белән дә ярап булмый. «Шул да булдымы җыр, шул да булдымы спектакль, шул да булдымы артист?!.» Аларның бер генә максаты бар – теләсә нәрсәдән кер эзләү, яман төсмер табарга тырышу. Алар шушы гамәлләре белән әллә махсус рәвештә, әллә белештермичә татарга мескенлек хисен сеңдерә. Әгәр дә балага иртәдән кичкә кадәр «Син надан», – дип тәкрарлап торсаң, ул, ахыр чиктә моның белән килешә һәм белемгә омтылудан файда юклыгына инанган битараф халәткә төшә.

Милләтнең атрибутикасы булырга тиеш. Аңа җыр, әдәбият, матбугат, бию, театр һәм башка бик күп нәрсәләр кирә. Бүген кайбер көчләр менә шушы гасырлар буе оешып килгән атрибутиканы җимерергә маташа шикелле. Татар надан – аңа барысы да гади булсын! Ул җитди текстларны укый алмый, ялкау! Татарга секс турында сөйләргә кирәк, чөнки ул тема гына кызык. Өчпочмак белән бәлеш пешерү рецепты ярап куя. Тарих, дин, әдәп-әхлак – үтә дә күңелсез, кирәксез, игътибарны җәлеп итми торган темалар. Татарның аларны ерып чыгарга акылы җитми!

Озын текстлы китаплар кирәкми – комикслар заманы! Гәрчә, комиксларга табыну Кушма Штатларда уйлап табылган нәрсә бит. Шулар нигезендә соңрак мультфильмнар, аннан соң кинолар төшерелгән. Гади рәсем белән гади җөмлә – аннан, көнбатыштан килгән шаукым. Без аны, әлбәттә, үз файдабызга кулланырга тиеш. Хәтерлим, мин бала чагында «Ялкын» журналында басыла иде ул комикслар, соңгы битендә. Әмма алар безнең әкиятләргә, безнең чынбарлыкка нигезләнгән иде.

Чыңгыз Айтматов чи дөя тиресе белән маңкортлаштыру турында язып калдырган. Бүген андый кыргый ысуллар кулланылмый. Адәми затның инстинктлары гына исән калсын өчен сүз көче дә җитә. «Синең телең беркемгә дә кирәкми, җырларың шырдый-бырдый, шәхес диярлек кешеләрең кызгану хисен генә уята, укырлык әдәбиятың юк...» Алар башка милләтләрдә дә шырдый-бырдый җырлар барлыгын искә төшереп тормый, бүтәннәрнең дә бик үк уңышлы булмаган әсәрләр иҗат иткәнлеген шәрехләми. Максат анда түгел. Максат – үзеңне бетерү, үзеңне таптау, бичара, мохтаж, булдыксыз итеп тасвирлау.

Татарны юкка чыгару өчен татарларның үзләре арасыннан ук «экспертлар» табыла. Гадәттә, теге яки бу юнәлештә әллә ни эш майтара алмаган бәндәләр була алар. Әлепле әртисе театрны типкәли, сәүдәгә сугылган элеккеге журналист матбугатны тар-мар итә, һәм башкалар, һәм башкалар.

Мактарга ярамый. Әгәр берәрсен мактыйсың икән, син йә куркак, йә куштан, йә сатылган. Мактасаң, сиңа оят булырга тиеш...

Дөнья белән Явызлык идарә итә. Явызлык юк икән, кызык түгел. Фәләннең баласы берәр кечкенә генә бәйгедә җиңү яулавын әйтсәң, синең әңгәмәдәшеңә берничә мизгелдән бу яңалык кызык булмый башлый. Фәләннең баласы берәр төрле бәлагә тарыганлыгын әйтсәң, энәсенә-җебенә кадәр төпчену, кызганган булып кылану, уфтану һәм сыкрану сәгатьләр буена сузылырга мөмкин.

Явызлык кешенең эчке халәтен үзгәртә. Аның эш-гамәлләренә үтеп керә. Бүген дөнья лидерлары дип исәпләнеп йөреп, шул явызлык кылучы бәндәләргә игътибар итегез. Күбесе – шәхси тормышларында бәхетсез мәхлуклар. Нәселе үзендә өзелгән Меркель, элеккеге укытучысы, карт әби белән ятак бүлешүче Макрон, кибеп-корып, эчтән кара янганлыгы йөзенә чыккан Майя Санду. Аларны исәпсез-хисапсыз санап китәргә мөмкин. Картаеп, акылын җуйган Байденны әйтеп тә тормыйм. Йөзләренә игътибар итегез – анда нур юк. Явызлык белән күңел җылылыгы янәшә тора алмый. Ул халыкара мәйдандагы лидерга да, гади генә бер адәм затына да бер үк төсле тәэсир итә, кара яндырып чыгара.

Явызлыкның тагын бер чагылышы – телеңә ни килсә, шуны сөйләү. Бүген моның белән чиксез горурланучылар бар. Янәсе, ни уйласам, шуны әйтәм, туры сүзле мин! Тик кешегә кечкенә генә тел белән бергә Ходай Тәгалә шактый зур баш мие дә биргән. Әйткәнче, нәкъ менә, уйларга кирәк. Һәр сүзнең үз урыны бар. Син иреңә дә, балаңа да бөтенесен дә әйтеп бетерә алмыйсың. Әгәр инде теләсә нәрсә әйтәсең икән, синең чолганышың сиңа кара тамгасын салып куя. Теленә килгәнне сөйләү – ахмакның эше, алдына килгәнне ашау – хайванның эше, диләрме әле?...

Дөнья күләмендә Явызлык шулкадәр котырды ки – әдәп-әхлакның әсәре дә калмады. Безнең ил Америка белән бүген генә хәрби каршылыкка кермәде. Моңа кадәр Корея, Вьетнам, Әфганстан, Сүрия һәм башка бик күп чит илләрдәге сугышларда кара-каршы очраштык бит инде. Әмма ул чакта тегеләр безне юк итү ниятләрен авыз тутырып әйтмиләр иде. Корал бирүләре дә, инструкторлар җибәрелү дә мәгълүм, тик моны күз буяу өчен генә булса да, яшерергә маташтылар, турыдан бәреп кычкырмадылар. Бүген исә әлеге тәртипләр юкка чыгарылды. Күперләр генә түгел, тар басмалар да яндырылып бетерелде. Кыямәт көне якынлашамы?!

Инде янәдән татарлык мәсьәләсенә әйләнеп кайтыйк. Милли атрибутика, дидем. Ул һичшиксез булырга тиеш. Эстраданы да сүгәргә ярамый – безнең дә шырдый-бырдый җырларыбыз булсын. Иң мөһиме – татарча! Баланың теле Әлифба белән ачыла, ул, хәреф тану белән, Тукайның «Шүрәле»сенә, йә булмаса «Торналар төшкән җиргә» ябышмый бит. Акрынлап үсә, гадидән катлаулыга таба.

Тик артык гадиләшүнең дә зыяны зур. Катлаулы әйберләргә милли кодлар, бары тик без генә аңлый алырлык менталь мәгънәләр салына.

Боларны кадерләп саклау да – безнең бурычыбыз. Иң мөһиме – күңел тарлыгына бирелергә ярамый.

Без тар даирәдә яшибез, бер-беребезне шәхсән беләбез. Шуңа күрә бер-беребезгә карата мөнәсәбәтләр дә бик кискен төсмер ала. Хөсетлек, көнчелек – һәрбер халыкка хас ул. Без бу очракта искәрмә дә, чиктән ашкан дәрәҗәдәге мисал да түгел. Бер-беребезгә карата ихтирам хисен тәрбияли алсак, без бүгенге каршылыкларны җиңәрбез төсле. Минемчә, эшне шуннан башларга кирәк.

Безнең географик яктан урнашуыбыз да бер яктан отышлы булса, икенче яктан кимчелекле. Үзебезгә йомылып яши алмыйбыз. Бу нисбәттән, әлбәттә, якут, тыва, алтай кешеләренә көнләшергә генә кала...

– Таулы Алтайга бардык, – дип сүзне борып җибәрү җае чыгуга шатланды Ильяс. Түрә булгач, сорап торуыбызны көтми, ул кайларга баруларын, кем белән нинди ресторанда салып утыруларын, бер утыруда күпме акча туздырганнарын үзлегеннән сөйләргә гадәтләнеп китте. Рамил моны мактану буларак бәяләсә, мин иптәшебезнең, ниһаять, хәерчелектән, юклыктан котылуына шатлануы, шул шатлыгын безнең белән бүлешүе дип саный килдем. – Минем дустымны беләсез бит инде. Василий атлы. Бай инде, мин сиңайтим! Акчасын кая куярга белми. Туган көннәрен бик зурлап үткәрергә өйрәнеп китте. Оештыру агентлыгын яллый, затлы җырчыларны чакыра. Бу юлы Лепс махсус безнең өчен генә килеп җырлады. Таулар арасында яңа гына төзелгән зур отель, үзенең аерым биләмәләре. Берничә ресторан, мунча, бассейн, матурлык салоннары, дәвалану урыннары... Бер сүз белән әйткәндә, җәннәт инде!

– Алтайның үзендә яшәүчеләр моңа бик үк шат түгел дип беләм...

Ильяс минем болай бүлдерүемне ошатмады, уң як кашын гына күтәреп миңа таба бакты:

– Яраталармы, яратмыйлармы, анда минем эшем юк. Мәскәү халкы шуннан кайтып керми икән. Пандемия вакытында да шунда гына яткannар.

– Менә шуңа яратмыйлар да инде. Гасырлар буе килгән тәртипләр бозыла, гореф-гадәтләр китә, табигатьне санлау юкка чыга. Ул син яшәгән җәннәтне төзеп чыгар өчен башта әлеге җирләрне трактор-бульдозер белән тигезләгәннәр бит. Ә Алтай кешеләре өчен һәр тереклек иясе кадерле...

– Ярый, синеңчә булсын. – Ильяс минем тарафка кулын ук селтәде. – Әйтерсең бульдозерны мин китерткән! Сүзем ул хакта түгел иде. Безне тауларга алып чыктылар, квадроцикллар белән. Югарыга, биеккә үк мендек. Андагы матурлык, андагы гүзәллек! Василий үзе генә күрә алмады – беренче көнне килү насыйп булмады, мескенгә. Самолёттан төшереп калдырганнар, чөнки, салонга кергәч тә, тәмәке тарткан бу. Электрон тәмәке, кәнишне, ләкин шулай да...

– Исерек булган, димәк. – Рамилнең хөкеме катгый булды.

– Исерек, билгеле. Анысы мөһим түгел. Квадроцикллар белән кайту юлында безгә табын корганнар. Тау сыртының кыл уртасында өстәлләр, урындыклар тора. Алда упкын, артта упкын, ә син нәкъ уртада утырасың. Ул тәлинкәләрне, пычак-чәнечкеләрне күрсәң син! Пластикның әсәре дә юк, барысы да затлы, алтын да көмеш! Официант егет-кызлар да кара чалбар, ак күлмәктән, муеннарында «күбәләк». Утырабыз, малай, иң шәп маркалы

коньяклар салып, артыннан марал итен капкалап. Көне чалт аяз, кояш кыздыра. Берзаманны әллә кайдан гына бүрек кадәрле генә болыт килеп тә чыкты, кояшны каплап та алды. И малай, купты давыл, купты давыл! Өстәлләр, урындыклар, затлы савыт-саба – барысын да җил очырта, бичара официантлар әле берсен, әле икенчесен тотып калырга ашыга! Кая ул?! Мин, хатынны эләктердем дә, бер агачка сыендым. Җиле кешене күтәреп китәрлек! Эре тамчылы яңгыр коеп яварга тотынды. Ярый да, плащларыбыз бар иде, юешләнмәдек. Ничек кинәт башланса, гарасат шулай кисәк кенә туктады. Теге башта мин тасвирлаган матурлыкның эзе дә калмады...

Ильясның да әлеге бәяны шул гарасат төсле килеп чыкты – капылт кына бетте, тик сөйләгәненә ниндирәк мәгънә салынганы гына аңлашылмый калды.

– Алтай рухы сезгә ачулы булган, шуңа табыныгызны тар-мар иткән, – дидем мин, тыелырга кирәклеген чәч тамырларым белән тойсам да.

– Хорафат...

– Хорафат түгел. Алтай – безнең халкыбыз яралган җир. Бүредән. Ашина нәселеннән бит без...

– Әстәгъфирулла, тәүбә! – дип әллә ниткән догаларын укырга кереште Рамилебез. – Нинди бүре инде тагын? Маймылдан димисеңме тагын?

– Бүредән. Телисезме-юкмы, бу – безнең ата-бабаларыбызның борынгы ышанулары. Алар аңа үзләренә мәгълүм мәгънәләрне салгандыр дип уйлыйм.

– Бисмилла әйтеп тәрбияләгәннәр бит үзеңне. Без, бүре балалары, – дип өстеңә гөнаһ алып утырмасаң...

– Гөнаһ дип... Ул нәселебезнең сабый чагы бит. Тамырларыбыз тирән, алар хәзерге диннәр барлыкка килгәнче үк яралган. Моннан тартынырга кирәкми. Киресенчә, горурлык урынлы. Тамырлар шундый нәрсә – аны югалту бик ансат. Сабан туен гына алыгыз. Совет хакимиятендә никадәр акыллы кешеләр эшләгән! Безнең мәҗүсилек чорыннан килгән бәйрәмебезне үзләренә отышлы идеологик калыпка салып куйганнар һәм ул хәзергә кадәр шул гадәтеннән арына алмый интегә. Түрәләрнең котлаулары, грамоталар, флаг күтәрүләр... Бәйрәмне дә тартып алмаганнар, үзләренә кирәкле мәгънәләрне дә оста итеп үреп калдырганнар. Хәзер менә Сабан туен элеккеге халәтенә ничек кайтарырга белми баш ватабыз...

Минем сүзләрне һавадагы самолёт гөрелтесе бүлдерде. Икенче тәмәкене көйрәтеп җибәреп, киң итеп сулыш алдым. Тәмәкенең тәме юк, әйтерсең көзге яфраклар тураклап салганнар. Хәер, яфрак салсалар, хет ичмасам исе чыгар иде, ә боларның ни исе, ни төтене... Мин тарта гына башлаганда, моннан егерме еллап элек, бөтенләй икенче иде ул фифируслар.

– «Тюркиш эйрланс», – диде Рамил, күзен чекерәйтә төшеп самолётка текәлеп. – Туристлардыр, мөгаен.

– Туристлардан башка да бездән киткәннәр күп, диләр анда. – Ильяс кулындагы электрон сигаретын боргалаган итенде. – Анда качып китәр өчен йортлар, фатирлар сатып алганнар, бәясеннән дә тормаганнар. Моны сизенгән төрекләр дә торак хакларын бермә-бер күтәргән икән.

– Көнчыгыш халкы, сәүдәгәрлек каннарына сеңгән аларның, – дип җөпләдем мин.

– Шулаен шулай да, хәзер Төркиянең төп халкы безнең килмешәкләрне куып җибәрергә өнди башлаган. Артыгын кыланалар икән. Безнең кызның кияү күргәне бармыни, диярсең...

– Әйтәсе юк! – Минем дә интернетта күземә чалынган бер шаккатмалы хәбәр исемә төште. – Ялгышмасам, Анталия шәһәрендә безнең мөһаҗирләр азанга каршы петиция язып, имзалар җыярга керешкән. Иртәнге азан бигрәк тә теңкәләренә тия икән, шуны тыймакчы булганнар. Йокыны бүлә, ди. Ул ахмаклар мөселманнарны ни дәрәҗәдә кимсетүләрен уйлап та бирмәгән, билгеле. Тик шул тинтәкләрнең наданлыгы аркасында безнең халык турында бик үк уңай булмаган фикер туа...

– Без андый фикерләрдән курыкмыйбыз үзе. Арттырып та җибәреп, шул стереотипларны расларга да күп сорамыйбыз бит.

Бәгъзе хәлләр башланганнан бирле башымда боргаланып йөргән күпсанлы сораулар, үз-үзем белән бәхәсләр сирәк аралаша торган бу иптәшләрем янында ничектер үзеннән-үзе оешып, укмашып, ташкын булып чыга торды.

– Гомумән, туган җиреңнән кубарылып, каядыр китүне мин күз алдына да китерә алмыйм, – дидем мин, әлеге гәп сатуның үзенә күрә комарын эләктереп. – Ничек чыгып китәсең?! Минем бөтен җаным-тәнем шушы җиргә береккән бит. Беренче чиратта, авылыма, аннан соң Казанга... Безне ата-бабалар каберләренә килеп, аларның рухларына дога кылырга өйрәттеләр, туган нигезне таратырга ярамый дип тәрбияләделәр. Әби, мәрхүм, җиреннән аерылган җиде ел елар, иленнән аерылган үлгәнче елар ди торган иде. Андыйлар азмыни? Хәер, нигез, ата-бабалар рухы кебек абстракт төшенчәләрне искә алмасаң да... Беләсезме, күпме туганым минем ярдәмемә өметләнеп яши? Кан басымы белән интеккән әнием, аяклары бетешкән әтием, тагын күпсанлы, инде олыгаеп барган якыннарым. Шөкер, ыруыбыз зур. Ничек итеп мин аларны язмыш кочагына ташлап китеп барыйм? Аларны бер күрергә тилмереп ничек яшәмәк кирәк?

– Ватсапта видеодан шалтыратырга мөмкин, – дип, бака ботын кыстыргандый, Рамил дәшми кала алмады. – Аннан соң, син әйткәннән тыш, туган җирдән туйган җир яхшы дигән гыйбарә дә бар бит...

– Бардыр, аңа күпмедер дәрәҗәдә хакыйкать тә салынгандыр. Торган җирне дә алмаштыру мөмкин. Тик ул хыянәт кенә булмасын. Кемдер кияүгә чыга, икенчеләре эшкә, өченчеләре сәламәтлек ягын кайгыртып күченә. Дөнья хәле төрлечә ул, барыннан да гаеп эзләргә ярамый. – Ильяс үтә җитдиләнеп китте. Моңарчы эленгән түрә битлеген салып ташлаган төсле тоелды. Хәзер мин чын Ильясның тавышын ишеттем. – Киттең, ди, ярый, яхшы. Ләкин нигә син анда баргач, туып-үскән җиреңне яманлыйсың?! Шуның әҗере булыр дип өметләнәсеңме? Моның өчен берәрсе түли икән, андый байлык нәрсәгә кирәк?! Нигә анда киткәч, безнең илебез фәлән дә, безнең илебез төгән дип, барлык яманлыкны тотып селкергә?! Әйе, минем дә туган илемә сорауларым шактый, хәтта бик күп дип тә әйтер идем. Ләкин ул сорауларны бүген түгел, дөньялар тынычлангач, тузан бераз утыра төшкәч бирергә кирәктер...

– Ни кызганыч, син әйткән төркем кешеләре үз илен яманлауда тегендәге дошманнардан да арттырып җибәрә шул. – Ильяс сүзләрен мин дә куәтләргә мәҗбүр булдым. – Интернетта «дошман» телеканалына

тап булдым. Бездә, үзегез беләсез бит, бер яктан барысы да тыелган, икенче яктан, барысын да күрергә, ишетергә, укырга мөмкин. «Тегеләр» безне «эшкәртер» өчен рус телендә тулы бер телеканал оештырганнар. Журналистлары – заманында бездән киткән егет-кызлар. Әйтергә кирәк, барысы да бик булдыклы, ышандырып сөйлиләр, белем дәрәҗәләре телтеш тидерерлек түгел. Менә шунда бездә туып-үскән бер егет эшләп ята. Алып баручы бу. Сөйли инде. Имештер, Татарстанда, Алабуга янындагы заводларның берсендә пилотсыз очкычлар җитештерә башларга ниятлиләр. Атап әйткәндә, Иранда уйлап табылган «Шәһит» дроннары. Дәлилләрен дә китерә – безнекеләр Иран делегациясе белән бергә заводта булган, моны телевизордан да күрсәткәннәр. Һәм менә бу егет фаразлар корырга керешә – янәсе, Украинадан җибәрелгән бомба Казанга кадәр күпме вакыт эчендә очып килеп җитәр икән, җитә калса, кайса завод-фабрикаларны беренче чиратта юк итәргә тиеш, һәм башкалар, һәм башкалар. Шулкадәр тәмләп сөйли, исең-акылың китәрлек! Аның да биредә туганнары, танышбелешләре калгандыр бит инде? Юк, уйлап та бирми. Картада менә моны юк итәсе, менә боларын шартлатасы дип, тамгаларга кадәр сугып чыкты.

– Икмәген бушка ашап ятмаганлыгын исбатларга тырыша, нәрсә дип әйтәсең? – Ильяс төкереп үк куйды. – Менә, янәсе, күрегез, кирәк икән, үземнең әниемне дә сатарга әзермен...

– Әйе, безнең замандагы ватанпәрвәрлек юк шул хәзер, – дидем мин. – Ике төрле яманга тап булырга туры килә. Йә чиктән тыш, чамасыз «урапатриотлар», йә инде туган җиренә карата нәфрәт хисе белән яшәүчеләр.

– Икесе дә куркыныч... – Ильяс та минем сүзләрне җөпләде. – Бездә эчтәлекне форма белән буталштыру гадәте – мәңгелек күренеш. Күптән түгел Мәскәүгә барган идек. Якшәмбе көн. Төш вакыты. Урамнар буш, башкала әле уянып кына килә. Берзаман Тверская урамы ягыннан затлы машиналар колоннасы күренде. Анда Порш та, Бугатти да, Роллс-Ройс та бар. Берсе түбәсенә бомба муляжы урнаштырган, икенчесе «На Берлин!» дип танк сурәтләре төшергән, Америкага йодрык янаганнары да бар. Машиналарын шулай бизәкләп бетергән болар. Тәрәзәләре ачык, аннан шактый кызмача егет-кызлар күренә, музыка акырталар, үзләре кычкыралар... Аңлавымча, яу кырында сугышучы солдатларыбызга теләктәшлек чарасы булгандыр ул. Әмма окопта яткан сугышчыга аннан ни файда?! Шул затлы машинаңны сат та, дошманга каршы көрәштә чыннан да файдалы җиһаз алып бир дә бит! Юк, арт санны җылыда йөртәсе килә!

– Бер сиңа гына җылыда йөрергә димәгән инде, Ильяс, – дип ыржайды Рамил.

– Керик, салкынча монда. – Мин яңа бәхәскә юл куймаска тырышып, егетләрне кире керергә өндәдем. Суык та сөяккә үтә башлаган иде.

Без, утырган урыннан торып, кабат ишеккә юнәлдек. Ишек дигәне бик нык тимердән эшләнгән, эчке яктан су асты көймәләренеке төсле борып бикләнә торган йозагы да барлыгын абайладым. Үзенең ачылу рәвешеннән үк авыр булуы сизелеп тора.

– Ишекне шәп итеп ясагансың, Фаил! – дип тел шартлаттым. – Моны кабан дуңгызларыннан сакланыр өчен шулай кордыңмы?

Фаил шаркылдап көлде.

– Моннан берничә ел элек Көньяк Кореяда төшерелгән «Паразиты» фильмын хәтерлисезме? – диде ул. Безнең беребезнең дә аны караган юк икән. – «Оскар» бүләген алган кино. Җаегыз булса, күз төшерегез. Без бу йортны шул фильмны караганнан соң уйлап таптык.

– Нәрсә турында соң ул?

– Көньяк Кореяда яшәүчеләр Төньяк Кореядан куркып яши. Аларның җитәкчеләре бомбалар белән мавыга, әледән-әле күршеләреннән ерак түгел диңгездә шартлатып, котларын алып тора. Кыскасы, аларның ничек яшәгәннәре сезгә мәгълүм дип беләм...

– Мәгълүм булмый, бигрәк тә ул шартлаулар турында очына-очына, елмаеп сөйләүче алып баручы бер хатын хәтергә уелган...

– Пенсиягә озаттылар инде аны. – Рамил бу очракта да үтә белдекле булуын ассызыклады. – Сиксән яшькә кадәр эшләде ул. Бомба шартлатуларны елмаеп сөйләде, Ким Чен Ир үлеме хакында елап хәбәр итте.

– Әйе, нәкъ үзе! Тик сүз башым бит Шүрәле... Кыскасы, череп баеган кореялылар шәхси йортлар салганда җир астына, бик тирәнгә төшеп китә торган бункерлар төзетә башлаган. Ул подвал гына түгел, чын мәгънәсендә бункер, аны тимер-бетон белән ныгытып ясыйлар, һава чистарту системалары урнаштыралар, бозылмый торган азык-төлек запасы туплыйлар. Кыскасы, күпмедер вакыт дәвамында җир йөзенә чыкмыйча яшәргә мөмкин.

Фаилнең кайсы якка авышканлыгы акрынлап аңлашыла башлады. Янә аркам чымырдап куйды, йөрәк кысып алган төсле булды. Кулымдагы электрон беләзеккә күз салдым – тамыр тибеше 140тан ашып киткән иде.

Табынга утыра-утыра тирә-якны күзәттем. Калын стеналарның, кечкенә тәрәзәләрнең нәрсә өчен кирәклеге хәзер аңлашыла башлады төсле. Тамак кипте, бокалга үрелдем. Ниһаять:

– Сез биредә бункер төзедегезмени? – дип әйтергә көч таптым.

Бүлмәдәгеләр башта миңа, аннан соң авызы колагына җиткән Фаилгә һәм, уңайсызланып, күзләрен идәнгә төбәгән Наиләгә текәлделәр.

– Бункер?! – дип пышылдады Сания. – Без лофтта түгел, бункердамыни?!

Әлеге ачыш аның чибәр йөзенә куркыныч төсмер салды. Ул, берни аңламаган кыяфәт белән ни уйларга да белми иде. Баш миендәге берничә фикер, уңлы-суллы бәргәләнеп, давыллы зилзилә чыгарды кебек. Һәм Саниянең чамалы акылы бу гарасат белән көрәшә алмаслык хәлгә төште. Ул, яклау эзләп, иренә сүзсез карашын юнәлтте.

– Бункерда түгел инде, мондый бункер буламыни?! – Рамил аңга килә алды шикелле, елмайгандай итте.

– Дөрес әйтәсең, бункер түгел. Без аның өстендәге корылмада. – Фаилнең йөзендәге елмаю киңәя генә төште, Наиләгә исә иренең болай ачылып китүе бер дә ошамаганлыгы әллә кайдан күренә. Тик анысы да бүлдермәде, каршы дәшмәде.

– Фаил, Наилә, сез нәрсә, атом-төш сугышына әзерләнәсезмени? – Кем дә булса әлеге сорауны яңгыратырга тиештер дип, мин дилбегәне үз кулыма алдым.

– Әлбәттә. Син телевизор карамыйсың, телеграм-каналларны укымыйсыңмы әллә? Дөньяның кая тәгәрәгәне аңлашыла бит инде. Без аңа алдан әзерлек чарасын күрергә булдык. – Фаил табыннан торды. – Әйдәгез, күрсәтәм.

Әйтерсең ул гадәти, табигый нәрсәләр турында әйтте. Күңел аның сүзләрен шаккатып та, куркып та кабул итмәде. Киресенчә, көне буе эчне яндырып торган шом, киеренке халәт шушы мизгелдә юк булды. Барысы да аңлашылды, шомлануның сәбәбе ачыкланды. Җиңел сулап куярга мөмкин. Бункер, нәрсәсе бар инде аның?! Телевизордан да күргән, интернетта да укыган бар. Тик бу бункерның танышларыбызныкы булуы гына сәеррәк, әлбәттә, ә тулаем алганда, күрәсең, хәзерге чорда гараж төсле үк файдалы һәм мөмкинлегең бар чакта салып куй...

Без, ирләр дә, хатыннар да, хуҗага иярдек. Наилә табын тирәсендә кайнашып калды. Бүлмәдәге ике бала рәхәтләнеп өр-яңа уенчыкларны өйрәнү белән мәшгуль иде.

Тар коридордан озак барырга туры килмәде – икенче бер авыр ишеккә төртелдек – ул, элеккесеннән аермалы буларак, түгәрәк иде. Фаил, аны ачып, беренче булып үзе атлады.

Күземә беренче ташланган нәрсә – бетон корылма. Ул текә баскыч рәвешендә каядыр еракка, дөм караңгылыкка китеп югала. Фаил стенаны капшап ут кабызды. Бик тирәнгә төшә икән әлеге баскыч. Хуҗа кеше ышанычлы адымнар белән алга атлады, без дә, бераз икеләнеп торганнан соң, аңа иярдек.

– Иң авыры җирне казып төшү булды, – дип аңлатырга кереште ул. – Сталинның Самарадагы бункеры 37 метр тирәнлеккә урнашкан. Аңлашыла ки, ул вакытта әле атом бомбасы хакында артык хәбәрдар булмаганнар. Әмма һәртөрле авиация бомбалары турыдан-туры эләксә дә, илбашчы исән калырлык итеп төзегәннәр. Гомумән, дөньяның бик күп илләрендә атом-төш шартлавыннан котылып калу өчен салынган бункерлар бар. Шул исәптән бездә дә. Аларның тирәнлеге төрлечә, саклык дәрәҗәсе дә аерылып тора.

Фаил сөйләгәннәргә, алай гына да түгел, әле генә күрелгәннәргә ышанырга да, ышанмаска да белми, алга атлыйм. Дөресрәге, аска. Калганнар да тынып кылган, бик зур осталык белән эшләнгән ныгытмаларны, аяк астындагы баскычларны өйрәнәләр.

Ниһаять, аска да төшеп җиттек. Фаил тагын бер түгәрәк ишекне ачты, ул да борылмалы йозак белән бикләнгән иде. Ишекнең калынлыгы егерме сантиметрдан да ким түгел, ялтырап торган тоташ тимердән эшләнгән.

Янә бер аралыкка килеп кердек. Күзләрне авырттырырлык дәрәҗәдә яктылык сирпеп, лампочкалар җемелди. Фаил безне бункер белән таныштырырга кереште. Берничә рәт булып тезелеп киткән лар төрендәге суыткыч тора, аларның кайсында балык, кайсында ит, кайсында туңдырылган яшелчә һәм җиләк-җимеш. Боларга электр энергиясен ничек җиткереп бетерәсез дигән сорауга Фаил кайдадыр җир өстендә автоном электр станциясе барлыгын әйтте.

Аннан ары консервалар белән шыплап тулган складка эләктек. Биредә дә төрле-төрле ризык, хуҗа сүзләренә караганда, кеше организмына кирәкле витаминнар күләмен истә тотып тупланган запаслар.

Су җир астыннан алына, аны яхшылап чистарталар, махсус җайланмалары бар.

Һаваны тазартып тору өчен дә кыйммәтле фильтрлар урнаштырылган.

Төрле калдык-постык үзенә күрә кечкенә генә бакчаны ашлап торырга тиеш. Фаил безгә инде хәзер үк үсеп утырган яшелчәләрне дә күрсәтте.

Бункер бик иркен, анда кешегә ни кирәксә, шул бар кебек. Бергәләшеп җыелу өчен зур зал, киштәләрдә китаплар тезелеп киткән, фәлән йөз мең гигабайтлы диска кинофильмнар тупланган. Шунда ук патефон сыман нәрсә – музыка тыңлар өчен. Кухнясы да бар, берничә йокы бүлмәсе һәм... уенчыклар белән тулы балалар бүлмәләре. Безнең гаҗәпләнүне, әлбәттә, Фаил күрми калмады.

– Бәлки, җирдә без исән калган соңгы кешеләр булырбыз. Кешелек нәселен дәвам итүдән өметебезне өзмибез, – диде ул, оятыннан кызарынып-бүртенеп.

Баш мие аңга килә башлады. Ул моның бер дә гадәти түгеллеген, ниһаять, исәпләп чыгарды, моңарчы күрелгән манзаралар рәтендә хәзергесе коточкыч дәрәҗәдә яман һәм куркыныч иде. Бугазга төер килеп тортелде. Кычкырып елыйсы, әни кочагына елышасы килде. Безнең өстебездә калын җир катламы ятканын, шушы гүргә кереп утыруны аңлаудан тәнем чемердәп куйды. Фаил белән Наилә уйлап тапкан түшәмнәр ул җирнең авырлыгына түзмәс, һичшиксез ишелер шикелле. Йә булмаса берәрсе өстәге ишекне бикләп куяр да, без мәңгегә биредә калырбыз кебек...

– Бу запаслар күпмегә җитәр соң? – дип аваз салды Рамил. Аның тавышында элеккеге белдеклелекнең әсәре дә калмаган иде.

– Мин бер ел дәвамында җир астында яшәү хәстәрен күрдем. Озаккарак җитсә, әйбәт, әлбәттә, ләкин ул кадәр үк әзерләнергә хәлебездән килмәде. Атом-төш сугышын төрлечә фаразлыйлар бит. Беркем дә анык кына итеп күзаллый алмый. Һәрхәлдә, Казан һөҗүмнән котыла алмас. Совет заманында безнең башкала янында берничә һава обороносы системасы эшләп торган. Берсе, әле дә хәтерлим, Дәрвишләр бистәсе ягында иде. Аны Локаторная дип йөртә идек. Туздырдылар инде аны, хәзер анда коттеджлар кукраеп утыра. Һәрхәлдә, Казан читтә калмас... Аннан соң, күпмедер ракеталарны безгә килгәнче бәреп төшерерләр...

Фаил безне кире өскә әйдәде. Атом-төш һөҗүме, бомба-ракеталар турында ул бик мавыгып сөйләргә кереште. Әйтерсең мәктәптәге мөгаллим еллар буе ятлаган дәрес материалын чираттагы сыйныф укучыларына кабатлый.

– Кушма Штатлар Советлар Союзына каршы атом-төш сугышын алып баруның берничә планын әзерли. 1960 елда кабул ителгән «Синоп-62» планы, мәсәлән, безнең илдәге 3423 объектка берьюлы бомбалар яудыруны күздә тоткан. Әлбәттә, ул чакта ил дә зуррак, тегеләрнең кораллары да азрак иде. Аннан соң су асты көймәләре, инде Европада ук торучы шахталар барлыкка килде. Кыскасы, дөнья үзгәргән саен атом-төш коралы да арта торды, аның җимерү көче дә үскәннән-үсә барды.

Кайбер галимнәр фаразлаганча, атом-төш сугышы башланган очракта җир йөзендә 10 мең мегатонна көчендәге шартлау булырга мөмкин. 2 миллиард кеше бер мизгел эчендә юк ителәчәк. Котылганнарга исә мәрхүмнәрнең язмышына кызыгырга гына кала. Бердән, яктылык, җылылык, су һәм башка шундый кирәк-ярак белән тәэмин итү системалары эштән чыга. Медицина ярдәме күрсәтү, азык-төлек җитештерү туктап кала. Шартлаудан күккә корым, төтен, тузан күтәрелә. Ул кояш нурларын җиргә якын да җибәрми. Планетабыз озак вакытка сузылган атом-төш кышына керәчәк. Тереклек юкка чыга, кешеләр генә түгел, кыргый җанварлар да үлеп бетә, агачлар, яшеллек бетә.

Әгәр инде шушы гарасатлардан соң да исән калу насыйп булса, тереклек иядәренә радиация сәбәпле килеп чыккан коточкыч авырулар яный, төрле мутацияләр, организмда төзәтелмәслек үзгәрешләр башлана. Аларның бер өлеше радиациядән зыян күргән җирләрдә күзәтелгән, хәтта өйрәнелгән дә инде...

Җир йөзендә күпме атом-төш коралы барлыгын кешеләр үзләре дә белеп бетерми. Дөнья алдау-йолдауга, бер-береңнең күзен буугa, ялганга корылды. Күреп торасыз – җитди сәясәтчеләр, дөньякүләм лидерлар, күз дә йоммый, кеше ышанмаслык сүзләрне ышандырып сөйли. Мондый шартларда теләсә кемнән шикләнергә, теләсә кайсы мәгълүматка саклык белән карарга гына кала.

Без исән калырга телибез. Шуңа күрә, авызыбыздан өзеп, бөтен керемнәребезне әлеге корылманы төзүгә, аны кирәк-ярак белән тәэмин итүгә юнәлттек. Зур күләмдә кредитлар алдык – күңелебез сизә – аларны кайтарып торуның хаҗәте калмас. Озакламый адәм баласына берни дә кирәкмәс. Әмма без бераз булса да яшәп калырга җыенабыз. Кешелекнең гомерен бераз гына булса да озайтырга ниятлибез...

Фаил, әлеге нотыгын тотканнан соң, бик олы хезмәт башкарып яман дәрәҗәдә арыган, талчыккан кеше рәвешендә калды. Сорауларыгыз юктыр инде дигән өмет белән безгә карап алды, аннан хатынына күз салды.

– Әйдәгез, күтәрик әле, айнып киттем алайса... – Шешәгә үрелгән Рамилнең тавышында элеккеге кирелек белән масаюның әсәре дә калмаган иде.

Без, бер генә дә карышмыйча, аның тәкъдименә кушылырга ашыктык. Аракы бу юлы су кебек, сизелми генә төшеп утырды. Әле генә кичерелгән тетрәнү, стресс шулкадәр көчле иде – хәтта тәм тою сәләте дә элеккеге көчен югалткан, ни эшләргә белми аптырашта калган...

– Бер уйласаң, сезнең бу шик-шөбһәләрегездә хаклык бар кебек... – дип суздым.

Минем бала йоннарым әллә нинди бер куркыныч барлыгын тойды, бу юлы гади бер шомлану, эч пошу гына түгел иде. Нигә аракы эчүемә үкенеп куйдым – рульгә утыра алмыйм. Хәер, хатын азмы-күпме йөртә белә, правасы да бар. Фаил белән Наиләдән безнең барчабызга да куркыныч янаганлыгы аермачык сизелде. Алар үзләренең атом-төш коралы белән саташуларында төрле мәгълүмат җыю, шуны кат-кат сөйләп бер-берсен өркетү стадиясен күптән узган. Алар инде анык гамәл кылырга өлгергән – әле генә күргән бункер моның кычкырып торган дәлиле. Әлбәттә, мондый корылманы салып чыгар өчен бераз гына түгел, тулы мәгънәсендә «ычкынган» булырга кирәк.

– Килешәм, бик дөрес юнәлештә фикер йөртәсең, Фаил, – дип, кинәт кенә миңа ярдәмгә килде Ильяс. – Ни кылганнарын белештермиләр, безнең илне тезләндерер өчен теләсә нинди явызлыкка әзер ул мөртәтләр. Иң куркыныч күсәкне күтәрүдән дә тартынмаслар. Иң мөһиме – беренче адымны без ясарга тиеш түгел.

– Тиеш түгел дә бит түгелен... – Фаилнең елмаюында янә усал чаткылар шәйләнде.

Наилә, чираттагы ризыкны алырга дип, газ мичен ачты. Фаил, дөньяда

ниләр булып ята икән дип, телевизорны кабызып җибәрде. Мин телефоныма үрелдем. Элемтә юк. Күрәсең, бу калын диварлар аша кәрәзле элемтә дулкыннары үтеп керә алмыйдыр...

* * *

Җир, Җир, көчем бир,
Ябага тайның көчен бир,
Алтын алма төсен бир,
Алтын атым куәтен бир,
Алтмыш арба арыш бир,
Алтмыш арба бодай бир,
Алтмыш арба борай бир,
Алтмыш арба тары бир,
Бир, бир, барын бир!
Җир! Җир!

Ул болай олылап мөрәҗәгать итүне, кадер-хөрмәтне беркайчан да ишетмәде, әмма аның бертуганнарына шулай дәшүләрен белә иде. Бозлы диңгез уртасында мәңге эремәс кар белән яртылаш капланган бер утрау булса да, аның да тамырлары бөтен Җир шары белән тоташкан, ул да Җир-Ананың бер мескен баласы бит...

Мескен шул... Аның өстендә беркайчан да яшеллек үсмәде. Мөгаен, әллә кайчан, моннан бик күп язлар һәм кышлар элек булгандыр. Әмма соңгы берничә миллион елда юк...

Хәер, күңелен күрердәй тереклек алай да бар. Таш булып каткан тәнендә оя корырдай тычканнар, симез гәүдәсен көчкә сөйрәп йөрүче диңгез хайваннары, ак аюлар, яман тавыш чыгарып кычкыра торган кошлар. Алар аның янына кояш чыккан вакытта килеп, рәхәтләнеп тукланалар иде. Чөнки биредә тыныч, дошманнар юк диярлек.

Дөрес, кояш кына аңа карата бик саран. Елның яртысы дәвамында диярлек күренми, дөм караңгылыкта иза чигәргә мәҗбүр итә. Алай да, табигать бөтенләйгә үк ташлап калдырмый үзен. Еш кына офыкта төрле төсләргә кереп җемелдәүче төнъяк балкышы гына ни тора!

Кешеләр бу якка килеп, аннан мул уңыш, шаулап үскән икмәк өмет итмәде, билгеле. Әмма аның кырыс шартларында да биредә яшәргә җөрьәт итүчеләр табылды. Күп түгел, шулай да алар бар иде. Һәм бу бәндәләр аңа, таш һәм боздан торган утрауга, олы хөрмәт белән карыйлар, рәнҗетмиләр, ул биргән саран сый-нигъмәтләрдән дә риза-бәхил иделәр. Рәхәт тормыштан килмәгәндер ул адәм затлары бирегә. Нәрсә генә булмасын, алар белән күңелле иде аңа.

Ә көннәрнең берендә кешеләрнең барысын да җыеп алып, каядыр олактырдылар. Алар урынына олы кораблар килеп туктады, аннан кырыс, усал бәндәләр коелышты, үзләре йөрүче тимер таулары пәйда була. Шулар ярдәмендә аның тәнен борауладылар, каезладылар, йортлар торгыздылар, ут төкерә торган тимер таяклар ярдәмендә ак аюларны кырып бетерделәр.

Бу кешеләр теге рәхмәтле җаннарга һич охшамаган иде. Аны шунда ук «Яңа җир» дип атадылар, аннан Полигон кушаматы тактылар, соңрак бөтенләй дә «700 нче Объект» дип кенә эндәшә башладылар.

Берничә дистә ел дәвамында ул мәхшәр кочагында яшәде. Аңа һавадан да, су астыннан да һөҗүм иттеләр, тәнен бораулап, дер селкеттеләр.

Тирәлегендә тереклек һәлак була, балыклар корсакларын өскә күтәргән көе диңгез өстенә калкып чыгалар. Ак аюлардан ташка сыланган шәүлә генә кала. Боз диңгезе кайнар шулпа төсле кайнап чыга. Күккә бер-бер артлы үлем «гөмбәләре», радиация белән шыплап тулган «солтаннар» күтәрелә, җил аларны олы җиргә, аңа карата явызлык кылган кешеләрнең туганнары, балалары яшәгән якларга алып китә. Ә кеше дигәнең моны аңламый төсле. Кемнәрдәндер яшерергә тырышып булса кирәк, мәгарәләргә качырып булса да бомбалар шартлата. «Патша-бомба» белән дөмбердәттек!» – дип шапырына, мактана, әллә кайда, еракта торган дошманнарына моннан торып йодрык күрсәтә, түфлиен салып мөнбәрләрне төя...

Бу кыланмышлар кисәк кенә туктады. Әйтерсең адәм затлары аңга килде, үзе кылган усал гамәлләрнең ни дәрәҗәдә зыянлы икәнлеген аңлады. Аның өстендә янә тереклек пәйда булды, ак аюлар кайчандыр хәрбиләр яшәгән бистәгә үк кереп йөри башлады.

Ә күптән түгел хәрбиләр яңадан кайтты. Таушалган биналарын сипләргә кереште. Болары элеккегеләрдән иманлырак күренергә тырышты бугай – агачтан матур гына итеп ясалган җыйнак кына чиркәү дә китереп куйдылар. Тик менә гамәлләре генә гел элекке, алар моңарчы бомба шартлатудан тәм тапкан мөртәтләрдән аерылмый иде.

Аның күңеленә янә хәтәр хис керде. Теге вакытта кичергән коточкыч тетрәнүләргә кабаттан әйләнеп кайтасы килми иде. Килми дә бит...

Офыкта олы кораб күренде. Аннан һичшиксез ракета атылып чыгар төсле тоелды. Чыкса да, берни эшләтә алмыйсың. Чөнки син Җир иясе Җирән сакал түгел. Син – бары тик Полигон гына. 700 нче Объект...

Җир-анага береккән җепселләре аша дөньяның төрле почмакларындагы үзе шикелле үк мескеннәргә – меңәрләгән Полигонның тавышына колак салды. Аларда да тынычлыкка өмет юк иде. Алар да уянган, алар да яңадан элеккеге халәткә кайтуларын курку хисе белән көтәләр...

* * *

– Бәлки, кайтырбыз, – дип, хатынга дәшәргә җай таптым.

– Син салмыш бит...

– Соң, рульгә син утырырсың.

– Рульгә? Син нәрсә, трассадамы? – Ул тәрәзәгә күз салды, анда дөм караңгы иде. – Караңгы, җитмәсә, юлларда бозлавыктыр...

– Кайту турында сүз дә юк, бездә кунасыз! – Фаил әллә кайдан гына килеп чыкты. Юкса, йомышым бар дип әле генә чыгып киткән иде.

– Үзегезгә дә кысан бит...

– Кысан түгел, сыябыз. Күңел киң булсын!

Мин авыр сулап куйдым. Хатынга яман ачуым килде. Беркайчан да сүзне тыңлый белмәде. Биредә калганчы, юл өстендә машинада кунуың хәерлерәк. Үземне маньяклар кулына эләккән тоткын итеп хис итәм. Җитмәсә, клаустрафобия сыман тойгы биләп алды. Бу йортның калын диварлары кысылып, безне сытып ташлар төсле тоелды. Әмма хатын белән кеше алдында сүзгә кереп тору һич килешмәс. Җитмәсә, чыннан да, алай ук кубарылып йөгерерлек сәбәп юк, бу ике мәхлук безгә янамый бит.

Калганнарга күз салдым – барысы да минем кебегрәк халәттә.

Архитекторларны ким дигәндә тилергән дип уйлыйбыз. Янә салып карадык – булышмады. Ә күңел тыныч түгел, ашказаны тирәсендә ялкын дөрләгән сыман. Тик аракы яндырып төшүдән түгел. Курку хисеннән. Һәм бераздан мин моның юкка түгеллегенә инандым...

Барысы да көтмәгәндә башланды. Телевизордан миңа билгесез яшь җырчының музыкаль клибын күрсәтәләр. Ул: «Ромашканың таҗларыннан синең исемне эзлим, кайчан күрешербез диеп, килер юлыңны күзлим» – дип шыңшып та бетермәде, шатырт-потырт килеп, сигнал өзелеп китте. Ул да булмады, телевизор экраннарыннан сиреналар кычкырып җибәрде. Аларның тавышы әллә нинди кыргый җанвар үкерүен хәтерләтә иде. Без, котларыбыз алынып, урыннарыбыздан сикереп тордык, телевизор каршына өелештек. Балалар, уен белән мавыгуларын онытып, әниләренең итәкләренәябышты. Хатын, яныма ук килеп сарылып, бер кулы белән учымны кысты, икенчесе белән авызын каплады.

– Игътибар, игътибар! Атом тревогасы! – дип, шәрран ярды диктор тавышы. Аның коточкыч мәкаме сирена үкерүе белән алмашынып торды. Әле генә ишетелгән хәбәрнең мәгънәсенә төшенә алмый, шактый басып тордык шикелле.

– Улыбыз, – диде хатын, аңына килгәндәй булып. Мин аңа борылдым. Карчыгым акылдан шашып бара иде бугай. Аның кыяфәтен күрү мине дә айнытып җибәрде. Тугызынчы каттагы фатирыбызда компьютерына төртелгән үсмер балабыз, авылда йокларга ятар алдыннан чәй эчәргә утырган әти белән әни, абыйлар, сеңелкәшләр, туган-тумачалар, тагын әллә кемнәр. Алары барысы берьюлы күз алдымнан үтте төсле. Һәм бу манзараны караңгы күктә ажгырып, ут көлтәсе чыгарып барган ракеталар алмаштырды. Алар илебезне төрле яклардан чолгап алганнар, очлы борыннары шәһәр-калаларга, без яшәгән урыннарга төбәлгән...

Калтыранган кулларым белән телефонымны тартып чыгардым. Элемтә юк иде.

Хатын-кызлар елаша башлады, аларга балалар да кушылды.

Ир-атлар башта дәшми торды. Беренче булып, Ильяс яман итеп сүгенеп җибәрде. «Ни кыланалар, ни эшләгәннәрен беләләрме, аңлыйлармы бу мөртәтләр?!» – дип, шашкан кеше төсле тәкрарларга кереште. Рамил ул яктан тынычрак кебек иде, әмма барлык хис-тойгылары эченә яшерелгән, алай да күңелендә давыл уйнаганы сизелә.

Бераз тынычландырырга ниятләп, хатынымны кочакладым. Күземнән яшьләр атылып чыкты. Туган якларым, якыннарым янә каршыма тезелде кебек. Тик алар инде исән түгел, ут белән өтелеп үткән шикелле. Бигрәк тә балабыз кызганыч иде, йөрәгемне пычак белән кискәләгән төсле тоелды. Хәзерге халәте дә түгел, бөтенләй нәни вакыты исемә төште. Искәрмәстән елап ук җибәрдем. Ванна бүлмәсендә коендырган чакта саклык белән кулымда тотып торуларым, аның, бердәнбер ышаныч чарасы буларак кабул итеп, минем бармагыма кечкенә учы белән ябышулары, соңрак эштән кайтканда йөгереп каршыма чыгулары...

Аны әнием алмаштырды. Башында яулыгы, җыерчыклы йөзе, моңсу, шул ук вакытта борчулы карашы, шатлыгын әллә ни күрсәтмәскә тырышып, «кайттыгызмы, улым», дип тыйнак кына елмаюлары...

Туганнар бер-бер артлы күз алдыма килә торды, мин аның саен аларны, һәм, әлбәттә, үземне дә кызганып, катырак елый башладым...

Бу мәхшәрдә Фаил белән Наилә генә тынычлыкларын югалтмады. Фаил, күпмедер вакыт үткәч, телевизорны сүндерде. Аннан хатыны белән ишек катына барып бастылар.

– Тынычланыгыз! – дип яман тавыш белән кычкырды Фаил. – Җитәр, сез елаудан гына берни дә үзгәрми. Буласы булган инде. Ракеталар Казанга җиткәнче берникадәр вакыт бар. Казан, Ульян, Чабаксар, Мари урманнары... Безгә иң зур куркыныч янаган һөҗүм нокталары әнә шулар.

Беренче булып курку чоңгылыннан Ильяс котылды шикелле. Ул Фаил белән Наиләдә әлеге афәттән котылу мөмкинлеге булуын исенә төшерде.

– Дусларым, барыбыз да исән калмаса да, безне генә булса да коткара күрегез, зинһар! Сезнең бункерга яшереник, бу яхшылыгыгыз мәңге онытылмас, үлгәнче догада торырбыз...

– Үләргә өлгерерсез, борчылмагыз... Әмма безнең бункерның сыйдырышлыгы чамалы, азык-төлек, эчә торган су запаслары да чикле. Шуңа күрә гафу итегез, дускайларым, – дип, безне ни көтәсен кырыс, ләкин аңлаешлы итеп шәрехләп куйды Фаил.

Мондый вәхшилекне ишеткән хатыннарыбыз янә кычкырып еларга тотынды, безне кунакка чакырган бәндәләргә карата ләгънәт сүзләре очты. Рамил, Ильясның сүзе үтмәгәнлеген аңлагач, йодрыкларын йомарлап тегеләргә таба бер адым атлаган иде, Фаил арка артына яшеренгән төштән пистолет тартып чыгарды һәм безгә төбәде.

– Атам, якын килмә! – диде ул. Без белгән Фаилнең эзе дә калмаган, каршыбызда әйтерсең тәмуггтан котылып җир йөзенә чыккан шайтан басып тора. – Шаяртмыйм, егетләр. Хәлләрнең кая барганлыгы барыгызга да мәгълүм. Сезне саклап калабыз дип, үзебезнең үләр хәлебез юк. Ә менә балалар...

Фаил Саниянең итәгенә ябышкан кызчыкка, аннан соң Ильясның кулына сарылган малайга таба пистолет көпшәсе белән ымлады. Бире килегез, янәсе. Тегеләре, әлеге гамәлнең ни дәрәҗәдә коточкыч икәнлеген сабыйларныкына хас булмаган сизгерлек белән аңлап, кычкырып елап җибәрделәр.

– Алар исән калыр, бәлки, татар халкының дәвамчылары нәкъ менә алар булыр, – дип пышылдады Фаил. – Үзегез түгел икән, нәселегез яшәр. Ничек туры килгәннәр бит – яшьләре дә тиң! Менә дигән ир белән хатын итеп тәрбияләрбез, бер дә борчылмагыз...

Балаларның килергә ниятләре юклыгын аңлап, Наилә үзе тегеләрне тупас рәвештә кулларыннан тотып, үзләре янына өстерәде.

Нарасыйларның әти-әниләре ни эшләргә белми югалып калган иде. Чыннан да, бу очракта нәрсә яхшырак та, нәрсә яманрак? Бәгырь кисәкләренең шушы аз-маз гына таныш бәндәләр тәрбиясендә җир астындагы бункерда исән калумы, әллә инде бергәләшеп бер мизгел эчендә атом-төш учагында янып, көлгә әйләнүме? Дөресен әйткәндә, мин хәзерге вазгыятьтә бу сорауга җавап табарлык хәлдә түгел идем. Пистолет көпшәсе дә бар бит әле, аның эчендәге кургаш кисәге дә үлем белән яный...

Балалары ачыргаланып елый, аларга хатын-кызларның үксүләре дә өстәлгән, әти кешеләр, ни эшләргә белми, башлары киткән ике архитекторга

текәлгән. Ә кайдадыр еракта, күзгә караңгы күктә, үлем алып килүче ракеталар гөрелдәве...

– Син дә бире кил! – дип боерды Фаил, пистолетының көпшәсе белән Саниягә таба төртеп күрсәтеп.

Тегесе әлеге тәкъдимнән сөрлегеп киткән төсле булды, елавыннан туктады. Бер Фаилгә, бер иренә күз ташлады. Акрынлап баягы куркуы да юк булды шикелле. Хәтта шатланды да кебек. Фаил янына тиз генә килеп, кечкенә кызчыгын чытырдатып кочып алды. Рамил әлеге күренештән телсез калды. Әмма аннан да бигрәк Наилә гаҗәпләнде кебек. Ул ут чәчрәп торган күзләрен иренә төбәде.

– Нигә кирәк ул әрәмтамак?! – дип ысылдады хатын, Сания белән ике арадагы күпьеллык дуслык булмаган да төсле усал рәвештә.

– Аңа гына житә, – дип ташлады Фаил, хатынына борылып карамый гына.

– Нәрсә житә?!

– Наилә, авызыңны яп. Юкса, болар белән бергә өстә генә каласың, бел дә тор.

– Фаил, әллә бөтенләй шаштыңмы?!

– Шашмадым. Безнең балалар булмауга кем гаепле? Син түгелмени?! Ә минем үз нәселемне дә дәвам итәсе килә.

Сания инде ихлас күңелдән елмая иде, ул, гомер буе бергә булганнармыни, Фаилнең киң җилкәсе артына ышыкланды. Бу тамашадан тәмам агарынган Рамил исә йөрәге тотып егылырга әзер иде сыман.

Наилә генә бирешергә җыенмады. Торган урыныннан кубарылып, яман кычкырып, ул иренә ташланды һәм аның пистолет тоткан кулына килеп ябышты. Шуны гына көткән төсле, Ильяс, Рамил, мин – өчебез дә Фаилгә таба сикердек. Ату тавышы яңгырады, әмма пуля түшәмгә тиде, беркемгә дә зыян китерә алмады. Бәргәләшә-бәргәләшә әүмәкләшергә керештек. Тәмам идәнгә барып төштек һәм...

...«Челтерр!!!»

Будильник челтерәде. Мин күзләремне ачтым. Лычма тиргә батканмын. Йөрәк дөп-дөп тибә. Як-ягыма карандым. Капшанып, телефондагы будильникны сүндердем.

Кайда икән мин? Өйдә бугай. Фаилләр белән сугышканым хәтердә. Атом тревогасы.

Кухня ягында хатынның савыт-саба белән шалтор-шолтыр килгәне ишетелде. Минем уянганлыкны белеп, йокы бүлмәсенә керде.

– Хәерле иртә, – диде ул, гадәттәгечә, миңа борылып карамый, киемсалым шкафындагы чүпрәк-чапракларга юнәлеп. – Бүген Наиләләргә кунакка барасы, онытмадыңмы?

– Онытмадым. Сәгать берләргә түгелме соң?

– Бергә.

– Алайса мин бераз ятып торыйм әле. Өлгерербез.

– Нәрсә кияргә дә белгән юк, – диде хатын, кием шкафында чаштырчоштыр казынып. – Бер юньле күлмәк тә юк бит, ичмасам!

– Әллә кем түгелләр, нәрсә кисәң дә ярый, арт саның гына ялтырамасын, – дип мыгырдандым мин, башымны юрган астына яшереп.

– Сиңа кызык... – Хатын, мине чыгырымнан чыгарыр өчен юри лап-лоп басып, тәрәзә янына атылып килде, бөдралары тешне авырттырып сызгырырлык итеп кисәк кенә элгечләрне як-якка тартты. – Әнә беренче кар яткан... Ул эреп бетәр инде. Иртәдән салкын, көндез җылы, кичен янә салкын... Синең сүзне тыңлап, Наташадан теге күлмәкне дә алмадым, ичмасам! Нәкъ бүгенге көнгә яраклы иде...

– Наиләләрнең коттеджы кайда, Идел буендамы?

– Идел кая да, Салмыч бистәсе кая? Бөтенләй тилердеңме әллә?

– Аллага шөкер... – Әле генә күрелгәннәрнең куркыныч төш икәнлеген аңлаудан рәхәт булып китте. – Хатын, яратам мин сине...

– Әстагы, исенә төшкән!

Хатын, лап-лоп басып, улыбыз белән әйткәләшергә дип, бүлмәдән чыгып китте.

Телевизор төймәсенә бастым.

«Америка Кушма Штатлары, рәсми рәвештә кисәтеп тормыйча, Бельгия, Германия, Италия һәм Төркиядәге хәрби базаларына 150 данә атом бомбасы урнаштырган. Бу хакта атом бомбасын юкка чыгару буенча Халыкара компания координаторы Алисия Сандерс-Закре белдерде. Аның әйтүенчә, Вашингтонның бу адымнары атом-төш сугышын тагын бер адымга якынайта».

Саташулы төшем, ни кызганыч, тәмамланырга уйламый иде бугай...

* * *

...Олы кораб Аңа якын килә алмады – ул артык зур, комга терәлергә мөмкин. Аны каршыларга дип, диңгез култыгында корылган пристаньнан кечерәк катер юлга кузгалды. Озак та тормый, ул кире әйләнеп килде.

Кешеләр зур саклык белән бушатырга керешкән әлеге әйбер Аңа яхшы таныш иде.

Күп күрде ул андыйларны. Ничек итеп ярылулары хәтереннән чыгарлык түгел.

Ул янәдән Полигон халәтенә әйләнеп кайтырга тиешлеген аңлады.

Җансыз «700 нче Объект»...

Ә бит кайдадыр, кайчандыр, аңа да башка төрле мөнәсәбәт булган. Һәм ул Хәтере чоңгылларыннан шул чактагы матур истәлекләрне тартып чыгарырга маташты.

Аның карлы, бозлы, ташлы тәненә килеп бәрелгән салкын диңгез дулкыннары моңлы бер көй чыгарып, Җир-Ана куенына йомырка тәгәрәтүчеләр келәүләрен көйлиләр төсле тоелды:

Икмәкләр булсын,
Ил бай булсын,
Бар кеше дә тук булсын,
Сугышлар булмасын,
Тынычлык булсын,
Дөньялар имин булсын...



Нәфисә
Сабирҗанова

# ҖЫЛЫ СҮЗЕҢ ҖАННЫ КОЧАКЛАСЫН...

## Ак хыяллар бүләк ит

Бөтерелеп тагын карлар ява,
Ак буранга шәһәр күмелгән.
Бәхет юрап әйткән теләкләрне
Дога кебек укыйм күңелдән.
Сынауларны җиңгән үзебезне
Югалтмаска иде ваклыкта.
Ак хыяллар бүләк ит син миңа
Карлар яуган шушы вакытта.

Буран эчендәге биек йортлар
Саклый кебек безне өшүдән.
Шул карларга ияреп уйный уйлар, –
Үткәннәрне искә төшерәм.
Элеккедәй булмас бернәрсә дә,
Элеккедәй түгел беркем дә...
Ак хыяллар бүләк ит син миңа
Карлар яуган шушы бер көндә.

Кала урамнары карлы бүген,
Буран күмә иске эзләрне.
Әйткән сүзләреңә елмайсам да
Дымландыра һаман күзләрне.
Чыдасам да килгән җәзаларга
Терелмәдем әле мин гел дә...
Ак хыяллар бүләк ит син миңа
Карлар яуган шушы мизгелдә.

---

Нәфисә САБИРҖАНОВА (1964) – *шагыйрә, тележурналист; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия иясе; «Кузгалуы кирәк күңелнең», «Икегә бүленгән гомер» шигырь җыентыклары, күп кенә популяр җырлар авторы. Әлмәттә яши.*

## Кузгалуы кирәк күңелнең

Тагын язам... Димәк, сәбәбе бар,
Бер сәбәпсез шигырь язылмый.
Күңелдәге әйтелмәгән сүзләр,
Җанда яткан хисләр азмыни?!

Азмы әллә үтелмәгән юллар,
Яуланмаган бәхет үрләре,
Хыялдагы сөелмәгән ярлар,
Утырмаган табын түрләре.

Уй-хисләрем бүген туган якта, –
Үз-үземә хуҗа түгел мин.
Язар өчен дә шул сәбәп кирәк,
Кузгалуы кирәк күңелнең.

## Хәерлесен биргән өчен

Булганына шөкер итәм һәрбер кичтә,
Олыгая барган саен һаман яшем.
Кызыктыргыч нигъмәт тулы җир йөзендә
Кунак кына икәнемне белеп яшим.

Аллаһыма рәхмәт укыйм һәрбер таңда:
Һәр мизгелдә минем җанда булган өчен,
Һәр теләгән теләгемне кабул итми,
Хәерлесен генә миңа биргән өчен.

## Оныт һәм истә тот

Вакытлыча гына онытып тор:
Шушы яшькә кадәр киленгәнен,
Борыныңа күзлек эленгәнен,
Иң зур үлчәм күлмәк тегелгәнен!

Һәрвакыттагыча исеңдә тот:
Күңелеңдә ялкын йөртәлгәнең,
Күтәралмастайны күтәргәнең,
Жиргә күпме бәхет китергәнең!

## Миңа әйтәләр

«Син – ныклыкның үзе, ахры», диләр,
Ныклы булмый кая барасың?!
Минем милләт – миңа үзе үрнәк,
Корыч кебек һәрбер баласы.

«Син – ышаныч үрнәгедер», диләр.
Чөнки халкым үрнәк алышлы,
Ышанычын җуймый көрәшкәннәр
Дошман өнендә дә Алишлар.

«Син – өметнең өлгеседер», диләр,
Без түгелме Җәлил онығы?
Үлгәндә дә өметеңне өзмәү –
Алар салган күңел орлыгы.

«Син – сабырлык эталоны», диләр.
Сабырлыкка өнди динебез,
Иманыбыз куша: «Булганына
Шөкерана кылып күнегез!»

Нык һәм сабыр бер мин генә түгел,
Бу сыйфат хас шактый күпләргә.
Татар каны шулай яшәтә... һәм
Ватыт җиткәч илтер Күкләргә.

## Салкын миңа

Карлар ява тышта... Аз булса да
Якты биреп кышкы төнемә.
Әллә нигә туңам, калтыранам,
Җылы җитми минем тәнемә.

Өйдә рәхәт. Тик барыбер өшим, –
Иңдәге шәл әллә юкарган?
Җылытучым йоклый төшләр күреп,
Суынмаган миңа, юк, арган!

Мин үзем дә аңа үзгәрмәдем,
Җанда сөю – буран тутырган.
Тик нигәдер бүген баш миемә
Бозлы уйлар кереп утырган:

«Көртләр ерып аның киләсе юк,
Мин дә көтмим янып буранда...»
Икебез дә өйдә. Салкын миңа.
Карлар гына ява урамда.

## Сакла

Җылы сүзең җанны кочакласын,
Җанны шулай җилдән капласын.
Күңелемә күптән кирәк булган
Хисләр белән мине сакла син.

Яман күздән, кырын карашлардан
Ходай безне үзе якласын.
Кеше күзе төшми торган серле
Урыныңда мине сакла син.

Сөю утың мәңге янсын, димим,
Бүгенгесе чынлап аклансын.
Уйласам да, кабатлана торган
Бәхет белән мине сакла син.

## Тун

Тун алган идем сатып.
Кидем жылысын татып
Тик берничә мәртәбә.
Яз икән ич иртәгә!

Фасыллар гел үзгәрсә,
Кыш шулай җылы килсә,
Кире сатармын тунны,
Алырмын куртка... Унны!

## Төн

Урамда төн. Караңгылык иңгән,
Күләгәләр генә шәйләнә.
Уйлаган уй шомга әверелә,
Гади нәрсә сергә әйләнә.

Билгесезлек ымсындырып дәшә,
Шүрләсәң дә һаман атлыйсың.
Йөрәк тибешеңне ишетәсең,
Төнге тынычлыкны ватмыйсың.

Чыны – ялган, хак – уйдырма була,
Тик яхшыга һаман юрыйсың.
Ни кылсаң да, йолдызлардан башка
Шаһитлар юк, диеп уйлыйсың.

Күрер-күрмәс күзгә бар да алтын,
Эңгер-меңгер барын тигезли.
Парлы үзен ялгыз итеп тоя,
Тиң түгелләр һаман тиң эзли.

Тәмле телләр сөйләп туя алмый,
Ялкын тулы караш ташлана.
Төн үтеп көн туа... Анда инде
Башка төрле ялган башлана.

## Сурәтләр барлаганда

Күңелемне аңлый алмыйм бүген,
Кәефе дә әллә нишләгән.
Утырамын альбом актарып мин,
Эзләп табып өске киштәдән.

Сурәтләргә ияреп хатирәләр
Бер-бер артлы искә төшәләр.
Яшәү – мизгел, бәхет – бер төш икән,
Кунак икән җирдә кешеләр.

Эш коралы тоткан әткәем дә
Безгә сынап карый сурәттән.
Хезмәт сөяргә дә балаларын
Өрләп түгел, мактап өйрәткән.

Әнкәй карый, елмайгандай итеп
(Ирексездән кайнар яшь чыкты),
Зәңгәр күзләр, кара озын толым –
Чибәр булган әнкәй яшь чакта.

Бала вакыт, үсеп килгән чаклар,
Яшьлек – еллар китә тезелеп.
Кем тормышның нигез ташын сала,
Кемнекедер – беткән төзелеп.

## Әти һәм ул

Әти кеше гел яхшыга сөйли,
Әти һаман акыл өйрәтә.
Үгет-нәсихәте, киңәшләре,
Тәнкыйтьләре белән йөдәтә.

Ярый әле, улы бүлдермичә,
Тып-тын гына тыңлый этисен.
Бераздан ул нәкъ үзенчә эшли,
Акыл сатмаганнар әйтерсең.

Искелек һәм яңалыкның бергә
Бәрелеше... Зыян тимәсен!
Кешелекне гомер буе борчый
Ата белән бала темасы.

## Ирләр

Ир гомере яшькә бәйле түгел,
Ак чәч белән бәя бирелми.
Ил язмышы иңнәрендә икән,
Яшь һәм картка ирләр бүленми.

Ир-егетнең яше мөһим түгел,
Егермедән түбән, өстә ни –
Кылган гамәлләре изге икән,
Еллар гына картлык өстәми.

Иярләнгән атлар һәр егетнең
Йөрәгендә ята тугач та.
Ышанычны аклап, саклап була
Малай чакта, бабай булгач та.

Имәндәй нык, кыя таштай каты
Булсалар да ирләр тормышта,
Бар дөньяны җылытырлык хисне
Җанда йөртә алар тумыштан.

## Ул минеке генә!

Назларыннан, иркә сүзләреннән
Мин аңладым сөю барлыкны.
Җаваплылык тоеп күтәрәм мин
«Хәләл җефет» дигән ярлыкны.
Кулны сораганда, йөрәкне дә
Төреп бирдем сөю хакына.
Шатлыктан ул күккә күтәрелде,
Шул көннән мин аның хатыны.
Без икебез бер камырдан хәзер,
Тормыш әвәләде... ни әйтим.
Кәефеннән аңлыйм кичерешен,
Күзләреннән укыйм ниятен.
Ул китерә, мин җиткерә торам,
Җитмәсә дә артык «аһ» ормыйм.
Юрганыма карап, аяк сузам,
Чынга ашмас планнар кормыйм.
Ул сыналган, йөз кат тикшерелгән,
«Ышанам», дип өндәү куялам.
Татлы уйлар белән йоклап китәм,
Тыныч күңел белән уянам.
Ул җитәкләп алып барган юлның
Ташлысы да булды, төзе дә.
Бергә узган гомеребез өчен
Үкенмәсә иде үзе дә.
Без бер җырның ике сүзе кебек –
Бер җырныкы, бер үк көйнеке.
Миңа башка беркем кирәк түгел,
Ул – минеке генә. Ми-не-ке!

## Матур булу сере

Туган якка кайтып кына
Бар газаптан терелэм.
Гади генә күлмәктән дә
Матур булып күренәм.
Бала чактан истә калган
Хыялыма күмеләм.
Күзләр очкынланса гына
Матур булып күренәм.
Җанда җылы кимеп китсә,
Мин кояшка үреләм.
Йөрәктә ут янса гына,
Матур булып күренәм.
Тагын да балкыйсым килсә –
Гашыйк булып тилерәм.
Мин яраткан чакта гына
Матур булып күренәм.



Вахит
Имамов

# МӘҢГЕЛЕК МӨҺАҖИР

ТАРИХИ ДРАМА

Гаяз Исхакый.
Садри Максуди.
Фуат Туктаров.
Корбангали хәзрәт.
Низаметдин хәзрәт.
Әмрулла хәзрәт.
Гариф Кәрими – Варшавадагы «Яңа милли юл» журналы хезмәткәре.
Фуртонен – Финляндиянең чит илләр белән багланышлар министры.
Мильеран – Франция Президенты.
Йозеф Пильсудский – Польша Президенты.
Хәмдулла Сөбхи – Төркиянең мәгариф министры.
Моника – поляк хатыны, фатир хуҗасы.
Сәгадәт Чагатай – Гаяз Исхакый кызы.
Таһир Чагатай – Исхакый кияве, үзбәк.
Ибраһим Дәүләткилде – Ерак Көнчыгышта яшәүче татар егете.
Яшь кыз Оркыя – Ерак Көнчыгышта яшәүче татар кызы.
Мирхуҗа Хәсән – Төркиядә Исхакый ярдәмчесе, элекке совет генералы.
Немец офицеры.
Шәфи Алмас – Германиягә качкан татар бае.
Ике полицейский.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

*1919 ел, Финляндия. Сәхнәнең бер ягында уртача гына байлыктагы эш кабинеты. Чит илләр белән багланышлар министры Фуртонен өстәл янында кәгазьләр караштырып утыра. Икенче яктан берсе –*

Вахит ИМАМОВ (1954) – *язучы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, «Ир канаты», «Татарларның Ватан сугышы», «Утлы дала» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

*җиңенә, икенчесе пальто изүенә ябышкан полицейскийларны иярткән Садри Максуди килеп керә. Кычкырышалар.*

Беренче полицейский. Финляндиянең чит илләр белән багланышлар министры Фуртонен әфәнде офисы бит бу! Сезнең Россия дәүләтеннән килеп, Франциягә виза юнәтә алмыйча йөрүегездә Финляндия министрының нинди катнашы бар?

Икенче полицейский. Җитмәсә, минем маңгайны яра язды бит әле. Әйткән бер сүзне дә аңламый. Россиядәге кызыллар режимыннан чыгып ычкынган бер качактыр инде.

Максуди. Мин – Россия парламентының әгъзасы, үзебездәге министрларның һәммәсе белән дә маңгайга-маңгайны терәп эш йөрткән депутат. Гади полиция участокларының кулыннан килми икән, миңа Финляндия министрының шәхсән үзе кирәк дип әйттемме мин сезгә?!

*Ниһаять, өстәл яныннан кузгалып, министр үзе уртага чыга.*

Фуртонен. Тавыш, тавыш, әфәнделәр. Урынсыз гауганы туктатыгыз әле. *(Максудига текәлә)*. Россиядә властьны үз кулларына эләктереп алган большевиклар Дәүләт Думасын гына түгел, Учредительное собрание депутатларын да куып таратты лабаса. Шулай булгач, кем генә вәкиле дә, Франциягә нинди виза, ди ул? Йә, әфәндем?

Максуди. Безнең татар халкында «Түрә булып алган кемсә чабатасын түргә элә», дигән бик хак гыйбарә бар. Югыйсә әле бер ел элек кенә сез дә, нәкъ татарлар шикелле үк, бер хокуксыз милләт булып яшәп ята идегез. Дәүләт Думасында бер дә туктамыйча нәкъ сез әйткән гауганы туктатмыйча, без хөкүмәттән фин халкына аерым дәүләт булып яшәү хокукын даулап килдек. Ә сез менә бер ел тулар-тулмас элек Россиядән аерылып чыктыгыз да сезнең хокук өчен көрәшкән депутатны да санга санамыйсыз.

Фуртонен. Туганым, туганым, сез Россиянең барча депутатын да бер чыбыктан сөрмәсәгез иде. Ул Думада туктаусыз рәвештә фин халкына мөстәкыйльлек таләп итеп чыгучы кеше бер Садри Максуди гына булды лабаса!

Максуди. Соң, шул Садри Максуди ул мин бит инде, мин, Алла колы!

Фуртонен. Максуди әфәнде үзе? Максуди! Йа Ходаем! *(Максудины кочагына ала)*. Әле 7-8 ел элек үк сезнең хакта күпме җылы сүзләр, матур бәяләр ишеттем, ә менә бер көн килер дә, сезне күрү бәхетенә ирешермен дип, һич кенә дә уйламаган идем. Сез – Думада Россия мөселманнарының хокукларын яклап чыккан бердәнбер көрәшче бит. Сезне Финляндиядә генә түгел, Германия, Польша, Төркиягә килеп төпләнергә өлгергән барча качак Россия мөселманнарының юлбашчысы, хәтта президенты дип тә атап йөртә. 30 миллионлы Россия мөселманнарының юлбашчысы бит сез. Франциягә виза бирүне дә хәл итәрбез, башка үтенечләрегез дә үтәлер. Ләкин болай гына, мәҗлесләрсез, рәхмәтләребезне җиткермичә генә җибәрә алмыйбыз. Мин хәзер үк мәдәният һәм мәгариф министрларына, нәшрият хуҗаларына, язучы һәм журналист халкына хәбәр салам. Бүген халыкны зур бер залга җыеп, мәҗлес үткәрәбез. 30 миллионлы мөселман юлбашчысы хөрмәт нурларында сәламләүгә лаек.

**Икенче күренеш**

*1920 ел, Франция. Сәхнәгә бер яктан – иске-москы киемнәргә төренгән Г а я з  И с х а к ы й һәм чех солдаты киемендәге Ф у а т  Т у к т а р о в, икенче яктан үтә шәп костюм кигән, борынына пенсне аскан С а д р и  М а к с у д и килеп керә. Берәм-берәм кочаклашып күрешәләр.*

М а к с у д и. Ничекләр генә итеп, нинди юллар белән Франциягә килеп җитә алдыгыз, бөркетләрем? Ике ел буена сыңар гына хәбәрегез дә юк иде, әле ярый Прага каласыннан мәктүб юлладыгыз. Шуннан соң гына сездәй аркадашларыма Франция тышкы эшләр министрлыгы аша виза ясата алдым. Һәм менә шушында, Париж уртасында, исән-сау күрешергә насыйп булыр дип кем уйлаган?

Ф о а т  Т у к т а р о в. Әйе, ике ел буе күрешкән юк. Син үзең кай тарафта гаип булып йөрдең, Садретдин?

И с х а к ы й. Унсигезенче елның гыйнварында Уфа каласыннан чыгып качкан идең, шуннан бирле үзеңнән дә бер хәбәр алалмадык. Син менә үзең нинди юллар белән Парижга килеп җиттең?

М а к с у д и. Милләт мәҗлесе исеменнән «Идел-Урал штаты» төзү турындагы фәрманны игълан итүгә үк, Мәскәүдәге комиссарларның түземе корыган шул. Мин фәкыйрегезне кичекмәстән кулга алырга һәм атып үтерергә дигән указ чыгарганнар. Син, Гаяз борадәрем, ул вакытта әүвәл Мәскәүдә «Сүз» газетасын чыгарып яттың, аннары, белүемчә, Мәскәүдән дә качарга мәҗбүр булгач, Казанга кайтып, Болак арты республикасын яклап йөрдең. Ә мин бичарага Уфа тирәсендәге татар авылларында качып йөрергә туры килде. Кайчан, кемнәр килеп эләктерәсен чамалау кыен иде. Яз җитүгә, Нижгар янындагы авылларга күченергә мәҗбүр булдым. Шуннан Питердагы Муса Бигиевка хат юлладым. Ул шәхсән үзе мине алтын прииcкалары хуҗасы Мөхәммәтшакир бай Рәмиевнең кызы Камилә белән кавыштырган кеше ләбаса. Миңа камыт кидерүдә төп гаепче бәндә, гөнаһын юу хакына булса да, мин сукбайга ярдәм кулы сузмыйча калмас, дип өметләндем. Ә Муса хәзрәт гади ахун булып чыкмады. Аның Польша белән Финляндиягә, һәм дә Швециягә яшерен товар ташый торган алыпсатар сәүдәгәрләр белән дә ахирәтлеге үтә көчле икән. Менә шул Муса хәзрәт мине әүвәл Питерга чакырды, ә атна-ун көннән соң яшерен сукмаклар аша Финляндиягә дә чыгарып җибәрде. Аннан инде Франциягә виза алу кыен эш булмады. Ә үзегез нинди Сират күперләре кичтегез соң, Гаяз?

И с х а к ы й. Син менә башта ук Европага чыгып качу ягын карагансың, син – остарак. Ә безгә Себерне генә түгел, барча Азияне җәяүләп үтәргә туры килде. Комиссарлар Казандагы Болак арты республикасын куып тараткач, әүвәл Самарага күчеп, андагы Учредилка комитетында «Идел-Урал» мөхтәриятен танытырга тырышып карадык. Анысы да барып чыкмагач, Уфага күчендек. Ул вакытта Бәләбәйдә мылтык илә коралланган 11 мең чамасы татар илә башкорт солдатлары тупланып тора иде. Аларны Казандагы «Болак арты республикасын» яисә Уфадагы Милләт мәҗлесен яклау өчен күрәшкә үгетләп карасак та, бер файда да булмады, күпчелеге Колчак ягына авышып, Себердә яу йөрде.

Ә Уфага кызыллар гаскәре якыная башлагач, үлемнән котылу өчен без дә Себер тарафына чигендек. Менә шушы Фуат сабакташым тырышлыгы белән татарча шрифтларны капчыкларга тутырып, арбаларга төяп чыккан идек, шуларны сазлыклы юллар буенча этә-этә, Кызылъяр дигән калага юл тоттык. Анда Милләт мәҗлесеннән Ибниәмин Әхтәмов, атаклы Каргалы авылы морзалары нәселеннән Гомәр Терегулов, Чистай төбәгендәге ахун Гыйльман хәзрәт Кәриминең углы, һәммәбез өчен горурлык булган аркадашыбыз Фатихның энекәше Гариф туган, менә Фуат Туктар, янә берничә егет күчеп килгән иде. Шунда әүвәл Кече Милләт мәҗлесе төзегән булып, качак татарларны берләштерү өчен омтылыш ясап карадык, «Маяк» атлы газета нәшер иттек. Аннары Мукден, Хайлар, Харбин калалары аша Владивостокка күчендек. Милләт мәҗлесе безнең өчебезне дә татар, башкорт, кыргыз, казакъ, кыскасы, Рәсәйдәге барча мөселман халкы хокукларын яклау өчен менә монда, Парижда узачак Тынычлык конференциясенә делегатлар итеп сайлады.

М а к с у д и. Монысы шәп. Мәгәр сез ни рәвешле большевиклар тырнагыннан чыгып ычкына алдыгыз? Фуатны карыйм, ялгышмасам, ул әнә чех солдаты шинелен япкан бугай. Алай сарык тиресе ябынып качмыйча мөмкин булмадымы?

И с х а к ы й. Әле ярый, шул чех солдатлары табылды, диң, аларга мең рәхмәт. Шулар фетнә кузгатмаган булса, аларны да сөреп чыгарачаклар түгел иде. Большевиклар әнә шул фетнәдән котылу өчен, аларны пароходларга утыртып, Владивосток аша, урата-урата булса да, кайтарып җибәрделәр. Көч-хәл белән, әнә Фуат шинеле төсле сарык тиреләренә ябынып, һәлак булган чех солдатларының документлары белән аларга ияреп качтык. 56 көн буе коса-коса эчләр актарылгач, Болгариягә китереп бушаттылар, шуннан Прагага кадәр кайтардылар. Чехлар табылмаса, без ул Тынычлык конференциясенә килеп җитәчәк түгел идек. Аптыраган үрдәк күлгә арты белән чумган, ди. Без дә ни кылырга белмәгәч, япон хөкүмәтенә дә, француз консуллыгына, кытайларга да ялварып карадык, берсе генә дә урындыкларыннан егылып төшмәде шул. Татар – дәүләтсез милләт, шулай булгач, башкалар белән тиңләшү дә, тибешү дә читен. «Сан ягыннан аз булганны санга сугучылар аз», дип раслаган бер шагыйрь. Әмма без барыбер чигенмәскә, халкыбызны хөр итү хакына көрәшергә тиеш, башка юл юк.

М а к с у д и. Анысы – иң олы миссия. Менә безне алда көткән Тынычлык конференциясендә дә без аерым, хөр милләт рәвешендә чыгыш ясасак, үзебезне шулай тотсак кына уңышка ирешербез.

Т у к т а р о в. Рус агае әйтмешли, тәк-тәк. Монда, Париж кебек зур мәркәздә сиңа әфәнде дип эндәшергә кирәктер инде, кем, месье Садри. Шуңа әйтәм, син үзеңнең татар халкы исеменнән делегат булып сайлануың турында ишеткән идеңме соң?

М а к с у д и. Телеграф аша Ибниәмин агай гына хәбәр салган иде, артыгын төпченмәдем.

Т у к т а р о в. Синең исемгә язылган делегат таныклыгы минем кулда, кайгыра күрмә берүк, эһем, кем, месье галиҗәнаплары.

М а к с у д и. Таныклык – вак мәсьәлә. Иң мөһиме – зур дәүләт-

ләрнең делегацияләренә дә, ул илләрнең министрлары янына да үтеп керү кирәк. Мин иртәгә конференциягә кыргыз, казакъ, азәри делегацияләре килеп төшәр дип, һич уйламыйм. Димәк, Россиядәге барча мөселман халыкларының тарихын, телен, мәгарифен, йолаларын, барча хокукларын яклау бурычы безнең җилкәгә кала.

И с х а к ы й. Аңлавымча, синең Парижга килеп урнашуыңа бер ел вакыт узган икән инде. Үзеңә ярашлы эш тә тапкансыңдыр?

М а к с у д и. Мине үзем үк укыган Сорбонна университетына кафедра мөдире итеп эшкә чакырдылар. Талибларга хәзер төрки дөнья экономикасы, хәтта күп очракта төрки халыклар тарихы хакында да гыйлем бирәм.

Т у к т а р о в. Имәндә икән чикләвек! Син, валлаһи, французлар арасында месьеларның асылына әйләнеп беткәнсең бит.

М а к с у д и. Алай ук түгел-түгелен, мәгәр чит ил кубызына да биемичә булмый. Башым мәгърур дип, баш белән таш яру ахмаклык буладыр ул. Һәм, менә, нәкъ вакытында искә төшердең, миңа университетка ашыгырга кирәк. Талибларга бүген дә өч сәгать лекция укыйсым бар.

И с х а к ы й *(йөзе кара көйгән)*. Син, без килде дип, майлы калҗадан коры кала күрмә. Сукбай кеше – урам эте кебек, иснәнеп йөри-йөри, сөяк тапмый калмас. Безгә үз көнебезне үзебез күрү язган. Тынычлык конференциясе корольләр утары булган Версаль сараенда уза дип ишеттек. Шунда күрешкәнгә кадәр саубуллашыйк. Бигайбә, кем, пишкадәм Садри кордаш. Бездәй сукбайлардан бер адым алдарак баручы икәнлегеңне янә бер тапкыр расладың, афәрин үзеңә.

**Өченче күренеш**

*1920 ел, Париж. Президент кабинетының ишек төбе. Кабинетта бик эре кыяфәттәге түрә утырганы күренә, ә ишек катында Г. И с х а к ы й белән Ф. Т у к т а р о в таптана, шунда ук С. М а к с у д и килеп керә, эчкерсез күрешәләр. Хәзер инде Исхакый белән Туктаров та шәп киемнән.*

И с х а к ы й. Аллага шөкер, нәкъ вакытында килеп җиттең, Садретдин сабакташ, афәрин. Берничә минуттан безне Франция Президенты Мильеран кабул итәргә тиеш, ә төштән соң Англия белән Америка делегацияләре көтеп тора.

М а к с у д и. Һәммәбезгә дә хәерле көннәр вә уңышлы сөйләшүләр насыйп була күрсен. Сез Париждагы вазгыятькә мин көткәндәгедән дә җитез ияләнеп өлгердегез. Суда батмый, утта янмый торган бөркетләр сез, афәрин, сабакташлар.

И с х а к ы й. Салпы якка салам кыстырыштык, инде эшкә тотыныйк. Син – безнең президент бит, әйдә, алдан атла, месье Максуди галиҗәнаплары.

*Ишек аша кабинетка узалар. Франция Президенты М и л ь е р а н кәгазьләрен калдырып, урыныннан тора, кул биреп, татар вәкилләрен сәламли.*

М и л ь е р а н. Хәерле көн, рәхим итегез, кунаклар! Миңа ясалган рапорт буенча сезне Россиядә яшәүче мөселманнар вәкиле дип беләм. Арттырып әйтмәганнәрдер инде, арагыздан берегез анда Америкача аерым штат төзергә

җыенган мөселманнар президенты да шикеллерәк.

Исхакый. Илбаш тиешле әфәндебез менә шушы инсан булыр, президент галиҗәнаплары. Без бичараларыгыз фәкать делегация вәкилләре генә. Ягъни мәсәлән, татар-башкорт, мари-чуваш, кыргыз-казакъ халыкларының сезнең тарафка вәкаләт биреп озатылган делегатлары булабыздыр, тәкъсир.

Максуди *(пышылдап диярлек Исхакыйга эндәшә)*. Ул татар яки башкортларның кемнәр икәнлеген ялгыш кына да белми, шуңа күрә артык бил бөкмәсәң дә була, Гаяз тәкъсир. *(Мильеранга таба борыла)*. Без – конференциягә дип, махсус озатылган мөселман делегатлары. Озакламый сез барча ил, шул исәптән Россия вәкиллекләре белән дә очрашулар үткәрә башлаячаксыз. Шул нияттән сез галиҗәнапларга аерым гозерләр бар.

Мильеран. Мин тыңларга әзер, рәхим итә күрегез.

Максуди *(Исхакыйга)*. Син – татар әдибе, галиҗәнап Тукай хәзрәтләре әйтүенчә, милли юлбашчы да. Халык күңелен, аның җанын синнән дә остарак вә нечкәрәк итеп ачып салучы булмас. Шуңа күрә, әйдә, син беренче булып җиткер. Мин тылмачлап барырмын.

Исхакый. Сез әлеге Тынычлык конференциясе буенча декларация кабул итәргә һәм киләчәктә илләр арасындагы сәясәтне дә билгеләп куярга омтыласыз, димәк, үзара мөнәсәбәт ярларын да тәгаенләп чыгачаксыз инде. Әмма килешү төзү өчен әзерләнеп килгән һәрбер дәүләт, иң беренче чиратта, үз илендә өстенлек итүче милләт мәнфәгатьләрен генә истә тотар сыман. Һәм дә байтак дипломат вә илчеләрнең, әйтик, Россия империясе составында яшәгән татар, башкорт, чуваш, мари, казакъ, азәри, кыргыз, бурят, чукча, төрекмән, якут, үзбәк һәм тагын дистәләгән «вак милләтләр» мәнфәгатен күз чалымына китереп сөйләшүе бик икеле. Ә сез, Җир шарында тынычлык төзүне яклаучылар, менә шул тарафны иң беренче игътибар угына алырга тиеш кебек. Беребез дә сукыр түгел, яхшы беләбез: соңгы елларда Америка хөкүмәте колонизация чорында кырып бетерә язган индеец кабиләләренең хокукларын тулысынча таныды, аларга китергән зыян өчен гафу да үтенде сыман. Алар бүген барча Җир шарына үрнәк. Ә бик күп илләрдә, әйтик, Мисыр, Алжир, Марокколарда әле һаман колониаль режим дәвам итә. Инглизләр – Согуд Гарәбстаны белән Һиндстанны, португаллар Мадагаскар белән Көньяк Америка дәүләтләрен талый. Тагын да аянычрагы – португал яисә инглиз хөкүмәтләре җирле халыкларның мәнфәгатен күз чалымына да китерми. Аларда милли мәктәпләр ябылган, милли китаплар гомумән нәшер ителми. Берсенең дә милли театрлары вә сәнгать ансамбльләре юк. Баскын көч ул илләрдә фәкать португал яки инглиз мәктәпләре ачып бетергән һәм хәзер алар колонияләрдәге барча мөселман, һинд вә негр балаларының да аларга чит-ят булган телдә укуын таләп итә...

Максуди *(пышылдап һәм итәгеннән тартып, Исхакыйны туктатырга тырыша)*. Син кирәкмәс сукмакка салулап кердең, тукта, Гаяз. Ул үзе үк баскыннарның бер башлыгы лабаса, синең зарны ничек аңласын, ди? Үзебез турында гына сөйлә инде, әйдә.

Исхакый. Эһем-эһем. Ярар, мин, Россия вәкиле буларак, моңа күз йомдым, ди. Ләкин минем үз илемдә, иге-чиге күренмәгән Россия империясендә дә шул ук хәл бит. Мин нахак яла якмыйм, Россиянең теләсә кайсы милләт вәкиленнән сораша аласыз. Бездә ар халкының, мәсәлән, сыңар гына да югары мәктәбе юк. Тагын дәвам итсәм, башкорт, якут, мукшы, кыргыз, төрекмән, мари, бурят милләтләре дә югары мәктәпнең ни икәнен дә белми. Ярар, менә без, татар милләте, XII-XIII гасырларда ук университетлар тотканбыз. Хәтта әле патша изүе астында калгач та, безнең бабайлар югары белем бирүче гимназияләр ачуга ирешкән. Алардан тыш, безнең бабайларның Каһирә, Бохара, Сәмәрканд, Мәдинә калаларындагы мәдрәсәләрдә җаннары теләгән белемне алырга форсатлары булган. Әле моннан ун-унбиш ел элек кенә безнең Иж-Буби, «Галия», «Госмания», «Мөхәммәдия», «Камалия» кебек, университетларга биргесез мәдрәсәләребез бар иде, тик аларның барчасын да ябып бетерделәр. XX гасырда өр-яңадан тәре походына кузгалдылар, диярсең, ябылган мәдрәсәләр урынына большевиклар хәзер күпчелек фән рус телендә укытыла торган «сәүвит» мәктәпләре ачып куйды. Билгеле ки, барча укыту программалары мөселман балаларыннан яңа комиссарлар әвәләп куюга юнәлтелгән. Менә, безнең Россия дәүләтендәге Дәүләт Думасы депутаты булып торган Максуди әфәндебез, мөнбәргә йөз тапкыр бәреп чыга-чыга, мөселман халыкларының хокукларын якларга тырышты. Хәер, мин нечкәлекләренә кермим, ул депутат бит, үзе бәян итсен.

Мильеран *(баш чайкап)*. Оһо, депутат! Ә сез моңа ничек ирештегез? Коллегагыз аңлатуынча, сез – изелгән халык вәкиле түгелме соң?

Максуди *(әүвәл – французча, аннары инглизчә бер-ике җөмлә әйтә)*. Мин – миллионлаган татар милләтенең бик тә сирәк бер вәкиле булып, Парижның Сорбонна университетын тәмамлау бәхетенә ирештем. Россиягә әйләнеп кайткач, мине кадетлар партиясе бик тиз үз итте һәм, шул партия исемлеге буенча, Дәүләт Думасы депутаты булып та тора алдым... Әмма үзегезгә дә мәгълүм – тормышта бер генә җиңү дә көрәшсез генә яуланмый. Мин фәкыйрегезгә дә мөселман халыкларының хокукларын яклап, йөз мәртәбә Дума мөнбәренә менәргә туры килде. Менә шул йөз мәртәбә кычкырып даулый торгач, мәгариф турындагы законга татар, үзбәк, азәри, казакъ, кыргыз, төрекмән кебек мөселман балалары өчен, «башлангыч белемне алар фәкать туган телләрендә генә алырга тиеш», дигән төзәтмә кабул иттерүгә ирештем. Мактану өчен әйтмим, моннан тыш, тагын хәрби законга «Россия мөселман илләренә каршы сугыш игълан итсә, анда Россиядәге мөселман солдатлары катнашырга тиеш түгел», дигән төзәтмә керттердем. Һәм мин моны зур гаделлек дип саныйм, чөнки мөселман солдатының икенче мөселманга каршы мылтык тотып сугышуы – зур җинаять...

Мильеран *(башын чайкый)*. Ә сез герой, валлаһидыр, герой! Сезнең янәшәдә дәүләт акчасын бушлай сосып утырган депутатларга мең кат гыйбрәт!

Максуди. Шунысын да әйтү урынлыдыр, фин халкын мөстәкыйль

дәүләт итү өчен көрәштән дә мин фәкыйрегез читтә кала алмады.

М и л ь е р а н. Фин халкы мөстәкыйль дәүләтле милләт булырга тиеш иде, моңа өлеш кертүегез өчен сезгә мең-мең рәхмәт.

М а к с у д и. Ләкин менә ун ел элек без ирешкән уңышларга юкка чыгу куркынычы яный. Мулланур Вахитов атлы бер комиссарыбыз мөселман илләре өчен интернационал төзергә омтылып караган иде дә, аны Казан Кремленең диварына терәп юк иттеләр. Икенче төр әйдәманнарны Мәскәүдәге өч тиенлек кәнәфиләр хакына үз якларына аудардылар. Үз хокукларыбызны аяк астына салып таптамасыннар өчен, безне өр-яңадан усал көрәш көтә. Әгәр күн итек астында калган милләтләрне башка илләр яклап чыкмаса, без бетәбез. Россия дилбегәсен үз кулларына эләктереп алган большевиклар хәзер, артларына ут капкандай, башка илләр белән дуслык килешүе төзергә, шул юл белән үз хакимиятләрен саклап калырга ашыга. Минем аркадашым Гаяз әфәнде Исхакый бик тә дөрес әйтте, яңа хөкүмәт белән өстәл янына сөйләшүләргә утырган чакта ук сезнең инде үз кыйблагыз һәм үз таләпләрегез тезеп салынырга тиеш. Безгә Америка индеецлары кебек юкка чыкмас өчен сезнең яклау, сезнең терәк кирәк!

И с х а к ы й *(ярсып, урыныннан ук сикереп тора)*. Мөселманнар – большевиклар төзегән җәмгыятьтән чүплеккә чыгарып ташланырга тиешле иске чүпрәк яки тишек башмак түгел! Без заманында Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Себер, Кырым, Касыйм ханлыкларын тоткан милләт. Башка президентларга да шуны җиткерегез! Без үз белдегебез белән генә йөрүче бушбугазлар да, булдыксыз йә томана милләт тә түгел. Без – утыз миллионлы мөселман депутатлары! Без дә үз җиребездә, үз телебездә сөйләшеп һәм үз телебездә сайрашып гомер итүгә лаек!..

М и л ь е р а н *(урыныннан тора)*. Барча таләпләрегез дә анык, аңлаешлы һәм законлы. Сезнең үтенечне башка делегация башлыкларына да җиткермичә калмам. Россия хөкүмәте килешү төзергә тәкъдим итә икән, сезнең таләпләрегез дә күз уңында булыр. Мин сезгә сокланам. Хәерле юл сезгә!..

**Дүртенче күренеш**

*1922 ел, Берлин вокзалы. Яхшы костюмнар кигән, кулларына чәчәк бәйләмнәре тоткан И с х а к ы й һәм Ф у а т Т у к т а р о в әрле-бирле йөренә. Бермәлне бер яктан хатыны К а м и л ә не кочагына кыскан С а д р и М а к с у д и һәм чәчләре өстенә калфак көйләп куйган япь-яшь С ә г а д ә т килеп керә. Сәгадәт шундук йөгереп килеп, Исхакыйның кочагына сеңә.*

С ә г а д ә т. Әти, әтием, бәгырькәем! Синең белән күрешер көннәр дә бар икән. Унсигезенче елның май аенда Яуширмәдә бабакай йортына төнлә генә кереп чыкканнан бирле, без синең хакта бер генә төпле хәбәр дә алмый яшәдек бит.

И с х а к ы й. Кызым, кызыкаем! Җаным, бердәнберем! Инде синең белән күрешә алуыма, сине кайчан да, ничек тә күрә аласыма өметемне өзеп бетерә язган идем.

С ә г а д ә т. Садретдин абыйга рәхмәт укы да, Муса хәзрәт имин-

леге хакына дога кылырга онытма, әтикәем.

М а к с у д и. Минем тырышлык бер мыскал гына биредә, тырнак очы кадәр генә, дустым. Мондый хыялда да була алмас очрашу-кавышулар өчен Муса ахун Бигиев хәзрәтләренә рәхмәт яңгыры яусын! Үзе ахун, дин эшләре белән идарә итәргә тиешле инсан югыйсә. Бактың исә, әллә ничә җөмһүрият сәүдәгәрләре илә уртак тел таба белә.

Ф у а т  Т у к т а р о в. Муса хәзрәтне контрабандистлар белән әвәрә килеп гомер итә, дисәң, комиссарлар кәнәфиләреннән егылып төшәр иде.

М а к с у д и. Алай ук димә инде, кордаш. Муса хәзрәтнең абруе бизмәннәрдә үлчәп бетерә торган түгел, һәркемгә сүзе үтә, менә нидә хикмәт!

И с х а к ы й. Әйе, абруе зур, үлчәп бетергесез.

М а к с у д и. Менә ул үзе һәм аның курку белмәс йөрәге булмаса, без газизләребез белән өр-яңадан күрешү бәхетенә ирешер идекмени?!

К а м и л ә. Күрешү түгел, кавышу диген, җаным! Ул безгә өр-яңадан никах укыгандай булды.

И с х а к ы й. Берсе – Парижда, икенчесе Казан тарафында яшәп яткан ике яр өр-яңадан кавышсыннар әле. Валлаһи, әкият бу!

С ә г а д ә т. Садретдин абый Париж каласында яши, талиб илә талибәләргә югары гыйлем бирә, анысын аңлап өлгердек. Ә син кайда гомер чигәсең дә, нинди ризык белән тукланасың, әткәй? Син берчакта да тазара белмәдең, мәгәр хәзер тагын да ябыккансың шикеллерәк. Шуңа эчем поша.

И с х а к ы й. Мин бирегә, Берлинга килеп төпләндем әле, кызыкаем. Бик озакка түгелдер, шәт. Берлин каласы да, нәкъ Париж, Хельсинки, Истанбуллар төсле, Рәсәй качаклары илә шыплап тулган. Чит илләргә чыгып качкан мөһаҗирләрнең гомум саны ике миллионнан артып киткән инде. Менә Гумбольдт университетында гына да илдән качып котылган кырыкка якын мөселман талибе гыйлем ала. Әле Берлинның башка университетларында, Мюнхен белән Дрезденда да йөзәрләгән татар яшьләре бар. Шул талиблар монда «Туран» атлы оешма төзеп куйган. Аларга юл күрсәтүче остаз шикеллерәк бер өлкән дус җитми. Менә мине дә мөгаллимнәре рәвешендә Берлинга чакырдылар. Алар белән бергәлектә Алманиядә татарча бер газета яки журнал нәшер итү җаен табу турында да уйлашабыз.

С ә г а д ә т. Алар кемнәр соң? Татарлар яки азәри, кыргызлармы?

И с х а к ы й. Син алар белән үзең дә иркенләп таныша аласың. Алай-болай, бавыл-төенчекләр күтәреп барырга кирәк булса дип, мин аларны да эндәшеп куйган идем.

*Исхакый кул чабып хәбәр бирүгә үк, уртага  и к е  е г е т  уза.*

И д р и с и. Әссәламегаләйкүм, миһман-кунакларымыз! Берлин җирендә үз туганнарыбызны күрүгә чиксез шатбыз.

*«Әссәламегаләйкүм, Максуди әфәнде», «Камилә ханым», «Сәгадәт туташ», дип сәлам алышулар яңгырый.*

И д р и с и. Мин үзем – Берлин янындагы Кинан бистәсендәге мәчеттә имам ярдәмчесе Галимҗан Идриси хәзрәтләре булам, бер үк вакытта университетта да гыйлем

эстим. Бабаларымның туган нигезе буенча Ырынбур ягыннан. Менә монысы – үзбәк егете Таһир Чагатай.

Ч а г а т а й. Үзбәк егете дигәннәре менә мин инде ул. Сездәй чибәр кызны үз янәшәмездә күрә алу бәхетенә чиксез шатбыз.

*Сәгадәт белән Таһир Чагатай бер-берсенә карап елмая, аннары Таһир Сәгадәтнең төенчекләрен тотып, янында торып кала.*

И д р и с и. Без дә герман тормышына ияләнеп бетә алмыйбыз әле, мисалга, шәхсән үзем Берлинга ике ел чамасы элек кенә килдем. Мин фәкыйрегез дә, Чагатай да немец телен камил өйрәнү өчен Гумбольдт университетына талиб булып кердек. Хәер, гомер алда, һәммәбезгә дә иркенләп танышырга форсат чыкмый калмас. Хәзер Европада безгә бер-беребезне югалтмыйча яшәү отышлырак.

**Бишенче күренеш**

*1925 ел, Анкара. Төркиянең мәгариф министрлыгы бинасы. Зур кабинетта С. М а к с у д и белән мәгариф министры Х ә м д у л л а  С ө б х и утыра, яннарына Г. И с х а к ы й белән Ф. Т у к т а р о в килеп керә.*

И с х а к ы й. Әссәламегаләйкүм, министр Хәмдулла галиҗәнапләре!

С ө б х и. Әссәламегаләйкүм! Хуш килдегез, татар борадәрләр!

М а к с у д и. Сәлам сиңа, сәлам, Гаяз сабакташым! Сине дә хәерле килеп төшүегез белән, Фуат кардәш! Берлинга киттегез дә югалдыгыз, юньле-рәтле бер хәбәр дә сала белмәдегез.

Т у к т а р о в. Син Гаязның тумыштан гыйсъянчы икәнен беләсең лә инде, ул сугышмыйча гына яши беләмени? Аның төп «ахирәте» Зәки Вәлиди Төркестан, Пакистаннар аша урый-урый, Берлин каласына килеп төшкән иде, Гаяз якташ аның лекцияләрен барып тетә-тетә, башына күсәк белән суккандай итеп, койрык кысарга мәҗбүр итте үзен.

М а к с у д и. Һай, Гаяз дус, син һаман да ярсыган үгез, йә булмаса, мөгезсез сыер сыман, сөзешмичә бер дә тора алмыйсың. Син хәзер кырык бишне тутырдың бит инде, аз булса да басылырга вакыт. Без Төркиянең мәгариф министры кабинетында басып торабыз бит, шуны онытмагыз. Хуҗа якның тәкъдиме бар сез галиҗәнапларга. Әйдә, аны тыңлыйк.

С ө б х и. Сез Максуди әфәндене безнең президентыбыз Мостафа Кәмал шәхсән үзе Франциядән Төркиягә чакыртып китертүе турында беләсездер, дип уйлыйм, борадәрләр. Максуди бәй хәзер Президентыбызның уң кулы яки иң зур ярдәмчесе дип атасам да, урынлы. Менә шул Президентыбыз фәрманы буенча, без һәммәбез дә төрек телен һәртөрле алынма сүзләрдән, чит илдән үтеп кергән кыргаяклар төсле микроблардан чистартырга тиеш. Монда беренче роль, әлбәттә инде, матбугат чараларына, шул җөмләдән безнең министрлык тарафыннан гамәлгә куелган газета-журналларга да юнәлтелә. Максуди әфәнде сезнең уттай кайнар һәм энә очыдай үткен каләм иясе булуыгызны тасвир кылды, ә без сезне «Төрек йорты» журналына иң төп авторларыбызның берсе итеп чакырырга булдык.

И с х а к ы й. «Төрек йорты» – тулысынча безнең борадәребез Йосыф Акчура журналы иде бит. Бу Йосыф бәйне каядыр этәреп кую була түгелме соң?

С ө б х и. Акчура бәйгә Президентыбыз яңа бер эш йөкләде. Төркиядә тарихчылар җәмгыяте бөтенләй юк, Акчура бәй белән сезнең ахирәтегез Максуди бәй тиз арада тарихчылар корылтаен әзерләргә тиеш. Шул сәбәпле «Төрек йорты» журналы тулысынча сезнең җилкәгә кала.

И с х а к ы й. Ә Фуат бәй?

С ө б х и. Фуат әфәндене без Казан университетын тәмамлаган адвокат буларак та беләбез, аңа аерым тармак бирергә уйлап торабыз, ул мәгариф челтәрендәге барча китапханәләр эшен җайга сала алыр. Сүз дә юк, сезнең һәр икегезгә дә бер-ике атна эчендә төрек гражданлыгы, төрек паспортлары гына түгел, яшәү өчен тораклар да бирелер. Хезмәт хакы түләү ягыннан да сезне рәнҗетмәбез. Сорауларыгыз бармы?

И с х а к ы й. Сез сорауларга урын калдырмадыгыз сыман, Хәмдулла бәй.

Т у к т а р о в. Тәкъдимегез өчен бик зур рәхмәт, министр галиҗәнаплары...

*Һәммәсе дә чыгып китә. Ут янып сүнә. Берникадәр пауза. Шул ук кабинетка ярсый-ярсый министр С ө б х и килеп керә, берничә мизгелдән ишекне ачып, сәркатибенә әмер бирә.*

С ө б х и. Минем карамакка ашыгыч рәвештә Гаяз әфәндене чакыртыгыз. Кайсы Гаяз, дип, теге, «Төрек йорты» журналында эшләүче Исхакыйны инде.

*Аптыраганрак кыяфәттә И с х а к ы й килеп керә, Сөбхи аңа ябырыла.*

С ө б х и. Максуди әфәнде тәкъдименә ышанып, мин сезне Берлиннан кадәр чакыртып китердем, кул астыгызга журнал кадәр олы журнал бирдем. Ә сез нишләп аның битләрен төрек телен чит ил алынмаларыннан чистарту түгел, ә Төркиядән ике мең чакрым арада яткан Россиядәге большевиклар властеның тетмәсен тетү белән тутырасыз соң?

И с х а к ы й. Нинди язма турында төртеп әйтәсез соң, конкрет ачыклагыз. Кайсы язмада мин большевикларның тетмәсен теттем икән?

*Сөбхи өстәлдә яткан 2-3 данә журналны кулына алып болгый.*

С ө б х и. Менә, Президентыбыз Мостафа Кәмал шәхсән үзе җөмләләреңнең асларына сыза-сыза, өтеренә кадәр укып чыккан. Менә бу мәкаләдә «большевиклар фиркасенең Россия мәмләкәтендә яшәүче йөзәрләгән милләт өчен аерым сәясәте юк, мәгариф кануннарының һәммәсе дә аз санлы милләтләрне йоту максатына гына юнәлтелгән», дигән җөмлә өчен Президентның җен ачуы чыккан. Яки тагын, «Россиядәге большевиклар фиркасе җитәкче постларга намзәтләр сайлаган вакытта фәкать русларны гына югары кәнәфиләргә утырта, ә татар, кыргыз, казакъ яки бурят вәкилләренең ялгыш кына да Үзәк Комитет сәркатибләре, шул аппараттагы бүлек мөдирләре яки кайсыдыр тармак министрлары булып сайлана алганы юк». Һәм соңгысы: «Барча күрше дәүләтләрдә коммунистлар фиркасе оештырып, Россия комиссарлары алар ярдәмендә бар җиһанга хуҗа булып алырга әзерләнә». Йә, Исхакый әфәнде, шушы да җитмәдеме? Ә төрек журналының, аеруча мәгариф буенча тәрбия чаралары үткәрүгә алынган

матбаганың Россиядәге хакимиятне тикшерергә, андагы большевиклар фиркасен эттән алып этkә салырга нинди хокукы бар? Йә, аңлат син, аңлат, Гаяз, Алла колы! Мин сине ике дәүләт арасын бутап яту өчен Берлиннан тикле чакырып кайтардыммыни? Менә болай итеп Төркиянең битенә төкергән өчен син үз сабакташың, ватандашың Максуди әфәнде йөзенә нинди күзләр белән карарсың соң?

*Исхакый бер сүз дә җавап кайтармыйча, башын түбән иеп чыгып китә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Алтынчы күренеш

*1930 ел, Варшава. «Яңа милли юл» журналы редакциясе. Түрдәге өстәл янында Исхакый, аннан беркадәр читтәге өстәлләр янында хезмәткәрләр, араларында С ә г а д ә т белән Т а һ и р Ч а г а т а й утыра. Ишектән йөгереп диярлек журналның сәркатибе Г а р и ф К ә р и м и килеп керә.*

Г. К ә р и м и. Гаяз, Гаяз абый! Менә, типографиядән мин «Яңа милли юл»ның тәүге нөсхәсен алып кайттым. Безнең үз журналыбыз «Яңа милли юл» бар!

*Исхакый да сикереп торып, журналны кулларына ала.*

И с х а к ы й. Сөбханалла! Җиңү бит бу, җиңү! Без чит илдә тәүге мәртәбә үз матбагабызны булдырдык, аңа сулыш бирү бәхетенә ирештек. Яңа туган сабый бала бит бу, сабый бала!

С ә г а д ә т. *(Әтисен килеп кочаклый)*. Зур җиңүең белән котлыйм, әткәй! Ә мин бит синең җиңәсеңә, батып калмасыңа шикләнмәгән идем. Исхакыйныкылар юкка чыга торган токым вәкилләре була аламыни?!

*Таһир Чагатай килеп, Исхакыйның каршына баса.*

Ч а г а т а й. Котлыйм үзегезне, Гаяз әфәнде! Сезнең җиңү Сәгадәт белән икебезгә дә бердәй шатлык.

И с х а к ы й. *(Елмаеп)*. Тукта-тукта! Син нишләптер каймак ялаган мәче төсле сәер елмаясың. Әллә миңа каршы берәр төрле этлек уйладыңмы, йә, Таһирҗан?

Ч а г а т а й. Сезгә каршы этлек әзерләргә кемнең генә кыюлыгы җитәр икән, әфәндем? Моның өчен ике башлы булып туу кирәк. Әле алай да таптап узачаксыз. Ә мин менә сез кичергән шатлык өстенә тагын бер нур өстәмәкче булдым. Мин дип, бер ялгызым гына түгел инде, кызыгыз Сәгадәт белән бергәләп. Мин сездән кызыгызның кулын сорарга батырчылык итәм. Без Сәгадәт белән бер-беребезне чынлап та яратабыз.

*Таһир Чагатай янына Сәгадәт килеп баса. Алар кочаклаша. Исхакый күзләрен куллары белән каплап, акрын гына елый.*

И с х а к ы й. Йа Ходаем, минем дә шушы бәхетне кичерәсе көннәрем булыр икән! Каторгаларда газап чиккән, жандармнардан качып йөргән чакта мин шушы бәхетле көннәргә кадәр яшәү турында уйлый алдыммыни?

Ч а г а т а й , С ә г а д ә т. Без синнән кечкенә генә туй мәҗлесе ясарга фатиха бирүеңне сорыйбыз, әткәй.

И с х а к ы й. Мин риза-бәхил, балалар, бәхетле була күрегез. Берүк Ходай Тәгалә сезне мин кичергән газап-җәфалардан саклый күрсен, амин!

*Ике сакчы солдат озатуында бүлмәгә Польша Президенты Й о з е ф П и л ь с у д с к и й килеп керә. Һәммәсе дә шәм урынына катып кала.*

П и л ь с у д с к и й. Миңа эчке эшләр министры, татар әдибе, татар милләтенең рухи юлбашчысы Гаяз Исхакый галиҗәнаплары шушы йортта өр-яңа журнал чыгарып ята, дип язган рапорт керткән иде. Мин адресны бутап ялгышмадым, дөрес кердемме, мөхтәрәм әфәнделәр?

И с х а к ы й. Йозеф, синме? Безнеңчә итеп, авыз тутырып әйткәндә, Йосыф Пильсудский үзе түгелме соң?

П и л ь с у д с к и й. Үзе, үзе, күзләреңне тутырыбрак кара. Исәнме-саумы, каторжан көрәштәшем?

*Икесе дә бер-берсен кочагына ала, шап-шоп күрешәләр.*

П и л ь с у д с к и й. Гаяз, Гаяз, Архангел һәм Пинега каторгаларын бергә кичкән дустым.

И с х а к ы й. Йа Ходаем, бу кадәр дә юмарт вә киң күңелле була белерсең икән! Әле яңа гына кызым белән киявем кавышуга фатиха биргән идем, ә монда Польша Президенты Йозеф Пильсудский галиҗәнаплары каторжан Исхакый качып яткан ояга шәхсән үзе килергә түбәнчелек итте. Йа Ходаем, ошбу миһербанлыгыңнан аера гына күрмә?

П и л ь с у д с к и й. Шәхсән үземнең сине күрергә килүем ул кадәр сәермени? Ә син, каторжан Гаяз, каторжан Йозефны Польша Президентына әверелер дип күз алдыңа китерә ала идеңме соң?

И с х а к ы й. Нинди президент булу турында хыяллану, ди ул? Без бит анда кайдан бер сынык икмәк табу яисә туйганчы бер ашау турында хыяллана идек. Ә тәкъдир дигәннәре сиңа карата миһербанлы булган. Кичәге каторжанны бүген Президент итеп күрү үзе әкият бит ул!

П и л ь с у д с к и й. Мәгәр, менә мин синең каршыңда басып торам. Сине дә, әлбәттә, исән-сау көенә күрә алуыма чиксез шатмын. Үзең әйтмешли, берүк, мине оныта, ташлый күрмә, минем кабинет ишекләре синең өчен һәрчак ачык. Мин синеке, Гаяз.

И с х а к ы й *(елмаеп)*. Бер каторжан кешегә икенчесе янына кул сузып бару килешеп бетәр микән?

П и л ь с у д с к и й. Менә, дөресен әйт әле, журнал чыгару өчен акча теләнеп, кемнәр каршында йөз суыңны түгеп йөрдең инде?

И с х а к ы й. Аптырама, бай татарлар байтак илләрдә бар. Финляндия татары Мөхәммәтҗан агай икейөзлеләнми ярдәм итә. Германиягә Оренбурдан качып килгән Шәфи Алмасның да, мин сораганда, артын куйганы юк. Төркиядә Әхмәтвәли Мәңгәр атлы зур сәүдәгәр яши. Америкада да Хәмит Рәшит атлы бер бай татар барча дөнья буйлап сәүдә итә. Шулай кармаштырам.

П и л ь с у д с к и й. Минем яныма акча соранып килүең бик икеле, син – бит горур бәндә. Менә шуны алдан күрәзәләп, үзем сиңа бер сумка акча төяп килдем. Үзең алырга кыенсынасың икән, әнә кызың белән кияwең туена миннән бүләк булыр.

И с х а к ы й. Син, валлаһи, аяктан егасың мине. Рәхмәт сиңа, Йозеф!..

**Җиденче күренеш**

*1934 ел, Япониянең Кобе каласындагы мәчет каршына бер төркем татар тезелеп баскан. Яшь е г е т һәм к ы з л а р иярткән И с х а к ы й килеп керә.*

И с х а к ы й. Аллага мең шөкер, Харбин каласында да «Милли байрак» атлы газета чыгаруны җайга сала алдык. Әле ярый, Фуат Туктаров атлы аркадашым Петропавел-Кызылъярдан күченеп киткән чакта Уфадан ук төяп килгән татар шрифтларын үзе белән алырга иренмәгән. Ул чагында Кызылъярда «Маяк» атлы газетаның ике-өч санын чыгарудан ары уза алмадык. Ә менә хәзер Казан каласыннан фәлән мең чакрымда да өр-яңа бер татар газетасын эшләтеп җибәрдек бит.

И б р а һ и м Д ә ү л ә т к и л д е. Харбин каласын, тутырыбрак нәтиҗә ясаганда, барча Кытайда яшәүче татарны матбагалы итү зур сөенеч. Мәгәр Токиодагы татар телендә чыга торган «Япон мөхбире»н кулыбызга ансат кына төшерә алмабыз сыман. Аның мөхбире, өстәвенә Токиодагы бер мәчетнең мөгътәсибе булып торган Корбангали хәзрәт байтак еллар буе татар әйдәманнарына каршы этлек кылып ята. Аның язмаларына ышансаң, Токиода ахун вә Җәмигъ мәчетның баш имамы булып саналган Габдерәшит Ибраһим хәзрәтләре дә японнар арасына коммунистлар тарафыннан махсус җибәрелгән, ул «кызыл хаҗи», имеш. Сез дә, Исхакый хәзрәтләре, барча төрки халыкларны күмәк бер дәүләткә берләштереп, Япония, Кытай, Франция, Россияләрнең һәммәсенә каршы сугыш игълан итәргә җыенасыз икән, янәмәсе.

И с х а к ы й. Оһо, хыял диңгезендә шәп йөзә бу!

И б р а һ и м Д ә ү л ә т к и л д е. Хыял гына түгел шул, Исхакый әфәнде. Японнарның «Чиугай» газетасына язып, ул сезгә «Россиядәге коммунистлар фиркасенең яшерен агенты» дигән кләймә дә сугып өлгерде. Бөтенләй дә нигезсез булмасын өчен сезне җир йөзендә булмаган төрки дәүләтнең булачак императоры дип хәрәкәләүдән дә тартынып тормаган. Имеш, сез Россиядән Ерак Көнчыгышка качкан барча татарларны Кытай илә Япониядән аерып, яңа бер төрки дәүләт төземәкче. Имеш, сезгә мондый миссияне Россиянең большевик комиссарлары тагып җибәргән дә, сез шуны тормышка ашыру максатыннан, качаклар тупланган барча кытай илә япон калаларын айкап йөрисез, татарларны гына түгел, барча мөселманнарны үз тарафыгызга аударасыз, ә ахыр чиктә, билгеле ки, сез яңа дәүләтнең ханы булачаксыз. Әмма япон хөкүмәтендә сәер, без әлегәчә төбенә төшеп җитмәгән мондый бер сәясәт бар. Японнар мөселман качакларын, ә алар аша инде мөселман илләрен дә берәм-берәм үз ягына аударырга тырыша. Менә шул максаттан алар качак татарларга яки башка мөселманнарга япон калаларында үз мәктәпләрен ачарга, мөселман мәчетләре төзергә рөхсәт итә. Димәк, япон хөкүмәте аеруча куәтле мөселман илләре белән тынычлыкта, тигез солых төзеп яшәү яклы...

*Шулчак мәйданга икенче яктан кулларына кайсысы таш, кайсысы тимер арматура топкан и р л ә р килеп керә. Иң алдан килгәне баш түбәсенә чалма элсә дә, кулына тимер ябалдашлы озын таяк эләктереп керергә онытмаган.*

К о р б а н г а л и х ә з р ә т. Польша

илә Кытай калаларына сыенган татар качаклары тормышын айкап йөрүең генә җитмәгән, инде Япониядәге татар җәмгыятьләрен дә җимерергә ниятләп килдеңме, кара елан?!

И с х а к ы й. Мөселманча иминлек теләп сәлам дә бирә белмичә төкерек чәчкәнче, син үзеңә ияртеп килгән мөридләреңнең исемнәрен әйтеп сөйләш, Корбангали хәзрәт. Үзеңнең мөселман җәмгыятьләрен талап, качак якташларың хисабына әрләән сымак байлык туплап ятучы бирән икәнеңне яхшы беләм. Елан янына елан җыелмыйча калмый, диләр. Ә иярченнәрең дә синең төсле караклык кылып яшәүче соран угрыларммы?

К о р б а н г а л и. Ни беләсең соң син, пычагым кергере, ни беләсең?

И с х а к ы й. Мине япон җиреннән куып чыгарырга дип ашкынып йөрүчеләрнең берсе Низаметдин хәзрәт булырга тиеш, кайсыгыз ул?

*Шәп тун кигән, бай кыяфәтле ир бер адым алга атлый.*

Н и з а м е т д и н. Йә, мин булам, шуннан ни әйтерсең?

И с х а к ы й. Син – большевиклар килеп җиткәнче дип, Хабаровск каласындагы мөселман җәмгыятенең бар мөлкәтен, шул җөмләдән мәчет бинасын, аның келәтләрен дә ашыга-кабалана сатып бетердең дә, әүвәл шулар хисабына Мукденда берничә йорт алып, алып-сатарлык белән мантымакчы булып карадыңмы? Аннары Япониядәге Кобе каласына күчеп киттең, анда башың сыймагач, янә Кытайга кайтып, бу юлы инде Харбин каласындагы мөселман качакларын таларга тотындың. Йә, шулаймы?

*Низаметдин бер сүз дә җавап кайтармыйча, чигенеп, төркемдә торган ирләр арасына кереп чума.*

И с х а к ы й. Корбангали хәзрәт, син бирегә уң кулың булган Әмрулла Агеевны да тагып килми калмагансыңдыр сыман. Анысы кайсыгыз?

*Төркемдәге бер ир шыпан-шыпан гына читкә чигенә башлый.*

И с х а к ы й. Качма-качма, Әмрулла хәзрәтләре. Син дә үзең тарафыннан таланган бичара качакларның чын бәясен ишетергә хаклы. Зәйнуллин атлы үзең шикелле үк бирән белән бергә син ун ел буе Хайлар каласындагы җәмгыятьнең бернинди дә җыелышын үткәреп тормыйча, ун ел буе әле теге эшкә, әле бу кирәккә дигән булып, җәмгыятьне 30 мең долларлык бурычка кертеп батырдың да Токиога чыгып югалдыңмы? Мәгәр юкка, Әмрулла хәзрәтләре. Туганнарың алдындагы җаваптан да хәтәррәге – сине Аллаһ каршына баргач җавап тоту көтә. Ә анда сиңа тәмугтан гайре бер сукмак та әзерләп куелмаган.

*Быр-быр килә-килә, Ә м р у л л а мәйданны калдырып китә.*

И с х а к ы й. Иярченнәреңнең кем икәнлекләре шактый ачыкланды. Инде синең йөздәге битлекне ачарга да рөхсәттер бит, кем, Корбангали хәзрәт?.. Дәшмисеңме? Син Низаметдин илә Әмруллага караганда да пакыч йөзлерәк. Чиләбе губернасында туып-үскән чи татар булсаң да, Зәки Вәлиди Ырынбурда Кече Башкортстан җөмһүриятен игълан итүгә үк, син башкортларның үзләреннән дә уздырып, «Безнең үз мөфтиятебез булырга тиеш» дип, бугаз ярып йөрдең. Синең сүзләреңне хәтта Вәлиди дә колагына элмәгәч, син адмирал Колчак эргәсенә барып елыштың, аның штабында бүленмәс

һәм бердәм Россия тарафдары булып кыландың. Качак колчакчылар белән бергә Маньчжуриягә күчкәч, андагы ресторданнарда кәеф-сафа коручы рус әфисәрләренә татар сөяркәләрен ташып йөрүче булдың. Байлык дигәннәрен хәтәр тупласаң да, 25 нче елда Токиога күченүгә үк син әле хөкүмәттән дә мәчет төзү, мөселман матбагасы нәшир итү өчен миллионлаган тиен акча талый белдең. Ә мәчет белән басмаханәләр пәйда булуга ук, син аларны шәхсән үз исемеңә рәсмиләштереп куйдың. Әле шулкадәр байлыкны да азсынасың икән, тән сакчың итеп яллаган җанкыяр Имаметдин Фәтхетдин исеменә яздырып, син Токиодагы ике ресторанны да сатып алырга өлгергәнсең. Тән сакчың итеп яллаган Фәтхетдиннең Россиядә чакта полковник Каппель гаскәрендә сугышып йөрүе бер хәл, иң яманы – ул Харбинга килгәч, үзе белән янәшәдә качкан бер рус офицерын суеп үтергән җәллад. Һәм син менә шул инсаннар белән япон хөкүмәте каршында мөселманның асыл йөзен тәкъдим итмәкчеме? Мин синең шакшы журналыңда мине «Печән базарындагы шикелле гайбәт сатып йөрүче бер шарлатан, вә мөһаҗәрәттә илдән-илгә куылган мөселманнарны талаштырып йөрүче авантюрист», дип язуыңа төкереп тә бирмим. Син минем хакта «аның Япониядән куылуы көтелә», дип ләббәйкә кычкырасың. Иллә мәгәр онытма, кешегә чокыр казысаң, аңа иң әүвәл үзең егылып төшәчәксең...

*Исхакый сакланырга өлгерә алмый кала, шул мизгелдә аның өстенә Корбангали хәзрәт карчыгадай очып ташлана да башына авыр таягы белән китереп ора. Исхакый ыңгырашып, җиргә егыла. Кайсыдыр бер кызый читкә чыгып йөгерә, ә ирләр, тәшвиш куптарып, кычкыра ук башлый: «Полиция! Полиция!» Ә дигәнче ике полицейский кереп, Корбангалине ияртеп чыгып китә. Ибраһим Дәүләткилде белән яшь кызый Исхакыйга аягына басарга ярдәм итә. Барысы да чыгып югала. Мәйданда Оркыя исемле яшь кыз белән Исхакый гына кала.*

Я ш ь  к ы з  О р к ы я. Мондый күңелсез хәлдә генә теленә килде бу бала, дип уйламагыз, зинһар, Гаяз абый. Мин хыялымда сезнең белән күптән аралашам, сезнең белән ятам, сезнең белән торам. Әлбәттә, сезнең минем кеби гакылсыз кызыйдан баш тартасыгызны да беләм. Бәлки, мин сезнең янәшәдә булырга лаек та түгелмендер. Әмма айлар буе күңелемнән кабатлап йөргән сүзләрне әйтми кала алмыйм. Мин яратам сезне, Гаяз абый! Әйе, сез бик өлкән, минем ишеләргә бөтенләй тиң түгел. Ләкин берни эшли алмыйм. Яратам бит мин сезне, Гаяз абый, үлгәнче яратачакмын!

*Яшь Оркыя йөгереп чыгып китә, Исхакый йөзен каплап кала.*

**Сигезенче күренеш**

*1939 ел, Польша. Пөхтә генә итеп җыештырылган бер фатир күренеше. Тәрәзәләр татар халкының чигелгән пәрдәләре белән бизәлгән, мич ягында да чигелеп бизәлгән татар чаршаулары, өстәлдә дә татарча чиккән тастымаллар һәм самавыр. И с х а к ы й  белән поляк хатыны М о н и к а  өстәл янында чәй эчеп утыра.*

И с х а к ы й. Менә, Польшаның мәркәзе Варшау каласының үзәгендә дә үз өемдә утырган шикелле рәхәтләнеп ял итәм бит, сиңа рәхмәт, Моника җанкисәгем.

М о н и к а *(кеткелдәп көлеп ала).* Һе, үзең бөтен дөнья буйлап йөри-йөри, кайда тапсаң, шуннан татар сөлгеләре, татар чаршаулары ташый-ташый, бөтен өйне тутырып бетердең дә, хәзер миңа рәхмәт укып утырасың, менә сантый. Иң беренче чиратта, син үзеңә рәхмәт укы. Ә мин синең хакка җаның теләгән һәр нәрсәне кылырга да әзер, үзең дә беләсең бит.

И с х а к ы й. Сөлге-чаршау гына өйне җылы да, якты да итми шул. Ошбу йортта кояштай якты Моника-чибәр яши. Менә шундый поляк кызы очрап, алтмыш яшемә җиткәндә мине бәхетле итте дә куйды. Әгәр кайсыдыр хыялые, кайсыдыр пырдымсызы «Исхакый, син җаныңны җылытырдай якты ярыңны алтмыш җиткәндә генә табачаксың», дисә, мин тилемсә шикелле кычкырып көләр идем. Ә тәкъдир кушуы буенча, Варшаудагы чибәр Моника минем фатир хуҗам гына түгел, җанымның яртысы булды да куйды. Ярты Җир шарын япа-ялгыз көе урап чыксам да, мине җылытырдай кояш Варшау каласында качып яткан икән.

М о н и к а. Гаяз атлы асыл татар ире адашып килеп чыкмаган булса, мин бичара гомеремнең азагына кадәр япа-ялгыз көе, парсыз калган аккош кебек каңгырап яшәр идем. Әкәмәт түгел, диген инде, сине Россия мәмләкәтеннән куып чыгарган өчен шул коммунистларга беркемгә дә күрсәтмичә генә рәхмәт укып алырга да туры килә. Көлмә-көлмә, шулар куып чыгармаса, мин сине кайдан гына эзләп табар идем?

И с х а к ы й *(кычкырып көлә).* Кайчан да булса юлбасар комиссарларга рәхмәт укырга туры килер дип кем уйлаган?..

*Кинәт сирена улаган тавыш ишетелә, аннары радио аша хәбәр яңгырый: «Бүген таңда, 1939 елның 1 августында, көнбатыш чикләр аша Польша дәүләтенә фашистик Германиянең генерал Гудериан җитәкчелегендәге гаскәре басып керде. Кулына корал тотардай барча ирләрне ашыгыч рәвештә хәрби комиссариатларга чакырабыз».*

М о н и к а *(үкси-үкси елый).* Миңа ирле булып, бер ел чамасы да бәхет-гыйшык татып калырга ярамаган икән. Кайдан килгән кайгы, нинди нәгъләт бу? Кая гына китик тә, кай тарафка качыйк?

И с х а к ы й. Син шундук тәшвишкә бирелмә әле, Моника. Чик буендагы солдатларның да хаталануы мөмкин. Әмма... алай дисәң... бу Гитлер Австрия белән Чехословакияне дә немец итеге астына сузып салырга өлгерде бит инде... Димәк, димәк, безгә асылда да чыгып ычкынырга кирәк. Гитлер гаскәре, ялгыш, Варшау каласына кадәр килеп җитсә, миңа тулы капут. Германиянең милли-социалистлар фиркасен дә, советлардагы коммунистлар фиркасен дә мин «Яңа милли юл» журналы, «Милли байрак» газетасы битләрендә таракан урынына сытып яздым. Миңа советлар белән чиктәш булган калаларга таба чигенү һич ярамый. Безгә Румыния, Болгария якларына ычкыну хәерлерәк.

М о н и к а. Мин сине ярты гомерем буе көткән идем, хәзер дә синнән бер адым да калмыйм. Алай-болай үлем язган икән,

бер-беребезнең кулларыннан тотып бәхилләшербез.

И с х а к ы й. Тфү-тфү, диген, авызыңнан җил алсын, Алла сакласын диген, җанкисәгем. Безнең тормышка ашырасы эшләребез һич бетмәде әле, туган якка кайтып та җиңү яулыйсы бар. Менә шул изге гамәлләр хакына безгә яшәү кирәк.

*Сәхнәгә әрле-бирле йөгерешкән кешеләр чыга. Һавада әледән-әле сирена авазы яңгырый. И с х а к ы й белән М о н и к а да кулларына чемоданнар тотып, төрле якка чабышкан кешеләр төркемендә чәбәләнә. Бермәлне инде бомба төшкән тавышлар ишетелә, сәхнә артында да гөрселдәү яңгырый. Моника кисәк кенә җиргә авып төшә. Исхакый аның янына тезләнә.*

И с х а к ы й. Моника, Моника, сиңа ни булды, җанкисәгем? Ничә еллар буе эзләп тапкан байлыгымнан, җанымның яртысыннан мәхрүм каламмыни?..

*Узгынчылар арасыннан ак халат кигән берәү, тезләнеп, Мониканың күкрәген тыңлап карый да, Исхакыйны терсәгеннән тотып күтәрә.*

А к х а л а т л ы у з г ы н ч ы. Ни кызганыч, иптәшегез вафат булган инде, аның тәнен бомба ярчыгы ярып кергән. Аны монда ташлап калдырмаслар, тиздән санитарлар килеп җитәр. Ә сезгә бу мәхшәрдән еракkарак качу хәерле. Газраилләр үзе белән качыш уйнаганны бер дә яратмый ул. Китик, дустым, ераккарак качыйк.

*Исхакый, «Моника, Моника» дип кабатлый-кабатлый, узгынчыларга иярә.*

**Тугызынчы күренеш**

*1942 ел, Истанбул. Ерактан азан тавышлары ишетелә. И с х а к ы й ап-ак намазлыкка тезләнеп, намаз укый. Ул үзе дә шау чал чәчле, кипшенгән картка охшый башлаган. Сәхнәгә немец киемендәге бер о ф и ц е р һәм качак татар сәүдәгәре Ш ә ф и А л м а с керә.*

Ш ә ф и. Азан тавышлары яңгырый, Гаяз бәй намазлык өстендә утырырга да мөмкин дип, бик тә белеп кисәткәнмен бит, гер офицер. Сез миннән табып бирүемне таләп итеп тинтерәткән Гаяз Исхакый галиҗәнаплары менә шушы инсан була инде.

О ф и ц е р. О-о, сәлам сезгә, сәлам, гер Исхакый. Сезнең эзгә төшү өчен ярты ел чамасы газап чиктем бугай. Әүвәл үзегезне Германиядә, аннары Польша белән Румыниядә эзләтеп карадык. Допрослаган чиновникларның яртысы «әле кичә генә монда йөри иде», дип баш катыра, калган яртысы бернәрсә дә белми. Инде Кытайга гына чыгып качмаган булса ярар иде, дигән хәвефкә төшкән идек, әле ярый, Алмас әфәнденең Төркиядәге дуслары белән элемтәсе көчле. Ком чүлендә оазис эзләгәндәй, көч-хәл белән таптык үзегезне.

И с х а к ы й. Хәерче бер татар качагы Гитлер вермахтына нигә генә кирәк булды икән? Хәрбиләр белән дуслыгым юк, мин разведчик та тү-

гел, хәзер гап-гади бер авыл карты гына. Сезгә минем нинди файдам тисен?

О ф и ц е р. Тыйнаклык – шәп сыйфат. Гәрчә тыйнаклык суга баткан кешегә һич килешми. Без сезнең дистәгә якын илдәге татар җәмгыятьләре белән тыгыз элемтәдә торуыгыз хакында бик күптәннән беләбез. Бу хакта хәтта япон кәмпэйтайлары да хәбәр итте. Барча илләрдәге татар җәмгыятьләренең сезне милли юлбашчы итеп тануы да бөтенләй сер түгел. Аннары сезне Россиядә калган кече ватаныгыз да әлләни көтеп тормый. Әтиегез 19 нчы, әниегез 23 нче елда ук вафат булган. Энегез Хәсәнгата сезнең туганыгыз булган өчен генә инде ничә еллар буе төрмәдә газап чигә. Апа-сеңелләрегез большевикларның НКВД җәлладлары җәзасына түзмичә, Төркестанга качарга мәҗбүр булган.

*Исхакый өстенә кайнар су сипкәндәй калтыранып куя.*

И с х а к ы й. Мин һәммәсе турында да беләм, хәбәрләре килде. Ә мондый серләр чишеп, мине кармакка каптырырга маташу сезгә соң ник кирәк?

О ф и ц е р. Сезне ватаныгызда беркем дә көтеп тормый, сез алар өчен – бик күптәннән дошман. Ә фюрерыбыз Гитлер Россияне Уралга кадәр басып алуга ук, татарлар өчен аерым дәүләт – сез хыялланган Идел-Урал штатын төзеп куярга вәгъдә бирә. Ул бу хакта күптән миллионлаган совет әсирләренә дә, Россиядәге гауляйтерларына да игълан итте инде...

И с х а к ы й. Димәк, сез татарларны ансат кына үз ягыгызга аударырга ниятлисез.

О ф и ц е р. Ансат түгел. Гитлер сезгә Идел буенда үзегезнең борынгы дәүләтегезне торгызырга вәгъдә итә, әмма бушлай түгел. Дәүләтле булу һәм аеруча аны үз кулыгызга алу өчен сез безнең файдага хезмәт итәргә тиеш.

И с х а к ы й. Гитлер мине үз армиясенә солдат итеп алырга җыенамы әллә?

О ф и ц е р. Ирониягез урынсыз. Германиянең сезнең яшьтәге солдатларга кытлыгы юк. Безгә сезнең байрак булуыгыз кирәк.

И с х а к ы й. Нинди байрак тагын?

О ф и ц е р. Гиммлер фәрманы буенча, әсирлектәге биш миллион рус солдаты арасыннан күпләре үз ватаннарын канечкеч комиссарлар хакимиятеннән коткару өчен ирекле рәвештә «Россияне азат итү армиясе»нә язылды. Элек совет гаскәрендә фронт башлыгы булган, Сталинның шәхсән үз кулыннан Ленин орденын алган генерал-лейтенант Андрей Власов шул «азатлык армиясе»нең башкомандующие итеп билгеләнде. Совет гаскәреннән вермахт ягына күчеп чыккан генералларның саны да инде иллегә якынайды. Алар арасында элек ике дивизия командиры булып торган сезнең татар генералы Мирхуҗа Хәсән дә бар. Дөрес, әлегә ул иң яхшы немец госпитальләренең берсендә дәвалана. Легионга тагын үз теләге белән Мостафа Айтуган атлы бер полковник та керде. Анысы Фрунзе исемендәге хәрби академияне тәмамлаган, Сталин совет гаскәрләрен Финляндияне басып алу өчен керткәч тә, әүвәл финнар ягына качып чыккан, аннары безгә кушылды. Кыскасы, 15-16 ай эчендә әсирлеккә бирелгән биш миллионлы совет солдатлары

арасында татар, башкорт, чуваш, мари кебек Идел буе халыклары да йөз меңләгән. Партайгеноссе Гиммлер алар арасыннан да Идел-Урал легионын оештырырга әмер бирде. Чөнки сезнең якташларыгыз үз ватаннарын денсез комиссарлардан азат итү, халыкка кабат мәчет һәм ислам динен, ата-бабаларыгыз йолаларын кайтару өчен атлыгып тора. Менә шул ватандашларыгыз сезнең Идел-Урал легионын җитәкләвегезне үтенә. Сезнең исем астында алар үлемгә барырга да әзер, гер Исхакый.

Ш ә ф и. Йөз меңләгән татар вә башкортны, әле аларга кушылган кыргыз илә казакъларны да исеме барча мөселман галәменә яңгыраган лидер җитәкләве үтә отышлы гамәл. Русларны генерал Власов җитәкләгән икән, «Идел-Урал» легионында да абруе аннан ким, исеме беркемгә билгесез бәндә лидер булып тора алмый. Син дә, мин фәкыйрегез дә тик бер теләк – коммунистларны властьтан чәнчелдереп төшерү һәм һичкемгә буйсынмый торган, үзебез – баш, үзебез түш булган мөстәкыйль дәүләт төзү. Андый бәйсез дәүләттә син дә читтә калачак түгел, сиңа урын түрдән.

*Исхакый ялкыннан куырылып калган шикелле, үз иңнәрен куллары белән кочып, хәрәкәтсез утыра. Бик көттереп кенә телгә килә.*

И с х а к ы й. Сез миннән хыянәтче ясарга җыенасыз, тәгаен аңлашылды. Әйе, мин – кызыл комиссарлар басымына түзмичә, үз иленнән чыгып качкан кеше. Әйе, мин большевиклар властька озакка килмәгән, алар тиз арада тәхеттән чәнчелеп төшәр, аннары хакимияткә демократик юл белән сайланган район башлыклары, кала әмирләре менеп утырыр дип өметләнә идем. Сталинның да, терсәкләренә кадәр канга баткан кызыл комиссарларның, НКВД ялчыларының да юкка чыгуына өметләнәм. Ләкин аларны милли-социалистлар фиркасенә тупланган һәм ярты Ауропаны канга батырып үткән өр-яңа җәлладлар белән алыштырудан да һичбер файда күрмим. Мин милләтче социалистларны да сөймим, бер үк вакытта коммунистларга да каршы.

Ш ә ф и. Син төптән уйлап тормыйсың, күбәләк тотарга чыккан бала-чага кебек һаман ашыгасың. Әгәр Гитлер илә вермахт ягына авышмасак, бездәй качакларга туган якны кабат күрү бәхете мәңге-мәңге эләкми.

И с х а к ы й. Юк, мин әтиәнием, әби-бабаларым җирләнгән туфракка кулыма корал тоткан көе әйләнеп кайта алмыйм. Бер генә гаиләдә дә, нинди генә ызгыш-талаш чыкмасын, күршеләр кереп тыкшынганны яратмыйлар. Һәрбер хуҗа үз өендә үзе тәртип урнаштырырга тиеш. Килер бер заман, йокысыннан уянган Россия халкы кызыл комиссарларны да, НКВД ялчыларын да әйләндереп атар. Мин чит-ят өсләткән өчен генә үземнең әткәм яки әнкәм итәгенә барып ябыша торган урам эте түгел.

Ш ә ф и. Димәк, баш тартасың?

И с х а к ы й. Тартам!

Ш ә ф и. Берзаманны терсәгеңне тешләрдәй булырсың, иллә мәгәр вермахт арбасында сиңа инде урын бөтенләй дә булмас. *(Немец офицерына таба борыла.)* Бу – яхшылыкның кадерен белә торган бәндә түгел, әйдә, киттек моннан, гер офицер.

**Унынчы күренеш**

*1954 ел, Истанбул. Чал чәчле картка әверелгән И с х а к ы й тәгәрмәчле коляскада утыра, аякларына плед ябынган, аркасында мендәр. Яндагы өстәл өсте дистәләгән китап-журнал, ап-ак кәгазь битләре белән тулган. Исхакый янында кызы С ә г а д ә т өтәләнеп йөри. Бүлмәгә кияве Т а һ и р Ч а г а т а й озатуында качак татар генералы М и р х у җ а Х ә с ә н килеп керә.*

Ч а г а т а й. Бабай, ошбу генерал Мирхуҗа Хәсән метеор кебек очып кына йөри. Әле көндез генә аны Баязит бакчасында күргән идем, инде менә ярты Истанбулны кичеп, синең тарафыңа да килеп җиткән. Аның телендә гел эш тә эш инде.

И с х а к ы й. *(Әүвәл гыжлап кына, суза-суза сөйли, тора-бара гына тавышы көчәя).* Мирхуҗага афәрин һәм машалла, кияүкәем. Мин йөри алмагач, «Идел-Урал мәркәзе»ндәге барча борчу аның җилкәсенә калды бит. Өстәвенә, әле менә «Идел-Урал» атлы өр-яңа журнал чыгара башларга ният иттек. Аны типографиягә тизрәк тапшыру өчен дә аңа йөгерергә туры килә.

М и р х у җ а. Яңа журналның яртысы калыпланып бетте инде, Гаяз әфәнде. Сезнең үтенечнең үтәлми калганы юк бит. Сез бер әйтүгә, кырым татарларының әйдәманы Мостафа Идегәй белән азәрбайҗанлыларның «Мусават» фиркасе рәисе Мирза Мәмәтзадә дә ике-өч көн эчендә үз язмаларын китереп бирде. Бүген күрешеп килдем, азәрбайҗаннарның атаклы шагыйре Рәсүлзадә Мәхмәт Әмин дә, чәчәннәрнең атаклы Шамил имам оныгы Мөхәммәт Сәет тә иртәгәдән дә калмыйча, өр-яңа шигырьләре белән бергә үзенең качак ватандашлары турында да бик тәфсирле язма китерәчәк.

И с х а к ы й. Әйбәт-әйбәт, Мирхаҗи борадәр. Мин үземнең мәңгелек аркадашым Садри Максуди Арсал-Арсланнан да шәп эчтәлекле мәкалә язып бирүен үтенгән идем, аны да тинтерәтергә онытма. Ул профессор гына түгел, Төркиянең мәҗлес депутаты да бит, вакыты тар. Өстәвенә, ул картайган ат кебегрәк, гел дилбегә белән җилкетеп алуга күнеккән.

*Ишектән пошкылдый-пошкылдый М а к с у д и килеп керә.*

М а к с у д и. Кем ул – «картайган ат»? Дилбегә белән сыптырып алырга кирәк, дисеңме? Бирермен мин сиңа! Мин менә Чагатай киявең кебек йөгереп йөрим әле. Мин синнән бер кыш, бер язга кечерәк тә бит әле, анысын да онытма.

И с х а к ы й. Бүген дә килеп җиткәнсең, ай, рәхмәт, сабакташ!

М а к с у д и. Соң, үзең әле Казандагы Күл буе мәдрәсәсендә укыган чагында ук, төнлә белән күл ярына чакырып чыгарып, мин сантыйны антлар иттердең бит. Беләкләрне кисеп, кан чыгарып, шул кулларны бер-берсенә ышкый-ышкый, нинди антлар бирдек, шулар исеңдәме?

И с х а к ы й. Бер-беребезне мәңге ташламаска, бер-беребезгә терәк булырга. Гомеребезне дә фәкать бер максатка – татар халкын хөр дәүләтле итүгә багышларга.

М а к с у д и. Нәкъ шулай, Гаяз аркадашым. Инде 75 яшебезне тутырдык, ә 60 ел элек биргән антыбыздан бер мыскал да тайпылганыбыз юк.

*Мирхуҗа, Сәгадәт, Чагатай – һәммәсе кул чаба. «Афәрин, машалла!» – дип дәртләндереп тә куялар.*

М а к с у д и. *(Башкаларга читкәрәк китәргә ым кага).* Гаяз, мин Төркиянең дәүләт мәҗлесендә булып килдем. Мин картлачның авыртмаган башына тимер тарак таптылар бит әле.

И с х а к ы й. Нинди тарак тагын?

М а к с у д и. Алдагы елда Төркиянең президентын сайлау көтелә бит. Азәрбайҗан белән Кырымның бәйсезлеген яклаучы депутатлар мине президентлыкка нәмзат булып чыгарга үгетли. «Хәтта, үзең каршы торсаң да, сине барча мәҗлес исеменнән чыгарабыз», – диләр.

И с х а к ы й. Үзең ниндирәк кыйбланы сайларга җыенасың инде?

М а к с у д и. Гаяз, мин – качак Казан татары. Унҗиденче елда дөньяга туып өлгермәгән Идел-Урал штатының илбашы булып сайлангач та, комиссарлар шундук мине атып үтерү турында фәрман игълан итте. Ярый, ул чагында чыгып кача алдык. Хәзер инде монда, төрекләр ватанында, мин президентлыкка нәмзат булып чыксам, бу – безне сыендырган Төркия җөмһүриятенең йөзенә төкергән кебек булып чыга бит. Үзебезнең татар мәкален онытмыйк. «Ит – изгелек, көт – явызлык». Шулай түгелмени?

И с х а к ы й. Үзең миңа сорау биргән буласың, ә җавабын менә тапкансың бит. Иллә мәгәр, барыбер, син шундук, казанны ут өстенә асканчы ук чигенмә әле. Исемеңне ялтыратып алу – һичкемгә дә зыян итмәс сыман. Синең исем нәмзатлар арасында шаулый башласа, моны Мәскәүдәге коммунистлар да ишетмичә калмас. Аларга безне онытыру, хәтта бөтенләй юкка чыгару отышлырак. Ә син, әйдә, аларга үч итеп, юк, без монда юкка чыкмадык, без яшибез дип, юри дөбердә әле.

М а к с у д и. Синең нәкъ шундый киңәш бирәсеңне әле ошбу тарафка атлаганчы ук белеп тора идем.

И с х а к ы й. Соң, без бит 60 ел буена аркадаш, без – бертуганнар. Безнең бер үк төрле уйларга өйрәнүебез гаҗәпмени?

М а к с у д и. Гаяз, миңа кузгалырга вакыт. Өйдә Камиләкәй дә чирләп тора әле, миңа ачуланма.

*Максуди Исхакыйны кысып кочаклый да ишектән чыгып китә. Берничә мизгелдән соң ук урамда машина тәгәрмәче чыелдаган тавыш ишетелә.*

И с х а к ы й. Аһ, Садри!.. Таһир, кияүкәем, бар, тизрәк чыгып бакчы? Сизеп торам, минем дускаема нидер булды анда.

*Чагатай чыгып китә дә йөзе җимерелеп керә.*

Ч а г а т а й. Профессор Максудины машина бәреп киткән.

И с х а к ы й *(өзгәләнеп).* Ул исәнме?

Ч а г а т а й. Аны ашыгыч ярдәм машинасы алып китте.

И с х а к ы й. Аһ, бу этләр!..

*Беркадәр тын торгач, Исхакый өстәл өстендәге китап-журнал-лар арасыннан бер бит кәгазь тартып чыгара.*

И с х а к ы й. Балалар һәм син дә, Мирхуҗа аркадашым, бер минутка мине тыңласагыз иде. *(Беркадәр тын тора.)* Мин берничә ай элек үк васыять язып куйдым...


С ә г а д ә т, Ч а г а т а й. Әти! Бабай!

И с х а к ы й. Мине бүлдермәгез. Үз хәлемне беләм. Яман шеш дигән каһәрдән беркемнең дә котыла алганы юк... Васыятем һәр кешегә аерым адреслана. Байлыгым юк, әмма минем 37 дәфтәрдән хасил көндәлекләрем бар. Төрле елларда язылып та, аерым китап итеп чыгарырга өлгермәгән әсәрләрем байтак. Менә шуларны югалтмыйча сакласагыз иде. Килер бер көн, Казан илендә дә яңа җил кузгалыр. Шул чагында әсәрләрем вә көндәлекләрне газиз милләтемә кайтарсагыз иде. Аннары, бик чамалыйм, коммунистлар власте да һич мәңгелек түгел. Унҗиденче елда алар ничек мәкерле түнтәреш ясап, Вакытлы хөкүмәтне алып аткан булса, берзаманны коммунистларның үзләрен дә алып атачаклар. Явыз хакимият Җир шарының һичбер почмагында да гасырлар буена дәвам итә алмый. Менә шул коммунистлардан арынгач, минем җәсәдемне ватаныма кайтарсагыз иде. Газиз Тукай юкка гына мин фәкыйрегезгә «милләт юлбашчысы» дигән дәрәҗә такмагандыр. Минем Тукай белән янәшәдә, аның түтәлендә җирләнгән Шиһабетдин хәзрәт, Ризаэддин хәзрәт, мөгаллимнәр мәктәбендә бер сыйныфта укыган Хөсәен Ямаш, Гафур Колахмәтләр белән серләшеп ятасым килә...

*Сәгадәт күз яшьләрен тыя алмыйча, акрын гына елый. Чагатай белән Мирхуҗаның да башлары түбән иелгән.*

И с х а к ы й. Ә син, Мирхуҗа бәй, «Идел-Урал мәркәзе»ндә минем төп ярдәмчем. Сине Төркиянең генераль штабында полковник дәрәҗәсенә ирешкән, үзебезнең Оренбург янәшәсендә Сакмар авылында туып үскән Мәҗит Сакмар белән дә бик күптән таныштырган идем. Ул әдәби сүзгә үтә сизгер, аңа «Идел-Урал» журналының барча эчтәлеген төзүне тапшырсаң да була. Аннары безнең ватандашлар Төркиядә генә түгел, барча илләр буенча санап бетергесез. Мин бер ай чамасы элек Харбиндагы «Милли байрак» газетасына «Милли юлыбызның нигезләре» дигән бер язма юллаган идем. Зинһар, шуны белеш, якындагы номерга куймый калмасыннар. Мәгәр иң мөһиме – монда ният иткән «Идел-Урал» журналын тиз арада дөньяга чыгарыгыз. Идел белән Урал арасында мәгыйшәт иткән бар халыкны тик бер максат – бөтенебез дә бергәләшеп һәм хөр яшәү нияте берләштерә. Ул көн килми калмас, мин ышанам!

*Пәрдә.*



*Гөлинә Балтач районы Борбаш авылы кызы. Ул Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтының театр факультетын тәмамлап, режиссёр белгечлеге алган. Күпләр аны «Китап» радиосының тапшырулар мөхәррире һәм социаль челтәрләрдә блогер, тормышындагы яңалыклары белән даими уртаклашучы иҗади һәм туры сүзле кеше буларак белә. Ул театр артистларының күбесе белән тыгыз элемтәдә тора, әдәбиятыбызның асыл үрнәкләрен шул артистларның тавышы аша татар дөньясына таныта. Үзе дә артист халкыннан калышмый, радио фонды өчен үз шигырьләрен, яки күңеленә яткан шагыйрь-шагыйрәләрнекен дә үз аһәңе белән сәнгатьле итеп сөйли, яздыра. Шул ук вакытта Гөлинә журналистика өлкәсендә дә танылып килә, репортажлар эшли, интервьюлар ала. Гөлинәнең сүзләренә иҗат ителгән җырлар да күзгә күренеп арта бара. Әүвәлге шигырьләре аның Борбаш авылы тарихына багышлап чыгарылган «Саклагыз нигез ташын» китабында дөнья күрә.*

Гөлинә
Шәйхи

# ҺАВА КЕБЕК ШУНДЫЙ КИРӘК ЧАГЫҢ...

***

Әллә заман, әллә мин үзгәрдем – усалландым кебек.
Тормышның һәр сынавына карыйм хәзер көлеп.

Сыгылмыймын давылда да, канат ныгыган!
Үтте инде ул заманнар – абынып егылган.

Җилләрнең дә (каршысына!) барамын атлап.
Яши белмим (җай чыкканча!) кемнедер кабатлап!

Кеше сүзе – кешенеке. Минеке түгел.
Усалланса да, сафлыгын җуймады күңел!

Беләм, кемдер тешләгәнгә кемдер тез чүгәр.
Кемдер җанының карасын чыгарып түгәр

Һәм сүгәр. Ә үзенең гаебен – аклар.
Соң тамчы сөюен шулай «Мин» диеп таплар.

...Яши белеп яшәмәсәң – нигә ул яшәү?
Сүзләр тансык бу заманда алтындыр – дәшмәү!

Әллә заман, әллә мин үзгәрдем…

***

Мин юк синдә. Син юк миндә. Югалттың Безне.
Бүгеннән соң кем дип атыйм икән мин Сезне?

«Матурым» дип эндәшә алмыйм. Ямьсез бүген көн.
Көннәрдән соң килеп җитәр кабат озын төн...

Үтәр шулай көн артыннан елак төннәрем.
Берәр кайчан мин аларны көлеп сөйләрмен!

Ә бүгенгә никтер авыр. Бәргәләнә җан.
Син оялма. Кирәк икән җанымны да ал!

Мәхәббәткә табынуым булган тик хата.
Араларда сөю түгел, минминлек ята.

Бүгеннән соң кем дип дәшим икән мин сиңа?!

***

Мин бу җиргә сине эзләп килдем,
ышанам мин синең барлыкка.
Табармын күк меңнәр арасыннан,
югалырга гына ашыкма!

Йөрәк белән йөрәк арасына
күпер салсам – кулың бирерсең.
Назларыңа мохтаҗ чакларымда
өметемә сулыш өрерсең.

Мәхәббәтне кемдер юктыр дисә,
ышанма син аңа. Алдалый.
Минем кебек эзләп табалмаган,
сөеп карамаган – аңламый.

Һава кебек шундый кирәк чагың...
Кайдан сине эзләп табасы?
Балкып алчы якты бер нур булып,
кая таба сукмак ярасы?!

***

Синле дөнья синдә калсын әле,
Күренмәслек булып беркемгә.
Беркөнгә җую бу үзеңне һәм...
Табудыр да, бәлки, кем белә?!

Син көлмә. Моңарчы бу кадәр
ашыккан юк иде һич гомер.
Мине генә керт тә, келәсен
элеп куй җаныңның – җил керер!

Йөрер дә җиләсләп, дөньяңны
күчерер эзлекле күчәрдән...
Мин барда син шуны танып кал:
бүгенгең бәхетле кичәдән.

Кичә дә... бүген дә... калганын
калдырыйк бу карсыз калада:
«Син бүген китәсең... иртәсен
Питерда синсез таң ярала...»

***

«Ардым, атлый алмыйм...» дигән чакта
син бит миңа кабат җан өрдең.
«Бирешергә синең хакың юк» дип
юатып, кат-кат назыңа төрдең.

«Бар да үтә, сабыр бул, балам!» – дип,
яшьләремне сөрттең күземнән.
«Сагыш күзләренә туры кара!
Качып булмый, – дидең, – үзеңнән».

Үгет-нәсихәтең белән, әни,
горур атлап барам эзеңнән.
Тирән мәгънә табып яшим Җирдә
һәр киңәшең, һәрбер сүзеңнән.

Ярый әле, минем син бар, әнкәй!
Ничек яшәр идем мин Синсез?!
Эзләсәм дә синдәй җан табылмас,
син бит бердәнберем, син – тиңсез!

***

Төн пәрдәсен ертып, җаннар җанга
йоккан мизгел исеңдәме әле?
Сулыш кайнарлыгы
белән өткән иренеңдә
калганмы соң минем ирен тәме?

Күзләреңдә минем күзләр төсе
чагыламы уйга батканда?
Кем дә булса орышамы сине
(минем кебек!),
тәүлегенә унны тартканда?

Ятканда да һаман укыйсыңмы
бәхет теләп миңа доганны?
Үз-үзеңә әл(е) дә бирәсеңме
җавабы юк шул бер сорауны?!

...Сорау арты сорау туган чакта
җавап табу, беләм, икеле.
Бар да бар һәм берни дә юк хәзер,
Җаннар җанга йогып кителде...

***

Мин идем бит, кар көртләрен ера-ера,
егыла-егыла сиңа ашыккан.
Йөгерү түгел, атлап булмый бүген...
Егерме биштә йөрәк талчыккан.

Һава җитми. Сулуыма каба
декабрьнең синле иртәсе.
Калдыр мине, дисең. Яратканны
ничек итеп ташлап китәсең?

Тугыз йөз унөч тәүлек, ул – аз түгел,
һәр көнендә – миллион вакыйга.
Сине генә уйлап уянам да
синең белән китәм йокыга.

Ә син миңа «яратмыйсың», дисең.
Нинди була соң ул ярату?
«Беркемгә дә бирмим! Минеке!» дип,
канатнымы каерып канату?

Миңа калса, җаннар туры килү
сирәк була. Беләм. Тик – була!
Читтән кара безнең охшашлыкны,
холык кына үзе ни тора.

Икебез дә кызу:
безгә хәзер, бүген кирәк!
Ә иртәгә, бәлки, булмабыз...
Ара ерак. Ләкин җаннар якын,
беребез өчен беребез туганбыз.

Вакыт чикле. Барыр юллар – бикле.
Тар сукмакта бүген икебез.
«Бизмәннәргә салып үлчәгәндә,
икебезнең гаеп бертигез!»



*Миләүшә Хәсәнова 1978 елның 1 сентябрендә Мөслим районы Вәрәшбаш авылында туып үскән, шунда ук урта мәктәпне тәмамлаган. 22 ел Вәрәшбаш мәктәбендә башлангыч сыйныфларны укыта, бүгенге көндә Мөслим гимназиясендә эшли. Хикәяләр, нәсерләр яза. Иҗат җимешләре республиканың вакытлы матбугатында даими рәвештә басылып килә. Шулай ук иҗади конкурсларда катнаша.*

# Миләүшә Хәсәнова

ХИКӘЯЛӘР

## ЧИГҮЛЕ КУЛЪЯУЛЫК

Мәдинә әби йокысыннан төш күреп уянды. Имеш, аңа ап-ак теш чыккан икән, төбендә бер тамчы кан да бар. Моны ул нәрсәгә юрарга да белмәде. Төштә кан күрсәң, туганың белән очрашуга була, диләр, әллә сеңлем Кәримә кайта микән дип уйлап куйды ул. Сагынуын, күрәсе килүен әйтеп, хат та юллаган иде шул сеңлесе.

Әле таң сызылып кына килә иде. Таллыкта өздереп сайраган сандугач тавышлары да ачык тәрәзәдән аермачык ишетелеп тора. Ап-ак җәймәләр җәелгән ятактан ап-ак йокы күлмәге кигән, ап-ак чәчле Мәдинә торып, алгы бүлмәгә чыкты. Киемнәрен алыштырып, чәчләрен тарап үрде дә бәйрәм көнне генә бәйли торган ак укалы яулыгын бәйләде. Тәһарәт алырга дип, комганын күтәреп тышка чыкты. Болдырда иртәнге матурлыкка, сихри рәхәтлеккә исереп, бер тын басып торгач, алга атлады.

Яңа сауган кәҗә сөте салып, шикәрләп чәй эчкәннән соң, нәрсәнедер исенә төшереп, өй түрендәге сандыгы янына килде. Ул сандыгын ачып, аннан кәгазьгә төрелгән бик кадерле әйберен алып, караватта өелеп торган чигүле мендәрләр өстенә куйды.

Көтүләр китеп, озак та үтмәде, ишектән мәктәп директоры Шәүкәт килеп керде.

– Озын сүзнең кыскасы шул, – диде ул, хәл-әхвәл сорашкач. – Безнең авылга яңа укытучы килә. Яшь кенә кыз, Гөлсәрия исемле.

Менә шул балага яшәргә урын кирәк иде, Мәдинәттәй. Ни диярсең икән, үзеңә иптәш тә булыр.

Мәдинә әби озак уйлап тормады, ялгызлыкның бик авыр, кышкы төннәрнең озын булуын әйтеп, директорга ризалыгын бирде.

...Ун ел элек гүр иясе булган Сәфәргали белән Мәдинә бик матур гомер иттеләр. Кеше арасында ким-хур булмадылар, алны-ялны белмичә, көн-төн эшләп, бердәнбер кызлары Гөлүсәне кеше итәргә тырыштылар. Ләкин ул кыз

игелекле бала булмады – ерак Себер якларына бер руска кияүгә чыкты да әтиәнисен бөтенләй диярлек онытты. Баштарак ике-өч елга бер булса да кайткалый иде, хәзер әтисе үлгәннән бирле күренгәне дә юк. Хатлары да килми.

Тәрәзәдән күзен алмыйча кызын көтеп, төннәрен һәр ят тавышка сискәнеп уянганда, Мәдинә әбинең күңеленә бик яман уйлар да килә: бәлки аны яшьлектәге гөнаһлары өчен Ходай үзе шулай газаплыйдыр. Ә гөнаһлары аз булмады аның...

Сугыштан соңгы авыр чорлар иде. Әтисе: «Без укый алмадык, син укы», – дип, барлы-юклы акчаларын табып, Мәдинәне Бөгелмәгә укырга озатты. Бер ел узгач, тулай торакта уздырылган кичәдә Мәдинә чибәр генә бер егет белән танышты. Шактый өлкәнрәк һәм күпне күргән егет иде бу. Ә Мәдинә – беркатлы авыл кызы, аның матур сүзләренә ышанды һәм... тиздән әни булачагын аңлады. Ләкин егет бу хәбәргә сөенмәде, ә киресенчә, сирәк күренә башлады һәм бер очрашуда соңгы сүзен әйтте:

– Синең теләсә кайда йөреп тапкан балаң миңа кирәк булмас. Аны миңа тагарга җыенма да!

Мәдинә ялгыз калды. Әниләре янына да кайтырга курыкты. Авырлы килеш аларга ничек күренсен? Ләкин бала туарга санаулы гына көннәр калгач, тулай торакка әнисе үзе килеп керде.

– Менә нигә кайтмыйсың икән, – диде ул елап һәм усал сүзләрен кызганмыйча. – Баланы табасың, әмма калдырып чыгасың! Укуың бар, яшь әле син!

Әйе, әнисенең холкын шәп белә иде кыз. Бала күтәргән килеш өйгә аяк та баса алмаячак ул. Димәк, сабыйдан чынлап та баш тартырга туры киләчәк.

Өч көн буе Мәдинә кулъяулыклар чикте. Аларның берсенә, малай тапсам, дип, «Гөлүс», икенчесенә «Гөлүсә» дип язды. Балага ул нәкъ менә шушы исемнәрне куярга теләгән иде. Ләкин хәзер исемне бүтән кеше бирәчәк. Шуңа да, бәлки минем теләгемне искә алырлар дип, ул бала белән бергә кулъяулыкның да берсен калдырырга ниятләде.

Биш көн хастаханәдә яткач, Мәдинә кызын соңгы тапкыр имезеп, күкрәгенә кысып елады да чыгып китте. Әле берни белмәгән сабый янында күз явын алырлык, исемле кулъяулык ятып калды – «Гөлүсә».

Озакламый Мәдинә укуын тәмамлады, эшкә урнашты. Кызы Гөлүсәне эзләп, күпме балалар йортына барса да, бернинди дә хәбәр ала алмады. Әнә шулай өметләре өзелеп, кара кайгыга батып йөргән чагында танышты ул ире Сәфәргали белән.

Озакка сузмыйча өйләнештеләр. Кызлары туды, Мәдинә аңа да беренче сабые истәлеге итеп, Гөлүсә дип исем кушты.

...Укытучы кыз Гөлсәрия Мәдинә әбигә көн уртасында килеп керде. Ачык йөзле, ярдәмчел, инсафлы бала икән. Сөйләшә-сөйләшә чәй эчтеләр, ашыкмыйча гына бакчада эшләп керделәр, бергәләп көтү каршыладылар. Ә кичен көтелмәгән хәл булды: урын җәйгәндә, Мәдинә әби мендәрен күтәргән иде – идәнгә кәгазьгә төрелгән әйбер килеп төште дә ачылып китте. Аны күреп, Гөлсәрия кинәт кычкырып җибәрде:

– Абау, мондый кулъяулык минем әниемнең сандыгында да бар. Бик кадерләп саклый, әнием бүләге, ди. Моңа Гөлүс дип язылган, ә бездә Гөлүсә. Әнием Гөлүсә минем.

Барысын да аңлагач, Мәдинә әби, оныгын кочып, тыела алмыйча елады да елады. Төштә кан күрүе юкка гына булмаган икән бит! Озакламый ул кызы Гөлүсәне дә, бүтән оныкларын да, киявен дә күрү сөенеченә иреште. Хәзер бәхетенә сөенеп туя алмый.

Кызы Гөлүсә аны берсүзсез кичерде.

# ЯЛГЫЗ ЧӘЧӘК

Юл читендә үсеп утырган кечкенә генә сары чәчәккә берәү дә игътибар итмәде. Ә ул, иртәнге чык тамчылары белән юынып, җылы кояш нурларына иркәләнеп, әкрен искән җилдә тирбәлеп үсә бирде. Туктаусыз тыз да быз узган машиналардан күтәрелгән юл тузаны тынына капланса да, сары күлмәген төссезләндерсә дә, бирешмәде. Узгынчылар өстенә дә баскалады. Андый чакларда авырткан, сыкранган тәнен язу өчен киерелеп сузылды да кабат кояшка таба үрелде.

Шулай инде: яшәү урының такыр юл булгач, дусларың да сирәк килә, йә бөтенләй күрмәмешкә салыша. Аның янына да күбәләкләр, бал кортлары анда-санда бер генә туктап алдылар. Анысы да юлда арганнан соң, ял итәр өчен генә. Ә юлдан ерактарак, болында үсүче чәчәкләрдә күбәләкләр, төклетуралар, май коңгызлары куышлы уйный. Әле – бер чәчәккә, әле икенчесенә кунып тирбәләләр. Тегеләре дә, безне ишетсеннәр әле дигәндәй, тирә-юньне яңгыратып чыркылдашалар. Матур тадж-итәкләрен каккалап, бер-берсе белән гәпләшәләр, серләшәләр. Үзләреннән читтә – юл буенда моңаеп утыручы ялгыз чәчәккә дә карап алалар. Арада аны кызганучылар да бар, ләкин ярдәм итүчесе генә күренми.

Хәер, аңа ярдәм кирәкми дә: иртәнге чык тамчылары, кояшның җылы нурлары – аның өчен яшәү чыганагы. Бердәнбер авырлыгы – ялгызлык. Тырнак очы кадәр генә булса да, шатлыгы да килеп китә шунда. Ә шулай да барына канәгать итеп, булганына шөкерана кылып яшәргә кирәк. Артык биеклеккә күтәрелмичә, чамадан тыш сикермичә яшәргә.

Юл буендагы ялгыз чәчәк тә, һәр туган көнгә сөенеп яши торгач, җиһанга көз аяк атлады. Көз, салкын яңгырлары белән үзәген өтсә дә, ялгыз чәчәккә яшәү бүләк итте.

Беркөнне кәттә машинада элдерүче бер юлчының тимер аты аның янында шып туктап калды. Аптыраган юлчы, төшеп машинасын карады, ләкин ник сүнгәнен аңлый алмады. Ачуыннан юл читендә үсеп утырган чәчәккә тибеп җибәрде. Тамырлары белән кубарылган ялгыз чәчәк, канатлана-канатлана очып, юл читеннән еракка – болын уртасына килеп төште. Бераз аптырап торганнан соң, үзен кулга алды. Язмыш типкесендә үскәнгәме, анда яшәү, нәсел дәвам итү омтылышы көчле иде. Ул тамырларын җиргә батырды, сабагы буйлап тормыш суты ага башлады. Ялгызлыктан туйган чәчәк җимшәнендәге орлыкларын җил иркендә болынга сипте... Алда гомере дәвам итәчәгенә, бу җиһанда бик күп дәвамчылары булачагына чиксез сөенгән чәчәк, кар юрганын ябынып, кышкы татлы йокыга талды. Төшләрендә ямьле язлар килүен, үзенең яңа тормыш башлавын, тордаш чәчәкләренең күп булуын күреп, рәхәт изрәде ул.



*Михаил Хонинов (01.01.1919–22.09.1981.) – калмык шагыйре, прозаик, драматург, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе; Бөек Ватан сугышында һәм Белоруссиядәге партизаннар хәрәкәтендә катнашкан шәхес. Аның калмык телендә унбиш, рус телендә унсигез китабы дөнья күргән.*

*Шагыйрь Әстерхан губернасы Малодербетовск районында Цаган-Нур посёлогында дөньяга килә. Туган авылында башлангыч, Малодербетовск мәктәбендә җиде сыйныф белем ала. Соңрак Әстерханда Калмык техникумының актёрлык бүлегендә укый. Элистада Калмык дәүләт театрында эшли. Калмык радиосының беренче дикторы була, калмык һәм рус телләрендә тапшырулар алып бара. Шулай ук Әстерхан сәнгать техникумында белем ала, Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институты каршындагы икееллык Югары әдәби курсларда укый, соңрак Әдәбият институтын читтән торып тәмамлый.*

*1969 елдан Бөтенсоюз журналлары «Крокодил», «Огонёк»та, шулай ук «Комсомолец Калмыкии» газетасында штаттан тыш хәбәрче булып эшли. М.В.Хониновның соңгы эш урыны – Н.Н.Пальмов исемендәге Калмык төбәкне өйрәнү музее.*

Михаил
Хонинов

# ҖӘЙ ҖИТТЕ ИСӘ...

## Болытлар акканда

Балачакта ишеттем мин, елгыр малай,
Күршеләргә әнкәй салды җан авазын:
Җәйге көндә үз тирмәсе каршысында
Тула басар өчен ничек йон язганын.

Кинәт купкан өермәнең кулы йонын
Күтәргән дә, кисәкләргә бүлә-бүлә,
Баш очында түгәрәкләп әйләндергән,
Китәр өчен алып күкнең кендегенә.

Ап-ак йонын бик кызганды әниебез,
Һәммәсенә, ятларга да бирде сөйләп:
«Бу, дип, язмыш, дуамал җил кулы түгел,
Йонны алып китте зәңгәр күкне иңләп».

«Юк, әнием! Карчыгадай өермә бу,
Мин беләм!» – дип әйттем аңа килешмичә,

Тирмә киртәләре артлап, читтән генә.
Бик кызганыч иде ул йон минем өчен.

Әнкәйнең дә аннан Җирдә гомере бетте.
Җәй житте исә, мин болытлы күккә карыйм.
Әнкәй белән бергә, балачактагыдай,
Кабарынып очкан сарык йонын барлыйм.

## Ни өчен кояш кызыл?

Иртә таңда
Кояш юлга чыга –
Килә тәрәзәмә,
Карый дикъкать белән.
Мин дәшәмен аңа:
– Әйдә, кер! – дип.
Җавап бирә:
– Вәгъдә, соңрак керәм…

Һәм керде ул.
Беләм, чәй ярата,
Тозлы калмык чәен.
Мин кояшны сыйлыйм:
– Эч, чәй күп! – дим, –
Әйдә, тагын өстим.
Йөзләребез бәкам агачының
Ала җете төсен.

Кояш рәхмәт әйтеп,
Хәл алгач та,
Менеп әкрен генә,
Түбә буйлап бара.
Өй ишелми,
Бакыр кояш яктысында
Балкып яна.

Барысын да
Сәламли кояш,
Яшерми ул нурын,
Якты елмаеп каршылый
Барча дусларын.
Ни өчен, кызыл ул? –
дип чумамын уйга.
– Калмык чәен эчә,
сандал агачыдай шуңа…

## Бөртек һәм дөреслек

Хаклык Ялган белән бил алышып,
Берчак көч-хәл котылыр җай тапкан,
Җиңелгән дә, кырга сузылып яткан –
Ял иткән ул, монда йортын тапкан.

Гаҗәпләнеп Бөртек сорау биргән:
«Кайдан, килдең, ни булды, әйт, Хаклык!»
Һәм Дөреслек шәрехләгән: «Бөртек!
Без бу җирдә бергә үсик, калкып».

Бөртек чыгып җирдән, җавап биргән:
«Тор, тизрәк! Кайт кешегә кире.
Хакыйкать чәч көчле йөрәгенә,
Караклык һәм ялганны җиң, ашык!
Бөртектән дә ашып шыт син бире!»

Бөртек нәсыйхәтен тыңлап Хаклык
Шытым бирә, йөрәкләргә ятып.

**Әлфия СИТДЫЙКОВА** *тәрҗемәсе.*

# КАЯ БАРАСЫҢ, ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ?

## ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘР БӘЙГЕСЕННӘН СОҢ УЙЛАНУЛАР – 2

Татар әдәбиятын, мәдәниятен үстерүгә һәм популярлаштыруга юнәлтелгән күпсанлы чаралар белән беррәттән, 2023 ел Татарстан Республикасы Язучылар берлеге һәм Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан игълан ителгән татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсы белән дә тарихка керер, мөгаен. Чөнки татар әдәбияты өлкәсендә бу кадәр масштаблы, номинацияләр ягыннан барлык төп әдәби юнәлешләрне колачлаган бәйге бүтән юк. Аның беренчесе, 2021 елда узганы да татар әдәбияты, аның бүгенгесе һәм киләчәге хакында күп кенә фикер алышуларга сәбәп булды. 2023 елгы бәйге дә бу сөйләшүне дәвам итәргә кирәклекне күрсәтә.

Гомумән алганда, миңа 2023 елгы конкурска килгән проза әсәрләре 2021 елгы белән чагыштырганда баерак, төрлерәк, кызыклырак тоелды.

Сүзне жанрлардан башлыйк. Конкурска барлыгы 59 хикәя тәкъдим ителгән. Шуларның яртысы «Казан утлары» журналында басарлык икәнен исәпкә алганда, жанрны торгынлыкта дип булмас. Тематик һәм әдәби-эстетик эзләнүләре белән дә, үзенчәлекле сөйләм кору һәм хикәяләү матурлыгы ягыннан да хикәя жанрында кызыклы үрнәкләр бар. Гомумиләштергәндә, конкурска килгән татар хикәяләре материалында иң зур кимчелекләр: публицистиклыкның, вакыйганы тасвирлап түгел, сөйләп чыгуның өстенлек алуын, әсәр текстында сискәндерерлек, күңелгә керерлек «энҗе бөртеге», образ-деталь яки яңалык булмауны күрсәтергә кирәк.

Сурәтләнгән вакыт ягыннан, хикәяләрдә йә үткән турында сөйләү, йә үткәнне бүгенге белән үреп җибәрү ешрак очрый. Дөнья әдәбиятында кече жанрның – оператив, көн кадагына суккан әсәрләрне мәйданга чыгару куәсен искә төшерсәк, татар хикәясендәге үткәнне тасвирлауга йөз тотуны кимчелек буларак аерып күрсәтергә кирәк. Әмма елдан-елга татар хикәясенең заман вазгыятенә якынаюын да билгеләп үтү дөрес булыр.

Шунысы да бар: татар халкы язмышы турында уйландырырлык текстлар нәкъ менә үткән-бүгенге үрелешендә бигрәк тә географик чикләрне узып иҗат ителгән. Менә шундыйлардан – «Куенында ни бар?» хикәясе авторның каләм көче белән Төркиягә алып китә. Аның үзәккә куелган герое – мөһаҗирләр оныгы Мөнир карт җомга намазы саен татарлар белән очрашуга өмет итеп мәчеткә юнәлә. Шунда Илнур исемле туган илдән эш белән килгән егетне очрата, кайтып киткәндә бабасының мөһаҗирлек юлы маҗаралары да теркәлгән Коръән китабын әманәт итеп, югалмасын – туган илгә кайтсын дип, егеткә тапшыра. Егет исә аны мәчет киштәсенә куеп калдыра.

Вакыйгалар бер елдан соң кабат ялганып китә. Инде Илнур үзе – мөһаҗирлектә, картны һәм китапны эзләп килә. Язучы бу тарихка аларның туганлык җебен фараз итүне китереп ялгый. Хикәяне башлаган символик образ – мәчеттәге җеназаханә тәрәзәсе өстенә оя корган карлыгачны борчымаска дигән язу детале – әсәр тәмамланганда аны Мөнир карт ябыштырганлыгын ачыклап, ояда күренгән 4 кошчык башы турында хәбәр итеп төгәлләнә һәм символга әйләнә. Бу символ әсәр исеме белән кисешә: куенында гел яхшылык булсын, аның нәтиҗәсе күренми калмас дигән фикерне ассызыклый.

Хикәя тәэсирле, узгынчы кыйммәтләрне һәм мәңгелек кыйммәтләрне капма-каршы куеп язылган дигән тәэсир кала. Мөнир карт һәм Илнур образларына карата психологизм

куллану аларның кичерешләрен, уйларын күзәтә барырга мөмкинлек бирә, укучыны да вакытның агышы, үзенең «куенындагы» байлыгы хакында уйлануларга этәрә.

Шулай ук психологизм алымы кулланып язылган «Юлаучылар» хикәясенең символик мәгънәле исеме һәм җентекләп эшләнгән характерлары фәлсәфи гомумиләштерү көченә ия. Сюжет бер гасыр чамасы узганга алып китә: илдә зур үзгәрешләр башланган, шәхес культы тамыр җәйгән вакыт. Вак детальләрдә күз алдына килерлек итеп тасвирланган кышкы юл, анда чаналары ауган Муллахан белән Нәгыйләттәй дә, аларга каршы очраган Мөхәммәт исемле малай, аның әтисе, төрмәдән чыгуга улын эзләргә керешкән Гомәр дә – юлаучылар. Язучы сәяси вакыйгаларны сөйләп узмый, ул аларның кешеләр җанында һәм гамәлләрендә чагылышын тотып алган (бу – безнең әдәбиятыбызда яңа!). Шушы буран геройларны очраштырып кына калмый, бәлки тормышның иң мөһим канунын ассызыкларга ярдәм итә. Без барыбыз да – юлаучылар, юлның авыр вакытларында бер-беребезнең ярдәменә мохтаҗбыз, ди сыман. Язучының осталыгы бу очракта буран тасвирын һәм табигый, һәм социаль, һәм фәлсәфи мәгънәләре күренеп торырлык итеп эшләвендә дә, дияр идем.

Шулай ук тарихка, 1914 елгы сугыш вакыйгаларына күз ташлаган «Мин кайтырга тиеш» хикәясе кешелеклелек, мәрхәмәтлелек, туган җирне, газиз кешеләрне ярату хакында сөйли. Яки 1946 ел вакыйгаларын тергезгән «Урман юлында» хикәясе куркытылган кешеләрдәге усаллык, хөсетлек сыйфатларын тетрәндерерлек күренеш мисалында күрсәтә, баласын сугыштан көтеп алган ата белән ананың, сеңелнең, авыр юллар узып кайтып кергән солдатның кичерешләрен үкенечле бер ноктада тасвирлый.

Бу хикәяләрнең барысында да – узганның гадәти булмаган вакыйгалары геройларның уй-кичереш көзгесендә чагылып, символик образлар яки детальләр аша фәлсәфи гомумиләштерү мөмкинлеге табылган. Татар хикәясенең күз алдына килерлек сурәт һәм күңелгә тиярлек кичереш тудыру көче – бүген әлеге жанрдагы иң мөһим сыйфат булып аңлашыла. XXI гасырда кече жанрның XX гасыр башы прозаиклары табышларын дәвам итеп китүе бәхәссез.

Кеше тормышындагы гадәти генә тоелган күренештә замананың олы фаҗигасен күрсәтә алган хикәяләр дә бар. Әйтик, «Әрнү» хикәясе шундыйлардан: өйләнмичә генә балалар үстерү шаукымы тормышта мәхәббәтне, гаделлекне җуюга китермиме дигән сорау куя. Шунысын да әйтергә кирәк: әлеге хикәядә проблема татар әдәбияты өчен яңа яссылыкта: гаепләү яки аклау аша түгел, бәлки аңларга тырышу кебек ачыла.

Аллегорик яки романтик дөнья сурәте тудыру кызыклы, тәэсирле текстлар тудыра, әмма аларның саны бик аз булуны әйтергә кирәк. Мисалга, «Образ» хикәясе студент вакыттагы хәлне искә төшерү кебек уйланылган. Мәхәббәт тарихы егетнең сөйгәненең үз күңелендә тудырылган образы – асыл нөсхә белән тәңгәл килмәгәнне аңлавы белән тәгәлләнә. Романтикага төрелгән фәлсәфә бик табигый күз алдына китереп бастырылган әсәр сюжетыннан саркып чыга, ышандыра, күңелгә тия. Тагын бер романтик хикәя – «Ания ядкаре» – шулай ук мәхәббәт тарихы, гадәти булмаган образлары белән игътибарны җәлеп итә. «Алтынчәч»тәге романтик мәхәббәт тарихы исә йомгакланып җитмәгән дигән тәэсир калдыра.

Яки аллегорик характердагы «Җирләү» хикәясе гадәттән тыш ситуация хасил итә, аның чынбарлык чикләреннән чыгып китүе, гайре-табигыйлеге шаккатыра. Телсез Талибның зиратта Газраилгә каршы чыгарга, аны үзе белән көрәшергә чакыруы – гадәттән тыш күренешне һәр кеше тормышына бәйләү мөмкинлеге белән уйландыра. Асылда, ул кешедә үлемгә каршы торырлык көч булу турында сөйли, кешедәге куәтне тагын бер кат искә төшерә.

Хәзерге көннең парадоксаль күренешләрен үзәккә куюэ ягыннан, «Калу» хикәясе игътибарны җәлеп итә. «Тукай» романын укыганда Габдулланың 3 әтисе турында гаҗәпләнеп һәм тетрәнеп сөйләгән укытучы үз сыйныфындагы һәр баланың диярлек 2-3 әтиле булуын аңлап ала. Заманның үзгәрешен күрсәтү ягыннан да, көтелмәгән ситуация тудыру җәһәтеннән дә текст сискәндерерлек.

Аерым бер герой характеры шактый тулы эшләнеп тә, хикәя төгәлләнмәү очраклары бар. «Кадер киче» – шундыйлардан. Әти һәм ул мөнәсәбәтләрен чагыштырып биргән хикәядә ир-ат геройның бик нечкә кичерешләре ышандырырлык һәм тәэсирле тергезелә. Бу кичерешләр үстерелешен йомгаклауны да үлем белән түгел, шундый югары кимәлдә күрәсе килеп кала.

Хәзерге көн турында сөйләүче хикәяләрнең күпчелеге – нигездә публицистик характерда, ярым-хикәя, ярым-мәкалә булуы белән аерылып тора. Күрәсең, бу сыйфат – татар хикәясенең иң зур кимчелегедер. Текстларда тормыштагы әхлак нормаларыннан читкә чыккан бер вакыйга сөйләп узыла, нәсыйхәт ачык белдерелә. Әйтик, оныкларның татарча сөйләшмәве («Татарча»), гаилә белән хезмәт арасында алтын урталыкны таба алмау («Көлгә әйләнгән сүзләр»), сәхнәдә роль уйнаган артист белән шәхеснең тәңгәл килмәве («Карт артист») җәмгыятьтәге күңелсез күренешләр («Урман тукталышы», «Өянәк», «Пәрәвез», «Чишмә» һ.б.). Хикәяләрдә дә сериаллар йогынтысы үзен сиздерә: «Ырым», «Сентябрь алмалары», «Сәгать күзләре», «Кара тасмалы фото» һ.б. Чиста публицистик текстлар да бар.

Көзбикә дигән псевдоним алган авторның хикәяләр сериясе чит җирлектә иҗат ителгәне күренеп торган 9 хикәяне берләштерә. Шуларның берсе – «Чын әкият» – Тәмим исемле малай торган җирдә кар яву күренешен тергезә. Әби белән бала арасындагы җылылык, әби кешедәге туган җирне сагыну хисенең тирәнлеге читтә яшәргә мәҗбүр булганнарның язмышы фаҗигасен якты нурга төрә. Калган хикәяләрдә татар укучысы өчен ятрак булган исемнәр йөрткән образларда мөселман әдәбиятына хас булган ситуацияләр тергезелә. Мондый тематик яңалык – стильләштерүнең бер үрнәге буларак игътибарга лаек дип исәплим.

Кайбер хикәяләр миңа повесть материалын үзенә сыйдырган кебек тоелды. Әйтик, фәлсәфи «Ак үрдәк» хикәясе шундыйлардан. Мондый күләмле материалны хикәя кысаларына кертү геройларны тиешле дәрәҗәдә эшләп бетерергә мөмкинлек бирмәгән.

Аерым бер әдәби әсәрләргә охшатып язылган текстлар да юк түгел. Мәсәлән, «Бөти» хикәясе Р. Габделхакованың «Сират күпере»н хәтерләтә.

Ни кызганыч, нәсер категориясендәге текстларны хикәяләр белән бер рәткә куеп бәяләү мөмкин түгел. Шулай да, «Бураннарда, әнкәй, сине күрәм», «Әби җыры» кебек әсәрләрнең тәэсирлелеген, сөйләм матурлыгын аерып билгеләп үтәргә кирәк. Бәлки, алда оештырылачак конкурсларда лиро-эпик чәчмә әсәрләр өчен аерым категориядә ярыш игълан итү, йә булмаса нәсер һәм поэманы бер номинациядә карау кирәктер: татар әдәбияты күтәрелеш кичергән вакытларда нәсер һәрчак үзенчәлекле язу стиле эзләү мәйданына әйләнгән бит!

Конкурска тәкъдим ителгән повестьларның да саны аз түгел – алар 30. Мин үзем шулар арасыннан 7 әсәрне көчле текстлар буларак аерып чыгардым. Алардагы төрлелек жанрның татар әдәбиятындагы тармаклануын да күрсәтә торган билгедер дип исәплим.

2023 елгы ярышка килгән повестьларның бер үзенчәлекле сыйфаты – нинди генә тема үзәккә куелса да, милли проблематикага кагылып китү. Гомуми зур кимчелек – кабатлану, ягъни яңалык булмау, яки аның повесть материалында мөһим урын били алмавыдыр, мөгаен.

«Шом» повесте бүгенге тормыш-яшәештәге шомны һәм аерым бер кешеләр тормышына йогынты ясаган шомны ике катлам итеп аера. Җир-Ана, полигонда атом-төш коралын сынау легендалар белән үрелеп китә. Атом бомбалары – шул гомуми шомны тудыра, кешене һәм табигатьне, Җир-Ананы киеренкелектә яшәргә мәҗбүр итә. Икенче катлам эчтәлек – бүгенге чынбарлык – ир, хатын, баладан гыйбарәт кечкенә гаиләнең архитекторлар Наилә белән Фаилгә кунакка барырга җыенуларыннан башланып китә. Моңа кадәр берсеннән-берсе затлы коттеджлар төзеп, дусларын шаккатырган, бер-ике елдан анысын сатып, яңасын төзүгә тотына торган осталар бу юлы бөтенләй үзгә корылма – коттедж-бункер төзеп куйганнар, аны бер еллык азык-төлек белән тутырганнар, имеш. Әлеге гаҗәеп корылманың өй туе вакытында атом тревогасы башлана: Фаил дусларын өеннән куа, алар Рамил белән

Саниянең балаларын алып калырга телиләр һ.б. Шушы абсурд хәлгә ышанып беткәч кенә, будильник шалтырый һәм әлеге вакыйгаларның төш икәнлеге ачыклана. Әмма повестьның ышандыру көче һәм бүгенге тормыштагы шом моның чынбарлыкка әйләнү мөмкинлеге турында сөйли. Повестьта кеше характерларының чарланган булуын, язучының сурәтләнгән заман һәм дөнья картинасын тергезү осталыгын, сиздерми генә ирония һәм сатира тудыру сәләтен дә әйтергә кирәк.

«Гомер» повесте да әле генә булып үткән ковидлы дәвергә алып китә. Яшь гаиләнең бала көтүе, вакцина ясаткан Илдар белән Айгөлнең хастаханәгә эләгүе булып үсә барган вакыйгалар баланың үле тууы һәм Илдарның үлеме белән тәгәлләнә. Айгөл исеменнән, психологик анализ кулланып язылган повесть әлеге чир кешеләргә алып килгән кайгыны тагын бер кат күңелдән уздырып тетрәнергә мәҗбүр итә. Бер гаилә мисалында күрсәтелгән фаҗигане – кешелек фаҗигасе итеп карау, бала үлеменә салынган фикер йөге повестьның көчле ягы дия алабыз.

«Әлләче, татар – малай!» повестеның жанрын автор «мини-роман» дип билгеләгән. Яшьләр прозасы кебек кабул ителә торган әлеге текст, ясалмарак тоелса да, заманча мәхәббәт тарихы булып чыккан. Аның герое Чынтимер интернетта башкорт кызы Артыкбикә белән язышa башлый. Бу онлайн-текстларга татар һәм башкорт халкы тарихына караган легендалар үрелеп китә, тарихи экскурслар ясала. Әсәрнең укылышын ике төп геройның самими, ихлас, юмор элементлары кушып тергезелгән романтик образлары тәэмин итә.

Ике повесть – «Әлиф ләм-мим» һәм «Борыла да карый...» – документаль әсәр категориясенә карыйлар. Беренчесе Сәләй Вагыйзов һәм Рәмзия Вәлитова язмышы турында сөйли. Икенчесе Роза Туфитуллова тормышына, эш-гамәлләренә багышланган. Әмма үз исемнәре белән бирелгән геройларның чынбарлыктагы тормышы турында сөйләсәләр дә, икесе дә – тәэсирле, матур тел белән язылганнар. Геройларны романтик идеаллаштыру биографик текстны әдәби әсәрләр белән бер кимәлдә бәяләү мөмкинлеген тәэмин итә. Геройларның милләтпәрвәрлеге, рух көче, үз язмышына тугрылыгы сокландыра, повестьларның бай, төзек-матур теле, хис-кичерешләрне тергезүгә юнәлтелгән сөйләме дә текстларның бәһасен күтәрә.

«Газизем!» повесте әнисен карап, авылда яшәргә мәҗбүр 44 яшьлек Газизнең эчке монологларын төрле гаиләләр һәм кешеләр көнитеше контекстында тергезә. Әнисе Рәшидәнең Газизне яратып бетермәве, әтисе белән әнисе арасындагы гауғалы тормыш, шәһәрдә яшәүче абыйсы белән җизнәсенең түбәнсетеп караулары ирнең тормышын гына түгел, төрле гаиләләр модельләрен күз алдыннан кичерергә ярдәм итә. Газиз белән Сәгадәт мәхәббәте, әнисенең һәм туганнарының яратуы Газизгә авыр чирне җиңеп чыгарга ярдәм итә. Газизем – һәр кешенең якыннары җылысына мохтаҗ булуын, әлеге җылылыкның бары тик авыр хәлгә тарыгач кына аңлануын сөйли, бүгенге авыл, кеше һәм табигать якынлыгының самимилеген һәм гади кешеләрнең матур күңелен бәян итә. Вакыйга-күренешләрдән бигрәк, психологик нечкә кичерешләр хәрәкәтеннән үрелгән повесть кеше язмышлары, холкы, мәңгелек кыйммәтләр турында уйланырга мөмкинлек бирә.

«Алар безнең арада» – фантастик повесть, заманча фәнни эзләнүләр, ясалма интеллектның якын киләчәктәге казанышлары турында мәгълүматларга таянып иҗат ителгән күләмле маҗаралы текст. Анда зоо-роботлар, манипуляторлар, машина-роботлар дөньясы тергезелә. Бу өлкәдәге галимнәр Данир Ярми, Вахит Гатин һәм Борис Костин «Ясалма интеллект һәм акыллы машиналар» дигән симпозиумда очрашалар. Алга таба аларның күрешүләре күп кенә гаҗәеп сорауларны калкуландырырга ярдәм итә. Әйтик, кеше үзе дә – ясалган җан иясе түгелме дигән сорау шундыйлардан. Вакыйгаларның үстерелеше фантастик әсәрләрнекен кабатлый: Костин яшерен лабораториядә роботлар җитештерә икән. Данир ярдәме белән ул роботларга үз хисләрен яздыра. Көннәрдән бер көнне роботлар баш күтәрә, дөньяны яулап алырга булалар. Кеше акылы аларны коралсызландыруга ирешсә дә, бу вакыйга кисәтү булып яңгырый.

Мондый типтагы фантастик әсәрләрдә сюжет яңалыгына ирешү авыр. Хәзерге дөнья әдәбиятында ясалма интеллект булдыру күчмә сюжетларның берсенә әйләнде. Кызганычка каршы, теманың катлаулылыгы еш кына хикәяләүне дә катлауландыра. Әмма шушы материалда көтелмәгән күренешләр яңалыгы мондый әсәрләрдә бәһале санала. «Алар безнең арада» повестенда да бар алар, әмма барыбер әсәр тукымасында темага караган гомуми тасвирлар алга чыга.

Шулай ук фантастик әсәр – «Дипломат» – кыска исемлеккә кермәсә дә, концепциясе белән истә кала. Ул җир өстендәге һәм җир астындагы мәчеләр яшәгән ике Казанның метро төзелешенә бәйле очрашуы турында. Кызыклы детальләре, юмор һәм сатира, аллегория образлары белән игътибарны җәлеп итсә дә, текст бик күләмле (160 бит) һәм шактый буталчык килеп чыккан.

Повестьлар арасында да сериаллар йогынтысын кичергән («Ятьмә», «Бала хакы», «Агачлар сере», «Тарту көче» һ.б.) яки киносценарий кебек иҗат ителгән («Күңел күзе») текстлар юк түгел. Ярым-публицистик әсәрләр күп булып, гомумән, бу жанрда тематик тарлык күзгә ташлана. Күп повестьлар аерым бер кешенең бәхетсез тормыш тарихын тергезеп, шул тарих мисалында гомумиләштерүгә алып китә алмыйлар.

Конкурска 23 роман килү үзе үк татар әдәбиятының чишмәләре саекмаган булу хакында сөйли. Әмма укый башлауга ук, бу саннар язгы кар кебек эри башлый. Иң беренче булып 2021 елны да конкурска «Казан серләре» исеме белән катнашкан «Сагыш каласы» романы «төшеп кала»: аның авторы экспертларны, чыннан да әсәрләрне укыйлармы икән дип, тикшереп шаяртырга уйлаган, күрәсең! Аннары ике повесть: «Сырхау» һәм «Татар Ия», бер хикәя – «Ятлар баласын тәрбияләрсең» – аерып куела. Әдәби әсәр булмаган «Болгар кызы Айсолтан» исемлектән төшә. Шулай итеп, техник яктан шартларга туры килгән 18 роман кала.

Роман категориясендәге «Үзәккә үткән онытылмас балачак хатирәләре», «Алтынчы бүлек», «Көбәй тауны күтәргән (Бер нәселнең тарихы)», «Хәтер» кебек текстларда да документальлекнең әдәбилектән югарырак булуын әйтергә кирәк.

Сыйфат ягыннан әсәрләр бик төрле булып, сүзне гомум тенденцияләрдән башлыйсы килә. Иң беренчесе – ни гаҗәп, күләм мәсьәләсе булыр. Мәгълүм ки, XX-XXI гасырлар чиге дөнья әдәбиятында роман жанры зур үзгәреш кичерә: ул күләм ягыннан нык кыскарып, тыгызлыкны алга куя. Кызганычка каршы, татар прозаиклары бу тенденциядән бихәбәр, һәм бу заман романнарының сыйфатына тискәре йогынты ясаганга күрә, сүзне шуннан башлыйбыз да. 500-800 битлек романнар – мәгънә тирәнлеге белән түгел, бәлки көпшәклеге, таркаулыгы, язучының алга куйган максаты-фикере күренеп тормау кебек сыйфатлары белән күңелне төшерә. Текстны укып бетергәндә, ике яки өч әсәр укыган кебек тәэсир кала. Мондый юл белән милли романнарның үсү мөмкинлеге чикләнгән булу аңлашыла.

Әйтик, югары балл җыйган «Кайсы яктан чыга соң бу кояш?» романы авторның тасвирлау осталыгы, характерларны психологизм яссылыгында тудыруы, вакыйгаларның яңа һәм кызык булуы белән игътибарны җәлеп итә. Монда Башкортстанның Казанлы авылында 1917-1918 елларда барган хәлләр сурәтләнә. Үзәккә куелган герой – «Галия» мәдрәсәсендә укыган Ильяс Ягафаров образы сәяси-тарихи вакыйгаларны җыеп тора. Әлеге геройның характерын ачу өчен язучы үтемле күренешләр уйлап тапкан: поездда өч хулиганга каршы чыгуы, Казан университетында уку теләге һ.б. Аның белән бәйле төрле геройлар да характерлар буларак ачылып китәләр: Революционер Яков Константинович Никонов, агач агызучы бай Матусов, Мөхәммәтҗан бай, Камил Якуб, поручик Салих Җиһаншин һ.б. Символлаштырылган табигать күренешләре, Гәрәй-Нина, Миша-Анна мәхәббәтләре, Ильясның яңа туган баласын коткарырга өлгерүе һ.б. бик күп күренешләр тәэсирле, ассоциатив кимәлдә язылганнар. Әмма авылдагы аклар белән кызыллар арасындагы каршылык бик озын хикәяләнеп, әйтелеп кителә ала торган күренешләр дә озын-озак җентекләп тергезелә башлый. 427 битлек роман ялкыта, тыгызлауны таләп итә.

Роман жанрындагы икенче зур тискәре сыйфат – тарихи романнарның классик калыптан чыга алмавы. Бу хакта без узган конкурс нәтиҗәләренә кагылышлы язмабызда да искәрткән идек. Тарихи романнар кирәкми дигән сүз түгел бу, һич юк. Киресенчә, тарихи роман жанры татар халкының узганына, язмышына кагылышлы бик күп сәхифәләргә реконструкция ясый, аларны шәрехләү чарасына әйләнә. Әйтик, «Дары бистәсендә» романы XIX гасырда Казан дары бистәсендә барган вакыйгалар аша татарлардагы армиядә хезмәт иткән солдатлар, аларның балалары язмышын да, фактологик материаллар белән ныгытып, матур итеп тергезә. Тема һәм материал үзләре үк яңа. Үзәккә куелган солдат улы Ибраһимның 14 яшендә дары заводы каршындагы кантонистлар мәктәбенә укуга баруыннан башлап, язучы аның хезмәтен, офицер дәрәҗәсе алып, морза булуын, бакыйлыкка күчүенә кадәр алып килә. Бер кешенең-гаиләнең тормышы, шул рәвешле, язучыга бер катлам шәһәр татарларының яшәешен, гомумән татар язмышын күрсәтергә һәм бәяләргә ярдәм итә. Фактологик материал булу яхшы, ышандыра, әмма вакыты белән документаль-публицистик башлангыч әдәбилекне күмеп китә.

Гомумән алганда, романнарның һәрберсендә диярлек татар халкының матур гореф-гадәтләре, аларны башкару үзенчәлекләрен җентекләп сурәтләү шактый зур урын алып тора. Бу шатландыра, билгеле. Шул ук вакытта еш кына романдагы төп сюжетны җыя торган концептуаль үзәк калкуланмый-күренми, сөйләп бару өстенлек алып, тасвирлау өчен вакыйгалар дөрес сайланмый. Әһәмияте зур булмаган хәл җентекләп күрсәтелә, мөһиме – әйтеп үтелә.

Гореф-гадәтләр белән бергә, татар байлары, сәүдәгәрләре, муллалары, көчле нәселләр турында сокланып сөйләү алга чыга. Аерым бер әсәрләрдә бу төп теманы тәшкил итә. Әйтик, «Татар лачыны» романы Фатиха Аитова язмышына багышланган. Байлар тормышы, аларның укымышлы катламы көнитеше тәэсирле итеп тасвирлана. Бигрәк тә Камил һәм Фатиха, Хантимер белән Һәдия образлары яхшы эшләнгән. Матур язылган романда шәхсилек иҗтимагый башлангычтан алга куела, әмма шул сәбәпле кайчак сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре өзелеп китә. Роман жанрының шушы ике якны тигез саклап бару шарты башка әсәрләрдә дә үтәлеп җитмичә, күп кенә текстларны, романнан бигрәк, озын повесть кысаларына кертә.

Хәзерге татар романының үсү-үзгәрү юлы – төрле әдәби катламнарны кушу-тоташтыруда түгелме дигән сорау узган конкурста да әйтелгән иде. Минем фикеремчә, бу юлы да иң көчле әсәрләр шушы юнәлештә иҗат ителгәннәр. Бу яктан, минем күңелемә ике роман аеруча хуш килде (дөрес, аларда да редактор каләме кирәклеге үзен сиздерә).

Аның беренчесе – «Серле тәңкә», романтик мәхәббәт тарихын, детектив тарихны, Казан ханлыгы тарихын бергә үреп бара. 17 яшендә чегән кызы Лаурага гашыйк булган Равил тарихы серле тәңкә аша Кырымнан Гәүһәршад белән килгән Мирела, Казан ханлыгы шәхесләренә дә, заманның криминал вакыйгаларына да килеп кагыла. Шулар белән бергә, Равил образы, аның характеры, Лаура, Гөлнара һәм Галия образлары тулы эшләнгән.

Бөтенләй үзгә темага мөрәҗәгать иткән, Нургали картның үлем алдыннан гаиләсендәге һәм илдәге фаҗигале вакыйгаларны искә төшерүе һәм аның оныгы Гаязның үзләре кайчандыр чыгып китәргә мәҗбүр булган авылга кайтып төпләнүе тарихларын тергезү кебек язылган «Каторжан» романы да чынбарлык сурәтен романтик һәм модернистик тасвирлар белән кушып җибәреп, кызыклы текст хасил итә.

Көчле романнар арасында да иҗади тасвирны публицистик сөйләү белән кушу еш очрый. Әйтик, «Үз илемдә – үз көем» романы Хәсәнша Әхмәтшинның истәлекләрендә 1898 ел, җанисәп белән бәйле кан коелу, кулга алуларны искә төшерүдән башлана. 6 малайлы гаиләдә өлкәне булган Әхмәтша укый, шахтага эшкә китә, хезмәт белән, тырышып көн күрә башлый. Беренче бөтендөнья сугышы, революция, кулга алыну, аклану, Бөек Ватан сугышы, Суслонгер, сугышка китү һ.б. – җентекләп сөйләнеп бара. Роман укыла, теле матур, әмма публицистиклык та көчле.

Шул ук гомуми бәяне «Күмелгән китап» романы турында да әйтеп булыр иде.

Әтисенең хатирәләрен малае язган истәлек формасында, әсәр Беренче бөтендөнья сугышы, революция, ачлык, гаиләнең Ташкентка китәргә карар кылуы, анда авырып киткән кече уллары Шәмсине калдырып, Төркиягә юнәлүе, малайның исә, терелеп, авылына юл тотуы һәм 4 ел буе кайтуы турында сөйли. Шушы вакыт эчендә сәяхәтче күп кешеләр белән очраша, күп язмышларның шаһите була. Биредә тәрбия-хезмәт мәктәбе дә, вокзал тормышы да, күмәкләштерү, кулга алулар да бар. Шуңа бәйләп, тарихка – туган җир, Бәрәнҗәр тарихы, болгарлар, Урта Азиядән килгән Мәхмүт Тимар турында – экскурслар урын ала. Вакыйгаларның Шәмсинең авылына кайтып җитүе белән төгәлләнүе символик төс ала.

Романнар арасында жанрлык төрлелеген билгеләп үтәргә кирәк. Әйтик, «Бер йотым су» автор тарафыннан роман-эссе дип билгеләнгән. Чыннан да, әсәрдә төзек сюжет юк: кешеләр язмышлары, аерым-аерым вакыйгалар яхшылык һәм явызлык, туган җир, җирсү, тел һ.б. турында уйланырлык итеп тупланган. Бу мозаиканы әлифбадагы хәрефләр бер баш астына җыя.

«Яшенле төн» мистика: буш йорт, портал ачылып, 15 ел элек булган җинаятьнең ачыклануы кебек уйланылган.

«Универсиада йолдызым» шигъри роман жанрын тергезә. Караклык темасына кагылган «Бисмилласызлар» – кыйссага тартым хикәяләве, Галәветдиннең тылсымлы лампасын уйнатуы белән үзенчәлекле.

Гомумән, татар әдәбияты олы жанрларда да идеаллаштыруны, ак-кара дип, ике чиккә аеруны, дидактизмны, бер яклы гына хикәяләүне атлап уза алмый әле. Бу, бигрәк тә, «Хөсетлек» романында көчле, әмма башка әсәрләрдә дә үзен нык сиздерә.

Синтетизм күренеше урын алып та, акцентларның дөрес куелып бетмәвенә мисал итеп соцреализм белән кырыс реализм, романтизм белән детектив катнашмасы булган «Тормыш җиле»н мисалга китерергә була. Ситуацияләрнең ясалмалылыгы, образларның берьяклылыгы башка әсәрләрдә дә күзәтелә.


Гомумән, романнар мисалында да әсәрләрнең нигездә укылышлы булуын, әмма эшләнеп, матурлап бетерелмәгәнлеген әйтергә кирәк. Конкурска килгән романнарның күбесе – тарихи яки заманча вакыйгаларны сөйләп чыгу, аерым бер кеше башыннан узганнарны бәян итү, үткәннең аяныч сәхифәләренә экзистенция белдерүдән гыйбарәт булып, гомумиләштерүнең җитмәве үзен нык сиздерә. Шул ук вакытта роман жанрында бәйгегә тәкъдим ителгән укылышлы әсәрләр психологизм алымы кулланып, образларның тип дәрәҗәсендә эшләнүе, фәлсәфи-фикри тирәнлек белән аерылып торалар.


Беренче конкурс вакытында безнең тарафтан әдәби тәнкыйть номинациясен кертү тәкъдиме әйтелгән иде. Чыннан да, милли әдәбиятның үсеш кыйбласын аның әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйте билгели. Бу мәсьәләдә дә шактый гына кызыклы материаллар килгәнлекне аерып билгеләп үтәргә кирәк.

Шул ук вакытта проза номинациясендәге текстларны укыганда, документаль-биографик әсәрләрне әдәби повестьлар белән беррәттән бәяләү мәҗбүрияте дә күңелдә канәгатьсезлек калдыра.

Әлбәттә, конкурс татар әдәбиятын камилләштерү, дөнья әдәбияты киңлекләренә чыгарырлык әсәрләрне барлау максаты белән уздырыла. Шуңа күрә бәйгегә килгән текстларга зур таләпләр куела: без, чыннан да, татар әдәбиятының киң катлау укучыларга кызык булуын телибез һәм җиңгән әсәрләрнең шулай буласына ышанабыз. Югары таләпләргә җавап бирә торган әсәрләрнең саны 3тән артып китү, бер яктан, шатландыра, икенче яктан, ул күп кенә бәхәсләргә китерде. Һәм проза, һәм поэзия номинацияләрендә 3 әсәрне генә түгел, 6-7 әсәрне билгеләп үтәсе килеп калды. Бу уңайдан, Нигезләмәгә үзгәреш кертеп, бер үк төрле балл җыйган әсәрләр өчен сумманы икегә бүлү мөмкинлеген хокукый беркетү кирәк түгелме икән?

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*



*Муса Җәлил – хәзерге «Ялкын» журналына нигез салучы.*



*«Ялкын» редакциясе коллективы. 1979 ел. Утырганнар (сулдан уңга): Разил Вәлиев, Роза Хафизова (баш мөхәррир), Фәния Хәйруллина, Айдар Үтәгәнов. Басканнар: Эльмира Закирова, Асия Кәримова, Хәйдәр Гайнетдинов, Фәридә Мөхәммәтшина, Рафис Гыйззәтуллин, Гүзәл Камалова.*



*1994 ел, апрель. Сулдан уңга: Эльмира Закирова, Фәйрүзә Мөслимова, Әлфия Зәйнетдинова, Җәүдәт Дәрзаманов (баш мөхәррир), Рәшидә Сафина, Ирек Нигъмәтҗанов, Гүзәл Камалова.*



*Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, халык шагыйре Разил Вәлиев «Ялкын»ның баш мөхәррире Эльмира Закированы юбилее белән котлый. 2005 ел, декабрь.*



*«Ялкын»ның яшь хәбәрчеләре Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев белән традицион очрашуда. 2000 ел, декабрь.*



*«Ялкын»ның бүгенге коллективы. Алгы рәттә (сулдан уңга): Гүзәл Закирова, Аида Шакирова. Арткы рәттә: Резидә Әлмиева, Зилә Дәрҗеманова, Илназ Фазуллин (баш мөхәррир), Илүзә Касыймова, Илсөяр Маликова.*

*Фотолар «Ялкын» редакциясеннән һәм Эльмира Закированың шәхси архивыннан алынды.*

# АВЫЛЫМА КАЙТЫП КИЛДЕМ ӘЛЕ

Үзебезнең милли журналыбыз «Казан утлары»н гаиләбездә бик яратып укыйбыз. Журнал кайсыбызның кулына иртәрәк эләгә, тәүдә шул укый. Калганнарыбызга журнал кайчан бушый дип көтеп йөрергә генә кала. Без укый торганнар заманында туган балалар. Ягъни үткән гасырның урталарында фани дөньяга килгән, китап, газета укып, шуның тәрбиясендә үскән буыннан.

«Казан утлары»ның гыйнвар-февраль саннарында якташыбыз, Башкортстанның Миякә районында туып үскән Айдар абыйның бик фәһемле «Әти-әни, миңа ничә йөз яшь?..» дигән әсәре басылды. Мин аны бар дөнья мәшәкатьләремне читкә куеп укып чыктым. Монда барысы да миңа таныш, барысы да безнеңчә. Әсәрне укый башлауга күңелем туган авылым Гөлемгә юл алды. Гөлем – исеме җисеменә туры килгән авыл. Бәләкәй Кәркәле кебек ул да таулар куенына кереп урнашкан һәм дә тирә-ягын урманнар каплап торган бер бәләкәй генә чокырга яшеренеп утырган. Тик безнең авыл Бәләбәй-Бөгелмә калкулыгының төньяк битенә караган ягына урнашкан булса, Бәләкәй Кәркәле аның көньяк битенә караган җирендә. Гөлем Стәрлебаш районына керә, Бәләкәй Кәркәле – Миякә районына. Бәләкәй Кәркәле Өязе елгасы буенда булса, безнең авыл Өршәк елгасы кушылдыгы булган ике елга, Олы Төләмәт белән Бәләкәй Төләмәт инешләре арасында. Элек Өязе елгасы безнең урмандагы Әгәрби сазлыгыннан башлана иде. Айдар абый язганча, сөренте басуларын киңәйтәбез дип, урманнарны кисеп төпләделәр. Сазлыкларны канаулар ерып киптерделәр. Шул ерткычлык аркасында Өязе елгасы да хәзер Әгәрби сазлыгын ташлап, түбәннәнрәк ага башлады. Елгалар гынамы соң, бик күп чишмәләр, күлләр корыды, балыклары бетте. Торналарына чаклы шундый сазлыкларны сагынып, ел саен моңсу гына җырлашып, башка якларга очалар.

Бәләкәй Кәркәле безнең Гөлем авылына урман аша турыга 11 чакрымнар чамасы булса, Айдар абый белән безнең яшь аралары да 11 генә ел. Айдар абый 1942 елның гыйнвар аенда дөньяга килгән булса, мин 1953 елның февралендә туганмын. Сизәсезме? Айдар абыйның балачагының дәвамы да, аның хәтерләүләре дә минем балачагыма туры килеп тора. Минем балачагым аның балачагының дәвамы дип тә әйтергә була.

Бу әсәрне мин үземне күз алдына китереп укыдым. Әсәрдә Айдар абый елаганда, мин дә еладым, ул шатланганда, мин дә шатландым. Ул да дүртенче сыйныфны тәмамлагач, туган нигезеннән укырга дип чыгып киткән. Безнең Гөлем авылында да башлангыч мәктәп кенә булып, 4 кенә сыйныфлы иде. Менә шул, әсәрне укый башлагач, күңелем белән авылыма кайттым да Магази тавына менеп, чирәменә утырып, күңелем булганчы елап алдым. Барча авылдашларым күз алдыннан узды. Әнә Шәвәли бабай бәләкәй арбасын тартып, шилек кисәргә Ает алды урманына кереп китте. Әнә Хайбыр (Хабибрахман) бабай Садыйка әбисе белән печәннән кайтып киләләр. Минем беренче укытучым Минезыя апа белән шулай ук укытучы Зифа апа мәктәп бусагасына чыгып бастылар. Әнә сыйныфташларым каршы як тау түбәсендә түбән оч малайлары белән туп тибәләр.

Безнең авылда да сугыш ятимнәре күп иде. Тик алар миннән олырак. Алар да авылның көч җитмәслек авыр тормыш йөген олылар белән бергә тарттылар. Коммунизм төзеделәр. Шунысын да әйтеп китми булмас: Аллага шөкер, безнең буынга ачлыкны күрергә туры килмәде. Әмма Хрущёвның кукуруз ипиләреннән авыз

иттек. Урман кисүләр үзе бер маҗара иде. Без укыганда, мәктәп утын ягып җылытыла иде. Ә ул утынны 4 нче сыйныфтан өлкәнрәк балалар урманда үзләре кисеп әзерли. Шулай алтынчы сыйныфта укыганда, урман кисәбез. Бишенче сыйныфтагылар без малайлар кисеп тазарткан чыбык-чабыкны учакка ташып яндыралар. Олы сыйныфлар аркылы пычкы белән агач аударалар. Менә шунда Равил дустым агач башына менеп китте. Иң биеккә менде. Мин дә аңардан калмаска тырышып, тагы да югарырак менәм. Уздым Равилне. Сыйныфташларның барысы да аһ итте. Тик кире төшкәндә, минем шароварның төбе ниндидер бер каһәр суккыры ботакка эләгеп ертылды бит. Нәрсә эшләргә? Җитмәсә, күзем төшеп йөргән сыйныфташым Рима да мине куәтләп: «Молодец, булдырасың, Равилне уздың», – дип кычкырды. Ә мин кире төшә алмыйм, ыштан төбем ертык. Төшсәм, барча җиһазым күренергә мөмкин. Утырам шулай агач башында. Ярый әле, укытучыбыз Закир абый минем хәлне чамалап алды шикелле. Сыйныфташларымны икенче өем агачларны тазартырга алып китте.

Айдар абыйның әсәрен укып, балачагым, яшьлегем күз алдыннан үтте, хатирәләр искә төште. Аны шулай бөтен нечкәлекләре, бизәкләре белән тик Айдар абый гына яза аладыр. Аның ничек комсомолга керергә барганы да, ничек комсомолга алмаганнары турында язган хатирәләре миңа да таныш. Әйе, безне дә комсомол Уставын ятлатып, райком комсомолы урнашкан бүлмә ишеге төбенә тезгәннәр иде. Сыйныфташлар берәм-берәм шул бүлмәгә кереп чыгалар. Кергәндә, барысының да муенында кызыл галстук булса, чыкканда, галстуклары кесәләрендә, ә күкрәкләрендә комсомол значогы ялтырый. Ул значок 10 тиен тора иде шикелле. Тик минем муенымдагы галстукның очы чәйнәлгән. Әллә ни эшләп шул галстук гел иренгә тиеп, ике теш арасына эләгә дә теш үзеннән-үзе тегене керт-керт иттереп кетердәтә дә куя. Шулай ярты ягы чәйнәлгән галстук тагып керсәң, әлбәттә, комсомолга алмаслар иде. Галстугын чәйнәп йөргән пионер комсомол булырга лаек түгел, диячәкләр. Мин ни эшләргә дә белми торганда, Әхәт Фаткуллин хәлемә кереп:

– Кайгырма, дус. Минем галстукны тагып керерсең, – диде. Чынлап та, аның галстугын тагып кереп, теге бүлмәдән комсомол булып чыктым. Менә хәзер Әхәтнең чираты җитте теге бүлмәгә керергә. Әхәт озак кына чыкмый торды, ә чыкканда, яртылаш үлгән иде. Комсомолга алмаганнар. Әхәт елап, урамга ук чыгып китте. Мин артыннан иярдем. Безнең арттан вожатый белән мәктәп комсомол оешмасының секретаре чыгып:

– Таралышмагыз! Стройга тезелеп килдек, стройга тезелеп кайтабыз! – дип кычкырды. Әхәт аны ишетми, ул елый иде. Мин дә аны кызганып елый башладым.

– Нәрсә булды? – дип сорыйм. Ул яшь аралаш үксеп:

– Әти гаепле. Язгы чәчү вакытында райком вәкиле басуга килеп, ничек чәчәргә кирәклеге турында өйрәтә башлагач, әти аны аты-юлы белән әрләп ташлаган. Аңа, сөт бозавы, маңка син, дигән. Әтиләрнең тракторлары ватылып, төшке ашны да ашамаган килеш шуны төзәтеп яткан чакларына туры килгән булган. Басуда райком вәкилен сүккәнгә күрә әтине коммунистлар партиясеннән чыгардылар. Менә шуның өчен мине дә комсомолга алмадылар. Әти гаепле, – ди. Менә шундый хәлләр дә булды.

Яшь укучылар һәм шәһәрдә туып үскәннәр бу әсәрне укыгач, Айдар абый язганнарга бик ышанып та бетмәскә мөмкиннәр. Әмма бу әсәрдә барысы да дөрес тасвирланган. Чагыштырулары гына ни тора! Түгәрәк имәннең ничек елап авыл ирләрен фронтка озатып, исән кайтканнарны ничек шатланып каршы алулары үзе бер шагыйранә әсәр!

Айдар Хәлимнең Чехословакиядә Татра таулары итәгендәге яу кырында ятып калган әтисенең каберен эзләп табуы үзе бер маҗаралы патриотик әсәр. Әйтегез әле, кем тагын шушындый эзләнүләр һәм үҗәтлек белән әтисенең каберен эзләп таба

алган? Рәхмәт! Айдар абый, Рәхмәт. Әйдә яз, шушындый үткән заманнарның шанлы көннәре турында! Сез язмасагыз, башка язучылар язмаса, үткәннәр турында кем язар? Сез язмасагыз, алар турында киләчәк буын кайдан белер?

**Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛОВ.**
*Башкортстан, Стәрлебаш районы.*

## КӨТЕП АЛГАН ЖУРНАЛЫБЫЗ

Хөрмәтле редакция!

«Казан утлары» журналын «Совет әдәбияты» чагыннан ук алдырабыз, аның елдан-ел үсә баруын тоябыз. Көтеп алабыз, чиратлашып укыйбыз. «Дәвамы бар» дигән әсәрләрне, кадерле кунак шикелле, түземсезләнеп көтәбез. Шундыйлардан Равилә Шәйдуллина-Муратның «Тау башында бүре бар» романы («Казан утлары», 2023 елның ноябрь, декабрь, 2024 елның гыйнвар, февраль саннары). Әсәр кай ягы белән үзенә тарта, укучыга нәрсә бирә? Өмет һәм үз-үзеңә ышаныч, дияр идем. Романда төп образ булган Асиянең үҗәтлеге, сабырлыгы, теләсә нинди хәлләрдә өметсезлеккә бирелмәве, тырышлыгы, максатчанлыгы сокландыра. Кешенең тормышы сынаулардан тора. Шул сынауларда сынмаска, «мин булдырам» дип яшәргә өйрәтә. Авторга сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез.

Соңгы елларда әдәбиятыбыз яңа исемнәргә, яңа әсәрләргә байый бара. Моңа төрле конкурсларның үткәрелүе дә зур этәргеч бирә. Ә аларны укучыга тиз арада җиткерүдә журналның өлеше әйтеп бетергесез зур.

«Сез иң гүзәл кеше икәнсез!» конкурсына җибәрелеп, журналда үз урынын алган барлык язмаларны укып бардым. Үзем күп еллар укытучы булып эшләгәнгәме, әллә Гөлүсә Батталованың әдәби осталыгымы, «Чыра» хикәясе күңелемне тетрәндерде. Бүген дә укучылар алдында басып торгандай тойдым үземне. Минем дә классымда бар иде Айнур кебекләр...

«Чыра» – әдәби әсәр. Укытучы да, укучы да бер-берсен аңлап, уңышка ирешәләр. Хикәя яхшы бетә. Ләкин тормышта гел алай түгел шул. Бүгенге тормышыбызда Айнур кебекләр күпме?!

Кечкенә авылларда, 7-8 укучылы сыйныфларда кимендә 2-3 баланың (исән килеш!) йә этисе, йә әнисе юк (әнисезлек бигрәк куркыныч). Кайсысы Айнур кебек әби белән үсә. Ә шәһәр мәктәпләрендә андыйлар күпме?! «Алия апа» кебек укытучылар бар ул.

Уңышлар сиңа, Гөлүсә сеңлем!

*Хөрмәт белән, ветеран укытучы*
**Гөлзәлифә ӘХМӘТГАЛИЕВА.**
*Актаныш районы, Качкын авылы.*

## БЕРДӘЙ ГОРУРЛАНЫП ҺӘМ СӨЕНЕП...

Бүгенге көндә 100 еллык татар әдәби басма мирасы сәхифәләрен заманча шартларда, ягъни электрон вариантта тәкъдим иткән татарча сайт бармы?!

Мин мондый үрнәкләрне төрек телендә даими күрәм. Соңгы елларда Төркиядә төрле газеталарның күпеллык саннары электрон рәвештә урнаштырылган махсус порталлар игътибарны җәлеп итә. Вакыт-вакыт аларны актарып, Төркия журналистикасы узган юл белән танышып, татар язучыларының, шәхесләренең шуларда басылган төрекчә әдәби әсәрләрен, мәкаләләрен, гәзит аша алып барган полемикаларын укып утырам. Дөрес, андый ресурсларның тулырак булганнары яки инкыйлабка кадәрге басмалар күбрәк урын алганнары дәүләт китапханәләре карамагында, һәм аларга билгеле бер

теркәлүләр үтмичә газета битләрен ачып карармын, димә. Шулай да махсус сайтлар корып, матбугат барлыкка килгәннән бирле дөнья күргән, шул исәптән күптәннән басылмый башлаган басмаларны да кертеп, pdf яки фото форматында интернет киңлекләренә урнаштыру Төркия матбугаты мирасын, тарихын, шулар аша илнең төрле еллардагы көнкүрешен, мөһим вакыйгаларын күзалларга ярдәм итә.

Инде үзебезгә килик. Бездә бармы моңа охшаш хезмәт? Бар! Һәм ул эшне «Казан утлары» башкарды! Электрон архивы 100 еллык әдәби мирасны туплап тора. «Безнең юл», «Яңалиф», «Атака», «Совет әдәбияты» буларак чыккан саннары белән таныша алабыз, иске имляда, латин хәрефләрендә басылганнарын укырга мөмкин. Теләсәң, 20 нче елларны кара, теләсәң, 70 нче елларны... Алай ук еракка китәсең килмәсә, соңгы елларны барла.

Бу электрон архив бер гасырлык булса, анда урын алган меңләгән журналларда чыккан әдәби әсәрләр гасырларны колачлаган әдәби аваз берлеге.

Бүгенге көндә укытучыдан алып, депутатка кадәр, кулына яңа каләм алырга җөрьәт иткән укучыдан башлап, тел-әдәбият галимнәренә кадәр катнашкан әдәби бәйгеләр кайда бара? Җавап кыска: «Казан утлары»нда.

Казанга кайткан саен төрле очрашуларда, чараларда теге яки бу әсәрнең нинди урын алуына кадәр хәтерләп сөйләшүчеләрне очратам. Югыйсә андый нечкәлекләрне автор исендә тотса тотар кебек... Юк, алай гына түгел шул. Укучылар да, авторлар да күзәтә, укый, сыный, чагыштыра... Шул арада яңа авторлар калкып чыга, бөтенләй таныш түгел исемнәр телгә алына башлый. Менә шул рәвешле «Казан утлары» сәхифәләре әдәби җанлылык берлегенә әверелә.

Сайтларын дәвамлы карап барсам да, журналны Казанга кайткач кулга тотып укыйм. Кем әйтмешли, уптым илаһи... Кайчак, 7-8 санын, кайчак бер елныкын, хәтта күбрәкне. Шулай укучылар бармы икән?! Бик кызык ул. Журналның аерым-аерым санына түгел, тоташ бер әдәби агымга чумасың. Менә шунда әдәби буыннар чылбырының дәвамлылыгы күренә. Журналны еллап-еллап укысаң, әдәби буыннар чылбырының табигый берлеге нәкъ менә «Казан утлары»нда саклануын аңлыйсың!

Менә шундый ул – «Казан утлары»! Бер яктан, гасырларны колачлаган әдәби аваз, икенче яктан, хәзерге заманда йөзләгән авторны илһамландырган әдәби җанлылык берлеге. Һәм, тагын да мөһиме – әдәби буыннар чылбыры берлеге.

Чыккан әсәрләрем, бәйгеләрдә алган һәртөрле урыннарым, журналны укучыларның иҗатыма карата олылап әйткән җылы сүзләре белән шушы берлектә булуыма бердәй горурланып, сөенеп һәм һич авырыксынмыйча рәхмәтләр укып язам. Аллаһыма шөкерләр булсын. Әле менә, сүз уңаеннан дигәндәй, Татарстан Республикасы каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе Рәисе белән Татарстан Республикасы Язучылар берлеге оештырган Татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсында урын яулаган әсәрләр дә «Казан утлары»нда басыла башлады. Шул исәптән минем дә «Хикәя» номинациясендә беренче урынны алган «Куеныңда ни бар?» дип аталган хикәям февраль санында дөнья күрде. Бәлки укырга да өлгергәнсездер...

Сүз башында Төркия матбугаты хакында искә алдым. Үзебезнеке белән тәмамлыйсым килә.


Безнең татар матбугатының бер гасырдан артык тарихы бар һәм мәдәни, әдәби, иҗтимагый кыйммәткә ия басмалар бүген дә нәшер ителә. 1905 елдан 1917 елга кадәрге чорда татар телендә егермегә якын шәһәрдә 120ләп татарча газета һәм журнал нәшер ителгән. 2025 елда татар матбугатына 120 ел тулачак.

**Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА.**
*Төркия.*

# ХАКИМЛЕК — ХОДАЙНЫҢ БҮЛӘГЕ ДӘ, АНЫҢ ЛӘГЪНӘТЕ ДӘ

## ФИРДҮС ГЫЙМАЛТДИНОВНЫҢ «УРДА ХАНЫ ҮЗБӘК» (2023) КИТАБЫНА КҮЗӘТҮ

Тәхет, хакимлек, идарә итү темасы хакында уйланулар, фикерләр Фирдүс Гыймалтдиновның «Урда ханы Үзбәк» тарихи романының үзәгенә куелган. Кыска вакыт эчендә ике роман язып, Фирдүс әфәнде татар әдәбияты даирәсен хосусан һәм киң җәмәгатьчелекне таң калдырырга өлгерде. Иҗатчының романнары — «Казан утлары» журналы укучылары өчен дә билгеле әсәрләр. «Буа» романы 2022 елның гыйнвар-март саннарында басылган булса, «Урда ханы Үзбәк» исә 2023 елның гыйнвар-март саннарында дөнья күрде. Басма китап рәвешендә «Буа» романы – 2022, «Урда ханы Үзбәк» 2023 елда укучыларга барып иреште.




«Урда ханы Үзбәк» 2021 елда Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан үткәрелгән конкурсның «Роман» номинациясендә II урынны яулады. Әлеге бәйге татар әдәбияты барышының үзәгендә торган моторга әйләнде дисәк тә, асла ялгыш булмас. Бәйге әдәбиятыбыз күгендә яңа йолдызлар калкыта, шул ук вакытта дәрәҗәле әдипләрне дә яңа әсәрләр язуга кызыктыра. Шуның белән бергә, милләттәшләребезнең әдәбиятка карата кызыксынуын да арттыра, монысы исә әлеге ярышның турыдан-туры вакытлы матбугатта, радио һәм телевидениедә яктыртылуы белән тыгыз бәйле. Шунлыктан, Комиссия тарафыннан үткәрелгән конкурсның эшчәнлеге тукталып калмасын иде, әдәбиятыбызны җанландырып торуын дәвам итсен дигән теләктә торабыз!

«Урда ханы Үзбәк» тарихи романы күләме белән замандашларыннан шактый аерылып тора. Сер түгел, мәгыйшәт тизләнгәннән-тизләнә бара. Бу күренеш әдәбиятны да читләтеп үтмәде сыман, әсәрләрнең күләме кыскара башлады. Мисал өчен шул ук бәйгедә беренче һәм өченче урын алган романнарны китерик. Зөлфәт Хәкимнең «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?» китабы 191 биттән тора, Равил Сабырның «Фәхрине үтереп ташладылар» әсәре 135 битле китапка сыешкан. Фирдүс Гыймалтдинов исә Үзбәк ханның тормышын 359 бит дәвамында бәян итә.

Роман җиде бүлек, пролог һәм эпилогтан гыйбарәт. Әсәр прологтан башланып китсә дә, андагы вакыйгалар фабула буенча ахырда торырга тиеш кебек, чөнки анда Үзбәк ханның үлем түшәгендә ятуы

сурәтләнә, ләкин автор әсәрнең кульминацион мизгелен юкка гына әсәрнең башына куймаган. Әлеге алым укучыны әсәргә беренче биттән үк җәлеп итәргә булыша, аны берникадәр дәрәҗәдә әсәрендереп куя. Әдәбиятыбызның классикасына күз салып, Габдрахман Әпсәләмовның «Газинур» романын искә алсак, шул ук алымга тап булачакбыз. Әсәрнең кульминациясе прологта бирелә. Анда Газинур Гафиятуллинның кылган батырлыгы сурәтләнә. Фирдүс Гыймалтдинов та үзенең әсәрендә әлеге алымны шактый оста файдалана, шул рәвешле укучы да әсәр мохитенә капыл кереп китә: «Урда ханы Үзбәк үлем түшәгендә ята иде. Табигатьнең яме аңа башка кирәкмәс тә, тик ул барыбер үзен бәхетле тоя. Шактый озын гомер кичереп, бу дөньядан үз үлеме белән китәргә насыйп булыр шикелле. Укыган догалары, мөселман өммәтенә хезмәте бушка түгел, димәк».

Роман укучысын Алтын Урда чорына кайтара, вакыйгалар XIV гасырда бара. Кодрәтле мәмләкәт тәхете бик күпләрне ымсындырып тора. Автор шул дәүләт-шөһрәт өчен яшерен көрәшне сурәтли.

Әсәрдә хәрәкәт итүче персонажларның да һәрберсе үзенчәлекле. Үзбәк хан персонажына аерым караш ташлаганда, аның каршылыклы холкы аермачык күренә. Ул ифрат гыйлемле хөкемдар, шул ук вакытта тиз кызучан да, дошманнарга карата рәхимсез дә була ала. Нәтиҗәдә, Үзбәк тулы канлы каһарман буларак, укучы алдына килеп баса, ул аның тормышы өчен кайгырып, йөрәгенә якын алып  әсәрне алга таба укый бирә.

Әсәр барышында укучы Үзбәкнең казанышлары белән таныша бара. Тарих битләренә Үзбәк ислам динен Алтын Урданың рәсми дине буларак кабул итүе, дәүләтнең яңа башкаласы – Сарай әл-Җәдидне торгызуы белән кереп кала. Шул ук вакытта гаять кансыз идарәче буларак та үзен таныта. Тәхеткә утыруга ук, аның хан булуын хуплап тавыш бирмәгән бик күп әмирләрнең гомерен өзә: «Үзбәк хан тәхеткә лаеклы дип санаган бәкләр – уң, шушы көнгә кадәр элеккеге фикерендә калганнар сул якка чыксыннар.

Аптырашта калган чыңгызыйлар, бер-берсенә карап алганнан соң, урыннарыннан зур авырлык белән торып, хан боерыгын үтәргә керештеләр.

– Хан әмер бирә! Кануни хакимгә каршы чыккан мөртәтләрнең башларын кисәргә!»

Ханның утыз елга якын сузылган идарә дәвере дә шулай уза, бер яктан дәүләтне үстереп җибәргән реформалар, икенче яктан төшләренә кереп бетә торган кан диңгезләре…

Эпилогта исә әсәрнең төп каһарманы тәхет хакындагы уйларга чума. Яшь чагыннан ук хакимлеккә ирешергә омтылган Үзбәк үзенең тормышыннан канәгать калдымы соң? Шул сорау ханның күңелен бимазалый: «Йа Раббым, Ходаем, мине саклаган Аллаһым! Миңа озын гомер биргән өчен, сиңа чиксез рәхмәтлемен! Ул гомер эчендә минем янәшәмдәге дусларым-иптәшләрем үлеп бетте. Болай да гомерлек ялгызлыкка дучар бәндәң бүген ятим хәлендә. Минем тәхет сорап ялваруларымны ишеттең, барча теләкләремне кабуллардан кылдың. Ләкин хакимлек өчен шушындый бәя түләргә кирәклеген ул чакта белгән булсам, синнән үзгә язмыш сораган булыр идем…»

Авторның өслүбендә кайсы якларны камилләштереп була соң? Беренче чиратта, кайбер урыннарда әдәби тел нормаларына бик үк сыешып бетмәгән гыйбарәләр күзәтелә: «Һаваны дер селкеткән дөңгер тавышлары астында хан нүкәрләре төз рәтләр белән таң калган халык каршысыннан үтте» җөмләсен: «Таң калган халык каршысыннан, һаваны дер селкеткән дөңгер тавышларына күмелеп, төз сафларга тезелгән хан нүкәрләре атлап узды», – дип, татарчарак әйтеп булыр иде.

«Икенче көнне кенәз Дмитрий, иртүк торып, чиркәүгә җыенды», диясе урынга, «чиркәүгә барырга җыенды» дип өстәп куйсак, текст татарчарак яңгыраш ала.

Икенчедән, әсәрдә Алтын Урда чоры-

на караган тарихи сүзләр җитенкерәми. Алар бөтенләй юк түгел, шулай да тарихи контексттан чыгып фикер йөрткәндә, күбрәк сорала. Мисал өчен, тарихи романнар авторы Нурихан Фәттах язган китапларының ахырында сүзлекчә бирелә – бу әсәрдә сирәк кулланыла торган лексиканың шактый булуын күрсәтә, әсәрнең сүзлек составы ягыннан бай булуын дәлилли. Тарихи романнар язуга алынган иҗатчыларга әсәрне югарырак кимәлгә күтәрер өчен әдиптән үрнәк алу зарур.

«Урда ханы Үзбәк» әсәре – тарихи роман жанрына нисбәтле. Татар әдәбиятында тарихи романнар түрдәге урынны били, дисәк, ялгышмабыз. Иҗади мирасыбызда тарихи роман жанрына караган әсәрләр шактый. Тарихи романнар язу белән танылган әдипләребез дә аз түгел. Билгеле, тарихи роман диюгә үк күпләрнең күз алдына Нурихан Фәттах киләдер. Аның атаклы «Итил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» романнары – мәдәниятебездә тирән эз калдырган шаһәсәрләр. Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан», «Илчегә үлем юк», «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» һ.б. романнары шулай ук китап сөючеләр тарафыннан яратып укыла торган әсәрләр сафында. Бүгенге көндә дә тарихи романнар иҗат итү – татар язучылары өчен табигый күренеш. Шуңа күрә милли әдәбиятыбызда бу жанрга карата билгеле бер таләпләр дә барлыкка килде.

Фирдүс Гыймалтдинов шушы таләпләргә муафыйк булырлык әсәр иҗат иткән. Әлбәттә, әсәр чын тарихта булган вакыйгаларны йөз процент әдәби җирлеккә күчерә дип булмый, ләкин әсәр алдына андый бурыч кую дөрес тә түгел. Минемчә, тарихи роман елъязма да, тарихи документ та, фәнни чыганак та була алмый, ә фәкать шуларга нигезләнеп, авторның әдәби уйдырмасы, иҗади фаразы белән баетылып тудырылган сүз сәнгате әсәре булырга тиеш. Авторның бу тема белән кызыксынганы да ачык тоемлана, ул үзе дә әлеге тарихи катламны кимендә 5 ел дәвамында өйрәндем, дип раслый, һәм сүзенең хаклыгы да тексттан ук бөркелеп тора. Кайбер детальләрнең бөтен вак-төяге белән бирелүе, теге яки бу фактның тарихи җирлегендә тәмле итеп тасвирлануы да аның фәнни әйләнештә булган барлык материалны җентекләп өйрәнеп чыкканлыгын дәлилли. Чынбарлык белән чагыштырганда, әсәрдә аермалар була ала, билгеле. Алар әсәрне әдәби яссылыкка күчерер өчен әсәрнең эстетик завыгын югарырак күтәрү өчен зарур (мәсәлән, Кара образын кертү һ.б.). Автор моңа ирешкән дияргә кирәк.

**Ихтыяр КЫЯМОВ,**
*Казан федераль университетының I курс студенты, КФУның «Рухият» түгәрәге әгъзасы, татар теленнән X халыкара олимпиаданың Гран-при иясе.*

# МИЛЛӘТНЕ АВЫЛ САКЛАП КАЛАЧАК

*«Россиянең татар авыллары ассоциациясе» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы рәисе Фәнир Галимов халыкка җәмәгать эшлеклесе, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, җырчы, җырлар авторы, эшмәкәр буларак та таныш. Әлеге әңгәмәдә аның белән проектлар, тел мәсьәләсе һәм авыл язмышы турында сөйләштек.*

**– Соңгы елларда илебезнең төрле төбәкләрендә яшәүче милләттәшләребез тарихи хәтеребезне яңарту, аны яшьләргә күрсәтү максатыннан шактый игелекле эшләр башкарды, төрле чорлардагы татар авыллары күренешләрен гәүдәләндерүче татар утарлары, татар ишегаллары булдырылды. Түмәнәк авылы янында да шундый тарихи урын төзелде. «Бабай утары» проектының идеясе ничек туды?**

– Әлеге идеяне миңа оныкларым әйтте дияргә мөмкин. Шимбә-якшәмбе кунакка килгәч, мин аларга кич белән әкиятләр түгел, ә бабаларыбызның ничек яшәве турында сөйлим. Алар ышана алмыйлар: «Ничек инде салам түбәле өйдә яшәгәннәр? Телевизорлар да булмаганмы? Ә телефоннар?» – дип сорыйлар. Шулай итеп, «Бабай утары»н төзү теләге туды.

Сүз уңаеннан, без биш ел буена архив документларында казындык, йортларның элек ничек булганын өйрәндек һәм шул тарихи язмаларда мәчетләрнең дә телгә алынуын күрдек. Архив материалларына ышансак, Түмәнәктәге беренче мәчет XVIII гасыр башында салынган булган. Гомумән алганда, әлеге җирлектә өч мәчет турында мәгълүмат бар. Кайчандыр беренче мәчет урнашкан урында без хәзер бар авыл белән яңасын төзеп куйдык.

«Бабай утары»нда без, XVII гасырдагыча итеп, салам түбәле өйләр тергездек. Күптән түгел ачык һавада музей ачтык. Чувашиядән 150 еллык җил тегермәнен алып килдек. «Бабай утары»нда хәзер экскурсияләр ясыйбыз. Балаларга ипинең ничек пешерелүен күрсәтәбез, хәтта мастер-класслар да үткәрәбез. Кунаклар өзелми, алар бездә ике-өч көнгә, кайчак озагракка да туктала.

**– Комплекс белән яшьләр кызыксынамы, танышырга киләләрме?**

– Безнең максат шулай ук авылыбызның 325 еллык тарихын шушы этнографик комплекста чагылдыру иде. Бабайларыбыз XVII гасыр якларында безнең авыл урынына Татарстанның Минзәлә районыннан килеп утырган. Шуннан алар йорт-хуҗалык булдырып яши башлаган. Күчеп килгән 7-8 гаиләдән башлангыч алган авылда бүгенге көндә 1250 кеше, 500 гә якын йорт бар. Тагын 150 йорт салу өчен җир бүлеп бирелде. «Бабай утары»нда XVII гасырдан алып, XXI гасырга, ягъни бүгенге көнгә кадәр тормыш итүнең эволюциясе күрсәтелгән. Аны үзебезнең һәм күрше районнардан килеп карамаган кеше калмады. Мәктәпләр, балалар бакчалары да килә, кызыксына. Балаларга сөйләп аңлатып булмый, ул тотып карарга, күрергә тиеш. Безнең бабайлар шундый тәбәнәк агач йортларда яшәгән дисәк, бала аны аңламый. Ә үз күзләре белән күрү – икенче нәрсә. «Карале, бабайлар кайда җан асраган, ә мин хәзер нинди сарайда яшим» дип фикер йөртә ала.

**– Хәзер нинди җәмәгать эшләре белән шөгыльләнәсез?**

– Без үзебезнең Башкортстанда инде җиденче ел рәттән балалар өчен «Сәләт» лагерен оештырдык. Аның төп юнәлешләренең берсе, әлбәттә, телне үстерү. Анда үткәрелгән дәресләрнең 60 проценты татар телендә алып барыла. Минем әлеге проектка алынуыма милләт балаларының ана телебезгә игътибары кимүе этәргеч бирде. Оныкларым өчен дә ояла башлаган идем. Минем белән рус телендә сөйләшергә керешсәләр, эчем поша. Мин сезне аңламыйм дип, үзем алар белән татарча сөйләшергә,

аларны өйрәтергә тырышам. Ә инде Татарстандагы «Сәләт» аланнарын күргәч, үзебездә дә бу изге эшкә алынырга булдык. Нәтиҗәләр дә бар инде. «Сәләт» аланына бер мәртәбә аяк баскан балалар икенче елны да, өченчесендә дә килде. Әлеге лагерь табигатьнең хозур төбәгендә урнашкан. Бу үзе үк күңелле һәм рәхәт ялга мөмкинлек тудыра. Әмма балалар ял итеп кенә калмый, көн буена әллә күпме шөгыльләр таба. Һәммә чаралар белемнәрне арттыруга һәм сәләтләрне үстерүгә юнәлтелә.

**– Моннан тыш, сез әле Бөтенроссия татар авыллары ассоциациясе рәисе вазифасын да башкарасыз. Бүгенге көндә авылны саклап калуның нинди юлларын күрәсез?**

– Авылны саклап калу өчен телебезне сакларга кирәк, телне саклау өчен авылны сакларга кирәк. Шәһәрдәге кеше, ни әйтсәң дә, русча сөйләшә инде ул. Шәһәр тирәсендәге авылларда да балалар күбрәк русчага күчә әле. Үземнең дә милли хисләрем илле яшькә җиткәндә генә уянды. Аңа кадәр механик булып эшли идем. Мәктәпне тәмамлагач, укырга чыгып китәргә җыенам, Бибинәкыя әбием мине җибәрмәскә исәпли бит. «Улым, кая барасың? Фермада эшлә! Дуга кергән йортка дога керә, диләр. Авылда кал!» – дип, каршы төште. Ул вакытта укымыйча да булмый иде, әмма әбинең догалары кабул булды, барыбер туган авылыма ярдәм итеп торам. Минем кебекләр күп булды. Хәзер исә яшьләр китми дә. Әле соңгы елларда гына да Төмәнәктә тагын берничә йөз ихатага урын бүленде, дидем бит, күбесе – үзебезнең авыл яшьләре. Йорт салалар, кайберләре әти-әниләре белән яшәп кала. Кош-корт асрыйлар, яшелчә, җиләк-җимеш үстерәләр. Фермер булып китәләр яисә шәһәргә йөреп эшлиләр. Бу – бер. Икенчедән, авылда яшәгән кеше чиста ризык ашый. Сәламәт туклану проблемасы хәзерге заманда көннән-көн кискенләшә бара. Милләтне авыл саклап калачак, дигәндә, мин менә шушыны да күздә тотам. Хәзер шәһәр кешесе экологик яктан чиста ризык эзләп, авылга кайта. Безгә сәламәт буын үстерергә кирәк. Мин үзем ишегалдындагы чирәмдә яланаяк йөрергә яратам. Кич белән шәфәкъ кызыллыгын күзәтеп, капка төбендәге эскәмиядә утырам. Менә шунда бөтен тән ял итә, уйлар тәртипкә килә. Өченчедән, әдәбиятны онытып барабыз. Милләтне әдәбият та саклый бит әле. Язучылар авылдан чыга иде. Хәзер менә бу турыда «иде», дип сөйләшәбез...

**– Чит төбәкләрдә дә танылу алган татар атларын үрчетүчеләр бармы хәзер?**

– Ат булган җирдә татар бар, татар булган җирдә ат бар. Татар аты чыдам, бу генетик яктан да расланган. Әмма соңгы елларда бу терлекне асраучылар кими. Татар атларының данын киләчәктә дә бөтен галәмгә танытуда җитәкчелек ярдәм күрсәтер, дип өметләнәбез. Башкортстанда ат җене кагылган егетләр шактый. Татарстанның Лениногорск районында да нәселле татар атларын үрчетүче бар. Фәрит дустым терлекчелек өлкәсендә бик уңышлы эшләп килә. Мин үземнең коллегаларга – эшмәкәрләргә нәселле татар атларын үрчетү юнәлешендә эшләргә киңәш итәм. Ике республика җитәкчеләре дә татар атларын үрчетүгә йөз белән борылсын һәм эшмәкәрләргә ярдәм кулы сузсын иде.

**– Сез «Төмәнәк» Татар иҗтимагый үзәген дә ачтыгыз. Анда бүгенге көндә нәрсәләр эшләнә, нинди эшчәнлек алып барыла?**

– Телләр мәсьәләсе көн үзәгенә чыкканнан соң, нидер эшләргә кирәк иде. Өйдән урамга чыгып киткән бала русча сөйләшә башлый. Телне ничек тә саклап калырга ярдәм булсын дип, Туймазыда «Төмәнәк» Татар иҗтимагый үзәге ачарга булдык. Анда студиябез бар. Гармун уйнау түгәрәге эшләп килә. Якшәмбе мәктәбендә балалар татар милли ашларын пешерергә өйрәнә. Соңгы вакытта икешәр төркем җыябыз. Шул базада безнең «Тәртип» радиосы да эшли. 70, 80, 90нчы еллар җырчылары иҗатларын куеп, шагыйрьләрнең шигырьләрен укып, җан азыгы бирә ул дулкын. Район җитәкчесе дә хуплады моны. Бу юлда да дөрес барабыздыр дип ышанасы килә.

*Әңгәмәдәш* – **Алинә ХӘБИБУЛЛИНА.**

## Мәхмүт Хәсәнов хаты

*1977 ел, 2 февраль*
*Азнакай*

Марсель туган, саумы!

Чукынып китсен инде, Мәхмүт дядяңа да 50 тулып килә бит. Чын әгәр! Ышанмасаң, менә паспортыма багып кара!

Кыскасы шул, бүлмәдәш дустыбызны[1] култыклап аласың да, «Казан –Уфа» поезды ресторанына кереп утырасыз. «Бөгелмә» дигән станциягә җиткәч, тиз генә расчёт ясап төшеп каласыз.

Атап чакыруым шушы. Көтәм.

*Сәлам белән, М.Хәсәнов.*

## Укытучы Рафика апа хаты

*1979 ел, 1 июль*

Марсель!

«Еллар чалымы» өчен, аны шулай зурлап, аерып алуың өчен беренче рәхмәтем.

Бер генә юлын да игътибарсыз укымадым һәм якын укучымның уй-хисләре, моңлы авазы итеп кабул иттем, бик яраттым.

Сине бу шигырьләрең өчен нык мактасам, горурланып китеп, юлыңны саташтырмассыңмы?! Чыннан да, алар йөрәк җылысы белән сугарылганнар, котлыйбыз үзеңне беренче уңышың белән!!!

Ышанып әйтә алам, бу юлбашына сыйган шигырьләрең, сине якын күрүче дусларың һәм туганнарыңны нык сөендергәндер.

Синең бу шигырьләрең кешеләргә ихтирамлы йөрәгең, бөтен дөньяны яратырлык табигатең барлыгын, икенче төрле әйткәндә, киләчәккә омтылышың, үзең сайлаган – олы җанлылар атлый торган туры сукмагың бар дип әйтергә ышаныч бирә. Амин!

Шигырьләреңдә дөньяны, тормышны, дус-ишләргә карашыңны табигатькә бәйләп, чагыштырып аңлатырга тырышуың куандыра.

Тагын шунысы ошады: аз гына сүзләр белән күп мәгънә бирергә тырышу. Бу сиңа күптәннән хас сыйфат.

Марсель, сер итеп кенә шуны әйтәм: син бу юлны сайлап ялгышмагансың. Чөнки һәр тырышканың кешеләргә синең исемнән эзең булып кала. Бу бәхет бар кешегә дә бирелми, аңа куану гына аз, саклый белү дә кирәктер.

Исемсез килдек дөньяга
Исем алып китәргә!

Мин барлык язучыларның да шигырьләрен укып бара алмыйм. Ләкин Хәсән Туфанның шигырьләре күңелгә бик якын. Сине дә «яшь Хәсән үсә...» дисәм, ялгыш булмасмы? (Масаймасаң, ярар иде дә).

Синең шигырьләрең аша үз хисләреңне, дөньяга карашыңны аңлатуда үз стилең бар дип уйлыйм. (Белгеч түгелмен, әлбәттә).

«...я-га», «Әй» дигән һәм башка шигырьләреңне дә «үземчә» аңладым һәм рәхмәт шундый юллар иҗат итә алуыңа.

[1] Разил Вәлиевне күз уңында тота.

Марсель! Без – синең укытучыларың, дусларың, якыннарың беренче шигырьләр җыентыгың белән котлыйбыз! Аны синең алга караган зур тәрәзәң итеп кабул итәбез. Казанда узган хезмәт елларың бушка китмәгән икән.

Киләчәккә дә теләкләр белдерәбез. Иң зурысы: юлыңнан тайпылмаска, аягыңда нык басып тору өчен алга омтылырга (билгеле, бу зур кешеләр теләге, чөнки гомер иткән кешеләр кебек язасың һәм безнең теләкләрне ишетергә хаклысың). Икенчесе: хезмәтеңдә иҗади уңышлар, тыныч һәм бәхетле хезмәт, зур сәламәтлек һәм бәхетле семья тормышы телибез!

Соңгарак калып җавап бирүем өчен гафу үтенәм. Җавабым башта ук язылган иде. Җибәрү өчен иркенрәк вакытны көттем, авылда... үзең беләсең.

*Ярый, Марсель, сиңа тагын бер кат уңышлар теләп,*
*күп сәламнәр белән укытучың Рафика апаң.*

## Нурихан Фәттах хаты

*1982 ел, 28 июль*
*Казан*

Марсель галиҗәнаплары!

Күптин-күп, чуктин-чук сәламнәр сезләргә безләрдән.

Мин әлерәк кенә авылдан кайттым. Кайтсам, синнән хат килгән. Хатың күңел төшерә торган күңелсез хәбәр китермәгән. Безне әнә поляклар, венгрлар укырга атлыгып торалар икән. Ләкин, Марсель дус, минем бер дә андый эш белән шөгыльләнәсем килми, егылып «иң яхшы хикәя» сайлау белән. Минем өчен иң яхшы булган хикәя сезнең өчен иң начары булырга мөмкин.

Шуңа күрә мин бу эшне тулысынча сезгә, ягъни төзүчеләргә (яисә төзүчегә) тапшырам. Дөрес, бу сезгә өстәмә эш йөкли инде. Ләкин шулай да төзүче үзе сайласа, яхшырак булыр кебек. Минем хикәяләр күп түгел. Басылганнары билгеле. Иң соңгы басма «Яшь чакларда» дип атала (1967 ел). Бик ачуың килсә, «Артта калган юллар»ны сайлый аласың. Анысы журналда гына басылды (КУ, 1967 (65?)). Сайлап алган хикәяне берәр машинисткадан чәкеттереп алырга була. Үзем түләрмен.

Мине искә төшерүең өчен, яхшы хикәяләр, романнар көтүең өчен, әлбәттә, бик зур рәхмәт, ләкин җыентык мәсьәләсендә шуннан да күбрәген эшләп булмас кебек.

Сезнең барыгызга да күп сәламнәр һәм изге теләкләр белән Нурихан абзагыз дип белерсез.

## Әсрар Галиев хаты

*1982 ел, 21 август*

Марсель туганкай!

Хатыңны алдым! Рәхмәт! Повесть бик аскы папкага эләгеп, югалып ятмыймы икән дип, Робертка язган идем. Ул аны сиңа әйткән, күрәмсең. Хәбәрең өчен янә бер рәхмәт! Инде сөенечле хат көтеп калам. Күз яше белән язган әйберем бит, бик тә бастырасым килеп яшим.

Үземдә үзгәреш юк. Эшлим, яза торам. Нәшриятка 550 бит күләмендә «Нурлар» исемле җыентык тапшырдым. 3 повесть. Хәзер яңа повестька тотындым.

«Ерак урман авазы»н яратып укып чыктым. Уңышларыңа сөенәм. Ни әйтсәң дә, яшь аермасы булса да, без бит әле бер чор сабакташлары. Мин һәр дусның уңышларына сөенеп яшим.

*Үзеңә, Робертка, Мөсәгыйткә һәм*
*башка егет-кызларга кайнар сәламнәр илә Әсрар.*

## Илшат Шакирҗанов хаты

*1986 ел, 17 июнь*
*Биектау, Ямаширмә*

Хөрмәтле редакция!

Мин Биектау районының Ямаширмә авылында яшим һәм «Казан утлары» журналын даими рәвештә укып барам. Быелгы июнь санын укыгач, кулыма каләм алырга һәм Сезгә шушы хатны язарга уйладым. Моңа мине Марсель Галиевнең бу санда басылган «Сатурн һәм умач» хикәясе мәҗбүр итте.

Әсәрнең сәнгатьчә эшләнеше һәм хәзерге Совет әдәбиятында тоткан урыны турында әдәбият белгечләре, әлбәттә, үз фикерләрен әйтерләр. Фәнни күзлектән караганда, минемчә, хикәядә берничә астрономик хата җибәрелгән. Әсәрдән өзек китерәм: «Әнә Сириус альфасы талпынып-талпынып яна. Ниндидер кодрәтле кул учлап сипкән шикелле бакый ераклыкта тоныкланып, Орион йолдызлыгы күренә...»

Билгеле булганча, Сириус – күкнең көньяк ярымшарындагы иң якты йолдыз. Сириус йолдызлык исеме түгел, ә бәлки йолдызның үз атамасы һәм грекчадан тәрҗемә иткәндә, «Эт йолдызы» дигәнне аңлата. Сириус Зур Эт йолдызлыгына керә, һәм бу очракта «Зур Эт альфасы Сириус» дип әйтү дөрес булыр.

Әсәрнең төп герое – астроном Камил Акчурин. Аның балачак хатирәләрен, туган туфрагын сагынып, туган авылына кайтуы хикәянең төп сюжет линиясе булып тора. Хикәядә сурәтләнгән мәтрүшкәләр өлгерү, бәрәңге матиклау эпизодларыннан чыгып, бу, һичшиксез, июнь-июль айлары булырга тиеш.

Татар әдәбиятында йолдызлы күкне тасвирлаганда, Җидегән йолдызлыгын сурәтләүләр күп булды. Бу, бер яктан караганда, үз-үзен аклый да, чөнки Җидегән елның теләсә нинди вакытында йолдызлы күкне бизәп тора. Ә хәзер төп герой Камил Акчурин әсәрдә сурәтләнгән йолдызларны күрә алдымы икән дигән сорауга җавап эзләп карыйк.

Зур Эт һәм Орион йолдызлыклары күк экваторыннан көньяктарак урнашканнар. Алар икесе дә сентябрь урталарында таң алдыннан күкнең көнчыгыш өлешендә күренә башлыйлар һәм декабрь-гыйнвар айларында төн урталарында горизонт сызыгыннан иң югары күтәрелеп күренәләр. Апрель урталарында бу йолдызлыкларны Кояш баегач, аз гына вакытка күкнең көньяк-көнбатыш өлешендә күрергә мөмкин. Җәй айларында исә әлеге йолдызлыклар бөтенләй күренми.

Шулай итеп, әсәрдә геройның июль уртасында Орион һәм Сириусны күрүе авторның фантазиясе булып тора һәм фактлар белән расланмый. Бу очракта җәй айларында зенитта була торган Вега (Лира альфасы), Альтаир (Бөркет альфасы) яки Денеб (Аккош альфасы) йолдызларын сурәтләү урынлы булыр иде.

Сезгә ихтирам белән, Казан дәүләт университетының физика факультеты студенты Илшат Шакирҗанов.

## Нур Сафиуллин хаты

*1989 ел, 15 сентябрь*
*Харьков*

Хөрмәтле Марсель иптәш Галиев!

Сезнең карамакка менә шушы кульязмамны җибәрәм. Ул сугыштан соң яза башлаган повестьның өзеге. Сезгә билгеле булсын, бу минем беренче тапкыр гына каләм тибрәтеп маташуым түгел. Сугышка кадәр балалар өчен язган: «Кечкенә Карл», «Кара диңгез буенда», «Аларның да йортлары бар» дигән китап кебек нәрсәләр бастырып чыгарган идем. «Яшь ленинчы» газетасында, «Совет әдәбияты» журналында хикәяләрем, очеркларым басылып чыккан иде. Еш кына радио аша да

үземнең әсәрләремне укый идем. 1941 елда Ватан сугышына киттем. Аны башыннан азагына кадәр үтеп, исән-сау өйгә әйләнеп кайттым. Аяк-кул таза, баш үз урынында булгач, яра кебек нәрсәләр исәпкә алынмый инде. Армиядән демобилизацияләнгәннән соң, химия фәннәре белән шөгыльләнә башладым. Диссертацияләр яздым, чөнки мин сугыш алдыннан Казан химия-технология институтын бетергән идем.

Хәзер мин Харьковта институтта укытам. Шулай да аз-маз язып маташам. Башта яңадан яза башларга соң инде дип, озак кына язмый тордым. Бервакытны «Литературная газета»да «Олы яшьтәге яшь язучы» дигән бер мәкалә күзгә чалынды. Аны укыгач дәртләнеп киттем. Алай булгач, миңа да язарга мөмкин икән әле дип уйладым. Баштан үткәннәрне искә алып, повесть яза башладым. Бу өзек – аның беренче бүлеге. Ул сезгә ошар микән, белмим. Үткән җәйне берничә көн Казанда булган идем. Шул чакта Сезнең белән танышырга уйлап, Татарстан Язучылар союзына кердем. Үкенечкә каршы, Сезне күрә алмадым. «Авылларга чыгып китте», – диделәр. Хәзер инде читтән торып, Сезнең карарны көтәм.

Текстка күп кенә төзәтмәләр кертелгәнне гафу итегез. Бездә татар хәрефләре куелган язу машинкасы юк. Шуңа күрә рус хәрефләре куелган машинка белән генә тукылдатырга туры килде.

*Хуш-сау булыгыз. Тирән ихтирам белән, Нур Сафиуллин.*

## Минтимер Шәймиев хаты

*2006 ел, 3 март*
*Казан*

Марсель!

Исеме җисеменә тәңгәл килеп торган «Рух» китабыгыз дөньяга чыгу белән ихлас котлыйм.


Күләме белән генә түгел, аһәңе, менә дигән фәлсәфи яңгырашы белән бик тә саллы бу китапны укыган кеше аның фикер, тел байлыгына сокланмый калмас дип уйлыйм.

Мин үзем Сезне моңа кадәр дә Әмирхан ага Еники кебек җәүһәр телле язучы дип белә идем. Инде менә моңа тагын бер кат инандым. Мәшһүр шәхесләребезнең портретларына килгәндә, Сезнең мемуар жанрына тартым бу бик кызыклы күзәтүләрегездән тирән милли рухлы халкыбыз иҗатчыларының уртак сурәте калка. Һәм йөрәккә ята.


Китабыгыз өчен рәхмәт. Үзегезчә әйткәндә, тел коегыз саекмасын, җан чишмәгез тулы сулы булсын.

*Ихтирам белән,*
*Минтимер Шәймиев.*

# ӘДӘБИ СКАНВОРД



Язучы Ләбибә ...
Зөфәр Хәйретдинов җырындагы үсемлек
Фатих ... (язучы, педагог, журналист)
... Кунанбаев
Дәрҗия... (балалар язучысы)
Шагыйрь Рәшит ...
«Робинзон Крузо» романы авторы
Фин-угор халкы
«Чук һәм ...» (Аркадий Гайдар)
... өмәсе
... де Бальзак
Таләпләргә җавап бирерлек
Хәй Вахит комедиясе
... Дангулов (рус язучысы)
Шомырт (диал.)
Россия кинопремиясе
Отышлы уен
... Гыйбадуллина
Шагыйрь Эдуардас Межелайтисның Ватаны
Разил, Диас, Равил
Уразада авыз ачу мәҗлесе
Прозаик, шагыйрь ... Сафин
1907 елда Оренбургта чыккан татарча журнал
Танылган рус шагыйре
... Эюпова (мәдәният министры)
... Гыйләҗев
Рәссам ... Шәйхетдинов
Камил Мотыйгый пьесасы
Габдерәхим ... Имәни
Әтнә районындагы авыл
Шагыйрь, прозаик ... Шәфигуллин
Шагыйрь Илдар ...
Усманов, Мирзаянов
Әмирхан Еники повесте
Рәсүл Гамзатовның милләте
«Башсыз җайдак» романы авторы
сиртмәле ...
... де Мопассан
...-Вегас
... Ошанин (рус шагыйре)



**Рәис ГАБДУЛЛА** *төзеде*

***Үткән санда чыккан сканворд җаваплары. Сулдан уңга:*** *Барлас, джаз, «Картуф», Ашыт, Рой, «Яшен», тип, багу, «Мират», Ермак, «Зоя», Әсән, Харис, «Зар», Төхфәтуллин, Икар, сармат, Римма, Садә.* ***Өстән аска:*** *Эдгар, Бәрхәт, Шота, Бакый, Генрих, Азат, Нур, фиорд, мәсләк, латыш, Мас, тасма, Ерикәй, урам, Сафин, рас, «Таз», «Золым», литота, Анд, Ринат.*

*Әмирхан Еникинең тууына – 115 ел*

# ЗАТЛЫ КАЛӘМНӘН ЗАТЛЫ ЭЗ КАЛА



Күренекле әдип-прозаик, Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әмирхан Еникинең (1909–2000) тууына 115 ел тулды.

Сугыштан соңгы еллардан алып бүгенге көнебезгә кадәр ничәмә-ничә буын әдәбият сөючеләрнең күңелен иркәләгән, елаткан, уйлаткан язучы әле дә арабызда кебек, чөнки аның сүзенә, фикеренә, әсәрләренә салынган хис-тойгыларга без әле дә мохтаҗ, алар шушы көндә дә кирәкле. Әдипнең «Саз чәчәге» (1955), «Йөрәк сере» (1957), «Рәшә» (1962), «Вөҗдан» (1968), «Без дә солдатлар идек» (1971 ), «Гөләндәм туташ хатирәсе» (1975) кебек повестьлары, «Ялгызлык» (1957), «Туган туфрак» (1959), «Матурлык» (1964), «Төнге тамчылар» (1964), «Коръән хафиз» (1964), «Әйтелмәгән васыять» (1965), «Курай» (1970), «Тынычлану» (1978) кебек хикәяләре китапханәләрдә дөнья әдәбияты классикасы киштәсендә урын алырга хаклы.

Ә.Еники юмор остасы, публицист, тәрҗемәче буларак та әдәбиятыбызда онытылмас хезмәт калдырды. Украин язучысы О.Гончарның «Знаменосцы» («Байрак йөртүчеләр», 1951 ) романы, А.Островскийның «Без вины виноватые» («Гаепсез гаеплеләр», 1953) драмасы, М.Бубенновның «Белая берёза» («Ак каен», 2 нче кисәк, 1954) романы, К.Паустовскийның хикәяләре (1960), Э.Казакевичның «Синяя тетрадь» («Зәңгәр дәфтәр», 1964), Ч.Айтматовның «Беренче мөгаллим» (1965) повесте һәм СССР халык әкиятләренең байтагы белән без нәкъ менә Ә.Еники тәрҗемәсендә туган телебездә таныштык. Хәер, аның үзенең дә төп әсәрләре рус теленә һәм башка милли телләргә тәрҗемә ителгән.


Әдипнең юбилее уңаеннан Татарстан радиосында күп кенә кызыклы тапшырулар көтелә. Әлбәттә инде, аларны әзерләгәндә, архив материаллары да актив кулланылачак. Әйтик, Г.Камал исемендәге ТДАТ артистлары катнашында «Шаяру» (1968), «Бер генә сәгатькә» (1975) хикәясе буенча куелган радиоспектакльләр эфирга әзерләнә. 1967 елда куелган «Төнге тамчылар» радиотамашасы да тыңлаучылар күңеленә хуш килер, дип өметләнәбез. Биредә Нәҗип Гайнуллин, Рауза Хәйретдинова, Мәрзия Миңнебаева, Вера Минкина, Ринат Таҗетдинов кебек татар театрының олпатлары катнашкан.

Ирек Баһманов язмасында «Матурлык» (1969), «Әйтелмәгән васыять» (1999), Алсу Гайнуллина һәм Айрат Арсланов укуында «Бала» (1995) хикәяләре бүгенге тыңлаучыларның да күңелен дулкынландырмый калмас.

Журнал укучылар игътибарына без әдипнең «Курай» исемле хикәясен тәкъдим итәргә булдык. Ул бу әсәрне 1999 елда Татарстан радиосы студиясенә килеп, үзе укыган иде һәм бу язма «алтын фондыбызда» кадерләп саклана. QR-код ярдәмендә «Казан утлары» сайтына кереп, безгә тиңсез мирас калдырган олпат милләттәшебезнең газиз тавышын ишетик.

*Әнвәр Давыдовның тууына – 105 ел*

# КЫСКА ГОМЕР, ОЗЫН ЮЛЛАР ҮТКӘН ӘДИП



Быел март аенда танылган шагыйрь Әнвәр Давыдовның (1919–1968) тууына 105 ел тулды.

1990 еллар ахырында коллегабыз, күренекле журналист Минвагыйз Зәйнетдинов «Шигъри төбәккә сәяхәт» дигән тапшырулар шәлкеме әзерләгән иде. Ул вакытта автор безне Самара өлкәсенең Камышлы төбәгенә, Зыя Ярмәки, Халикъ Садри, Әнвәр Давыдов, Рөстәм Мингалимнәрнең туган бишеге булган, аларның иҗатында, шигырьләрендә җырланган Сок елгасы, Касады су буйларына эфир дулкыннарында сәфәргә алып чыккан иде. Менә шул тапшыруларның берсе Камышлы авылы, татар поэзиясендә үз урынын алган шагыйрь Әнвәр Давыдов турында иде. Шагыйрьнең 105 еллыгын билгеләп үтә торган көннәрдә, без әлеге тапшыруны кабатларга булдык.

Бу язма тагын шунысы белән дә кадерле: биредә шагыйрьнең үз тавышы бар, анда әдипләребездән язучы Хисам Камал, Әхсән Баян һәм Рөстәм Мингалим, шагыйрьнең туганнан туган энесе Альберт Нарбеков катнашкан булган. Хәзер инде исемнәре телгә алынган әдипләр үзләре дә бакыйлыкта, газиз тавышларын ишетеп, аларны да юксынырбыз.

Әлеге язмадан соң журнал укучылар игътибарына Әнвәр Давыдов шигырьләренә язылган җырлар тәкъдим ителә. Алар күп түгел, әмма әгәр игътибарлы җырчы табылса, әле бүген дә татар эстрадасының «йөзек кашы» булырлык әсәрләр. Мәсәлән, шагыйрьнең шигыренә Алмаз Монасыйпов иҗат иткән «Казаным» җыры үз вакытында өч күренекле җырчының даими репертуарында булган. Ул 1958 елда – Нияз Даутов, 1981 елда – Ренат Ибраһимов, 1987 елда Рафаэль Сәхәбиев тарафыннан магнитофон тасмасына яздырылган. Аллаһияр Вәлиуллин көйгә салган «Ике кыз такмаклары» алтмышынчы-җитмешенче елларда Венера Шәрипова һәм Фагыйлә Тимерова тарафыннан зур концертларда башкарылып, халык арасында гаҗәеп популярлык казанган. Әлеге җыр 1968 елда безнең студиядә яздырып алынган. Сөекле җырчыбыз Әлфия Авзалова язмасындагы «Яратам дисең син» (Алмаз Монасыйпов музыкасы) әле дә бик күп милләттәшләребезнең күңел түрендәдер.

Инде әйдәгез, тапшыруның авторы Минвагыйз ага Зәйнетдиновка фәнни-популяр дәреслеккә тиң шушы олы хезмәте өчен ихлас рәхмәт әйтеп, язманы тыңлыйк.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

### ҖӘЛИЛНЕҢ ТУГАН КӨНЕНДӘ

15 февраль – каһарман-шагыйрь Муса Җәлилнең туган көнендә әдәбият-сәнгать әһелләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, әдипнең иҗатын яратучылар Казанда 1 Май мәйданындагы һәйкәленә чәчәкләр салдылар. Шул көнне ТР Милли музее фондларыннан Җәлил шигырьләре тупланган «Моабит дәфтәрләре»нең төп нөсхәсен чыгардылар. Кыйммәтле экспонатны музей заллары буйлап Россия Герое Рәсим Баксиков алып барды.

Музейдагы тантанада ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, ТР Милли музее генераль директоры Алисә Вяткина, Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗанов, җырчы Илүсә Хуҗина һ.б. чыгыш ясады. Чараларда Башкортстаннан килгән бер төркем каләм ияләре дә катнашты.

### ШӘЙХИ МАННУРНЫ ИСКӘ АЛДЫЛАР

Мамадыш районында күренекле язучы Шәйхи Маннур истәлегенә багышланган чаралар узды һәм аның исемендәге премияләр тапшырылды. Быел бу бүләккә шагыйрә Дания Нәгыйм, Мамадыш районы үзәкләштерелгән китапханәләр системасы, Мамадыштагы 5 нче «Бәләкәч» балалар бакчасы тәрбиячесе Гөлия Сөнгатуллина, Казандагы 186 нчы мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Алия Мөбарәкшина лаек булды. Шәйхи Маннурны искә алу чараларында Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, Татарстанның халык шагыйрьләре Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев, язучылар Ринат Мөхәммәдиев, Ләбиб Лерон, Амур Фәлах, Мансур Сафин, Рәкит Аллабирде, Рафаэль Газизов, Минневарис Мингалиев, әдәбият галиме Әлфәт Закирҗанов, галим-текстолог, нәкышче Нәҗип Нәккаш һ.б. катнашты. Кунакларны Мамадыш муниципаль районы башлыгы Анатолий Иванов сәламләде.Ул шулай ук Ш.Маннур премиясенең быелгы лауреатларын котлады.

### ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе утырышы булды. Анда ике идарә арасында башкарылган эшләргә хисап ясалды. Татарстан Язучылар берлегенең 90 еллык юбилеена әзерләнү турында фикер алышу булды. Идарә әгъзалары Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә берлекнең иҗат остаханәләренең берләштерелгән утырышында тәкъдим ителгән Рафис Корбан, Марат Әмирханов, Рәфкать Кәрами, Ләис Зөлкарнәй һәм берлекнең Чаллы бүлеге аша кергән Айдар Хәлим кандидатураларын карадылар. Утырышны алып баручы, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла олы бүләккә кандидат итеп ике язучыны – бер шагыйрь белән бер прозаикны үткәрү тәкъдиме белән чыкты. Әмма яшерен тавыш бирү нәтиҗәсендә прозаикларның берсе дә җитәрлек тавыш (нигезләмә буенча утырышта катнашучыларның өчтән икесенең яклавы кирәк) җыя алмады. Шулай итеп, Татарстан Язучылар берлегеннән Г.Тукай премиясенә кандидат итеп шагыйрь Ләис Зөлкарнәй тәкъдим ителде. Утырышта әдәби премияләргә дә кандидатлар каралды. Нәтиҗәдә әсәрләрне төрек теленә тәрҗемә итүче Фатих Кутлу, төбәкне өйрәнүче тарихчы, язучы Нурулла Гариф – Гаяз Исхакый, шагыйрь Айрат Суфиянов – Һади Такташ, прозаик Кәрим Кара – Фатих Хөсни, Рухия Ахунҗанова – Абдулла Алиш, Дамир Гарифуллин – Җамал Вәлиди, Айгөл Әхмәтгалиева – Туфан Миңнуллин, тәрҗемәче Наил Ишмөхәммәтов Максим Горький премияләренә тәкъдим ителде. Идарә әгъзалары Фирдүс Гыймалтдинов белән Рәмис Латыйповны Татарстан Язучылар берлегенә кабул итте.

### ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ КОТЛАУ

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Татарстан Язучылар берлеге оештырган ябык әдәби конкурста җиңүчеләрне котладылар. Бәйгегә 1641 эш килгән. Җиңүчеләргә диплом һәм сертификатларны ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла тапшырды. Тантанада Татарстанның халык

шагыйре Рәдиф Гаташ, конкурсның «Роман» номинациясендә беренче урынны алган Әлфис Гаязов чыгыш ясады. Чара Рөстәм Насыйбуллин, Айгөл Хәйри башкаруында җырлар, Казандагы Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназия укучылары чыгышлары белән үрелеп барды. Тантананы Резеда Сәлахова белән Илдар Кыямов алып барды. Чарада ТР Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты рәисе урынбасары Камил Нугаев катнашты.

Менә алар – әдәби конкурста җиңүчеләр:

**«Әдәби тәнкыйть, рецензия»**

I урын – **Лилия Хөснетдинова** («Бикләр ачылырга тиеш»); II урын – **Фәүзия Галиуллина** («Мин сызланам, син дә сызлан әле, укучым!»); III урын – **Хәбир Ибраһим** («Өч шигырь»).

**«Хикәя» (балалар әдәбияты)**

I урын – **Фатыйма Гыйльметдинова** («Саташулы көннәр»); II урын – **Лилия Фәттахова** («Бердәнберданәдә»); III урын – **Галимҗан Гыйльманов** («Батыр булу авыр»).

**«Поэма, шигырьләр» (балалар һәм үсмерләр әдәбияты)**

I урын – **Рафис Корбан** («Таз малай», шигырь); II урын – **Айгөл Әхмәтгалиева** («Вакыт», поэма); III урын – **Галимҗан Гыйльманов** («Түбәтәй», шигырь).

**«Кыска драма әсәрләре, скетчлар» (балалар әдәбияты)**

III урын – **Фатыйма Гыйльметдинова** («Зумерлар һәм бумерлар»).

**«Хикәя» (үсмерләр әдәбияты)**

I урын – **Ләлә Гыймадиева** («Азаматка сүз әйтмәгез!..»); II урын – **Гөләндәм Галиева** («Тормышка ашкан план»); III урын – **Илсөяр Иксанова** («Басма»).

**«Повесть» (үсмерләр әдәбияты)**

I урын – **Айгөл Әхмәтгалиева** («Без андый малай түгел»); II урын – **Марат Кәбиров** («Миллион»); III урын – **Лилия Гыйбадуллина** («Game of Kans»). Жюри бу номинациядә «Сине Каенсарда көтәбез» повестена кызыксындыру премиясе бирергә тәкъдим итте. Авторы – **Гүзәл Шакирова**.

**«Поэма, шигырь»**

I урын – **Ләис Зөлкарнәй** («Татар җөе», дастан); II урын – **Гөлсәрия Басыйрова** («Күзге җыр», шигырьләр шәлкеме); III урын – **Мөнир Вафин** («Уф-ф-ф», шигырьләр шәлкеме).

**«Хикәя»**

I урын – **Айзирәк Акчура** («Куеныңда ни бар?»); II урын – **Рәҗәп Бәдретдинов** («Юлаучылар»); III урын – **Наилә Харисова** («Мин кайтырга тиеш»).

**«Повесть»**

I урын – **Фирдүс Гыймалтдинов** («Шом»); II урын – **Марат Әмирханов** («Әлләче, тармалай!»); III урын – **Лилия Гыйбадуллина** («Әлиф-ләм-мим»).

**«Роман»**

I урын – **Әлфис Гаязов** («Кайсы яктан чыга соң бу кояш?..»); II урын – **Зөлфәт Хәким** («Серле тәңкә»); III урын – **Зәбир Гыймаев** («Каторжан»).

## ЮБИЛЕЙ

Арча балалар сәнгать мәктәбендә язучы, журналист Риман Гыйлемхановка 75 яшь тулу уңаеннан «Каләм очындагы затлы сүз» дип аталган кичә булып узды. Бәйрәмдарны Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров, язучы, нәфис сүз остасы, җырчы Алмаз Хәмзин, язучы, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, Татарстанның халык артисты Әсхәт Хисмәт, «ТАТМЕДИА» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары Илдар Миргалимов, «Татарстан» дәүләт телерадио компаниясенең милли тапшырулар хезмәте җитәкчесе Миңназыйм Сәфәров, «Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәррире урынбасарлары Габделбәр Ризванов, Зөлфия Хәлиуллина, Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы Альбина Мөхәммәтгалиева һ.б. котлады. Тантанада катнашучыларны Арча муниципаль районы башлыгы Илшат Нуриев сәламләде һәм юбилярга ихлас теләкләрен ирештерде.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы Рәисе Указы белән күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге һәм татар әдәбиятын үстерүгә мөһим өлеш кертүе өчен шагыйрь **Ибраһимов Илфак Мирза улы (Мөхәммәт Мирза)** «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены медале белән бүләкләнде.

* * *

2 март – шагыйрь, публицист, журналист **Нәҗибә Сафинага** 75 яшь; 5 март – язучы, рәссам **Хәмит Латыйповка** 75 яшь; 15 март – язучы, журналист **Илдус Диндаровка** 75 яшь (журналыбызның киләсе саннарының берсендә аның әсәрен бирү күздә тотыла); 18 март – язучы, публицист **Вахит Имамовка** 70 яшь.

2024 елның 20 февралендә 79 нчы яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, балалар язучысы **Ринат Николаевич Архипов (Ринат Мәннан)** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Казандагы Самосырово зиратына җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повесть Н.ГИМАТДИНОВОЙ «Рассказ о Гульханым», повесть Ф.ГИМАЛТДИНОВА «Тревожность»; стихи Л.ФАТТАХОВОЙ, Н.САФИНОЙ, Н.САБИРЗЯНОВОЙ.*
*«Драматургия»: историческая драма В.ИМАМОВА «Вечный эмигрант».*
*«Новые имена»: стихи Г.ШАЙХИ, рассказы М.ХАСАНОВОЙ.*
*«Дружба между литературами – дружба народов»: стихи М.ХОНИНОВА в переводе А.СИТДИКОВОЙ.*
*«Литературная критика»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*Фотоархив: журналу «Ялкын» – 100 лет.*
*«Отклик»: статьи Х.ИСМАГИЛОВА, Г.АХМЕТГАЛИЕВОЙ, А.ГАРАЕВОЙ-АКЧУРЫ.*
*«Обзор книги»: статья И.КИЯМОВА.*
*«2024 год – год личностей»: интервью А.ХАБИБУЛЛИНОЙ с Ф.ГАЛИМОВЫМ.*
*«Памятные письма»: письма М.Хасанова, учительницы Рафиги апа, Н.Фаттаха, А.Галиева, И.Шакирзянова, Н.Сафиуллина, М.Шаймиева  М.Галееву.*
*Литературный сканворд. Составил Р.АБДУЛЛА.*
*«Бесценные голоса»: статьи к  115-летию А.Еники  и 105-летию А.Давыдова. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: озеро Кабан на закате. Фото И.АБРАМОВОЙ; поэтесса, тележурналист Нафиса САБИРЗЯНОВА.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: story by N.GIMATDINOVA «The Story of Gulkhanym», story by F.GHIMALTDINOV «Anxiety»; poems by L.FATTAKHOVA N. SAFINA, N. SABIRZYANOVA.*
*«Dramaturgy»: historical drama by V.IMAMOV «The Eternal Emigrant».*
*«New names»: poems by G.SHAYKHI, short story by M.KHASANOVA.*
*«Friendship between literatures is friendship of peoples»: poems by M.KHONINOV translated by A.SITDIKOVA.*
*«Literary criticism»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*Photo archive: «Yalkyn» magazine is 100 years old.*
*«Response»: articles by H.ISMAGILOVA, G.AKHMETGALIEVA, A.GARAEVA-AKCHURA.*
*«Book review»: article by I.KIYAMOV.*
*«2024 the year of personalities»: interview by A.KHABIBULLINA with F.GALIMOV.*
*«Memorable letters»: letters from M.Khasanov, teacher Rafiga Apa, N.Fattakh, A.Galiyev, I.Shakirzyanov, N.Safiullin, M.Shaimiyev to M.Galeev.*
*Literary crossword puzzle. Compiled by R.ABDULLA.*
*«Priceless voices»: articles on the 115th anniversary of A. Yeniki and 105th anniversary of A. Davydov. The column is led by N.AKMAL.*
*Diary of public and cultural life.*
*On our covers: Lake Kaban at sunset. Photo by I.ABRAMOVA; poetess, TV journalist Nafisa SABIRZYANOVA.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Кабан күле.
*И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә, тележурналист Нәфисә САБИРҖАНОВА.